Индекс 73210

# КАЗАН УТЛАРЫ

8.2013



# ГӨРЛӘП УЗДЫ ГАЛӘМИ БӘЙРӘМ
























**Казан утлары**

**Qazan utlari**

2013

# 8

**(1090)**

*ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:*
*«ТАТМЕДИА»*
*ачык акционерлык җәмгыяте*

татмедиа

*БАШ МӨХӘРРИР*
**Равил Габдрахман улы**
**Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Разил Вәлиев**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Рәдиф Гаташ**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Дания Заһидуллина**
**Дамир Исхаков**
**Рафис Корбан**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Айрат Сибагатуллин**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Марат Закир, Әлфәт Закирҗанов, Камил Кәримов.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Флера Сабирова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Гөлнара Галиева** (баш бухгалтер).

---

Редакция һәм нәшер адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
*Баш мөхәррир — 562-10-62.*
*Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге — 222-09-83 өст. 1612.*
*Исәп-хисап бүлеге — 222-09-80.*

**Факс** — (843) *222-09-83 өст. 1612.*

**E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

Казан утлары

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Гәрәй РӘХИМ. Минем өчен шигырь – тормыш ул. *Шигырьләр.* 5
Рауль МИРХӘЙДӘРОВ. Дингез аша ялгыз. *Бәян.* 9
Лениза ВӘЛИЕВА. Урап ала моң дәрьясы. *Шигырьләр.* 54
Тәлгат ГАЛИУЛЛИН. Замана балалары. *Истәлекләр.* 57
Руслан СӨЛӘЙМАНОВ. Язмыш – Ходай кушканча. *Шигырьләр.* 90
АХИР. Кәбисә елы. *Сатирик бәян.* 94

РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИНГА 70 ЯШЬ

Дания ЗАҺИДУЛЛИНА. «Шаш, рухым – дуласын җан!» 116
Айдар ХӘЛИМ. Йөрәк җебе өзелгән җирдә. *Эссе.* 129
Радик САБИРОВ. Уйлар, уйлар, уйлар... 137

ПУБЛИЦИСТИКА

Хәлил ШӘРИФ. Күңел авазы яки мең дә бер сорау. *Эссе.* 141

СӘНГАТЬ

Әхтәм ЗАРИПОВ. Кадерле хатирәләр... 153

ФӘН

Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы. 168
«Татар энциклопедиясе» битләреннән. 171

ХӘТЕР

Нурихан ФӘТТАХ. Четерекле булды безнең заман. *Истәлекләр.* 176

ШӘХЕСЛӘР ҺӘМ ШӘРЕХЛӘР

Фәнзаман БАТТАЛ. Өстәл китабы. 186

«Казан утлары» архивыннан. 174
Безнең календарь. 189
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. 191

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: повесть Р.МИР-ХАЙДАРОВА «Из Касабланки морем»; воспоминания Т.ГАЛИУЛЛИНА «Дети своего времени»; сатирическая повесть АХИР «Високосный год»; стихи Г.РАХИМА, Л.ВАЛИЕВОЙ, Р.СУЛЕЙМАНОВА.
«Равилю Файзуллину — 70 лет»: эссе А.ХАЛИМА, аналитические статьи Д.ЗАГИДУЛЛИНОЙ и Р.САБИРОВА.
«Публицистика»: эссе Х.ШАРИФА «Голос сердца».
«Искусство»: А.ЗАРИПОВ. «Дорогие воспоминания».
«Наука»: Ф.ГАРИПОВА. «История наших деревень».
Страницы из «Татарской энциклопедии».
«Память»: Н.ФАТТАХ. «Мы жили в непростое время».
«Наш календарь».
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: церемония открытия XXVII Всемирной летней Универсиады 2013 года в Казани; церемония закрытия Универсиады.

## IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

«Prose and poetry»: story by R. MIRKHAYDAROV «From Casablanca by sea»; memories by T.GALIULLIN «Children of their time»; satirical story by AHIR «Leap Year»; poems by G.RAHIM, L.VALIEVA, R.SULEYMANOV.
«Ravil Faizullin is 70 years old»: essay by A.HALIM, articles by D.ZAGIDULLINA, R.SABIROV dedicated to anniversary of poet.
«Journalism»: essay by H.SHARIF «Cry from heart».
«Art»: A.ZARIPOV. «Dear memories.»
«Science»: F.GARIPOVA. «History of our villages».
Pages from «Tatar Encyclopedia.»
«Memory»: N.FATTAH. «We lived in difficult times».
«Our calendar».
From photo archives of magazine.
Diary of social-cultural life.
On our covers: opening ceremony of the XXVII World Summer Universiade in Kazan in 2013, closing ceremony of the Universiade.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 01.08.2013, график буенча 01.08.2013.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 1/16.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ С-1853. Тираж 3809.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча Федераль хезмәтендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекс 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

«ПИК «Идел-Пресс» ААҖ «ТАТМЕДИА» филиалы типографиясендә басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2013 ел.



Гәрәй
Рәхим

# МИНЕМ ӨЧЕН ШИГЫРЬ — ТОРМЫШ УЛ

## Хатирә

**Авыл өстеннән бер болыт оча,
Минем шул болыт буласым килә.
Түбәночта бер тал-тирәк бар,
Шуның очына кунасым килә.**

**Күп еллар элек шушы тал-тирәк
Бик тә яшь иде, ямь-яшел иде.
Тирәк төбендә тәү кат үбештек —
Безгә унсигез генә яшь иде...**

**...Авыл өстеннән бер болыт оча.
Шул болыт булып агасым килә.
Тирәккә төшеп шушы яшь парны
Карт кочагыма аласым килә...**

## Шигырь

**Әй, шигырьне ничек мактыйлар да,
Әй, шигырьдән ничек көләләр...
Янәсе лә алар шигырьләрнең
Ничек язылганын беләләр...**

**Шагыйрь булган өчен миннән күпләр
Көнләшәләр (данны бүләләр....),
Ә күпләре, «Тел бистәсе бит ул,
Җитди түгел...» диеп көләләр.**

**Ә шигърият шундый бөек гамәл,
Җаннарыңда хыял кормыш ул —
Минем өчен тормыш шигырь түгел,
Минем өчен шигырь — Тормыш ул!..**

Гәрәй РӘХИМ (1941) — *Татарстанның халык язучысы; 5 томлык «Сайланма әсәрләр» һәм төрле телләрдә басылган күпсанлы китаплар авторы. Казанда яши.*

## Алып кайт...

«Алып кайт мине өеңә!..» —
Диеп шыңшый бер көчек...
Ташлап калдырганнар аны
Мин алып китсен өчен.

«Алып кайт мине өеңә,
Кыш бит, туңдым, бик салкын.
Син алмасаң үләм мин...» — ди
Нәни песи баласы.

«Алып кайт мин өеңә... —
Дип ялвара дус-салмыш, —
Синдә кунып айнырмын, — ди —
Өйгә кайтарма ялгыш...»

«Алып кайт мине өеңә!» —
Ди сөяркә җаныем.
Өем бер генә бит минем.
Тагын каян алыем?..

«Алып кайт мине өеңә...» —
Дип сайрамый сандугач.
Аның өе табигать ич,
Ул бәхетле шул булгач...

...Ничек чыдарга соң миңа,
Бу хакыйкать, бу моңга?!.
«Алып кайт мине өеңә! —
Дип кычкырам, — әй, Дөнья!..»

## Яран гөл

*Диләрә минем язу бүлмәсендәге*
*тәрәзә төбендә яран гөлләр үстерә*

Яран гөлләр чәчәк атты инде...
Тәрәзләрем балкып киттеләр.
Яран гөлдәй кебек яшь чакларым
Яран гөлдәй гөрләп үттеләр.

Яран гөлгә гашыйк чордашларым
Югалышып, үлеп беттеләр.
Алар белән яран гөлгә назлар
Чорыбызны ташлап киттеләр.

Миңа инде хәзер яшь кызларга
Яран гөлдәй карау ярамый...
Юк шул инде, алар яраннарга
Миндәй итеп сөеп карамый...

Картлык шушы буладыр шул инде —
Күңелләрдә татлы яра гел...
Балчык чүлмәгеннән миңа табан
Моңсу гына карый яран гөл...

## Хыялый тәбикмәк[1]

Мичтә кып-кызыл күмерләр яна —
Тәбикмәк пешә әнә табада.

Әнием әйтә: «Татлы бу икмәк —
Табадан төшкән татлы тәбикмәк,

Уян, улым, — ди, — булыр сөенче,
Аша тәбикмәк кайнар көенчә...»

Каз мае белән майлап бирә ул —
Тәбикмәк тәмен әнкәй белә ул!..

...Картайдым инде, туздым — эш яман.
Тәбикмәк тәме телемдә һаман.

НЛО кадәр зур таба алып,
Шуңа мең, мильон тәбикмәк салып,

Пешереп бирим сезгә, илдәшләр,
Ашагыз әле, дуслар, иптәшләр!..

Ашагыз, аша — булыр сөенче
Ашап калыгыз кайнар көенчә.

Барыгызга да булыр сөенче!..

## Җир — Җир булып калды

*2012 елның декабрендә*
*дөнья бетә икән диган*
*фараз-хәбәр таралган иде*

Күпме галим, патша, күрәзәче,
Тиздән Җир бетә, дип көттеләр.
Дөнья һәләкәте уты белән
Безнең күңелләрне өттеләр.

Шөкер, Аллабыз да, Җир үзе дә
Саклап калды безне, Кешеләр!..
Күпме «бөек» ялган булып чыкты,
Хаклы булды безнең ишеләр.

Бездәйләр бит җыен юк-барларга
Ышанмаучан ныклы, көчлеләр!..
Җир-планета! Ул Җир булып калды,
Кеше булып калды Кешеләр!..

## Үпкәләттем

Мин бик каты үпкәләттем бугай —
Телем юк-бар сүзләр әйләде...
Кинәт миңа шундый салкынайдың —
Синең күңел бозга әйләнде.

[1] Тәбикмәк — зур табада пешерелә торган коймак.

Инде кыш та үтте, карлар эри,
Урамымда җылы язларым.
Тик эреми синең,
Юк, эреми синең,
Ник эреми күңел бозларың?!.

## Көч

Җир җимертер көчләрем бар —
Шаккатам мин бу көчкә!..
Тик шигырь яза башласам
Тын алам көчкә-көчкә...

Йөрәккәем тынып кала,
Сулышым бетә минем.
Көннәрем төнгә әйләнә,
Төнгә әйләнә көнем.

Дәрманымны, көчләремне
Суырып ала шигырь.
Мин бер колга әвереләм —
Мисле бер кара нигыр...

Көчләремне ала да ул,
Сихри дөньяга сала.
Тәнемдә һич җисми түгел,
Тик хисси көчем кала...

## Юлым уңды

Артымнан козгын каркылдап калды...
Кап-кара мәче юлымны кисте...
Буш чиләк тоткан кортка очрады...
Җен өередәй әче җил исте...

Бу юрамышлар минем күңелгә
Күпме куркыну, хәвеф бирделәр!..
Юлым уңмасын өчен һәрберсе
Кичеп булмаслык киртә иделәр...

...Мәхәббәт көчле хорафатлардан!..
Зыян тимәде миңа пычак та —
Күр, рәхәтләнеп, изрәп ятам мин
Сөйгәнем, синең назлы кочакта!..

## Алмагачым

*...гә*

Алмагачым, бәрмә тәрәзәмә,
Мин болай да уяу бит инде.
Тәрәзәмне ачып үбәм сине,
Назларыңа куям битемне.

Алмагачым, какма тәрәзәмә,
Мин уйларга баттым әлегә —
Күңелемдә дөнья мәшәкате,
Авыр миңа, кер син хәлемә.

Алмагачым, син тәрәзә аша
Ничә еллар миңа багасың...
Әле якты, әле моңлы-зарлы,
Әле ярсу синең карашың.

Алмагачым, мин тәрәзә аша
Күрәм синдә дөнья язмышын...
Сине дөнья белән тәңгәлләвем
Әллә ялгыш, әллә табышым...

...Әллә табыш, әллә ялгышым...



Рауль
Мирхәйдәров

## ДИҢГЕЗ АША ЯЛГЫЗ

БӘЯН

Ул Касабланкага иртән-иртүк бер шәхси авиакомпаниянен «Боинг»ында очып килде. Мансур Гатауллин соңгы өч елда яшәгән һәм эшләгән дәүләтнен үз һава юлы юк әле.

Анын Касабланкада беренче генә булуы түгел: берничә тапкыр жирле портта йөк кабул иткәне бар; төзелешкә килгән эшчеләрнен зур төркемен каршылау һәм озатып куюю дисеңме... Шушы аэропорттан ул берничә тапкыр Парижга очты, аннан исә еш һәм көтелмәгәндә була торган киңәшмәләрдә катнашыр өчен Мәскәүгә юл тотты.

Таможниклар яхшы хәтерле халык: аны исләрендә калдырганнар бугай, документларын кат-кат тикшереп төпченмәделәр, шундук кирәкле төшенә штамп сугып, хәерле юл теләделәр. Чемодан һәм юл сумкасы салынган арба өстерәп таможня бинасыннан чыгып та өлгермәде, аңа шундук берничә такси чакыру авазы бирде. Әле Ауропадан зур самолетлар килеп житмәгән һәм тәүлекнен иртәнге сәгатьләре, һәр юлаучы кадерле шул алар өчен.

Мансур, яңа машиналарны әйләнеп узып, иске, инде шактый юл йөргән «Вольво»га юнәлде. Бу машина аңа тышкы кыяфәте белән ватанындагы «Волга»ны хәтерләтә иде.

— Портка! — диде Мансур.

Машина шундук выжлап урыныннан кузгалды. Анын житезлегенә хәтта янәшәдәге яңа «Мерседес»тагылар да шаккатты һәм көнләшеп карап калды бугай.

Касабланканың такси йөртүчеләре сүз тәмен белә. Бу юлы да дингез яры буйлап барганда шофер футбол турында иркенләп сөйләде. Сөйләмәслек тә түгел шул: үз тарихларында беренче тапкыр Марокко футболчылары дөнья беренчелегенә сайлап алу уеннарында жиңү яулады.

Африкада узган ун ел вакыт эчендә Мансур инглиз һәм француз телле илләрдә эшләде, шуңа ул ике телне дә яхшы белә. Дистә ел элек бу материкка аяк басканда исә алман телендә генә аралаша ала иде. Беренче мәлләрдә файдасы тигән алман телен дә ул махсус өйрәнмәде. Көнбатыш Казакъстанның ул туып-үскән кечкенә, аулак район үзәгендә урыслар, алманнар, татарлар һәм казакълар бергә укмашып яши иде.

Рауль МИРХӘЙДӘРОВ (1941) – *язучы; төрле телләрдә чыккан дисталәгән китап авторы. «Ирталәгән сагыш», «Кара аксөякләр» («Карга короле»), «Һәрнәрсәгә – акчалата» романнары, «Игълан буенча танышу» повесте, байтак хикәяләре «Казан утлары» журналы битләрендә дөнья күрде. Мәскәүдә яши.*

Гатауллиннарның уң як күршеләре дә, сулы да алманнар — Вуккертлар һәм Штайгерлар иде. Русиядәге алман гаиләләре гадәттә күп балалы була. Күршеләрендә дә бала-чага мәш килә иде. Генрих, Сигизмунд, Вальтер, Март, Паульләр белән аралашып, ул алман телен өйрәнде. Телләр өйрәнүгә хирыслыгы да, мөгаен, әнә шул чактан ук киләдер.

Касабланка порты — Африкада иң борынгылардан санала. Аның гаваньнары һәм причаллары кемнәрне генә кабул итмәгәндер. Менә әле дә порт кына түгел, аның бөтен тирә-ягы көймәләр, кечкенә судно, танкерлар, төрле әләмнәр җилфердәгән баржалар белән тулган. Лоцманнар бу кадәр кысынкылыкта ничек идарә итә алалардыр — шаккатарсың.

Җәй — диңгез сәяхәтләренә бай вакыт. Портның күптән түгел төзелгән ерактагы причалларында күз явын алырдай яхталар, берсеннән-берсе үзенчәлекле шәхси җилкәнле суднолар иртәнге җиләс җилдә тибрәләләр. Әләмнәр урынына әлеге диңгез чибәркәйләренең геральдик тамгалар һәм символлар белән бизәлгән томанлы җилкәннәре җилферди. Ерактан караганда причаллар Марк акварелен хәтерләтә. Мансур, монда килгәч, диңгез портларында саубуллашу һәм күрешү вокзал-аэропортларга караганда тәэсирлерәк икән, дип уйлап куйды. Шулай да Мансурның Касабланкадан өйгә диңгез аша кайтуы романтика эзләүдән түгел иде. Сәбәбе гади: ул самолетка билет алырга торганда, аңа диңгез аша кайтырга киңәш иттеләр. Өстәвенә, совет туристларын үзенә җыйган өч палубалы «Лев Толстой» теплоходы Аурупа тирәли сәяхәттә булып, аңа нәкъ менә Касабланкада утыру мөмкинлеге бар иде. Кабат Парижга очып, анда тәүлек ярым Мәскәү рейсын көтеп утырганчы, теплоход белән бөтен «төньяк»ны колачлап: Барселона, Марсель, Неаполь, Пирей, Истанбул аша үтүләре һәрхәлдә мәгънәлерәк иде. Ул ике дә уйлап тормыйча, теплоходка утырырга булды. Аннары Мансурның сиздерәсе килмәгән тагын бер сәбәбе бар: ул бик нык арыган иде. Бөтен уңайлыклары булган теплоход, беренче класслы каюта, бассейннар, спорт заллары, бию холлары һәм сигез көн дәвам итәчәк бәйрәм сәяхәте аңа менә дигән ял вәгъдә итә кебек. Кечкенәдән таныш, әмма әкренләп онытыла башлаган телне — үз теленне сигез көн буе ишетеп, сөйләшеп, аралаш әле син! Җитмәсә теплоходта китапханә дә бар. Бер-ике көнгә Мәскәүгә килеп-китүләрне санамаганда, ун ел буе чит илдә яшәгән һәм чит телдә сөйләшкән кеше өчен ватанга кайтыр алдыннан тел чарлый торырга менә дигән мөмкинлек иде бу!

Чит илнең яр буе белән Мансур сагышларсыз һәм үкенүләрсез генә хушлашты. Югыйсә ул бу җиргә ун ел гомерен багышлады. Балигъ кеше өчен аз гомер түгел ул. «Лев Толстой» горур гына тибрәлгән диңгезгә карап та күзенә яшьләр килмәде, тамагына төер тыгылмады. Кырык биш яшьлек Мансур эшкә башы-аягы белән чумган, үзен бөтен барлыгы белән шуңа багышлаган кеше. Энергиясе ташып торган ир карап торышка үз ишләреннән нәкъ ун яшькә яшьрәк кебек күренә. Андыйларга үзләрен күрсәтер өчен кинлек һәм мөстәкыйльлек кирәк, ул дигәндә алар иң кадерле нәрсәләрен — шәхси тормышларын, буш вакыт, күңел ачу, рәхәтлекләрен дә корбан итә алалар. Андыйлар өчен хезмәттәге уңышлар бар нәрсәдән өстен.

Көнбатышта мондый хезмәткәрләрне технократлар дип атыйлар. Тормышның матди ягын хәрәкәткә китерүчеләргә анда ихтыяҗ зур. Болындагы һәр чәчәкне кулларына алып сокланып карап тормасалар да, көзен яфраклар коелуын күреп күз яше агызмасалар да, камера музыкасына мөкиббән китеп хисләнмәсәләр дә, җәмгыять аларны шелтәләми. Гармонияле шәхес булу — һәркемнең шәхси эше. Әлбәттә тегүче, уракчы, шул ук вакытта курайда да уйнаучы булуың бик яхшы. Әмма тормышта, ни кызганыч, барысын да булдыра алган осталар бармак белән генә санарлык.

Африкада шундый житәкчеләрне менеджерлар дип атыйлар. Осталык, сәләт ягыннан аларга сүз әйтеп булмый, үз эшләрен алар көнбатыш технократларыннан ким белми. Безнекеләр бу континентта төзелеш эшләре башлап жибәргәч, чит илнен атаклы төзелеш фирмалары бик күп заказдан колак какты. Тиз төзү белән беррәттән, башкарган эшенә гарантия дә сорала бит әле. Эре гидроэлектростанция һәм металлургия комбинатлары төзелешендә безнен оешмаларга көндәш булырдайлары юк дәрәжәсендә иде. Шуна да Мансур ватанына тыныч күнел белән кайтып китә. Ул төзегән һәр корылма намус белән эшләнде, хәтта гарантия вакытын ике тапкырга арттырырга мөмкинлек бар иде. Сыйфат һәм сан ягыннан караганда да төзелгән корылмалар белән горурланырлык. Әмма ул андый хис кичермәде. Ул нәрсә төзергә тиеш булса — шуны төзеде, анын тормыш мәгънәсе дә шуна корылган. Бәлки, кайдадыр, күнел төпкелендә, анын горурлыгы яшеренгәндер дә, әмма ул үзенчәлекле хис әллә шәхси, әллә эшендәге инженерлык уңышы белән бәйле шунда, белмәссен...

...Тирә-якка күпме генә күз салмасын, Мансур причал тирәсендә хәрәкәт күрмәде. Таксист аны диспетчер портында калдырды. Анда теплоходнын ике сәгатьтән сигезенче причалга тукталачагын хәбәр иттеләр.

Тукталышнын алты сәгатьлек икәнен Мансур алдан ук белде: лайнер Касабланкада эчә торган су, ризык ала, туристларны исә дүрт сәгатьлек экскурсия көтә иде.

Мансур әйберләрен саклау камерасында калдырды да порт мәйданына чыкты. Кояш инде күтәрелеп килә, әмма су әле жылынып өлгермәгән. Шулай да бакчачылар клумбалар һәм газонга су сиптергәннәр инде, жир катыш бакча исе борынны ярып керде. Ачык төстәге пластик өстәлләр янына техник хезмәткәрләр иртәнге ашка утырган. Алар униформалары белән танылып тора. Куе каһвә исе портнын зур мәйданына чаклы таралган. Әлеге ис ана якын иде. Яхшы чәй ин яраткан эчемлеге булса да, Африкада яшәгәндә Мансур да каһвәгә күнекте. Ул кояштан саклану өчен корылган чатырлы өстәл янына урнашты да бозлы бокал белән каһвә алды. Каһвә йоткалап, тирә-ягына күз салгалап утыра торгач, Мансур уйга калды: Касабланкада күпме торып та, ул шәһәрне чынлап торып күрмәгән икән бит әле. Һаман да шул минутына кадәр бүлеп куелган эше гаепле инде. Хәзер исә анын хозурында сигез сәгать буш вакыт бар!

Махсус үзем өчен экскурсия оештырам әле дип, Мансур узып барган таксига кул болгады. Көн бик тиз үтеп китте. Ул шәһәрне карап кына калмады, ачык һавадагы ресторанда сыйланды, хәтта бер сәгатьләп комлыкта аунарга да өлгерде. Касабланканын сәүдә рәтләренә кереп тулган урыс туристларын күргәч, «Лев Толстой»нын килеп житкәнен анлады. Сатып алудан канәгать калган туристлар, баш өстендә көйдергән кояшка исләре китмичә, шат йөз белән шау-гөр килеп теплоходка таба агыла. Утырту вакыты килеп житкәч, Мансур ковбойларныкы сыман салам эшләпә алмавына үкенде — менә бу челләдә ярап торыр иде ул. Портнын таможня залында аннан кала тагын дүрт испан көтә иде. Кыяфәтләренә караганда эшмәкәрләр булырга тиеш. Шар ярып сөйләүләреннән аларнын Барселонага кадәр генә барачакларына төшенде. Таможня тикшерүе нибары ун минутка сузылды. Мансур бортка күтәрелгәндә, теплоход кузгалырга шактый вакыт бар иде әле. Урта палубадагы каюта шактый унайлы булып чыкты. Мансур әйберләрен урнаштырып тормыйча, урын-жирне көйләп тизрәк ятакка чумды. Тынычсыз төн, иске «Боинг»та Касабланкага очу, уйламаганда гына шәһәргә экскурсия ясау үзенекен иткән: «Лев Толстой» Африка ярыннан кузгалганда, ул тирән йокыда иде инде. Шуна ул «Сау бул!» — дип тә әйтә алмады, анын өчен бүтән туристлар — ватандашлары кул болгады.

Теплоход ачык дингезгә чыккач, ул көтмәгәндә уянып китте. Тиз генә юынып киенде дә палубага аяк басты. Билет белән бергә бирелгән белешмәдә Гданьскида Польша корабелалары заказы белән эшләнгән бу теплоходның икенче генә сәяхәте икәне искәртелгән иде. Дөньядагы иң яхшы су корабларыннан калышмаган лайнеры һәрьяктан унайлы, җайлы, күз алдындагы җиһазның ялтырап, балкып торуы сокландыра иде.

Ул төшке ашка икенче сменага билгеләнгән иде. Өстәл янына утыруга, каршындагы ике чибәр кызга күзе төште. Алар Кишиневтан икән. Мансур өчен көтелмәгән сәяхәт әнә шул мизгелдән башланды. Кызларга сүз катуга ук ул югалып калды. Соңгы ун елда ул инде совет кешесенә хас булган тәмләп әңгәмә кору сәләтен югалткан булып чыкты. Беркайда да бездәге кебек тиз танышып китә алмыйлардыр, мөгаен. Бу мәсьәләдә без аерылып торабыз. Алай... Барысын да яңадан башларга, яңадан өйрәнергә туры киләчәк икән, дип уйлап куйды Мансур... Өйдә өйдәгечә яшәргә кирәк...

Көньякның эре якты йолдызлары белән бизәлгән караңгы төне хакимлекне үз кулына алуга гөлт итеп якты утлар кабынды, шундук музыка тавышы яңгырый башлады һәм теләсә кайсы сәяхәтнең иң истә кала торган вакыты — теплоходның кичке тормышы башланды. Мансур бию залларын һәм шау-шулы барларны читләтеп узды да коктейль-холлга юнәлде. Монда тынычрак иде. Ул ачык ишек каршына утырды да, төнге матурлыкка сокланып, вакытны шушында уздырырга уйлады. Әмма ярты сәгатьләп үттеме, юкмы — аны Кишинев кызлары эзләп тапты.

— Күршебезне эзләп теплоходны айкап чыктык: менә кайда икән ул, — диде, икесе дә беравыздан.

Үзенә карата мондый игътибарны күптән күрмәгән Мансурның күңеле канат какты. Төнне алар шәп уздырды: барлык ял урыннарын урап палубадан иң соңгы булып кузгалдылар.

Мансур төн уртасында уянып китте дә йокысы качты. Киенеп, өске палубага күтәрелде. Озакламас, караңгылык пәрдәсе ертылыр, көньякның эре йолдызларын бер-бер артлы сүндерә-сүндерә, офыкта яктылык сызыгы шәйләнер.

Ул да булмады, еракта тоташ яктылык балкышы күренде, әйтерсен йокысы качкан зур шәһәрнен бөтен халкы яр буена җыелган иде. Мансур үзенең испан ярлары буйлап сәяхәтен искә төшерде. Аның фаразынча, бу утлар — Аликанте курортыныкы иде. Дөньяның бар төбәгеннән җыелган калын кесәле агайлар монда күңел ачарга, иртәнгә кадәр типтерергә ярата.

Тәмам яктырып житкәч, ул үз каютасына кайтты, чишенде һәм тизрәк юрган астына чумарга ашыкты. Иртәнге аштан соң теплоход Барселонада туктаячак. Кызлар исә аны гид итәчәк, димәк, йокы туйган булырга тиеш!

Теплоход Испанияне артта калдырып, Франция ярларына борылды. Өстәл күршеләре тизрәк Францияне күрү теләге белән яна. Ә Мансур исә бу сәфәреннән болай да канәгать иде: унайлы каюта, аралашучан юлдашлар, иң мөһиме — балачактан ияләнгән, таныш кухня...

Көндезләрен, эсседән качып, ул күрше кызлары белән палубадагы бассейнда рәхәтләнә, тегеләре үз каюталарына ял итәргә китсә, теплоходнын китапханәсенә төшеп утыра. Ел буе җыелып килгән гәжит тупланмәләрен алып, бер мәкаләсен дә калдырмый танышып барырга тырыша ул. Дөрес, Африкада да гәжитсез тормады. Әмма анда көн саен танышып бару мөмкинлеге юк иде. Аның эшендә көннен генә түгел, төннен дә сәгатьләре санаулы булды шул. Ә монда жанын күпме тели, шул кадәр укы — илнең сулышы белән таныш. Гәжитләр аны соңгы унъеллыкка алып кайтты. Анын

башына беркайчан да, Африкада яшәве күпкәрәк китмәде микән, дигән уй килгәне булмады. Дөресен генә әйткәндә, эш белән мавыкланып ул вакыт агышын сизмәде дә. Менә хәзер, иске гәҗитләрне актарганда, Мансур туган җиреннән аерылганына шактый вакыт үтүен сизде. Шушы уку залында аны беренче тапкыр: « Мөгаен, бу ун ел минем өчен үсү, үземне табу чоры булгандыр. Шул ук вакытта кайтарып булмастай күпме нәрсә югалттым», — дигән сагышлы уйлар биләп алды.

Гәҗитләр йә шатландырды, йә сагышка салды — бер генә язма да аны битараф калдырмады. Ул мәкаләләрнең төбенә төшәргә теләп, җентекләп укыды. Әйтик, нәрсә ул агросәнәгать комплексы? Бу — аның өчен бөтенләй яналык. Дулкынлана-каушый ярлы туфраклы җирләр турында материаллар эзләде. Ул киткәндә аларга игътибарны арттыра башлаган иделәр. Хәзер, ун елдан соң нәрсә үзгәрде икән? БАМ төзелеше турында ул белә иде, әнә гәҗитләр тиздән аның тәмамланачагын хәбәр итә. Ә менә тауарларның сыйфаты, алай гына да түгел, халык хуҗалыгы эшенең сыйфаты турындагы мәкаләләр аны сагайтты. Нәрсә соң бу? Ул чит илгә киткәндә нәкъ менә сыйфат бишьеллыгы игълан ителде. Бүген дә сыйфат турында сөйләшәләр икән, димәк, мәсьәлә хәл ителмәгән булып чыга түгелме?

Мансур Балтыйк буена караган язмаларга аерым тукталды. Әле кайчан гына, туган ил белән саубуллашканда, бу республикалар аның өчен бик еракта кебек иде. Ул аларның шигъриятен дә, әдәбиятын да, күмәк җырларына мөкиббәнлеген дә аңламады, аларның рәсем сәнгате һәм сынлы сәнгате турында аерым фикере булмады. Балтыйк буе кешеләренең үз эченә бикләнгәнлеге мин-минлектәндер дип уйлады. Хәзер исә бу республикалардагы тормыш якын иде, анда булган һәр вакыйга турында ул дулкынланып укыды. Мөгаен, андагы ватанпәрвәрлек дигән кадерле хис чит илдә яшәүдән тугандыр. Бу табышы күп кенә югалтуларны каплыйдыр дип ышандырырга тырышты ул үзен.

Мансур Үзбәкстанның елына биш миллион тоннадан артык мамык җыюына сөенде. Мамыкның нәрсә икәнен ул яхшы белә. Аны ничек үстерүләрен дә Мисырда, Суданда, Мароккода үз күзләре белән күргәне бар. Ун ел элек ул «Жигули»ның беренче маркасын күргән кеше иде, хәзер исә ике ишекле спорт моделе чыгуы турындагы хәбәрне укыгач горурлык хисләре кичерде. «Нива» машинасы инде соңгы елларда Сахара чүле буйлап оештырылган раллида дөньяның шактый атаклы машиналарын артта калдырды.

Сүз дә юк, кызлар белән бассейнда яки кичен барда очрашкач ул аларга күп вакытын китапханәдә уздыруы хакында тел тибрәтмәде. Үзен сөендергән яки көендергән хәбәрләр турында кызыксынуын сиздермәде, алардан шәрехләүне үтенмәде, чөнки тиз арада гына бөтен дөньяны колачлап алу мөмкин түгел дип санады. Аннан соң ул, тормышның әчесен-төчесен шактый мул татыган ир, шушы яшь чибәр, бар белгәннәре шаяру да көлү булган кызларга таяна аламы? Өстәвенә, алар гуманитар белемгә ия, чынбарлыктан, төгәлрәге — мөһим тармаклардан ерак торган оешмаларда эшли һәм тормышны кондиционерлы бүлмә тәрәзәсеннән генә күрә. Ә ул — прагматик, хуҗалыкчан инженер, аналитик фикергә ия — хәтта текстлардагы икенче мәгънәне ачык тоя, кайчакта мәкаләдә күтәрелгән проблеманы авторының үзенә караганда да яхшырак аңлый. Чөнки автор да — гуманитар, ул да чынлап торып аңлауга караганда, үзенә нәрсә күрсәткәннәр, шуңа гына таяна. Журналистиканың йомшак ягын чамалый Мансур. Тиздән гәҗитләрдәге һәр мәкалә аерым белгечләр тарафыннан язылырга тиеш дип саный ул. Гәҗит һәм тема арасына арадашчы булып — журналист кысылуын аңламады тәки. Һәркем аңлы, грамоталы булган чорда моның кирәге бар микән!

Шулай да өйгә теплоход белән кайту аның өчен шәп булды әле. Мансур, палуба шезлонгында ятканда, күзен йомып йөзен назлы җилгә, кояшның җылы нурларына борды, тирә-ягында ни-нәрсә сөйләшүләренә колак салды. Ул шаһит булган әңгәмәләр әлеге сәфәргә, алар күңел ачкан, сәяхәт кылган яки кылачак романтик портларга, йә булмаса төрле илләргә хас булган үзенчәлекләргә бәйле түгел иде. Гәпләшүләр – туган-үскән җирләр, ил тормышы, ял тәмамлануга көтеп торган эш турында иде. Көндәлек мәшәкатьләрне онытып тора белмәү, гел хезмәт турында уйлау — монысы да безнең кешеләргә хас сыйфат. Колакка ягылган бу сүзләр Мансурны рухландыра, аларның эш-мәшәкатьләре әйтерсең лә аңа да кагыла.

Сетне уздылар, Марсельгә якынлаштылар. Инде һәммәсенең дә телендә бер генә сүз: Франция, Франция....

Ни өчен кеше «Франция» сүзен ишетүгә шулкадәр канатлана соң? Бу сорау Мансурны уйга салды. Мөгаен, бу безнең илнең мәдәнияте һәм тарихы Франция белән нык бәйләнгәнлектән шулайдыр. Без укып үскән урыс әдәбияты да Франциягә мәхәббәт белән сугарылган бит.

«Лев Толстой» Марсельдән сәгать ярымга сонарып кузгалды. Эш шунда ки, туристлар экскурсиядән кайтып, җыелып бетүгә, теплоходка «СССР-Франция» җирле дуслыгының активистлары килде. Бу очрашу, әлбәттә, билгеләнгән вакытка сыеша алмады. Ул шау-шулы бәйрәмгә әверелде, Мансурга исә тәрҗемәче вазыйфасын үтәргә туры килде...

Марсельдән кузгалганда, причалларда утлар балкый иде инде. Теплоходтагы көндәлек кичке тормыш та гадәттәгедән давыллырак булды — әйтерсең лә Франция бортка үзенә хас күңел ачуны, тормыш сөюне һәм бетмәс-төкәнмәс мәзәкләрен төяп җибәргән.

Иртәгесен аштан соң, Кишинев кызлары бассейнга килгәндә, кулларында француз журналлары һәм гәҗитләре иде, тик Мансур кызларның кайчан сатып алганнарын хәтерләми. Югыйсә, алар Марсельдә аннан бер генә адымга да читкә тайпылмады. Матур тышлы журналларның күпчелеге мода, спорт һәм дөнья яңалыкларына багышланган. Матур фотолы язмаларны сайлап, кызлар аның тәрҗемә итүен үтенде. Журналлардан соң чират гәҗитләргә җитте. Әмма кызларга алар ошап бетмәде: җәнҗалга бай журналлардан соң гәҗит язмалары кызыксыз тоелды. Мансурның да исе китмәде. Аның бөтен уй-фикере китапханәдәге гәҗитләр белән бәйле иде. Төшке аштан соң ул шунда юнәлде. Теплоходта аны үзенә тартып торган урын — нәкъ менә китапханә иде.

Уку залында күңелгә рәхәт салкынча һава тора, тавышсыз гына кондиционерлар эшли иде. Мансур стеллажлар янына килде. Ул сайланып тормады, кулына нәрсә эләкте — шунысын укыды, чөнки аларның һәммәсе дә аның өчен кызыклы иде.

Ул «Правда», «Известия», «Комсомолка» стеллажлары яныннан үтеп китте. Һәр санын булмаса да Мансур аларны укыштыра иде. Кинәт аның күзенә «Әдәби гәҗит» төпләнмәсе чалынды. Бу гәҗитне ул бик сирәк күрә иде. Бәлки, илчелеккә һәрдаим килгәндер, әмма төзелеш мәйданына – аның кулына килеп ирешкәне булмады. Мансур аның күп булса елга өч-дүрт санын укыгандыр. Анысы да Ватаннан кем дә булса килә калганда. Туган илдән гәҗит-журналлар төяп килү — төзүчеләргә хас нәрсә. Әмма төзүче-хезмәттәшләре арасында бу гәҗит иң көтеп алганнардан санала иде. Әлбәттә, күпчелек өчен гәҗитнең икенче өлеше кызыклырак. Анда хуҗалык проблемалары, тәҗрибәләр, эзләнүләр югары дәрәҗәдә бирелә. Дөрес, кемнәрдер гәҗитнең беренче өлешенә, әдәби, иҗат проблемалары күтәрелгән өлешкә дә битараф калмады. Шулай итеп, Мансурның хезмәттәшләре арасында «Әдәби гәҗит»не укучылар күбрәк иде. Монысы

һәркемнең үз эше. Мансурдан исә техника өлкәсенә караган теләсә кайсы мәсьәләдә кинәш сора — бервакытта да җавапсыз калмыйсың. Аны шуңа да үзара шаяртып «аяклы энциклопедия» дип атап йөрттеләр. Африкалы хезмәттәшләре аңа «Мистер Гост» дип исем кушты, чөнки ул барлык чималга, материалга һәм төзелеш конструкцияләренә кагылышлы ГОСТларны яттан белә иде.

«Әдәби гәҗит»тәге мәкаләләргә карата алар арасында бәхәс купкан чаклар да булгалады. Африкадан торып та алар ватандагы проблемаларны яхшы чамалый иде. Бәлки, алар өйдә чакта бу проблемаларны күрмәсләр һәм сизмәсләр дә иде, монда исә алар калку булып күренә. Менә хәзер дә, гәҗит төпләнмәләрен кулына тоткан килеш, Мансур Найроби мәдәни үзәгендәге кискен бәхәсне исенә төшерде.

Ул чакта Мансурның Найробига яңа килгән генә чагы һәм аның танышлары да әле бармак белән генә санарлык. Шуңа да ул бәхәстә катнашуны кирәк тапмады. Шимбә саен әлеге мәдәни үзәктә кичке чаралар уздырыла, кешеләр бер-берсе белән китаплар алмаша, нәшрияттан беренче чиратта монда китерелгәнгә, китапханә дә яңа китапларга, журнал һәм гәҗитләргә бик бай. Китаплар һәм аларның авторлары турындагы бәхәс тә менә шушы китапханәнең зур булмаган холлында кабынып китте...

Кызыксынып тыңлаганнан соң, Мансур сүзнең әлеге дә баягы эчтәлексез, кирәксез китаплар азрак басылуда язучының гына түгел, нәшрият хезмәткәрләренең һәм рецензентларның да укучы алдындагы җавапсызлыгы турында барганлыгын аңлады. Холлда эшлекле, фикерле кешеләр җыелган иде. Шундук тәкъдимнәр, фикерләр яңгырый башлады.

Әйтик, кемдер китапта автор исеме генә түгел, рецензентның да фамилиясе күрсәтелергә тиеш дип белдерде. Аның фикеренчә, әгәр эчке рецензент берничә йомшак китапка унай бәя бирә икән, укучы аның кемлеген беләчәк, аннан соң ул адәмне кулыннан килмәстәй эштән читләштерү мөмкин булачак.

Кайсыдыр талантсыз авторлар повесть яки романын журналда бастыра, «Роман-гәҗит»тә чыгарта, борылып карарга да өлгермисең — аерым китап булып дөнья күргән. Бер-ике ел да узмый, ул китап кабат бастырыла. Әзерлексез укучы исә һаман да шушы фамилияне күреп, китапларын кулына алгач, ул зур язучы дигән фикергә килергә мөмкин. Хәер, моның сәбәбе бик гади — ул авторның кайда эшләвенә бәйле. Бәхәстә кызып китүчеләр һәр китапта язучы турында кыскача белешмә булырга тиеш һәм анда мәҗбүри рәвештә аның эш урыны да күрсәтелсен дип хәл иттеләр. Монда авторны кимсетерлек бернинди сәбәп тә юк. Әгәр ул профессионал язучы икән — белсеннәр, әгәр ул нәшрият директоры яки журналда бүлек мөхәррире икән — яшермәсен, әйтелергә тиеш тә тиеш инде. Безнең укучы дөньяда иң әзерлеклесе, ул теләсә кайсы хисаплау машинасыннан да житезрәк итеп, кем кемне ни өчен бастырганын ачыклаячак, исәпләп чыгарачак. Менә шул бәхәс хакында «Әдәби гәҗит»кә мәкалә язарга булдылар.

Әлеге күпләгән тәкъдимнәрнең язмышы турында Мансур башкача ишетмәде, белмәде, әмма бераз вакыт узгач, кулына килеп эләккән очраклы китапта рецензент фамилиясен күргәч, сөенде — димәк, ул чакта юкка гына тавыш күтәрмәгән алар! Мансур әнә шул вакыйганы исенә төшерде.

Ул җайлап утырды да гәҗитләр өеменә чумды. Бер сәгатьтән палубага тәмәке тартырга чыкты һәм, кире әйләнеп кергәч, алдагы айларның төпләнмәсен актара башлады. «Әдәби гәҗит»тәге проблемалы мәкаләләрне укый торгач аның башына бер фикер килде: «Проблемалар ташкын кебек илгә агылганмы, әллә җыелып килгән мәсьәләләрне бүгенгә кадәр читкә куеп торып, хәзер аларны хәл итәр чак җиткәнме? Бәлкем Ленин хыялланганча,

массаларның иҗади өлгерүе сәбәпчедер моңа? Күп проблемаларның укучылар башлангычы белән күтәрелүе бераүгә дә сер түгел бит.

Мансур «Төрле фикер» рубрикасын укып сөенде. Монда бер үк әсәр турында төрле фикер белдерелә. Үзе дә сизмәстән, аның уйлары хуҗалык өлкәсенә күчте: «Их, әдәбиятны төрле яклап караган кебек, халык хуҗалыгына да шундый караш начар булмас иде. Төрле фикерләрне тынлагач, без вак табышка өметләнеп, ничәдер елдан соң артык зыян белән әйләнеп кайтачак ашыгыч нәтиҗәләр чыгармас идек. Кайбер язмалар анда дәрт һәм өмет, азарт уятты, аның башына: бәлки, миңа да гәҗит аша үз фикерләрем белән уртаклашыргадыр», — дигән уйлар да килде. — Бу елларда жанны борчыган мәсьәләләр шактый күп, тәҗрибә дә юк түгел...

Ул Ватанында, чит илләрдә, шул ук Африкада да аз төземәде. Мөгаен үз эшен яхшы белгәндер, чөнки алдынгы илләрдә төзелеш алып барган дөньякүләм билгеле фирмалар үзләренең проектларын чагыштырма анализ өчен бәяләргә дип аңа бирергә тырышты. Шулай ук халыкара оешмалар да Мансурны белгеч буларак файдаланды. Африкада эшләү вакыты тәмамлангач, аңа рәсми төстә БМОның белгече вазифасын тәкъдим иттеләр. Әмма Мансур ризалашмады. Контракт килешүе ун елга исәпләнгән, димәк дөнья буйлап әле бик озак сәяхәт итәргә туры киләчәк иде. Аның өйгә кайтасы килде. Әнисеннән килгән хатны еш исенә төшерде: «...дөньяда бик күп мөһим эшләр бар, улым. Минемчә, иң мөһиме — туган җиреңә хезмәт итү, якты эз калдыру. Син белем алган һәм мин кырык биш ел буе укытучы булып эшләгән мәктәп җимерелеп килә. Менә чит илдән кайткач, өйдә бераз хәл жыяр идең дә яңа мәктәп төзеп куяр идең. Синең кебек тәҗрибәле кешегә ул зур эш саналмыйдыр да. Синең мактау бүләкләрең бик күп, мәктәп төзелешен кузгата башласаң беркем дә каршы килмәс».

Әнисенең шушы хаты аның күңелендә ниндидер өермә кузгатты, тәгәллек механизм кебек узган тормышын үзгәртте. Хатны, мәктәпне исенә төшергәч, Мансур туган авылы Аксай турында уйланды. Ул бик күпләр уфтанып, сагышланып искә ала торган, кайтарып булмастай мәктәп еллары турында бик сирәк искә төшерә иде. Шушы гүзәл яшьлектә һәркемнең үз елгасы, урманы, авылы, дусты, сөйгәне кала. Туган авыллары поезд белән ике-өч сәгатьлек арада гына урнашса да, бик күпләр аны сагынып яши. Ә Мансур моңарчы хәтта бер куагы, чәчәге туган җирне хәтерләтмәгән чит илдә дә бу хакта алай ук уфтанып уйланмады...

...Сугыштан соңгы елларда ул ничектер атаклы архитектор турында Һолливуд фильмы карады. Бәлки, фильм талантлы режиссер тарафыннан эшләнгәндер, бәлки, үзе дә кинодагыча ат кәнүшние тирәсендә ярлы бистәдә үскәнлектән, архитекторның эше аңа могҗиза булып күренгәндер. Ул чакта ул кино төшерү өчен махсус төзелә торган папье-машедан зур бер шәһәр төзеп буладыр дип башына да китермәгән иде. Менә шул көннән архитектор булам дигән уйны башына киртләп куйды. Әмма ул проектлау белән төзүнең бер-берсеннән аерылганын белми иде әле. Әлбәттә, бу максаты хыял житмәстәй булып тоелды, чөнки ул елларда бистә егетләре ике генә юлны сайлый иде: беренчесе — Гурев мореходкасы, икенчесе — жирле химкомбинат өчен слесарь-аппаратчылар әзерли торган Алга һөнәр училищесы. Ни өчен дигәндә җавабы гади: икесендә дә белгечлек бирү белән беррәттән бушлай ашаталар, киендерәләр иде. Аксайда соңрак бу ике уку йорты турында белдерү дә элеп маташмадылар, чөнки жидееллыкны тәмамлаган егетләр бергәләшеп станциягә китәләр дә вагон түбәсендә Гурев белән Алгага барып житәләр иде. Бу хәл алтмышынчы елларга кадәр, тормышлар бераз рәтләнә башлаганчы дәвам итте. «Дингез» яки «Химия»гә киткән егетләрнең берсе дә кире Аксайга әйләнеп кайтмады. Кызык:

коры жирдә, судан ерак урнашкан Аксай илгә бик күп диңгезчеләр бирде. Мөгаен бүген дә диңгез-океаннарда Мансурның якташлары штурман, механик, матрос булып хезмәт итәдер әле. Әлбәттә, «Лев Толстой» кебек затлы теплоходларда да, сухогруз, танкер һәм балык сейнерларында да бардыр алар. Ә ул менә архитектор булырга уйлады! Дөрес, Мансур хыялы турында беркемгә авыз ачып сүз әйтмәде. Мөгаен шул сер аның холкына да йогынты ясамый калмагандыр. Тыныч, кешегә әллә ни ачылмаучан, мөстәкыйль Мансур беркемне дә күңеленә якын китермәде. Әмма аның тормышында аздан гына ахыры күңелсезлек белән тәмамланмый калган бер вакыйга булды. Бу вакыйга Мансурның башыннан һич китми. Аның Аксайга кайтмавының сәбәбе дә шуна бәйле иде. Бу вакыйга өчен улының ничек кайгырганын теләсә кемнән күбрәк аңлаган әнисе аннан ял вакытында Аксайга кайтуын таләп итмәде. Менә хәзер генә, соңгы елларда, ул аның кайтуын көтеп яши башлады.

Уйлары Аксайга килеп бәйләнгәч, Мансур гәжитләрне читкә этәрде — уку дәрте сүнгән иде инде. Ул палубага күтәрелде. Жинелчә жил буш шезлонг аркаларының тукымаларын йолыккалый. Франциядәге шау-шулы кичтән соң туристлар ял итә. Гажәп, ул монарчы туган йорты турында ныклап уйланмаган икән. Югыйсә анда булмаганына егерме елдан арткан. Буш палубада йөренгәндә: «Менә бит, уйланыр өчен иң кулай вакыт һәм урын», — дип, үзалдына көлемсерәп куйды.

Үз гомерендә беренче төзелештә — Аксайда булган хәлләр турында аның беркемгә авыз ачканы булмады. Хезмәттәшләре дә бу хәлләрдән бихәбәр. Кем белә, бәлки тормыш юлын башлаганда алган бу зур сабак ана зыянга булмагандыр.

Ул Мәскәү институтын иң алдынгылардан булып тәмамлады һәм юлламаны беренчеләрдән сайлау хокукына ия булды. Ул Казакъстанны сайлады. Туган ягы булганга гына түгел. Ул чакта бу республикада чирәм жирләрне үзләштерү бара, төзелеш эшләре дә гөрләп тора иде.

Республиканың төзелеш министрлыгында аның кайда тууы, ни өчен нәкъ менә Казакъстанны сайлавы белән кызыксынып торучы булмады. Ул Аксай исемен атауга, икенче көнне килергә куштылар. Кызыклы һәм мөстәкыйльлек таләп итә торган эш кайдадыр читтә түгел, нәкъ менә Аксайның үзендә табылды. Бу вакытта чирәм жирләрне үзләштерүнең алтынчы көзе бара, Казакъстан исә беренче миллиард пот икмәк уңышын көтә иде. Чирәм жирләрне күтәрү икмәк проблемасы белән бәйләп каралганга, далада эш кайный. Монарчы игътибар үзегеннән төшеп калган дала бистәсе Аксайда зур төзелеш эшләре көтелә иде. Аксай зур юллардан читтә урнашкан. Район үзәге Нагорныйга һәм тимер юл станциясенә егерме чакрым ара бар. Бүгенге көн күзлегеннән караганда, бу ара бик кыска кебек. Ул чактагы дала юлы өчен, бигрәк тә көзен, трактордан башка бер генә машина да район үзәгенә барып житә алмый иде. Аксай икмәк үстерде, чирәм жирләрне үзләштерү нәтижәсендә совхоз эчендә совхозлар барлыкка килде. Шулай итеп аның районы иң икмәкле районга әйләнде дә куйды. Шуңа да биредә ике элеватор төзеделәр. Берсе тимер юл буенда — Нагорныйның үзендә, ни дисәң дә икмәкне озату күпкә жиңелрәк иде. Икенчесе Аксайда урнашты. Анысы дала эчендәге авыллардан икмәк жыю өчен жайлы. Моңа кадәр зур колачлы төзелешне күрмәгән Нагорныйда төзелеш-монтаж идарәсе, Аксайда исә шул идарә өчен хужалык исәбе участогы төзеделәр. Әнә шул төзелеш-монтаж идарәсенә юллама алып, яшь инженер Мансур Гатауллин кайтып төште.

Ярты ел элек кенә төзелгән идарәдә оештыру эшләре дәвам итә: янарак кына территория тирәсен төзекләндерү тәмамланган. Мансурның эшкә

килүенә барысы да шатланды, чөнки ярты ел эчендә Аксай участогыннан ике җитәкче качкан иде инде. Әйтерең бармы, читтән килеп эшләүчеләр өчен шартлар мактанырлык түгел: бистәдә ни кунакханә, ни ашханә юк, бар булган чәйханә дә көндез генә хезмәт күрсәтә. Мансурны шундук участок җитәкчесе итеп билгеләделәр. Кемгәдер сәер тоелыр, бүген дипломлылар белән буа буарлык заманда, мондый хәл меңгә бер була микән? Прораб итеп куйсалар сөенеп туялмыйсың. Бәлки Мансур очрагында Мәскәү дипломы үз эшен башкаргандыр. Хәер, иң мөһиме — аны билгеләгәндә тарта алырмы кебек шөбһәле сорау бераүнең дә башына килмәде. Инженер — димәк инженер үзе дә эшләргә һәм төзелешне дә өстерәргә тиеш. Мансур эштән курыкмады, хуҗа булуына сөенде дә әле. Һәр кешегә андый уңыш елмаймый дип сөенде эченнән генә.

Хәзер, Урта диңгез буйлап сәяхәт иткән теплоход палубасында басып торганда, Мансур уе белән әнә шул төзелешкә әйләнеп кайтты. Ул беренче көннәреннән үк эшкә төптән җигелде: кадрлар тупларга, прораб бинасын, складлар, элеваторга килү юлларын төзергә туры килде.

Бәлки, ул үз кулы астындагылар турында бик югары фикер йөртәдер, әмма шунысы хак: андый булдыклы, карусыз эш башкаручыларны ул башка очратмады. Африкада пөхтәлек, төгәллек ягыннан охшасалар да, осталык, мөстәкыйльлек ягыннан Аксай төзүчеләренең кисеп ташлаган тырнакларына да тормый иде.

Дөрес, башта Аксайда да җиңел булмады. Төзүчеләрне якын-тирә авыллардан җыярга туры килде. «Төрле эш башкаручы итеп эшкә алуыгызны сорыйм» дигән гариза тотып килүчеләрнең һәммәсен дә кабул иттеләр. Кайберләренең гаризаларында «кара эшче итеп» дигән сүзләр дә бар иде. Мансур тау кадәр өелгән шундый гаризаларны күреп башын тотты. Аңа иң беренче нәүбәттә балта осталары, арматурчылар, бетончылар, ташчылар кирәк иде — аларсыз ул ике кулсыз. Әүвәл Нагорныйдагы идарәгә мөрәҗәгать итәргә теләде, әмма кеше кайгысы кешнәктәдер дип, мөстәкыйль эш йөртергә булды.

«Матур, зур эшләргә тотынган вакытлар», — дип сагынып искә алды Мансур ул көннәрне. Тату, бердәм булдылар, авырлыктан чыгу юлын бергәләп эзләделәр, житешсезлекләр булганда бер-берсенә бармак төртеп күрсәтмәделәр.

Мансур эш башлаганда участокта сиксән эшче санала иде. Аларның күбесе төрле эш башкаручылар булса, унбишләбе генә белгечлеккә ия, тик читтән килгәнлектән, аларга таяну — язгы бозга ышану белән бер иде. Үз кадрларың булырга тиеш, үзеңнеке!.. Мансур моны тиз аңлады.

Икенче көнне смена ахырында ул барлык эшчеләрне буш төзелеш мәйданына җыйды. Иң элек аларга элеватор төзиячәкләре турында әйтте, сафка баскач, аның ни рәвешле булачагын тәфсилләп аңлатты, алдагы төндә ватман кәгазенә төрле төстәге буяулар белән ясалган рәсемен күрсәтте. Эшчеләр нәрсә төзегәннәрен алдан ук белеп һәм аңлап торырга тиешләр. Ахырдан шушындый зур төзелешне башкарып чыгар өчен аларга укырга, яңа һөнәр үзләштерергә кирәк булачагын әйткәч, үз «гвардия»сенең башы түбән иелгәнен күрде. Бу аңлашыла: аларның уртача яше иллегә якынлаша, күбесе фронтовиклар, грамота яклары да чамалы. Кая инде аларга уку — якташларының тын гына басып торуы әнә шул хакта сөйли иде.

Мансур шулай булачагын алдан ук белде, белемсез кешене укырга кирәк дигән сүз куркуга сала. Әмма алар даими эш урыны булмаган бистә өчен төзелеш — тормышны яхшырту юлы икәнен бик яхшы аңлыйлар иде.

Шуңа да Мансур хәйлә юлына басты:

— Мине дөрес аңлагыз, — диде ул. — Төзелеш өчен шулкадәр төрле эш

башкаручылар кирәкми. Әгәр сез белгечлек алырга теләмисез икән, мин сезне эштән куарга яки Нагорныйга, станциягә йөкче итеп җибәрергә мәҗбүрмен. Мин сездән конспектлар язуны сорамыйм, имтихан да алмаячакмын. Мина сезнең инструкторларыгызның эшли ала яки алмый дигән сүзе җитә. Үзем дә ярдәм итәрмен, эшнең һәр циклы, аның күләме, бәясе, төзелеш вакыты һәм материаллар чыгымы белән таныштырырмын. Әйтик, кемдер балта остасы һөнәрен үзләштерергә тели икән, барып чыкмаса, кайгырмасын — бетончы яки ташчы булып күчәргә мөмкин. Әмма бер-ике-өч айдан сезнең һәммәгез төзелештә үз урының табарга тиеш.

Ул үзен урап алган кешеләргә күз йөгертеп чыкты, бу юлы инде аларның карашларында курку түгел, кызыксыну һәм өмет чаткысын тойды. Моны күреп, тавышы тагын да ышанычлырак яңгырады:

—Хәзер исә, кем дә кем балта яки пычкы тотарга маһир — бер якка, үз гомерендә сарай төзегән яки мич чыгарып караган кешеләр — икенче якка җыелыгыз. Кем яшьрәк һәм үзендә көч тоя, акчаны да күбрәк эшлисе килә — бетончылар төркеменә язылыгыз. Бу иң авыр һәм мактаулы эш. Ишеткәнегез бардыр, бетон — төзелешнең икмәге! Бу һөнәрне үзләштерүе дә ансат — арканны гына сындырма.

Һәркемгә акча кирәк: балта осталары һәм ташчылар төркеменә барып басканнар да бетончылар төркеменә таба атлый башлады. Мансур аларның шундук юлын бүлде.

—Ашыкмагыз, берегез дә акчасыз калмас, вәгъдә бирәм. Бары тик эшкә генә өйрәнегез. Хезмәт хакыгыз да үзегездән тора: никадәр эшлисез, шулкадәр аласыз.

Ул эшчеләренең авырткан сөялләренә басканын аңласа да, сүзен ныгытып әйтте:

—Әгәр дә бер бригада аркасында икенче бригада эштән туктап тормаса, безнең төзелештә эш гөрләп барачак. Күреп торам, сез бирегә бер генә көнгә дип килмәгәнсез. Барыгыз да ашлык төягән машиналар күренә башлаганчы эшләргә җыенасыздыр. Шулай икән, бу айдан хезмәт хакыгыз бермә-бер артты дип исәпләгез. Иң мөһиме, минемчә, өйдәгеләрегез сезнең зур эш белән мәшгуль икәнегезне белсеннәр.

Ул туктап калды, эшчеләр исә, җанланып, үзара фикер алыша башлады.

Мансур эшчеләреннән бигрәк үзе дулкынланды. Аңа беркемнең бу кадәр хокук биргәне юк. Бигрәк тә хезмәт хакы мәсьәләсендә. Әмма шунысына инанды ул: элеватор төзелеше өчен дә, кешеләр язмышы өчен дә бүгеннән ул җаваплы. Төркем таралырга ашыкмады, шулвакыт «бетончы»чылар арасыннан аның күршесе, күп балалы гаилә башлыгы Саша Буккерт аерылып чыкты.

— Син, Мансур, безне уку белән шактый куркуга салдың. Белем белемгә охшамый. Укуың укырбыз — һәммәбезнең кулыннан килер дип уйлыйм. Син читтән килгәннәр укытыр диден. Минемчә, безнең арада да төзелешне яхшы аңлаучылар бар. Мисал өчен мин сугыш вакытында Чиләбедә завод төзедем, тимерне эретеп ябыштыру һәм арматур эшен яхшы беләм. Кирпеч салуны да онытып бетермәдем шикелле. Әгәр дә хезмәт хакы син әйткәнчә барса, без бурычлы булып калмабыз. Дөрес әйтәмме, егетләр? — Саша якташларына борылды.

— Дөрес! Кыен хәлгә куймабыз, — диделәр ирләр бертавыштан.

...Алар каршысына — әле сул, әле уң яктан төрле әләмле, төрле рәвешле теплоходлар айсберг кебек калкып чыкты. Палубаларда күнелле көйләр яңгырый — һәр корабның үз тормышы, үз тәртибе. «Җирдә дә, суда да, һавада да, мөгаен, галәмдә да шулайдыр. Кысан була башлады», — дип

куйды нигәдер Мансур. Әмма уйлары һаман да Аксайда, егерме өч ел элек элеватор төзи башлаган туган ягында иде.

Ике елдан Мансур, гомерендә беренче тапкыр, объектны куллануга тапшырды. Яшь булса да вазифасында шактый күтәрелгән Мансурга тәҗрибә уртаклашуын сорап мөрәҗәгать итүчеләр артканнан-артты. Аларның барысын да: «Вакытыннан алда далада, тимер юлдан еракта урнашкан элеваторны ничек төзеп бетерә алдыгыз, смета чыгымнарыннан ничек арттырмадыгыз?» — кебек сораулар кызыксындырды. Бөтенсоюз «Элеватор-тегермән төзелеше» тресты эшнең аерым этаплары төшерелгән фотолардан бюллетень бастырып чыгарды. Мансур исә техник-икътисади күрсәткечләр, Вуккерт житәкчелегендәге зур комплекслы бригада турында сөйләде. Алар жилкәсенә барлык төзелешнең өчтән бер өлеше төште. Барлык уйлап табуларның, яңа тәкъдимнәрнең яртысы нәкъ менә алар өлешенә туры килде. Әйе, ул чакта алны-ялны белмичә эшләделәр...

Әлеге бюллетеньдә танылган бригадир, эш алдынгыларының — һәммәсенең фотолары бар иде. Әмма араларында Мансурныкы гына күренмәде. Мөгаен, житәкчелек кичәге студентның инженер һәм житәкчелек талантын әлегә күрсәтми торырга булгандыр. Ул беркемгә дә рәнжемәде, үзенең уңышы киләчәгенә ышанды.

Болар барысы да ахырдан килер. Әлегә кәгазьдә барысы да яхшы, күңелле булса да, чынбарлыкта алай ук жинел булмады. Ул чакта Мансурга нибары егерме ике яшь иде. Элеватор исә аның эш дәверендә беренче төзелеше иде.

Нигезне ясап бетерүгә, төзелеш бик кызу темплар белән күтәрелә башлады. Эш Нагорныйга караганда тизрәк бара иде.

Мансур чит тәҗрибәне тулысы белән кулланырга ярамавын аңлый. Ул чит тәҗрибә белән артык мавыкмыйча, үз кул астындагы талантлы эшчеләрне күтәрергә, аларга үсәргә булышырга карар кылды. Бәлки, шуңа да һәр бригадир үз эшенә бик жаваплы карагандыр. Түрәлек чире йоктырганнарга мондый нәрсә хас булмый. Хәтта табель хисабын алып баручы Мария Николаевна Яблуновская да төзелеш эшен яхшы аңлый иде. Фикерләү, энергия, максатчанлык ягыннан караганда, ул нәкъ менә төзелеш өчен, гөрләп торган эш өчен яралган иде. Кешенең үз урынын табуыннан да әһәмиятлерәк нәрсә юк бу дөньяда! Һәр жаваплы ноктада үз эшенең осталары барлыкка килде.

Мондый колачлы эштә исә вак-төяк хатасыз булмыйдыр. Әйтик, кулыннан эш килмәгән сантехник эшли ди. Аның сәләтсезлеге аркасында төзелештә су юк икән, димәк, өч йөз кеше эшсез торачак. Бу инде көнлек, айлык планның үтәлмәве дигән сүз. Су эшләре слесаре булып фронтовик Геннадий Александрович Кужелев эшләде. Ике ел эчендә бер генә мәртәбә дә су туктаганы булмады. Бетон эшендә су елга булып акты. Нагорныйдагы житәкчелек слесарь белән нык кызыксынды. Әмма Мансур аны беркайчан рәнжетмәде, бернечә булдыксыз эшче тотканчы, бер остага күбрәк түләүне кулай күрде.

Мансур үзендә эшләгән өч йөз кешенең исемнәрен генә түгел, холык-фигыльләрен яхшы белә иде, чөнки үзе дә Аксайныкы буларак, эшчеләрнең яртысы диярлек әтисенең таныш-белеше, калганнары — яшьләр — аның кормалары иде.

Арматурчыларның хатын-кызлар бригадасын кара син! Ирләрне бу эштән кысрыклап чыгардылар. Алар сүзенә ышансаң, арматура хәзерләү ирләр эше түгел! Тырышлыкларын күр: биш-алты метрлы арматураны смена буе ташыйлар, әмма телләреннән ник бер зарлану сүзе чыксын. Ирләр төзелешнең башка өлкәсендә кирәгрәк дип, тешләрен кысып эшли

бирәләр. Беренче төзелеше менә шундый үҗәт, тырыш кешеләре белән истә калды. Теләсә кайсы уныш кешеләргә һәм эш шартларына бәйле. Күп нәрсә житәкчедән тора: ул нинди – кул астындагылар да шундый. Үзең булдыра алмаганны кешеләрдән таләп итәргә ярамый. Яшь булуына да карамастан, тиз төшенде ул моңа.

Балачакта караган, аның тормышын үзгәрткән теге фильмда әкияти матур виллалар, сарайлар, концерт заллары төзелде. Мансур да шундый матур сарайлар төзү турында хыялланса да язмышы сәнәгать төзелеше белән бәйләнгән булып чыкты. Бу өлкәдә дә инженер өчен кызыклы эш бетмәс-төкәнмәс иде. Илдә, дөньяда беренче тапкыр алып барылган төзелеш язмышы, һәммәсе дә диярлек икенчесенә ярамый. Һәр төзелеш – язучының яңа әсәре кебек: тәҗрибә тупланган, әмма барысын да яңача башларга кирәк. Сәнәгать төзелеше менә шушы ягы белән җәлеп итте дә инде Мансурны.

Менә хәзер, уйлары үткәндәге елларны гизгәндә, юлга чыгар алдыннан Америкада басылган «Архитектура» журналыннан укыган кызыклы мәкалә хәтеренә килде.

Мәкалә беренче юлларыннан ук игътибарын җәлеп итте. Тулы ике биткә элеватор сурәтләре төшерелгән иде. Американнар икенче бөтендөнья сугышына кадәр үк төзегән әлеге икмәк саклау корылмалары теге чакта Аксайда һәм Нагорныйда төзелгән элеваторны хәтерләтте. Әлбәттә, мәйданы ягыннан алар зуррак һәм конструкциясе дә башка төрле. Ни әйтсәң дә ике арада егерме ел вакыт ята. Ә бу төзелеш өчен бик зур сынау. Журналда язылганча, әлеге элеваторлар бүгенге көнгә кадәр хезмәт итәргә тиеш булсалар да заман үзенекен иткән. Кайчандыр икмәк районы саналган районнар сәнәгать үзәгенә әверелгән, кайбер штатларда хәтта бер гектар чәчүлек мәйданына тап булмаска мөмкинсең. Бу динозаврларны хәтерләткән зур корылмалар эшсез тик басып тора. Жимерергә дә кызганыч: алар гасырлар өчен дип төзелгән. Әйтик, ниндидер химия сәнәгате өчен дә үзгәртеп кору мөмкин түгел аларны. Менә шулчак кызыксынучан бер архитекторның башына кызыклы уй килә: элеваторларны заманча фатирлы йортларга үзгәртеп корырга! Нәтиҗәсе көтелгәннән дә яхшырак, фатирлар иң югары таләпләргә җавап бирерлек була!

Мансур шул чакта америкалыларның буш торган корылмалар белән акыллы эш итеп, файдалы гамәл кыла алуына сокланган иде. Аларда да бездәге кебек үк, мондый корылмалар ун меңнәр белән исәпләнә бит.

Аның беренче элеваторы да сыйфат ягыннан бик яхшы иде, әмма ничек кенә хыяллансаң да аны фатирларга үзгәртеп булмас иде. Урынын да дөрес сайладылар: якында гына бистәнең паркы терәлеп тора. Мансур элеваторны тапшырып берничә ел үтүгә ул Аксайның иң зур предприятиесе саналыр дип уйлаган иде. Шуңа да җыелыш-киңәшмәләрдә төзүчеләрне: сез элеваторны төзүчеләр генә түгел, киләчәктә аның беренче эшчеләре дә булырсыз әле, дип кисәтә килде.

Беренче төзелеш уңай тәэсирләр калдырды Мансурда. Ана мөстәкыйль гамәлләр кылырга мөмкинлек бирделәр һәм шуның белән оттылар да, чөнки Нагорныйдагы төзелештә ике ел эчендә өч җитәкче алышынды. Бу исә төзелеш эшен шактый аксатты. Идарә шунда урнашканлыктан, ул төзелешкә игътибарлары зуррак булды, Мансурга юллары төшмәде диярлек. Ул моннан оста файдаланды, беркайчан алардан ярдәм сорамады. Аның участогында ике мастер эшләде. Алар гамәли эшне бик яхшы белә, әмма күп эшне җайланмалар белән түгел, күз белән генә үлчәп башкаралар, шуңа да инженерлык һәм документлар белән эшләү тулысынча аның җилкәсендә булды.

Вакыт-вакыт аның кайбер карарлары искитәрлек иде. Әйтик, беркайчан да: аңа кадәр дә, аннан соң да, илнең бер генә сәнәгать предприятиесендә дә төзелештә дүрт сәгатьлек төшке ялга тукталуның ишетелгәне юк иде. Ул чакта Аксайда бүгенге кебек, Испаниядән соң — сиеста (төшке ял) дип әйтмәделәр. Мансурның ул чакта мондый сүзне ишеткәне дә юк, андый гамәлнең кайдадыр кулланылуын да белми иде. Ул бары тик аны белән генә тоемлады: шулай иткәндә эш өчен дә, кешеләр өчен дә яхшырак булачак. Төзелеш янында ашханә юк, булса да анда берәү дә бармас иде. Аксай зур бистә түгел, һәркем төшке ашка өенә кайтырга тырыша. Аксай җәе Урта Азиянекеннән бер дә ким түгел, кайбер көннәрдә эсселек кырык градустан да артып китә. Бигрәк тә көн уртасында кояш рәхимсез кыздыра. Төзелеш эше исә күп көч сорый. Күзәтүләреннән чыгып шуны аңлады: эшчеләр өйләренә төшке ашка кайтып килгән арада ял итәргә өлгермиләр икән. Бер сәгатьлек тәнәфес йөгереп кайтып аягөсте ашап килүгә кала. Эш вакыты беренче көннән үк катгый исәпкә алынып барылды: эш сәгатьләрен үз эшләренә исраф итү тыела иде. Мансур менә шунда куркыныч адымга барды. Дөрес, ул эшчеләр белән киңәште. Алар исә бу яңалыкны шатланып кабул итте. Ялдан беркем соңарып килмәде, иң мөһиме —яңа көч белән эшкә тотына иделәр. Бигрәк тә бу яңалыкка арматурчылар һәм вак-төяк эш башкаручылар сөенде: алар балаларын мәктәптән каршы алырга, ашатырга өлгерделәр. Өйдәге мал-туар да вакытында карала башлады. Көннең икенче яртысында җитештерүчәнлек хәтта беренчесенә караганда югарырак та булды. Мансурның алдан исәпләве акланды.

Бәлки менә шундый исәп-хисап алып бару аңа эш күләмен, вакытын, хезмәт хакларын, материаллар чыгымын төгәл исәпләргә ярдәм иткәндер. Шунысы кызганыч, институтта чакта «Смета һәм отчетность» курсыннан укытучы аларга төп лозунгны искәртергә онытткан. Мөгаен, «әгәр санарга өйрәнмәсәң, беркайчан да чын инженер була алмаячаксың», — дигән сүзләрне кафедра диварына зур хәрефләр белән язып элеп куярга кирәк булгандыр.

Ул Аксай ирләренә төзелеш курсларын мәсьәләне хәл итүдә бердәнбер юл дип караудан гына булдырмады. Әгәр төзелештә эшләр бармаса, читтән эшчеләр җибәрәчәкләр иде. Күп очракта мәсьәлә шулай хәл ителә. Кич буе хәзерге калькуляторларның бабасы булган арифмометрны тотып уйланып, исәпләп утырганнан соң, ул шуны аңлады: читтән килүчеләргә хезмәт хакы фондының күп өлешен бүлеп бирергә туры киләчәк. Ул чакта исә эшчеләргә зур хезмәт хакы түләү турында хыялланасы да юк. Читтән җибәрелгән эшчеләрнең гадәттә разрядлары югары була. Ул аларны төшерә дә, баш тарта да алмый. Алар аерым бер бригада булып оешачак, хезмәт хакы сорап даулаячак. Һәм калганнар белән ике арада ризасызлык туачак. Иң яхшысы — башкарылган эш өчен түләү. Каяндыр, әйтик, Алма-Атадан җибәрелгәне өчен генә түләү дөрес адым булмас иде. Бу очракта үз кул астындагы тырыш эшчеләренең разрядын күтәрү аларның хезмәт хакын арттыруга да йогынты ясаячак иде.

Дөресен әйтергә кирәк, Мансурның эшчеләргә акча эшләү мөмкинлеге тудырасы, якташларын аякка бастырасы килде. Ике-өч ай узып, эшләр көйләнеп киткәч, аны төзелеш дәрте биләп алды, ул үзен бу зур төзелешнең тулы хуҗасы итеп тойды. Үзенең берничә көнгә генә түгел, хәтта айга кадәр алдан күрүчәнлегенә сөенде. Нәтиҗәдә ул, гроссмейстер шахмат тактасын тулысы белән күргән һәм алдагы йөрешләрне алдан ук белгән кебек, эшенә киң колач белән карый башлады. Сукыр күз белән дә күрә диярләр иде аның кебекләр турында.

Мансур сигез бригаданың кайсы нәрсә белән шөгыльләнгәнен, менә хәзерге минутта ни эшләгәнен төгәл белеп, тоеп торды. Бәлки аның

яңалыгы әллә ни зур да булмагандыр, тик вакытында, уңган, булдыклы хуҗа кебек, бригадирларга эш кушып, дөрес юнәлеш биреп торуы хак. Әйтик, берсен эш вакыты тәмамлануга чакырып ала да, эштән соң биш кешенне калдыр, алар әнә шуны, моны эшләп куйсыннар, юкса, иртәгәсен иртән барча бригадирлар эш башлый алмаячак ди. Яисә дүшәмбе зур эшкә тотыныр алдыннан, аларга эш фронты әзерләп куяр өчен бер бригаданы эшкә якшәмбе чыгара. Бу өстәмә эшләрнең һәммәсен дә табельщица төгәл исәпләп барды һәм аларга шуның өчен өстәмә акча түләнде. Шуңадыр, хәтта ял көнендә дә эшкә атлыгып тордылар. Ун кешегә өстәмә акча түләү, калган йөзләрне тик бастырып торуга караганда күпкә файдалырак иде. Мансурның эшчеләрне дәртләндереп торуда тагын бер алымы бар иде. Ул бу хакта ни кызганыч, беркемгә дә сөйли алмады.

Землянкаларны хәтерләткән, тәрәзәсе җиргә тиеп торган кара, урыны белән черек, рубероид түбәле Аксай йортларын күргәч, Мәскәүдән диплом белән кайткан Мансурның күңелен сызлану биләп алды. Авыл советы бинасыннан, мәктәптән кала тагын бик сирәк, бармак белән санарлык йортта гына идәннәр такта иде. Төзелеш акча эшләү мөмкинлеге белән беррәттән, шушы җир өйләрдән котылуга өмет чаткысы уятты.

Ләкин ничек төзергә? Акчаны хәзер шактый мул эшләсәләр дә материаллар табу мөмкинлеге юк дәрәҗәсендә. Хуҗалык товарлары кибете район үзәгендә генә булганлыктан, Аксайда хәтта кадак табу да мәшәкатьле нәрсә. Мансур кайдан, ничек материал табарга дигән уй белән янды. Әгәр бу мәсьәлә хәл ителмәсә, эшчеләр урлый башлаячак, тотылачак һәм Мансурга аларны эштән куарга туры киләчәк иде. Ә төзелеш өчен материалларны шәхси йортлар төзүдә кулланырга кем ирек куйсын? Сатып-алуны ничек рәсмиләштерергә? Ничекләр генә боргаланса да, чыгу юлы булмас кебек иде.

Мансур зур төзелештәге диплом алды практикасын исенә төшерде. Анда саксыз караш аркасында тонналаган цемент югала, арматур өчен чыбык бәйләмнәре күгәреп ята. Агач материаллар юкка чыга, кирпеч бушатканда яртысы ватыла, эшкә яраксыз хәлгә килә. Йөзләгән кубометрда опалубкалар яндырыла. Аларны бер генә тапкыр кулланырга ярый, шуна кая куярга белмиләр. Иренмәгәннәр кем нәрсә эләктерә ала, шуны өенә ташый. Беркем тотылмый, сүгелми. Прораблар да игътибар итми. Димәк, ниндидер чыгу юлы булган. Нинди юл икән соң ул? Шул диплом алды практикасында аның Аксаен төзеп бетерерлек материалларның юкка чыгуын күрде ул. Бүген нишләргә соң? Эшкә тоткарлык китермичә, эшчеләренә ничек ярдәм итәргә?!

Мансур тормыш тәҗрибәсе, җитәкче тәҗрибәсе җитмәвен сизде. Башына бер юньле фикер килми, прораб өстәлендә исә йөзләп гариза җыелды инде. Беренче вакытларда нигездә кое төзү өчен цемент сорадылар. Аксайда үз ишегалдында кое булдыру модага керде. Кое еракта булу бердән, күп вакытны ала, икенчедән, үз бакчаңны тоту шактый мәшәкатьлегә әйләнә. Сусыз кеше – ике кулсыз кебек. Цемент чыдамсыз агач бураны бетон боҗраларга алыштыру өчен кирәк иде. Бер коега өч йөз, дүрт йөз килограмм цемент кирәк иде. Сүз дә юк, бик теләсә дә, Мансур һәр кешегә шулкадәр цемент өләшә алмый иде.

Тора-бара бу мәсьәләне хәл итәргә мөмкинлек туды. Яшь чакта тәвәккәл адымга бармаган егет егетмени ул? Яшьлек ул авырлыкны кеше җилкәсенә салмыйча, үз өстенә алуы белән көчле. Ноябрь бәйрәменә Нагорныйга цемент, арматура һәм пиломатериаллар төягән вагон килеп туктады. Шуның уникесе Аксайга тәгаенләнгән иде. Октябрь буе көннәр матур торды, шуңа вакыт белән исәпләшмичә эшләделәр дә эшләделәр. Эшчеләргә бәйрәм рухы

тудыруга бөтен мөмкинлекләр дә бар. Алар мона лаек. Тик менә вагоннан материалларны вакытында ташытыр өчен шофер һәм йөкчеләрне ничек кызыксындырырга соң?

Мансур болай гына, кызыксынып станциягә шалтыратты һәм йөк төялгән вагонның бер сәгать тик торуы күпмегә төшүе белән кызыксынды. Ишеткән сан аны артына утыртты. Тизрәк нидер кылырга кирәк иде. Ул прораб бүлмәсенә кереп, эшчеләрнең ярдәм сорап язган гаризаларын аралап алды. Арифмометрын тартып китерде дә вагон бушатуның бәясен исәпләп чыгарды һәм иренмичә һәр кешегә наряд язды. Аннары наряд һәм гаризаларны алып, өйләр буенча китте. Иң беренче чиратта үзе ышанган кешеләргә — бригадирларга барып керде. Эшне кызуында сугып, яңалыгын житкерде: кем дә кем вагон бушатырга чыга — кое өчен цемент яки агач материаллары ала. Бер сәгать үттеме, юкмы – шактый кеше җыелып станциягә китте.

Станциянең йөк бушата торган ишегалдында Саша Вуккертны чакырып алып әйтте:

— Александр Вильгельмович, материаллар белән сак эш итсәгез иде. Читкә китә күрмәсеннәр. Безгә шуның кадәрле вагонның беренче кайтуы бит. Минем исәп-хисап буенча элеваторга ике йөзләп вагон цемент кирәк булачак, пиломатериаллар турында әйтмим дә. Алар әле, оһо-һо, күп кирәк булачак. Димәк, вагоннар килә торыр. Әгәр бүген урлашу башланса, эш ахыргача шулай дәвам итәчәк. Мине аңлыйсыздыр дип уйлыйм, биргән вәгъдәне ерып чыгу ансат булмас, әмма сүземдә торырмын.

Саша дәдәй аны бүлдерми тыңлады. Аннары, алман төгәллеге белән тезелешеп яткан тәмәкеле портсигарын чыгарды.

— Мансур, бу сүзләрең белән рәнҗетәсең. Хәер, бүген үз теләге белән килүчеләр арасында төрлесе бардыр. Әмма кемгә ышанырга, кемгә таянырга була, син баштан ук күз салып куй. Кабул итү, тезеп кую урыннарына мин улларымны калдырдым. Үз дусларына ышанасыңдыр дип уйлыйм. Өч йөз капчык цемент таратуга килгәндә, ышан: граммы да югалмас. Сез — безгә, без — дәүләткә. Әйдә, шулай хәл итик. Иң мөһиме: күр, эшчеләрнең күнеле канат какты — үз коелары булачак бит.

Көчле, каты кулы белән Мансурның җилкәсеннән җиңелчә кагып, бригадир вагоннар буйлап китте. Йөк бушатучылар аның лидерлыгын сүзсез кабул итте, чөнки беләләр: бригадирның сүзе эшеннән аерылмый.

Менә шулай итеп һич уйламаганда Мансур туган бистәсен аякка бастыру юлына керeште. Чыгу юлы исә бер генә — ныклы экономия. Хәер, алай дип әйтү Мансурның ниятенә туры килеп бетми. Дөресрәге, төзелештәге гадәти югалтулардан качарга, барысын да күз унында тотарга һәм бернинди югалтуларга юл куярга тиеш түгел ул, бары тик шулай гына якташларын тораклы итүдә ярдәм итә алачак. Мансур бер яктан чыгу юлы табылганга куанса, икенче яктан, әлеге юлның юридик яктан дөрес булмавын аңлап, борчыла иде. Әмма чигенергә соң инде.

Бәйрәмнәрдән соң, Мансур янына Саша дәдәй килде.

— Әйдә, Мансур, кичәге бригадирларны җый әле. Безгә булган материалларны ничек файдалану турында сөйләшергә кирәк. Кешеләр безне аңлар дип уйлыйм. Аксайда яхшылыкны аяк астына салып таптаганнарын ишеткән-күргәнем юк. Әгәр без үз кешеләребезне алама гадәтләрдән арындыра алабыз икән – димәк, без яхшы хуҗалар. – Кинәт аның җилдә ярылган ирен читләренә елмаю кунды. — Төзелеш халкының үзенне кем дип атауларын беләсеңме соң?

Мансур җилкәсен сикертте.

— Хуҗа диләр. Бу исә сина зур җаваплылык өсти, Мансур. Синнән яхшы

хужа чыгачак. Мин тормышымда күпләрне күрдем. Безгә, бригадирларга, шикләнмичә таяна аласың, сине кыен хәлдә калдырмабыз , — диде дә эре, ныклы адымнар белән китеп барды...

...Теплоходта, күрәсең, сиеста төгәлләнде — палубада берән-сәрән пассажирлар күренә башлады. Бүгенге әңгәмәләр Мансурның күнелен били алмады. Төзелеш турындагы уйларына комачау иткәне өчен уфтанды гына. Ничәмә-ничә еллардан соң, нигәдер, бүген тәүге тапкыр шул төзелешкә әйләнеп кайтасы, беренче көненнән ахыргача хәтер иләге аша үткәрәсе килде Мансурның. Туган нигезенә сәфәр кылудан шулай килеп чыктымы соң бу? Ул бит өен элеватордан, элеваторны өеннән башка күз алдына китерми иде. Әле дә Аксайны искә алганда, күз алдына икесе янәшә килеп баса иде.

Бәлки хәзер, тәҗрибә туплаган белгеч буларак, ул чорны җентекләп күзәтәсе килгәндер. Әллә алны-ялны белми эшләп, ниһаять беренче тапкыр алган ялы үткәннәренә тарттымы, Мансур моны тәгаен генә аңлата алмый иде. Тик шунысы хак: ул елларны искә төшерү җанына рәхәтлек бирде...

...Ул теге мәгълүмати бюллетеньдә күп нәрсәләрне әйтми калдырды. Болай да күләм ягыннан көч-хәл белән сыешканнар иде.

Ул чакта монолит бетон чоры, бар корылмалар да шуннан салынды. Катлаулы, авыр, күләмле эш иде бу: арматурчылар, балта осталары һәм бетончылар бригадаларының эше берләштерелде. Бары ярты елдан соң гына Саша дәдәй комплекслы бригада оештырды. Мансур бик теләсә дә, тагын шундый бер бригада оештыру эше барып чыкмады. Хәер, югары кимәлдәге башка бригадиры да, эшлим дип торган кешеләре дә табылмады. Саша дәдәйнен бригадасы эшләп тә күрсәтте! Төзелештәге һәркем шунда эләгер өчен җан атты.

Бюллетеньдә Мансур якташларының һәрбер такта кисәген, кадакны сакларга тырышуын әйтә ала идемени?.. Кулланылган опалубканы бригадирлар советында төзүчеләргә, беренче нәүбәттә хезмәт алдынгыларына, авыррак хәлләләргә бүлеп бирергә дигән карар чыгарылды. Төзелеш нормасы юка итеп кисеп цемент белән укмаштырылган, сүткәндә җимерелергә торган бу такталарны юкка гына кабат кулланудан тыймый. Бәлки, вак-төяк эшләрдә файдаланып булыр иде, тик кем аның белән матавыкланып маташсын, эшче куллар болай да житешми.

Мансур корылмада опалубканы ике тапкыр, кайчакларда хәтта өч тапкыр куелуы турында да әйтә алмый. Әмма бу сыйфатка зыян салмады. Әле өч тапкыр файдаланганнан соң да такталар учакка ташланмады, эш өчен тотылды. Материалларга сакчыл карау мәсьәләсендә эшчеләр көн дә ниндидер бер яңалык уйлап тапты, ник дигәндә, прорабның вәгъдәсе бар: һәр сакланган нәрсә — сезнеке. Баштарак бетон ярылмасын яки опалубканы җимерергә туры килмәсен өчен такталарга солярка, керосин йә бензин сиптерәләр иде. Сонрак Нагорныйдан зур, сигез йөз килограммнар чамасы булган бобина китерделәр. Аны опалубканың эчке ягына түши башладылар. Болай иткәч, бетонның өске өлеше тигез, шома була, штукатурсыз да хәлдән чыгып була. Такталарны кадак белән тишкәләмәс өчен төрледән төрле кыстыру, беркетү җайланмалары уйлап таптылар, бу үз чиратында җыю һәм сүтү эшләрен тизләтте, ә иң мөһиме, материалга зыян килмәде. Югары сыйфатлы бетон да опалубканы сакларга ярдәм итте. Дөрес, монысын эш барышында аңыштылар. Баксаң, сыйфатлы бетон тигез сылана, опалубкадан бөтен буе белән тигез каерыла икән, шуңа такталарны җимереп алуның хаҗәте калмады. Әнә шулай бер изге ният үз артыннан башкаларын ияртте.

Күп еллардан соң, Африкада, күрше төзелештә, инглизләрнең (ул аларда еш була иде) гадәти булмаган ысулларына игътибар итте. Инглизләр су белән

тәэмин итүнең бер генә каналын, бер компрессор станциясен, бер электр тапшыру линиясен генә файдалана икән. Алар Мансурга бинаның бетон фасадын күрсәтте. Бу — аның өчен яңалык иде. Мансур аларны игътибар белән тыңлады һәм эстетик карар кабул итүләре белән чын күңеленнән котлады. Ул шуны аңлады: алманнар да, инглизләр дә бетонның тигез өслек булып ятуын өнәп бетерми, шуңа опалубкага матур текстуралы древесина төшерәләр икән. Опалубка өчен такталарны да сирәк очрый торган аз әйләнешле түгәрәк пычкы белән кисәләр. Агач рәсеме саклансын өчен кулдан башкарырга тырышалар. Инглизләр аңа шундый гадәти булмаган фасад күрсәтте. Сүз дә юк, бик матур килеп чыга, әмма яхшы агачтан эшләнгән опалубканы кую, бердән, зәркәнче хезмәтен хәтерләтсә, икенчедән, ул шактый кыйммәт тора иде.

Мансурның болары турында мәгълүматы булганга, баштагы кызыксынуы кимеде.

Алар элеваторның административ-техник корпусын корганда, Красноярск краеннан егерме вагон такта килеп төште. Араларында авыр карагай күренгәләсә дә, күбесе бик матур текстуралы нарат такталар (кискәндә дә инглизләр махсус эшләгән агач кебек киселә) иде. Саша Вуккерт бинаның тышкы ягына әнә шул үзенчәлекле агачларны төшерергә киңәш итте. Иртәнге киңәшмәдә үзенең уй-нияте белән уртаклашты, сызымнарын күрсәтте. Фикерен ошатып, бертавыштан идеяне кабул иттеләр. Әлбәттә, мондый опалубканың тоташкан урында җөе җөйгә туры килергә тиеш булганга, аларга шактый тир түгәргә туры килде. Аны ике тапкыр файдалану турында исә сүз дә була алмый иде. Хәер, кулларыннан гөл тамган балта осталары аны ике тапкыр куллана алдылар. Такталар җитәр микән дип борчылдылар, шуңа анда-монда посып калмаганмы дип вагонннарны тагын бер кат инәсеннән-җебенә кадәр тикшереп чыктылар да, булганнарын чит күздән ераккарак яшереп куйдылар.

Александр Вильгельмович ни өчен бу алымны тәкъдим итте икән? Матур булсын дип борчылуымы, әллә элеватор Аксайда күзгә бәрелеп торсын дип тырыштымы? Кем белә, бәлки, киләчәктә элеваторда эшләргә теләгәндер? Атказанган төзүче буларак Саша дәдәйгә һәрхәлдә эш табылыр иде. Юктыр, башына тегенди-мондый уйлар кереп тә чыкмагандыр. Бу бер очраклылык кынадыр...

Аксайны төзелеш чире басты. Ишегалдында кое булдыргач, һәркем үзенчә кымшана башлады: кайсыдыр өй эчендә вак төзекләндерүгә тотынды, кемдер өен зурайтырга уйлады, кайберләре сарай яки мунчасын яңарта башлады, кыскасы, яхшы гына «төшә» башлаган хезмәт хакларына урын табылып торды. Аксай белән рәттән Нагорныйда да яңа мавыгу барлыкка килде.

Ун еллар элек, әле паровозлар йөргәндә, Нагорный станциясе тирәли Монблан тавын хәтерләткән шлак өеме пәйда булды. Күпләр Нагорныйның исемен шушы шлак тавыннан чыгып аңлата иде. Хәзер инде Оренбург юлында тепловозлар йөри, шуңа өем кирәксез ята бирде. Бервакыт Нагорныйдан берәү шлактан өй тышларга уйлаган. Моңарчы ике бистәдә дә йортлар сәманнән иде. Йорты шәп килеп чыкты моның! Җинел, җылы, артык көч куюны таләп итми, иң мөһиме — бушка. Тирә-якны тутырып яткан шлак тауларыннан җилләр исте: ике бистә халкы ярыша-ярыша ташыды. Тимер юлчылар бу «эпидемия»не күреп шатланып туя алмады. Шлак мәсьәләсе хәл ителсә дә цемент табу, ай-һай, бер дә җиңелләрдән түгел: акчага сатып алу мөмкинлеге юк дәрәҗәсендә иде. Әмма бригадирның башы шәп эшли: әлеге матур такталарны күргәч, проектта каралган штукатур эшеннән котылып, бетонны алдан ук сыйфатлы һәм матур итеп эшләргә

кирәклеген аңлатты. Алар бинаны тышладылар да сыек цемент белән сылап чыктылар. Бик матур фигуралы, обойны хәтерләткән штукатур килеп чыкты. Заказ бирүчеләр дә, дәүләт комиссиясе дә, Нагорныйдагы хезмәттәшләр дә аны махсус штукатурка дип кабул иттеләр. Мансур исә тырышлыклары өчен якташларына артып калган цементны өләште. Ләкин бу хакта ләм-мим, чөнки туган авылын халкына ярдәм иткәнсең икән дип тормаслар, житәкчелек башыңнан сыйпамас. Инглизләр шаккатып сөйләгән яңалыкны унбиш ел элек куллануы турында әйтеп тормады. Картада урын алмаган Аксаенны каян белсеннәр дә, сүзләренә ничек ышансыннар. Нигә исбат итеп вакыт әрәм итәргә дип Мансур тел тешләүне мәгъкуль күрде.

Гәҗитләрне су кебек эчкән бу көннәрдә ана пенсионерларның, яшьләрнең, үсмерләрнең ял вакыты турында язылган мәкаләләр күзенә күп чалынды. Шәһәр халкы белән рәттән, авылдагыларның проблемалары да күтәрелгән язмалар Мансурны гаҗәпкә калдырды. Хәзер һәр өйдә телевизор, радиоалгыч, магнитофон, күпсанлы китаплар, биш көнлек эш — тагын нәрсә кирәк? Төп игътибарны шәхси вакытка юнәлтү Мансурны сискәндереп җибәрде, ахыр чиктә болар уйлап чыгарылгандыр дип кабул итте. Аның өчен бу әйбер җыю чиреннән дә куркынычрак тоелды. Аяк тыпырдамыйча, авыз шапылдамый дигәндәй, әйбер җыяр өчен, һич югы, маңгай тиренне сыпырып эшләргә кирәк. Монда исә беравыздан шәхси ял (өстәвенә бушка әле) оештыруны таләп итәләр. Аксайда чакта ул буш вакытын ничек уздырды икән соң? Мансур анда төп-төгәл ике ел эшләде: август аенда төзелешне кабул итеп алган иде, август ахырында — иң кирәкле чакта, урып-җыю башланган вакытта элеваторны куллануга тапшырды.

Телевизор ул чакта юк булса да, Аксайга бу могҗиза турында имеш-мимешләр генә килеп житкән иде әле. Дөрес, китапка игътибар зур иде, яхшы китапның бушаганын китапханәдәге чират буенча бирәр ай көтәргә туры килде. Хәзер бөтенләй икенче заман: китапханәләрнең буш залларын күреп, күңел елый. Ә ул чакта... Ике көн саен яңа фильм күрсәттеләр, элеватор янәшәсендәге паркта шимбә һәм якшәмбедә биюләр! Оркестры шәп иде — чын эстраданыкы! Анда төзелеш эшчеләре уйнады. Житәкчеләре — Саша дәдәйнең кече улы трубачы Клайф иде. Вуккертлар гаиләсе гомумән музыкага гашыйк. Саша дәдәй үзе дә аккордеонда шәп уйный. Әлбәттә, малайлары уйнаган оркестрда ул күренмәде. Район беренчелегендә Аксайның «Төзүче» футбол командасы чыгыш ясады. Аның да төп составы әлеге дә баягы элеваторның яшь эшчеләреннән торды. Аларга күп дигәндә югары сыйныфның ике-өч укучысы өстәлсә өстәлгәндер. Оркестр җәмәгать башлангычы тәртибендә чыгыш ясый иде, футболны якшәмбедә генә ял исәбеннән уйнадылар. Мансур гәҗиттәге язмаларны укыгач, хәзергеләрнең яллары турында борчылучыларга билгеле мәкаль белән урысчалап: «Делу время — потехе час», — дип җавап биргәләде. Мәкаләләрдә исә киресенчә килеп чыга : «потехе время — делу час». Язмаларда авыр эштән соң кирәкме, ялның нинди турында сүз бара — бер сүз әйтелмәгән бит. Хискә бирелеп язылган мәкаләләр арасында таләпчәнлеге белән аерылып торганнары да очрый. Димәк, авторларга теләктәшлек белдерүчеләр дә шактый булырга охшаган. «Хезмәт, эш хакында да шулай борчылсагыз иде сез», — дип уфтанды Мансур...

...Нагорныйда тимер юл буйлап сул якта казакъларның Актүбә шәһәре җәйрәп ята. Уң якта — Оренбург шәһәренең төтене күтәрелә.

Мансур мәктәп укучысы булганда да, студент чагында да Оренбург шәһәрен барып күрә алмады. Мәскәүдән каникулга кайткан чакларда яныннан узып киткәне бар барын. Анысы да бик сирәк, ул чакларда студентлар җәйләрен Казакъстанда, чирәм җирләрдә уздыра иде. Сугышта

һәлак булган әтисе дә, әнисе дә тумышлары белән Оренбургтан. Мансур, Алма-Атага юллама алгач, тирә-яктагы шәһәрләрне барып күрермен дип ниятләгән иде.

Бер шимбәдә, ниһаять, Оренбургка килде. Бер генә төнгә дип үтенүенә карамастан, шәһәр кунакханәсендә буш урын табылмады. Җәй иде, төннәрен җылы, яшь инженер урын булмаудан фаҗига ясап тормады — парктагы урындыкка ятты да йоклады. Ни тырышса да, башка шәһәрләрне күрү хыялда гына калды, чөнки элеватор көннән-көн вакытны күбрәк ала иде.

Шактый татар әдипләренең ватаны, дөньяга Муса Җәлилне биргән Оренбургтан кайтып килгәндә, Мансур озакламый ул якларда бик эре газ чыгару урыны табылыр да, барына канәгать булып көн күреп яткан тыныч шәһәрнең тормышы танымаслык булып үзгәрер, гөрләп үскән индустрия гиганты кызыл кирпечле сәүдәгәр йортлары урнашкан тыныч кварталларны кабып йотар һәм Форштадт, Аренда, Татар Бистәләре дә мәңгелеккә юкка чыгар, дип башына да китермәде.

Әйе, юл уңае туры килгән йөк машинасында бистәгә кайтып барган Мансур шушындый үзгәрешләр булыр дип уйламады да. Аның уйлары Аксай кебек бистә-авылларга юллама белән җибәрелгән үзе кебек йөз меңләгән яшь инженер, табиб, укытучылар тирәсендә бөтерелә иде. Алар да мөгаен, үзе эшләячәк район үзәген, авылны картадан тапкач, якын-тирәдә шәһәр булуын күреп сөенгәндер. Нинди уй-ниятләр кордылар икән?! Якшәмбедә шәһәргә — музей-театрларга, күргәзмәләргә, шәһәр китапханәсенә ашкынган яшь белгечләр арасында иркенлеккә сусаганнары табылып, авылларда төпләнеп калганнары да булгандыр. Төпләнә алмасалар да гаҗәп түгел — эшләгән вакытлары өчен дә рәхмәт аларга. Яшь белгечләр турында уйлыйлар икән, аларның эше турында гына түгел, яллары турында да кайгыртсыннар. Шәһәр һавасы сулап үскән белгечләрнең күпчелегенә шау-шу, театр, музей, кино җитми. Аларның мәдәни үсештән читтә каласы килми...

Оренбургның йолдызлы күген күзәтеп йөк машинасында кайтып килгәндә, Мансурның уйлары шул тирәдә йөрде.

Аксайда кайчак кинодан соң алар паркка керәләр иде. Ул чакта бию мәйданчыгына өлкәннәр хуҗа. Үсмерләр мондый урыннан читтәрәк йөрүне хуп күрә, теләгән очракта да аларны анда кертмиләр. Ул чакта ярый белән ярамый дигән чик бар иде әле. Бию мәйданчыгының яртысыннан күбрәген төзелеш яшьләре тәшкил итә. Клайф үз житәкчесен күрүгә ул чакта модада саналган «Тынлык» тангосын уйный башлый. Гаҗәп, ләкин аның бу җырны ошатуын кайдан белгән ул? Нишләптер, бередә ул үзен иркен тота алмый, шуңадырмы, биергә теләсә дә тизрәк китү ягын карый.

Бию мәйданчыгыннан ул өенә түгел, һәрвакыттагыча туры үзенең төзелешенә таба атлый.

Инде өлкәнәеп килгән каравылчы казах — Нургали ага кайчан килсән дә үз урынында. Ул Мансурны елмаеп каршы ала, аның гадәтен белгәнгә күрә, төзелештәге прожектор утларын кабыза. Әлеге якты утлар даланың ерак почмакларында да күренгәндер, мөгаен. Мансур төзелеш өчен прожекторларны җәлләмәде. Утлар төнен дә төзелеш мәйданын уч төбендәге кебек өзлексез яктыртып торырга тиеш иде. Кайчакларда зур конструкцияләрне көн-төн тоташ бетонларга туры килә. Көндез түзеп булмаслык эссе һава торганда, бетончылар үзләре үк төнлә эшләүне сорады. Бары тик төннәрен генә дала жиле тын алырлык салкынча һава алып килде. Ул ашыкмый гына зур төзелешнең бер башыннан икенче башына атлады. Барысын да энәсеннән җебенә кадәр белә кебек, тик төннәрен уңышлы

һәм житешсез яклар көндезгегә караганда ачыграк күренә иде. Шунамы, кичләрен элеватор тирәли бер әйләнеп кайтмый түзә алмый иде...

...Төзелештәге беренче кышның декабре бик салкын, буранлы булды. Температура да җәйдәге кебек утыз градустан артык торды. Аерма бары аның минус тамгасында гына иде. Төзелеш туктап калды диярлек, бары яхшы җиһазланган, җылы арматур цехлары гына гадәти режимда эшләвен дәвам итте. Кыш көннәрендә хатын-кызларның хезмәт житештерүчәнлеге күзгә күренеп артты. Шунлыктан төзелеш алар әзерләгән материаллар белән алдагы бер-ике айга запас туплады. Башка эшләр туктап калды.

«Нәрсә эшләргә?». Бу сорау һәр киңәшмәдә күтәрелде. Көннәрдән бер көнне Мансур менә шундый тәкъдим ясады:

— Минемчә, котылу юлы бер генә — барыбызга да ялга чыгарга. Тик бер шарт белән — язын бар көчебезне куеп туктап торганны артыгы белән кире кайтарырга! Югыйсә, безнең чыгымнарны киметү мәсьәләсендәге барлык тырышуларыбыз юкка гына... Бетонның һәр кубометрын җылытып, измә катмасын өчен учаклар ягып, опалубканы гына түгел, бөтен агач материалын утынга әйләндерәчәкбез... Өстәвенә суык аркасында бетон сыйфатын югалтса конструкцияне гомумән җимерергә туры киләчәк. Бу очракта инде тонналаган цемент җилгә очачак. Иптәшләр, эшчеләр янына барыгыз да бу эш төзелеш мәнфәгатьләреннән генә түгел, һәрберсе турында уйлап эшләнгәнен, янып торган учак тирәли уч җылытып басып торудан мәгънә юклыгын төшендерегез. Яхшымы?!

Бригадирлар Мансурны бертавыштан хуплады. Алар исәп-хисапта яшь прорабтан һич калышмыйлар, үзара бу турында ым кагышканнар да иде, әмма Мансурның мондый тәвәккәл адымга баруына өметләнмәделәр.

Әлбәттә үзен хуҗа итеп сизмәсә, коллективына, бригадирларга ышанмаса, мондый адымга ул бара алмас иде! Өстәге җитәкчеләр аның әлеге адымын башбаштаклык дип атар иде. Мансурның үзенә булган ышанычы көннән-көн артты. Шундый ук элеватор төзелгән Нагорный белән чагыштырганда күпкә алдарак барулары да ышаныч өстәде. Аксайга килгән кебек аларга да уналты вагон кайткан, әмма бәйрәм көнендә биш көн бушатылмый тору сәбәпле, банк тимер юл хезмәте файдасына штраф салып, төзелештән шактый күләмдә акча күчерттергән. Шуңа эшчеләргә хезмәт хакын вакытында түли алмаганнар. Нагорныйдагы эшче көч, әлбәттә, тәҗрибәлерәк һәм сан ягыннан да күбрәк иде. Әлеге дә баягы, районнарга җибәрелгән белгечләрнең күпчелек өлеше үзәктә калуны хуп күрә. Аксайда белгечләргә кытлык бар, ә эшче кулларны исә үзләрендә үстерделәр. Һөнәр үзләштерсеннәр өчен, читтән килгән калайчы, верхолаз, наладчик, монтажникларга үз егетләрен беркетергә тырышалар иде. Читтән килүчеләр аркасында Нагорныйда фонд кечерәйгән, шуңа да эшчеләре хезмәт хакы белән мактана алмый иде.

Тапшырылыр вакыт якынлашканда, урып-җыю вакытына Аксайдагы элеваторның гына эшли алачагы ачыкланды. Җәй көне Көнбатыш Казакъстан корылмаларын тикшерергә чыккан Алма-Атадагы «Көнбатыш элеватор — тегермән төзелеше» тресты идарәчесе Нагорныйга килде. Нагорный төзелеше белән танышканнан соң, киңәшмә җыйды. Анда Мансур да катнашты. Дөрес, аны киңәшмә дип атау хата булыр, чөнки идарәче рәттән барысын да аягүрә бастырып сүкте. Сүкте генәме соң! Пыран-заран китерде. Чыгышын исә болай тәмамлады: «Җитәкчелек якында урнашкан элеватор шундый мескен хәлдә икән, Аксайдагысы турында авыз ачып торасы да юк».

Җитәкчелек идарәчегә сиздерми генә Мансурга күз кысты: эндәшмә, тик кенә утыр, парын чыгарып бетерсен, янәсе. Кемдер өстәл астыннан

үрелеп аягына басты. Ләкин Мансур түзмәде, сүз сорап Аксайдагы төзелеш турында кыскача гына бәян итте. Идарәче, әлбәттә, Мансурга ышанмады һәм кинәшмәдән соң ук алар бистәгә кузгалды. Корылманы игътибар белән карап чыкканнан соң, идарәче эш журналын актарды, актларны тикшерде, канәгать сыман тоелса да мактарга ашыкмады. Машинасына утырганда гына СМУ җитәкчесенә ике участоктагы күрсәткечләрне аерым алып барырга әмер бирде. Саубуллашканда Мансурга борылып:

— Сентябрьдә мин сезне Алма-Атада, трестта көтәм, — диде.

Ни өчен беренче төзелеше Мансурның күнеленнән китми соң? Бер уйлаганда, шаккатмалы төзелеш тә түгел, гадәти бер элеватор. Инженер буларак та йолдыз ачмады, монарчы билгеле юлдан барды. Аннан соң да Целиноградта шундый дистәләгән элеватор һәм бер комплекс төзеде бит. Мөгаен, моның сәбәбе башкададыр. Беренче төзелешкә баш-аягы белән чуму аның өчен аздан гына фаҗига белән тәмамланмады. Өйгә сукмакны тәмам онытты, ике элеваторның Аксайдагысы гына тапшырыла аласы билгеле булгач Мансурны ашыктыра башладылар. Нагорныйдагы эшчеләрнең бер өлешен аңа тапшыру тәкъдименнән Мансур шундук баш тартты: ул кулындагы саннар һәм графиклары белән җитәкчелеккә элеваторның вакытында, урып-җыюга кадәр тапшырылачагын исбат итте.

Элеватор зурайды — бистәдә яңа урамнар, йортлар барлыкка килде. Шлактан ясалган өйләрне бик тиз күтәрделәр. Халыкка төзелештәге тәҗрибә нык ярдәм итте. Түбә ябу һәм штукатурлау кебек эшләрне өмә белән башкардылар. Тырыш, эшче куллары күп булган хуҗалыкларның зур тәрәзәле, биек түбәле йортлары узган-барганнарга сәлам бирә. Авыл кешесе һәрнәрсәгә сакчыл карый, барысының да диярлек ишегалдында монарчы гомер иткән җир өйләре сүтелмичә чүнкәеп утыра. Шаккатмалы: кичәге белән бүгенге йортлар арасындагы аерма җир белән күк арасы иде!

Мансурның кәефен кырырлык сәбәп юк сыман: төзелешне тапшырырга күп дигәндә ай ярым вакыты калып бара, күнеле күтәренке, алда яңа төзелешләр көтә. Шундый көннәрнең берсендә аны милициягә чакырдылар. Эшчеләренең берсе өстеннән анонимка язылган икән. Янәсе, ул өенә буш кайтмый: ярты капчык булса да цемент алып кайта, велосипед багажнигына кирпеч төйи, йә булмаса кулланылган рубероид кыстыра, кесәләре тулы кадак. Бу хат әлеге хәлләрдән хәбәрдар кеше кулыннан белеп язылган иде. Әллә кем түгел, нигез күршеседер, мөгаен. Хәзер, әнә, каләм чарлавыннан канәгать калып, телевизор каршында утырадыр. Авылда гына түгел, шәһәрдә дә шундыйлар очрап тора: алар үзләре дә берни кыймылдатмый — башкаларга да яшәргә ирек бирми.

Милициягә ияреп әлеге эшченең өенә киттеләр. Яңа йортның нигезе инде әзер иде. Ишегалдында исә аноним хаттагыдан да күбрәк нәрсәләр табылды: әзер тәрәзәләр, ишекләр, тәрәзә аслары — хуҗа кышкы ял вакытында борыс опалубкадан барысын да тырышып әзерләп куйган иде. Әлбәттә, аның кулында бернинди түләү кәгазе дә, квитанцияләр дә юк. Тырышып эшләгән һәркемгә прораб материалны үзе бирә ди ул.

Аксай милициясендә күптән түгел курслар тәмамлап кайткан яшь лейтенант җитәкчелек итә иде. Ул, күп булса, Мансурдан бер-ике яшькә зурraктыр, җитмәсә фамилияләре дә бер үк, чөнки әтисе ягыннан ерак кардәш тиешле кеше икән.

Мансур, үзен гаепле санамаганга, кардәшенә дөресен сөйләде: материаллар табу зыянга чыкмый, беркемнән дә өстәмә акча алганы булмады, материалларны кемгә бирәсен бригадирлар советы хәл итә, табельне тутыручы хатын исә профсоюз җыелышының беркетмәләрен

төгәл алып бара, диде. Тыңлавын тыңлады, әмма җавабы Мансур көткәнчә яңгырамады:

— Бу әкиятеңне, Гатауллин, башкаларга сөйләрсең. Утсыз төтен чыкмый. — Ул үз сүзләреннән канәгать елмайды, — менә без сине шундый итеп селкетербез һәм акча колымы, юкмы икәнен белербез. Яхшы чакта хәзер үк әйт: акчаларыңны кайда саклыйсың? Тапканнар, кая борын тыкма, Гатауллин да Гатауллин диләр. Һе, хәйрияче, имеш... Бөтен Аксай аңа эшлимени. Нәрсә, Гатауллинград төзергә булдыңмы?

Мансур лейтенантның мыскыллы көлүен ишетмәмешкә сабышты. Ә тегесе исә акыл сатуын дәвам итте:

— Менә мине һәр чатта сөйләмиләр, әмма мин Аксайда дәүләт милке сагында торучы намуслы кеше булуымны исбат итәчәкмен...

Әңгәмә Мансур теләгәнчә барып чыкмады. Бу кешегә күңелеңне ачу — диварга борчак ату белән бер иде. Алар икесе ике телдә сөйләде, авылдашларына карата мөнәсәбәтләре буенча да, әйтерсең, елганың ике яры иделәр.

Әнисе Мансурны милициягә чакыруларын ишеткәч бик борчылды. Күз яшьләрен тыя алмыйча: «Их, улым, улым, кисәтмәдем түгел, кисәттем бит. Элеваторыңда нәрсәдер дөрес эшләнми синең. Төшке ашка дисеңме, кичкесенәме, тегесе дә, бусы да нәрсәдер күтәреп кайта».

Мансур анының сүзләренә көлеп кенә карады: «Ташулары бик яхшы, әни, ник дисәң, минем төзелеш мәйданы ялт итеп тора: ни бер кадак, ни цемент капчыгы таба алмыйсың. Әнә бит японнарда да төзелеш мәйданы чип-чиста дип сөйлиләр. Аякланадыр дип уйлыйм, аларга бит материалны көн дә китереп торалар. Без исә айга бер-ике, кайчакта ярты елга бер кабул итәбез. Миндә күрше Саша дәдәйләр ишегалдындагы кебек тәртип. Алар урламыйлар, әни, вакыты чыккан материалны рөхсәт белән алып кайталар. Нәрсә, әле файдаланып була торган тактаны учакка салыйммы? Җитәр, җир өйләрдән котылырга вакыт».

«Шулай икәнен беләм дә, улым, никтер шикләнәм», — дия иде әнисе. Улы белән сөйләшкәч, беразга тынычланып калгандай була, тик кемнәрдәдер нәүбәттәге төзелешне күрә дә кабат йөрәге сыкрарга тотына.

Шул кичтә үк, эшнең төбенә төшенергә һәм барысын җайларга теләп, ул туганнарына йөгерде. Әмма лейтенант кардәшен һәм элекке укытучысын тыңларга да теләмәде. Бары эшлекле кыяфәт, бугаздан чыккан тавыш белән әйтеп куйды:

— Закон каршында барыбыз да бертигез. Урлаганмы-юкмы икән, нәкъ менә шуны ачыкларга телибез.

Шуннан башланды! Аксай милициясенең штаты зур түгел һәм җитәкченең үз эшләре дә муеннан иде. Нәкъ шул көннәрдә вак хулиганлыкны җавапка тарту турында указ чыкты. Лейтенант баш-аягы белән шуларны эзләү мәшәкатенә чумды. Районда, беренчеләрдән булып, указны гамәлгә ашыру турында рапорт тапшырасы килде аның. Шул ук вакытта Мансурны да күз уңыннан җибәрмәде, тышына кызыл карандаш белән язылган папка өстәленең иң күренә торган җирендә ята иде. Мансурны көн саен диярлек чакырып, әле бер, әле икенче кәгазь алып килүен таләп итте. Мансур гына түгел, аның кул астында кемнәр эшли — бар да чакырылды. Кайбер йортларга ул шәхсән үзе барды. Мотоциклы белән җилле генә килеп туктый да, беркемгә сүз катмыйча, сарайларны карап йөри һәм төксе генә хөкемен чыгара: «Көтегез, чакырырмын».

Ничек туры килгәндер, нәкъ шул көннәрдә Мансурга Алма-Атадан, тресттан шалтыратып, лейтенант таләп иткән кәгазьләрне соратып ала башладылар. Мансурның эченә шом керде. Трестка төзелеш турында

чираттагы хисап кәгазьләре җибәргән саен, ул: «Милициядә мина «эш» ачулары турында әйтергәме-юкмы икән?» — дип уйланды. Ләкин һәрвакыт нидер тыеп калды. Кемгә әйтергә сон? Тресттагылардан ул беркемне белми, идарәче үзе шалтыратмады. «Мөгаен, беләләрдер, югыйсә, бу кадәр төгәллек белән мәгълүмат җыймаслар иде», — дип борчылды һәм үзен алдагы кыенлыкларга әзерләде.

Аксай буйлап «элеватор белән милиция кызыксына» дигән хәбәр таралды. Имештер, прорабны төрмә көтә икән, дип тә сөйләүчеләре дә табылган. Озак та үтмәде, кем үз хуҗалыгында төзелеш алып бара, шулар җәзага тартыла дигән сүз чыкты. Бер эшче, гариза язып, ашыга-ашыга төзелештән китте һәм яңа өен ниндидер акча капчыгына юк бәягә сатып, Фирганә ягына күченде. Авыл кешесе законга һәм хакимияткә хөрмәт белән карый, шуңа төзелеш эшләре тынып калды. Төзүчеләр өйләренә буш кулларын селкеп кайта башладылар. Төзелеш буйлап йөргәндә, Мансур күпләрнең аннан күз карашын яшергәнен сизде. Милициягә чакырылган эшчеләр битараф кыяфәт чыгарырга тырышты. Милициядә исә янадан-яңа аңлатма язулары өстәлде. Мансур аларга күз сирпеп, лейтенантның җавап бирергә килүчеләргә басым ясавын аңлады.

Мансурга бригадирлар терәк булды, алар аны ялгызын калдырмады. Тормыш тәҗрибәләреннән чыгып, элеваторның вакытында тапшырылуы хәлне үзгәртергә мөмкинлеген чамалап, алар төзелешкә ике куллап ябышты.

Милициягә һәм трестка яңадан-яңа кәгазьләр әзерләгәндә, Мансур төзелеш материалларының һәр графасында «кызыл» торуын күреп алды. Бу исә прораблар телендә экономия дигәнне аңлата иде. Берничә кат исәпләде, хата чыкмады. Әгәр ревизия килеп төшсә, моның өчен баштан сыйпамаячак. Ни өчен шулкадәр экономия дип сораячаклар, аңлатуны таләп итәчәкләр. Төзелештә чыгымнарның артыграк булуы хуплана.

Бригадирлар советын җыеп, Мансур чыгымнары киметелгән материаллар исемлеген укыды һәм аларны төзелештәгеләргә өләшә алачакларын әйтте.

Тынлык урнашты. Аны бер бригадир бүлде.

— Алмаячаклар. Халык куркуда...

— Алайса үзегез алыгыз. Әгәр дә ревизия килеп төшсә, бу «кызыл»ны мин ничек аңлатыйм. Ревизия озак көттермәс, минемчә.

Тагын тынлык хакимлекне үз кулына алды. Ниһаять, Вуккерт исемлекне тартып китерде дә тыныч кына әйтте:

— Ярар сон, берегезгә дә кирәкмәгәч, үземә алам. Улыма өй кузгатырбыз. Өйләнәм дигән сүзе дә бар. Онытканчы әйтим әле, элеваторны тапшыргач шимбә көнне барыгызны да туйга чакырам.

Өстәл тирәли утырышканнар уянып киткәндәй булды. Кайсыдыр ашыгып:

— Нәрсә син, Вильгельмович, һаман үзенә дә үзенә! Әйдә, иптәшләрчә сигезгә бүлик: җавабын да бергә бирербез.

Бу сүзләрдән соң Мансур җиңел сулап куйды...

— ...Синең идәнең дә тактадан, капкаң да яңа. Бу такталарны кайдан алдың, түләнгәнлеккә кәгазьләре бармы, аның урман базасыннан яки райпотребсоюздан законлы рәвештә сатып алынганлыгын исбатлаучылар кайда?— Бер Гатауллин икенче Гатауллиннан сорау алуын дәвам итте. Ул милиция кәнәфиендә хуҗаларча җәелеп утырган, чистартылган хром итеген күрсәтергә теләгәндәй тезен тезгә куйган, үз-үзеннән бик канәгать кыяфәттә иде.

— Мин бер ярым куб тактаны Нагорныйдан алдым димәдем бит...

— Менә-менә, ниһаять, хакыйкать калка башлады. Шулай дип язарбыз да. Акча колы син, үзеңне әллә кемгә куеп, шау-шу куптарырга теләдең. Өлгермәдең, вакытында сизеп алдык. Менә ревизия ясарбыз. Күпме үзләштергәнең ачыкланыр. Имештер, экономия ясаган. Юк, мине алдый алмассың: урлагансың син, урлагансың. Бу якты көн кебек ачык һәм мин төбенә төшмичә туктамаячакмын. Мә, укы, Әхмәтжанов исемле эшчең ни яза:

«Үткән елның җәендә, июль ае иде, төгәл көнен хәтерләмим, без Илек елгасына балыкка бардык. Шимбәдән якшәмбегә куна калдык. Элеватор складыннан брезент палатка алдык. Аның белән гадәттә яңгырлы көннәрдә цементны каплыйлар иде. Казах авылыннан бәрән сатып алдык, Нагорныйдагы базардан вино һәм капкаларга ризык юнәтеп, Жанатан колхозына киттек. Анда елга киң, тирән, балык та күп. Яр буе да матур, урманлы, төнгә калыр өчен аннан да уңайлы урынны күпме эзләсәң дә табып булмый. Бәрәнне суйдык, шашлык әзерләдек, шурпа пешердек. Җәен тоттык. Коендык, кызындык та, Аксайга якшәмбе кичен генә кайттык. Әлеге бәйрәмгә акчаны эретеп ябыштыручы Камалетдинов җыйды. Һәммәбез дә унбишәр сум бирдек. Безнең белән прораб Гатауллин да барды. Аннан акча алмадык. Камалетдинов, сорарга уңайсыз, диде...» Аңлатыгызчы, иптәш Гатауллин, ни өчен уңайсыз булды икән аларга?

— Иптәш Гатауллин, анысын инде үзегез сорагыз...

— Сорармын, барысын да сорармын. Ләкин миңа сезнең җавабыгызны ишетү кызык. Менә мине пикникка да чакырмыйлар, минем хөрмәткә бәрән дә чалмыйлар, Нагорныйга да ризык артыннан чапмыйм... Ни өчен сездән акча сорау уңайсыз булды икән? Сөйкемле йөзегез өчен бушка сыйладылар микәнни?

— Белмим. Үзләреннән сорагыз. Дөресе болай: җомга акча бирделәр. Барысы да шактый акча алды. Яшьләр шул вакыйганы билгеләп үтәргә булды, елга бер тапкыр булса да елгага барырга булдылар. Китәр алдыннан гына мине дә чакырырга уйлаганнар. Хәтеремдә: алар миңа юл уңае керделәр. Чакырдылар, нәрсә мин каршы килергә тиеш идеммени?

— Ачыклармын, ачыклармын...

Алар һәр очрашуда шундыйрак әңгәмә кордылар. «Гатауллин эше» көннән-көн кабара барды. Әнисенең идән такталарына каршы булуы келт итеп исенә төште Мансурның. Янәсе, җир идәндә дә бик әйбәт яшиләр иде әле. Әнисе кайгы киләсен алдан ук сизгән икән. Такталар ике кеп-кечкенә бүлмәгә күп булса унбиш метр җыеладыр. Әле дә ярый, йорт төзи башламады. Әнисе баш-аягы белән каршы төште. Хәер, үзенең дә вакыты тимәде. Рәхмәтле бригадирлар ничәмә-ничә мәртәбә сиздерде: участок алыгыз, өмә ясарбыз да бер-ике якшәмбедән яңа өйгә күчәрсез, диделәр. Ул бу адымга бармады, күңеле белән җитәкче кешегә килешмәгәнне аңлады.

«Идән белән кечкенә капка өчен дә никадәр сүз, яңа өйгә кергән булсам, аяк астына салып таптарлар иде», — дип уйлады Мансур.

Элеваторны тапшырыр көннәр җиткәндә, төзелеш мәйданында эш кимегәннән-кимеде. Арматур цехлары туктады, андагылар вак-төяк эш башкаручыларга ярдәмгә кушылды, элеватор бинасын тәртипкә китерде, тәрәзә, идән юды... Һәркөнне диярлек бер, әле икенче бригада бушады. Сугыш эченнән чыккан солдатлар кебек, эшсез утырырга күнекмәгәнгә, алар элеваторны камап алган койманы буяды, икенчеләре территориядәге ял урыннарын матурлады, клумбалар ясады, проектта каралмаган эшләр башкарды. Шулай итеп элеватор тирәсе матурлыкка күмелде. Мансур эшчеләрнең йөзендә шатлык белән бергә сагыш үрелгәнен тойды. Барысы да үзләренең зур эш башкарганын тоя, белә, әмма икенче яктан, эшләнгән

эшкә түләү кимеде. Яшьләрнең исә юк-барга исе китми: шушы ике елда алар мотоциклларга утырды. Күбесе Нагорныйга күчәргә карар кылган. Бер бригада оешкан да инде. Аның белән Клайф Вуккерт җитәкчелек итә. Ул да, әтисе кебек, комплекслы бригада төзергә карар кылган.

Элеваторны тапшырырга ун көн кала, алдан искәртмичә генә, Нагорный райкомы секретаре кагылды. Карап чыкканнан соң ул бик канәгать калды һәм киткән чакта ачылыш тантанасын купшы итеп уздырачаклары хакында сиздерде. Элеваторны җибәрергә өч көн калгач, көтмәгәндә, Алма-Атадан трест идарәчесе килеп төште. Ул Нагорныйга сугылып тормыйча туры Аксайга килгән. Вакытны юкка исраф итмичә, комплекс белән танышып чыкты, элеваторны җибәреп карадылар — ул эшли иде.

— Дустым, шәп эш башкаргансың! Молодец! — Идарәче бөтен кеше алдында Мансурны кочаклап үпте.

Мансур кисәк кенә сорап куйды:

— Сез һәр элеваторны шәхсән кабул итәсезме?

Кәефе күтәрелгән идарәче башын артка ташлап рәхәтләнеп көлде.

— Юк, әлбәттә. Ләкин бу элеватор үзенчәлекле. Беренчедән, ул сезнең беренче төзелешегез... икенчедән, серне ачыйм инде: әлеге төзелеш — рекордлы төзелеш. Сез вакыт, экономияләү, сыйфаты ягыннан да гомуми союз рекорды куйдыгыз. Үзегез сизмәдегезме? Юкка гынамыни сездән хисап арты хисап таләп иттек. Дөресен әйтим, әгәр үзем килеп күрмәсәм, андагы саннарга гына ышанмас идем. Алма-Атага баргач, сезгә бу хакта сөйләргә туры киләчәк. Трест халкы һәрнәрсәгә шик белән караучан, саннарда мәгълүматыгыз төгәл булсын. Сорау арты сорау яудырырлар. Бу — иң мөһиме түгел әле... Безнең трест алты ел рәттән Казакъстанда тегермән, икмәк саклау биналары төзи. Бу унайдан да уңышларыбыз юк түгел. Менә быелгы урып-җыю алдыннан республика хөкүмәте иң яхшы төзүчеләрне бүләкләргә карар кылды. Бүләкләр без теләгәнчә үк күп түгел, әмма... мондый элеваторны, үз вакытында һаман тапшырып тормыйлар, килешәсездер. Кәчтүмегезгә һич икеләнмичә тишек тишә торыгыз, Мансур. Кая, алдан ук котлап куйыйм әле...

Мансурның кинәт агарып китүен күреп, идарәче куркып калды:

— Хәлегез начарландымы әллә?

— Шәяхмәт Корбанович, хәлем чыннан да бик начар. — Тамагына төер тыгылудан Мансур аздан гына үксеп җибәрмәде.

— Анламыйм, мондый сүзләрдән соң кешегә канатлар үсеп, хыял күгендә йөзәргә тиеш, минемчә. Нәрсә булды, Мансур, дөресен әйт?

— Минем бик кайгылы көннәрем әле, Шәяхмәт Корбанович, — диде Мансур, ниһаять батырлыгын җыеп. — Милиция мина эш ачты...

— Нинди эш? — Шәяхмәт Корбан улы гаҗәпкә калды. — Әйдәле, бүлмәнә кереп сөйләшик әле. Тик син башта тынычлан, йәме. Дулкынланма. Үлемкитем булмагандыр бит?

Прораб бүлмәсендә Мансур идарәчегә ничек бар шулай дөреслекне ачып бирде. Шәяхмәт Корбан улы тынлап бетерүгә, җилкәсеннән үз итеп какты:

— Борчылма, ябарбыз...

Ул шундук Нагорныйның райком секретарена шалтыратты һәм үзен кабул итүен сорады. Аннан рөхсәт алгач, хәйләкәр елмаеп, Мансурга борылды:

— Башыңны имә, егет! Барысы да яхшы булыр. Мондый эшләр өчен бездә төрмәгә утыртмыйлар. Илдә иң арзанлы элеватор төзе, шул ук вакытта кешеләренне дә кайгырт, яшь булсан да башын житкән бит, ә... Юк, сине орденга тәкъдим итүебез чыннан да дөрес булган...

Аксайга ул икенче көнне дә килде. Мансур еректан ук аның кулындагы таныш папканы күреп алды.

— Мә, тот, егет, истәлеккә сакла. Анда синең өчен кызыклы гына кәгазьләр бар. Түзмәдем, актарып чыктым.

— Яла якканнар өчәү генә икән, — диде Мансур. Ул әле дә эшнең шундый юнәлеш алуына ышанып житми иде. Һәм сагышлы тавыш белән өстәде: — Шулай да безнең эшчеләр — бик яхшы кешеләр...

Шәяхмәт Корбанович, аны үз улыдай якын күреп, жилкәсеннән кочты. Аннары урыс белән казах сүзләрен кушып, болай диде:

— Юкка сагышланма. Син башлы инженер... синең эшең — төзү һәм зур нәрсәләр төзү. Бүген кардәшең лейтенант Гатауллин белән күрештем. Башка прораблар кебек урлашсаң, сатсаң, аңлашылыр иде дә... ә болай... дөресен әйткәндә хаклы булуыңа инандыру бу очракта кыен эш. Ә кардәшең кебекләр, ни кызганыч, аз түгел. Шуңа күрә, егетем, мыегыңа яхшылап чорна, киләчәктә эшнең ни белән бетәсен алдан чамала...

...Идарәче киткәннән соң, Мансур уйларына батып шактый озак утырды. Кулындагы папканы нишләтергә белмичә бер кулыннан икенчесенә күчерде. Тәрәзәгә күз салды, төзелеш калдыкларын ягалар икән. Ул, икеләнеп тормастан, учакка таба атлады. Папкасын тоткан килеш, бермәл уйланып торды. Аннан аңлатма язуларын, башка кәгазьләрне — һәммәсен учакка ташлады. Учак шундук кәгазьне ялмап алды. Ак һәм кара сүзләр дөрләп янды. Аның: «Мин азат! Мин ирекле!» — дип кычкырасы килде. Ләкин көче дә, теләге дә калмаган иде инде...

Митингка Аксайның аяктагы бар кешесе дә килгән иде. Төзүчеләргә бик күп жылы сүзләр әйтелде, күкрәкләренә орден һәм медальләр тагылды. Аннан соң вакыйга уңаеннан оештырылган мәжлескә — Нагорныйга юл тоттылар. Ни өчен Аксайда уздырмаулары билгеле — әлегә андый урыны юк. Мәжлескә бүләкләнүчеләрнең һәммәсе дә чакырулы иде. Барысы да бәхетле, сөенечләре йөзләренә чыккан. Берсенең дә башына инде яратып өлгергән яшь прорабларыннан аерылабыз дигән уй килмәде. Мансур да кабат күрешкәнче егерме ел үтәр дип башына да китермәде...

Мәжлеснең нәкъ гөрләгән чагы булса да шат, энергиясе ташып торган Шәяхмәт Корбан улы Мансур белән бер-ике авыз сүз алышырга вакыт тапты. Аның эше тыгыз, аңа тамадалыкны тапшырганнар иде.

— Син канәгатьме? — дип сорады идарәче.

— Рәхмәт, — дип жаваплады Мансур.

— Бу очракта рәхмәтне мин әйтергә тиешмендер.... Гадәти сыман тоелган эшкә яңача карарга өйрәттең. Күңел биреп эшләгәндә, әллә никадәр мөмкинлекләр ачылуын аңлатып бирдең. Синең башбаштаклыгың да үзенә күрә бер ачыш. Дөресен әйткәндә, зур төзелешләр авыл тормышын да гөрләтеп жибәрергә тиеш. Арада иң тырышып эшләгәннәрне арзан бәяле материаллар белән бүләкләү — бу саваплы эш. Мәсьәләнең социаль ягына басым ясап та тормыйм. Бу хакта әле без синең белән бер генә сүз кузгатмабыз... Ун көнләп ял ит тә Алма-Атага кил. Аннан соң бергәләп, Тургай даласына юл тотарбыз. Андагы элеваторларны, инде ничә ел, сафка бастыра алмый интегәләр, кабул итәрсең дә — төзеп тә бетерерсең...

Казах өстәленең төп ризыгы — бишбармак китерделәр. Табындагыларның игътибары бәрән башына юнәлде. Йола буенча бу кунакларга хөрмәт күрсәтүне аңлата иде. Аны аерым савытта, бизәп китерделәр. Шәяхмәт Корбан улы бу ритуалның бөтен нечкәлеген белүче кеше буларак, кунакларга итне кисәкләп бүлеп, тарата башлады. Ул һәрбер кешегә мактау сүзе тапты. Мансур исә беркемгә сиздермичә әкрен генә шау-шулы өстәл янынннан чыгып китте...

Барысы: кайгысы да, шатлыгы да бергә уч төбе хәтле йөрәккә кереп укмашты шул. Мансур үзенең соңгы көннәрдә нык арганын сизде. Хәзер

анын уенда бер генә теләк: тезмәгә менеп хуш исле печән арасына чуму һәм туйганчы йоклау.

Улының орден алуына әнисе бик сөенде. Ул елларда Аксайда мондый югары бүләккә лаеклар юк иде әле. Орденнан бигрәк милициядә улының эшен япканнарына куанды ана. Мансур белән тиздән азгамы, озаккамы аерыласы турындагы уй да арткарак чигенде. Улы бу хакта хәбәр иткәч тә артыгын кайгырмады. Әле куанды да бугай. Ни генә дисәң дә милиция белән бәйле вакыйга әнисен тәмам кешелектән чыгарган иде шул. Имеш-мимеш, гайбәтләрдән дә начар нәрсә юк. Мәктәптә кайбер усал телле укытучылар читләтеп кенә, «утсыз төтен булмый» дип төрттергәли башлаганнар иде инде. Урамга чыксаң да, кайгырган кыяфәт белән хәл белешеп йөргән талкучылар артты. Кечкенәдән эш белән тәрбияләп үстергән бердәнбер улының авыл тарихына ямьсез булып кереп калуын, һай, теләмәде әнисе.

Мансур әнисенә мәҗлес турында сөйләгән арада урамда карангы төште. Парк ягыннан музыка тавышы ишетелде. Бүген Аксай бәйрәм итә иде. Клайф Вуккерт оркестрыннан бер-бер артлы күңелне күтәрә торган җинелчә көйләр агылды. Зур бәйрәм икәнен искәртеп, һәр өйдә утлар балкыды. Бистәдәге күпчелек элеватор белән бәйләнгән иде. Орден һәм медальләрдән тыш, бүген төзүчеләрнең шактыена грамота һәм премияләр тапшырылды — читтә калучылар юк иде диярлек.

Мансур ашыкмый гына яңа йортлар тезелгән урам буйлап атлады. Тәрәзәләреннән якты балкыган һәр өйнең хуҗасы аңа таныш.

Бистәнең бер очыннан икенчесенә барып җиткәч, ул үзе дә сизмәстән, элеватор ягына борылды. Ишек төбендә әлеге дә баягы Нургали абый сакта тора иде. Хәзер Мансур монда хуҗа булмаса да каравылчы карт аны эчкә уздырды, гадәтенчә, прожектор утларын кабызды. Прожекторларны сүтеп алмаганнар, элеватор төнлә эшләгәндә файдаланачаклар икән.

Төнге ут яктысында баганалары җиргә яткан, мәгърур басып торган элеватор, Мансурга бала чагында карап, язмышын үзгәрткән фильмдагы әкияти сарай кебек тоелды.

«Чү, хыялым тормышка ашты түгелме?» — Көтмәгәндә килгән уйдан Мансур сискәнеп китте һәм тизрәк китәргә ашыкты. Кинәт прожектор утлары сүнде. Ул артына борылып карады — күзгә төртсәң берни күренмәслек карангыда элеватор да, сарай да шәйләнмәде...

Шәһәр һәм авылларның язмышы да адәмнеке кебек — уңыш белән уңышсызлык чиратлашып бара. Кайберләре ныклы адымнар белән өскә үрли, икенчеләре шундый ук тизлек белән аска тәгәри. Кайчандыр гөрләп торган шәһәрләр бүген шау-шусыз, тыныч кына гомер сөрә. Алар инде макталуга, танылуга өмет өзгән. Моңа кадәр билгесез булганнары исә киресенчә, алмаз, күмер яки газ үзәгенә әйләнә. Буш урында шәһәр калкып чыга да тирә-яктагы йөзләрчә еллык тарихы булган шәһәрләрне бәреп ега.

Зур юлдан читтә урнашкан Аксай да бер арада гына яңгырап алды. Зур борылышлар вәгъдә иткән элеватор исә бистәдә бердәнбер зур предприятие булып калды. Шунамы, төзелеш белән бәйле еллар Мансурның авылдашлары күңелендә озак сакланды.... Яңа буын ул чактагы вакыйгаларны дивардагы истәлек такталарыннан, рамкалар эчендәге грамоталардан, әти-әниләренең бәйрәмнәрдә таккан орден-медальләреннән генә күреп белде.

Төзелештән соң ике ел үтте микән, лейтенант Гатауллинны хезмәтендә күтәрделәр, ул кайсыдыр бер шәһәрдә эреп югалды. Ул киткәч, авылның иң ачы телләләре дә «прораб Гатауллин эше» турында ялгышып та тел ачмады. Киресенчә, үзләре дә сизмәстән, элеваторны аның исеме белән бәйләп карый башладылар. Малайлар елгадан су коенып кайтканда икмәк саклау

бинасының баганаларын күрүгә: «Гатауллин элеваторы күренә», — дип кычкырды. Хуҗабикәләр үзара сөйләшкәндә: «Гатауллин элеваторындагы кибеткә барам», — диеште. Районда да бу элеватор хакында Гатауллин белән бәйләп сөйләргә күнектеләр. Ни өчен Гатауллин элеваторы әле? дигән сорау берәүнең дә башына килмәде. Халык шулай дигән икән, димәк Гатуллинныкы...

Дөрес, Аксайда тагын бер шундый бина бар иде. Анысы да якташларының исемен йөртте. Ләкин аның даны бистәдән читкә чыга алмады. Ниндидер бер кибетчекне зур элеватор белән чагыштырып буламы соң? Бу кибеттә, картлар әйтүе буенча, кырык елдан артык Рәшит абый Мәрдәнов эшләгән. Шул вакыт эчендә ул кырык мәртәбә дә ябылмаган, ял көннәрендә дә, бәйрәмнәрдә дә халыкка хезмәт күрсәткән. Рәшит абый кибеттә яши иде, дип тә сөйлиләр. Картлар хәтеренә уелып калганы шул: кибеттән бик авыр чакта бурычка алып торып булган. Ишле гаилә башлыгы булган Рәшит абый үзе дә, күрәсең, балда-майда яшәмәгәндер.

Аксай халкын үзенә суырып алган тагын бер төзелеш турында искә төшереп үтмәсәк хакыйкатькә хилафлык китерербез. Монысы Мансурга кагылмый.

Җиде елдан соң Нагорныйдагы элеватор сафтан чыкты. Мансурныкы районда берләнбер элеватор булып калды. Беренче көздә үк Нагорный белән Аксай арасындагы егерме чакрымлык юлны яхшырту мәсьәләсе килеп туды. Менә бит, урыслар әйтмешли, бәхетсезлек булмаса, бәхетләләр булмас иде. Икмәк белән шаярмыйлар: юл мәсьәләсенә тотынуны бер атна эчендә хәл иттеләр. Аксайда тиз арада юл-төзелеш идарәсе оештырылды. Кешеләр тагын бер тапкыр бердәм, күмәк рәвештә төзелешкә тотынды. Бистәдә кабат чүкеч тавышлары яңгырады, яна түбәләр ялтырады. Бу вакыт эчендә төрле якларда эшләп йөргән яшьләр ике елга авылда тотканланды. Бу ике ел эчендә эшчеләр Мансур исемен бик еш телгә алды. Шул рәвешчә җитәкчелеккә карашларын аңлатырга теләде. Алар беренче төзелешне бик яхшы хәтерли иде. «Мансур бу юлны бер елда салыр иде» яки «Гатауллин вакытында материалны болай сакламыйлар иде», — диеште алар. Халык аны гел яхшы сүз белән искә алганга ачулары кабарган прораблар: «Шулайдыр, бер Гатауллин гына укалы булгандыр, бу — хыял җимеше, фольклор, Робин Гуд турындагы сафсата», — дип сүгенделәр...

Пенсиядәге әнисе озын-озын хатларында элеватор хакында, бистәне район үзәге белән тоташтырачак юл төзелеше турында, инде берәм-берәм бакыйлыкка күчә барган аның кул астында эшләгән карт гвардия турында язып, хәбәр итеп торды...

...Афинаның һава порты булган Пирей силуэты күренүгә, Мансур грек ярларында озын-озак еллардан соң әтисе йортына кайтарачак юлны күргәндәй булды...

Өе, яшьлеге турындагы уйлар кәефен күтәреп җибәрде. Монда, теплоход палубасында, ул гомерендә беренче тапкыр иркенләп Аксайдагы төзелеше, тыгыз эш графигы белән үткән көннәре турында уйланырга җай чыгуына куанды. Нагорныйдагы мәҗлестә иреннә бер тамчы аракы тидермәве исенә төште... Ә нигә дип бүген кызлар белән минем беренче төзелешемнең юбилеен билгеләп узмаска ди әле? Күптән түгел элеваторның аякка басуына егерме ел булды. Әнинең хатларына ышансаң, ул әле тагын егерме ел эшләячәк...

Фикере үзенә ошады һәм ул ресторанга өстәл алып куярга китте.

Бу кичтә Мансурның кәефе бик күтәренке иде. Кызлар җитди, хәтта әйтергә кирәк, аз сүзле йомыкый күршеләренең шулай тиз үзгәрүен нигә дә юрарга белмәде. Казакъстандагы ниндидер элеваторның егерме еллыгын

билгеләп үтүне алар бер сәбәп кенә итеп кабул итте, уенга санады, шулай да алар бик теләп бу датаны билгеләп үтәргә риза булды. Кәеф ул йогышлы чир кебек: синеке күтәренке булса, башкаларга да күчә, аларның өстәле ул кичне шау-гөр килеп торды. Мансур аларга үзенең беренче төзелеше турында озаклап сөйләде, эш барышында килеп чыккан күңелле вакыйгалар белән рәттән күңелсезләрен дә телгә алды, беренче карашка әчкерсез тоелган авыл кешесенең хәйләкәрлеге, зирәклеге турында бәян итте.

Кызлар һәр вакыйганы күңеленнән үткәреп, күзеннән очкыннар чәчрәгән Мансурның кәеф күтәренкелеге кайдадыр дала уртасындагы элеваторга бәйледер дип ахыргача ышанмады. Алар фикеренчә, егерме еллык юбилейны ул кызлар белән күңел ачарга сәбәп булсынга дип уйлап чыгарган. Әчтән генә икесе дә болайрак фикер йөртте: «Аның беребезгә күзе төшкән булырга тиеш. Дингез сәяхәте тәмамланып килә, Одессада аларның юллары мөгаен мәңгегә аерылыр. Причалда аны көтеп торучы юктыр, менә шуңа ул вакытны бушка уздырмаска тели».

Мансурга берсеннән-берсе чибәр, акыллы туташлар белән аралашу бик рәхәт иде. Ул кызларның авызыннан чыккан ватан турындагы һәр сүзне, һәр җөмләне күңеленә сеңдереп барды. Алар исә хатын-кызларга хас күзәтүчәнлекне юморга төреп һәр вакыйганы үзләренчә шәрехли бирделәр. Мансур хатын-кызның фикер йөртешенә, мантыйгына исе китеп утырды.

«Безнең гүзәл затларыбыз бу елларда зур үзгәреш кичергән икән. Холык-фигыльләре ирләрне хәтерләтә. Үтә мөстәкыйль тоталар үзләрен», — дип уйлады ул. Моңа сөенергәме, әллә борчылыргамы — белмәссең. Ләкин аларның балкып торган чибәр йөзләренә күзе төшүгә, әле генә башына килгән җитди уйлары таралды да китте.

Аларның өстәле иң кырыйда ук иде. Кызлар ара-тирә дивардагы көзгегә күз ташлап күрше өстәлдәге ирләрнең карашын тоеп, матур итеп күпертелгән чәчләрен нәфис куллары белән төзәткәләп торалар.

Мансур чибәр туташлар өчен бәйрәм оештырып, аларның күңелләрен күтәрүдән канәгать калды.

Ресторанга чакыргач, кызларның берсе шаяртып:

— Шундый мөһим юбилей бары тик чит ил ресторанында гына үткәрелергә тиеш, башкасына без риза түгел, — дип әйтеп куйган иде әле.

Теплоходта Аурупа буйлап сәяхәткә чыгучылар арасында чит ил кешеләре дә байтак. Шунадыр, өстәге палубада чит ил акчасы әйләнештә булган ресторан да хезмәт күрсәтә.

Мансур теге кызның шаяртып әйткән сүзләрен чынга алып, шул ресторанга дәште.

Институтны хәйраннан тәмамлап, шактый эш һәм тормыш тәҗрибәсе туплаган булсалар да, кызлар бу тәкъдимгә яшьләр кафесына беренче тапкыр эләккән мәктәп укучысы сыман шатланышып, кулларын чәбәкләделәр.

Алар Мансур белән чиратлашып та, өчәүләшеп тә биеделәр. Егет исә һәрберсе белән аерым-аерым биергә тырышты, чөнки аңа шулай рәхәт иде. Ул ике туташның да үзенә битараф булмавын һәм шул сәбәпле икесе арасында күзгә күренмәс көндәшлекнең баш күтәрә башлавын сизеп алды, шуңа игътибарын тигез бүләргә тырышты. Мондый кызыксыну катыш соклану кебек карашлар күптән онытылган, көтелмәгән илтифат аны дулкынлануга дучар итте. Ләкин Мансурга артыгы кирәкми, талгын көйгә кызларның нечкә биленә кулын салып биесә, шул җиткән. Ул өенә кайта, уйлары туган нигезе тирәсендә әйләнсә, теплоходта мәхәббәт куерту аның ниятенә керми иде. Хезмәтен тәмамлап кайтып килгән солдат хәлендә тоя ул үзен, алда ниләр көтә, нәрсәдән башлар — берсе дә анык түгел. Теплоходка

утырып юлга чыгуы — шул билгесезлеккә беренче адым ясавыдыр, мөгаен. Очраклы кызлар белән вакытлы мажаралар исә ана азгынлык, пычрак бер гамәл сыман тоелды. Үзен өенә кайтып барган солдат белән чагыштыру күнеленә хуш килде. Дөрес, ул яшь солдаттан өстенрәк — аның инде бай тормыш тәҗрибәсе бар. Шушы тәҗрибәсе аңа һичшиксез ярдәм итәргә тиеш.

«Ретро» стилендәге кәчтүмнәр кигән оркестр уенчылары танго арты танго уйнады. Ауропага кабаттан танго модасы әйләнеп кайтты. Мансур якташы Клайф Вуккерт оркестрын исенә төшерде. Кызык. Кайда икән ул бүген, ни-нәрсә белән шөгыльләнә икән? Төнге рестораннарда уйнап йөри микән, әллә чын төзүче булып киткәнме? Аның уйларын бүлеп кызлар тост тәкъдим итте...

— Моннан соң мин бер генә элеваторның да юбилеен калдырмаска тырышачакмын, — диде кызларның олырагы, Наталья исемлесе. — Кара, нинди күнелле чара икән бит — монарчы белми идем.

Бар утларын балкытып, көчле музыка яңгырап торган теплоход, җиңелчә генә уйнаклаган дулкыннарны ера-ера, алга барды. Кемнәр өчендер кадерле Ватаны белән ара якынайса, икенче берәүләре күрешү сәгатьләрен саный, кайсыларыдыр бәйрәмнең озаккарак сузылуын теләде. Ксана аның уйларын сизгәндәй сорап куйды:

— Безнең теплоход соңгы көннәрдә тизрәк хәрәкәтләнгән кебек тоелмыймы сезгә? Әйтерсең лә ул ватан ярларын сизә.

— Сезнең өйгә кайтасы килмиме әллә? — Мансур гаҗәпләнеп аңа бакты.

— Әйе дә, юк та. Миңа менә бүген, шушы корабта, музыка уйнаган залда рәхәт. — Ул аның кулын учына алды. — Әйдә, биик әле, Мансур.

Гатауллинның башыннан яшен тизлегедәй уй йөгереп үтте: «Аның чираты түгел бит!».

Ресторан әкренләп бушый бара: кемнәрдер йоклар алдыннан диңгез һавасы суларга чыкты, кәеф-сафа корырга яратучылар төнге барга күчте. Иң соңгылар булып Мансур белән ике чибәр туташ кузгалды. Кызларны аскы палубадагы каюталарына озаткач, ул үзенә күтәрелде.

Күңеле кор иде аның, хатирәләр кабат Аксайга алып кайтты, үзе төзегән элеватор, бистәнең яңа, биек түбәле йортлары белән горурланды. Шушы яхшы кәеф белән ул йокыга талды. Авылы, йолдызлар белән чуарланган биек күк йөзе, парк, Клайф Вуккерт төшенә керде. Иртәнге аштан соң ул палубага күтәрелде, туташлар белән бергә, «Лев Толстой»ның тизлеген киметеп, Дарданелла ярына якынлашканын күзәтте. Дарданелла бугазы Босфор белән чагыштырганда кинрәк, урыны-урыны белән алты-җиде чакрымга җитә. Әмма бик еш кына сайлыклар очрый. Шуңа да «Лев Толстой» сак кына, талгын җилдә яшелгә алтын хилал ай төшкән әләмен җилфердәткән төрек корабы артыннан хәрәкәт итә. Теплоход лоцмансыз иде. Дөрес, Чакаккале дигән төрек кирмәненә кергәндә, алар каршында кечкенә генә көймә калыкты. Мансур лоцман бортка ашыгадыр дип уйлаган иде, дөрес фаразламады: ул санитар көймәсе булып чыкты һәм теплоходка килүнең сәбәбе рәсми эш белән бәйләнгән иде.

Иртә кояшлы, якты иде, җәйге җиләс җил исә, теплоход пассажирларының барысы да диярлек палубада кайнаша. Сул як ярдагы калкулыклар куе яшел төстәге асылташлардан торган ясалма кәс белән капланган шикелле, үлән гольф мәйданы өчен чабылган кебек тигез, өстәрәк урманлык урнашкан, аның итәгендә чикләвек агачлары күзгә бәрелеп тора. Калкулыклар артында, бугаздан нибары егерме сигез чакрым ераклыкта, борыңгы атаклы Роя каласы бар. Тик кызганыч: теплоходлар бу урында туктамый.

Мансур палубада туташлар белән Спарта, озакламый тукталасы шау-шулы Истанбул турында гәп куертты. Кызлар сүзне үзләре теләгән якка борып, ресторандагы кичне телгә алдылар, шаяртып, Мансурдан тагын берәр юбилее якынлашмыймы-юкмы икәнен сораштылар. Тискәре җавап алгач, икесе дә авыр сулап куйды, аннары төнлә начар йоклаганны сәбәп итеп, бассейнга барудан баш тарттылар. Мансурга: «Хәтереңне янартып кара әле», – дип төрттереп, каюталарына төшеп киттеләр.

Мансур да бассейнга барасы итмәде. Иртән салкын душ керде, кызынасы да килмәде — болай да ике күзе белән авызында тешләре генә ялтырап тора. Тән төсе африканнардан ким түгел, эфиоп белән бутарсың үзен. Бераз уйланып торгач, ул китапханәгә юнәлде. Бусагадан атлап керүгә, китапханә хуҗасына елмаеп сәлам бирде. Тегесе дә аны таныды, дустанә кул болгады. Залда якты, уңайлы; тирә-яктагы китапларга карап, ул беренче көннән үк үз иткән кәнәфиендә, өске киштәдән алган «Әдәби гәҗит» төпләнмәсен актарырга да онытып бик озак уйланып утырды.

Инде ничәнче тапкыр өен сагынып искә алды, әнисенең яңалыклар белән тулы хатлары күзалдына килде. Пенсиягә чыкканнан соң, өлкәннәр үзләре дә сизмәстән яшьтәшләре, кордашлары белән ныграк аралаша башлый. Татар халкының күптәннән килгән гореф-гадәте: шатлык килсә дә, кайгы килсә дә өйгә өлкәннәр җыела. Әлеге мөхтәрәм кунакларны чакырып, йорт хуҗалары өлкәннәргә булган хөрмәтен белдерә. Инде йортта өлкән кеше дә яшәсә, бу икеләтә бәйрәмгә әверелә.

Әнисе дә хатларында әнә шундый кунакка йөрешүе турында күп язды. Һәр хатында диярлек мәҗлесләрдә, хәл-әхвәлеңне сорашкан булып, синең турында сүз чыгаралар да мин кыен хәлдә калам, дип сиздертә иде. Авылдашлары аны җәллиләр: янәсе, ул үзенең элеваторының гөрләтеп эшләгәнен күрми дә калды, якташларының яңа йортларга күчү мәрәкәсе дә аннан башка үтте, Коръән ашларында, өй котлау мәҗлесләрендә булмады, үзенә рәхмәтле хуҗаларның бер чынаяк чәен дә эчә алмады диләр икән. Янәсе, егетне зур тормыш, олы эшләр үзенә суырып алды да, әнә, Африкага ук илтеп ташлады дип әйтәләр икән. Ләкин әнисе язганча бу сүзләрдә җәлләү, кызгану түгел, киресенчә, якташ егет белән горурлану сизелеп тора иде. Мансур турындагы сүзләре һәрвакыт бер җөмлә белән тәмамлана: «Менә кайтсын гына әле, зур итеп мәҗлес корырбыз, бер үгез чалырбыз, һәр өйдә кунак итмичә аны Аксайдан җибәрмәбез диләр икән...

Өстәл өстендә гәҗитләр җәелеп ята, ул аларга һаман да кагылмаган әле. Китапханә мөдиренең: «Ни булды? Ярдәмем кирәкмиме?» – кебек сораулар чагылган карашын күргәннән соң гына уянып киткәндәй булды. Уйларын ераккарак күчереп гәҗитләргә капланды.

Шунысы гаҗәп, «Әдәби гәҗит»не укып, теге яки бу өлкә турында ул теләсә кайсы һөнәри гәҗиткә караганда да тулырак мәгълүмат туплады. Мөгаен, бу — гәҗитне чыгарганда йөз меңләгән укучы язмалары урын алганга шулайдыр. Иң мөһиме — белгечләрнең язмалары арадашчысыз, ягъни ничек язылган, шулай бирелә. Үз эшенең осталары исә проблеманы проблема итеп таный һәм күтәрә белә иде. Бу — гәҗитнең һәр битендә сизелеп тора. Гәҗит кайсы гына өлкәләрне колачламый: мәктәпкәчә балалар турында язылганнан алып, су эшләре слесарьлары эшчәнлеген җентекләп яктырткан мәкаләләргә кадәр бар иде. Кайбер язмалар хәтта теге яки бу министрлыкның коллегия утырышына әзер программасын хәтерләтте — рәхәтләнеп укы, файдалан, баш ватып торасы юк. Мондый тормыш, яшәешкә битараф булмаганнарның инәсеннән-җебенә кадәр уйлап язган мәкаләләр шулай да еш очрамый. Мансур сәрхушлекнең зарары турында басылган мәкаләләрнең күплегенә аптырады. Кемгә адресланган алар?

Эчкечеләр гәжит укымый, күз салганнарының да кәжүнни сүзләр намусын уята микән? Андыйлар намусларын күптән эчеп оныткан инде, ә аеклар өчен бу мәкаләләр әллә бар, әллә юк. Димәк, туптан чыпчык аткан кебек килеп чыга...

Теплоходның эчке радио челтәре аша беренче сменаны төшке ашка чакыру яңгырады. Мансурга да уку залыннан кузгалырга кирәк иде. Төшке аш алдыннан палубада йөреп, диңгез һавасын сулау комачауламас иде, ләкин аның күзе зур хәрефләр белән «Су басу» дип куелган мәкаләгә төште. Башыннан: «Һаман бер балык башы — су үткәрүче турындамы?» — дигән уй йөгереп узды. Ләкин мәкалә күләме буенча фатирны су басудан күпкә зуррак иде. Таныш елга исеме күзгә чалынгач, Мансур йөреп керү уен онытты.

Мәкалә аны гаҗәпкә калдырды. Уйларына батып күпме вакыт узгандыр, әлеге дә баягы китапханә мөдиренең аптыраулы карашына юлыкмаса, белмим, тагын күпме утырасы булгандыр. Журналист җавапсыз кешеләр тарафыннан ике райондагы елга һәм җирнең бозылуы турындагы фаҗигане бәян иткән иде. Китерелгән зыян шулкадәр күп була ки, хәтта аның очына да чыга алмыйлар. Өстәвенә, бу елгада утыз елдан соң тормыш кабат барлыкка киләчәк дип бирәү дә ышандыра алмый. Елга янындагы җирләр нишләр? Аларга салынган зыянны кем исәпләр? Елгада хәзер коенып та, суын эчеп тә булмый. Яр буена килергә күнеккән киек-җанварларны кем саклап торыр? Агуланган елга күпме күлне, кечкенә елгаларны, инеш-чишмәләрне яраксыз хәлгә китерер? Алар бит бергә кушылган. Бу сораулар Мансурның башында чебен кебек безләделәр. Табигать-ана алга таба нәрсә күрсәтер — билгесез. Бәлки, кайсыдыр балыклар агулы, пычрак суда яшәргә күнегер, күп итеп уылдыгын чәчәр, һәм берничә елдан безнең өстәлләргә агулы балык менеп утырыр. Бәлки ярны сырып алган куаклар, өянкеләр, сүсемнәр дә ияләнер. Шуннан ни? Берәр лаборатория аларның агулы булмавына ышандыра аламы? Елгадан күтәрелгән пар сулары тирә-якка яңгыр булып явар, кышларын усал җилләр боз булып каткан елга өстеннән карны себереп, тирә-юньгә таратыр, һава пычраныр.

Пычранган сулыклардан йөз, меңнәрчә чакрым ераклыкта гомер кичергән кешеләр басу-кырларда, болыннарда шакшы су белән сугарылып үстерелгән ашлык, печәнне файдаланып нишләп бетәрләр? Бәлки, ул кисәк үлем дә китермәс, кешеләр ана ияләнер, мал-туар да һәлак булмас, ләкин агуланган елга тирәли урнашкан тереклек ияләре белән ни булыр?

Гәҗит битләрен ачкан саен, Мансур пычранган елгалар һәм сулыклар турында язмаларның артуына игътибар итте. «Пычрану!» — журналистлар бик җиңел әйтелешле, йомшак яңгырый торган, тынычландыра торган сүз уйлап тапканнар. Мәкаләдә исә сүз елгаларга һәм сулыкларга ташланган сәнәгать калдыклары турында бара! Берничә урында пычрануга кагылышлы, һәлакәте азрак күләмдә булган шуның ишеләр турында телгә алына. Журналистлар агуланган балыкларның пычранган елга буйлап тәүлек буе су өстеннән агып төшүе, яр буенда үлем белән тартышып яткан кошчык турында яза. Әмма бу мәкаләләрдә җирле хакимият вәкилләренең әлеге хәлләрнең киң яңгыраш алуын теләмәве күзгә бәрелеп тора. Менә шуңа алар пычрану дигән әллә ни куркыныч булмаган сүз уйлап тапканнар. Бәла-каза бар, әмма куркыныч түгел, түзәрлек, димәкчеләр. Мансур шулай дип фикер йөртте.

Әгәр дә сулыкларга, елгаларга «Кызыл китап» булдырсалар, кешеләр күпме сүсемнәр, тереклек ияләренең юкка чыгуын күреп шаккатыр иде. Китапларда, география дәреслекләрендә язылган, җырларда җырланган,

риваятьләрдә сөйләнгән күпме елгаларның юкка чыгуын яисә коточкыч хәлдә булуларын күреп, гаҗәпкә калырлар иде.

Бу очракта исә елга белән бәйле вакыйга гафу ителмәслек, шуңа күпме генә тырышсалар да, бу фаҗигане яшереп кала алмаганнар. Шунысын да искәртергә кирәк: мәкаләдә гаепле затларның исемнәре аталган иде.

«Бу фаҗигане башка гәҗитләр ничек яктыртты икән?» — дип кызыксынды Мансур. Ул төшке аш турында бөтенләй онытты, кабаланып-ярсып, бу хәлләргә битараф калмас дип санаган басмаларны актарырга тотынды. Алты-җиде исемдәге гәҗитнең ник берсендә әлеге елга язмышына бәйле язмалар очрасын.

«Басу» — бу сүзне ишетүгә, йөрәк кымырҗый. Кешегә хәят бирүче җир һәм су һәлакәте белән бәйле сүз бит ул! Кеше өчен җир белән су һәрвакыт үлемсез тоела. Мәкаләдә кеше турында телгә алынмый, ул әйтерсең лә пәрдә артында кала. Аның кайгысы турында сөйләп торасы юк, ул болай да билгеле. Әлбәттә, халыкны башка җиргә күчерерләр, йорт-җирләрен яңабаштан корырга ярдәм итәрләр, каралты-куралары элеккедән дә яхшырак булыр бәлки. Әмма... аңа карап кына хәл яхшыга үзгәрми бит.

Идел тирәли миллионлаган кеше яши. Аларның һәрберсе Иделне үзенеке саный. Ул үзе яшәгән тирәлекне — ике-өч чакрымны яхшы белә. Елганың биек, урыны белән сөзәк ярлары, кискен борылышы, аның тирәсендәге куе урманлык — бу аның туган ягы. Яланаяк Идел буенда үскән кешеләр өчен ул — изге урын. Аны берни белән дә алыштырып булмый. Тиң ярын, үз йортын, урамын, беренче тапкыр сөйгәне белән очрашкан елга буен, әйтегез, кем нәрсәгә алыштыра ала?

Җир турында исә бөтенләй өстән-өстән генә язылган. Бу журналистның зирәклегеннән киләдер. Бәла-казадан интеккән бу җир турында тагын ничек язып булсын. Фаҗигане төгәл ачып бирә торган чагыштыруны кайдан, ничек табарга? Мәкаләдә язылмаса да, Мансур җирле химик сүс җитештерү комбинатыннан агып чыккан, утлы лава кебек, юл өстендәге барча тереклекне көйдергән, кыр һәм болыннарны тутырган кислотаны ап-ачык күрде...

Төштән соң Мансур шезлонг астына кереп ятты. Бассейнга барасы килмәде. Өстәл күршеләре, мөгаен, шунда чупырдыйдыр. Әкренләп аның баш миен, зиһенен чуалткан хисләр өермәсе узды. Ул инде мәсьәләгә инженер-прагматик буларак карый. Кем гаепле? Нәрсәдән килеп чыккан? Ул мәкаләне бер тында укыды. Шуңа кайбер детальләр, фамилияләр исендә калмаса да, барысы да төгәл язылган иде. Ул инженер белеменнән чыгып, вакыйгага бәя бирергә теләде. Урыныннан сикереп торды да каютасына керде, чемоданнан калькулятор, блокнот алып кабат китапханәгә юнәлде. Аңа элегрәк туннель, күперләр җимерелгән урыннарда эзләнү-тикшеренү эшләрендә катнашырга туры килсә дә, су басу белән тәүге очрашуы иде.

Мәкаләне игътибар белән кабаттан укып чыккач, Мансур ак биттә үзе өчен әлегә таныш булмаган схема төзеде, һәр кеше исеме, җаваплы хезмәткәр, оешма турысына нindидер тамгалар салды. Тамгалар төрле иде: анда вакыт һәм суммаларны чагылдырган плюс-минуслы, саннар иде. Алар йөз меңнәр һәм хәтта миллионнар белән исәпләнде. Схемада мәкаләдә аталмаган оешмалар, күзәтү хезмәтләренең дә исемнәре күренде. Автор аларның барлыгын белә, аларның су басуга катнашын да чамалый. Ләкин ул аларга төп игътибарын бирмәгән.

Мәкалә Мансурның ачуын кабартты: комбинат ник бер мәртәбә яхшы яктан телгә алынсын — бу күп нәрсә турында сөйли иде. Дәүләт муенына атланган, әрәмтамак, бушка ипи кимерүче — болары әле комбинат турында йомшартып әйтелгәннәре генә. Елгага әлбәттә атаклы оешма, әйтик,

«Азовсталь» зыян салса да, шушындый ук авыр тойгылар кичерелер иде. Ичмасам аларының күрсәтер, макталыр эше бар.

Химик сүс житештерү комбинаты, мәкаләдән анлашылганча, унбиш ел элек велюр, вельвет, замш, мех, дакрон, плащ һәм пәлтә өчен күн, соңгы елларда модага кергән спорт кәчтүмнәре өчен кирәкле тукыма — эластик житештерү өчен сафка бастырылган булган. Әлеге төзелешнен тәмамлануын, модалы тукымаларның пәйда булуын фабрикалар һәм тегү ательелары дүрт күз белән көткәндер. Әмма аларның өмете акланмаган. Унбиш ел буена комбинат бер генә мәртәбә булса да планны үтәмәгән. Кая ул! Журналист барысын да жентекләп өйрәнгән — хәтта ай буена житештерергә тиешле тукыманы егерме биш проценттан арттыра алмаган! Кулланучылар аз күләмдәге тауарны бер-берсеннән йолкып алыр дәрәжәдә сатып алган дип уйлар иден — алар кеше кулына эләкмәгән, кайдадыр складларда юкка чыккан. Үзеннән-үзе сорау туа: ни өчен берәүнең дә шундый бәлале комбинат белән бәйләнешкә керәсе килмәгән? Тукыманы вакытында ала алмыйча, гөрләп торган фабрикаларның туктап калу ихтималы булган бит! Комбинатның тулы көченә эшли алмавында берничә сәбәп күрсәтелә. Башыннан ук проект тупас хаталардан башланган. Проект институты катлаулы инженер корылмаларны минимумга кадәр гадиләштерә. Шулай итеп алар объектның смета бәясен киметә. Бу исә проект институтларының төп казанышы санала — дәүләт тиеннәрен саклап калган өчен аларга мактау арты мактау, премия арты премия ява. Чыгымнарны берничә дистә мең сумга киметү исә бәяләп булмый торган зыян китергән. Хата әнә шуннан ук киткән. Икенчесенең килеп чыгуы да шуна бәйле.

Комбинатны шаулатып-гөрләтеп, төче сүзләр белән мактанышып эшләтеп жибәрүгә, нәфис бәрхет һәм күзне иркәли торган велюр түгел, канализация торбаларының тишекләрен томаларга яки ферма түбәләрен жылытырга гына ярарлык ясалма пычрак мамыкка, чүпрәккә охшаган тукыма гына житештерә алачагы ачыклана. Бу кемне канәгатьләндерсен инде, комбинатны яхшы якка үзгәртергә булалар. Бердәнбер дөрес гамәл була ул. Әмма карар кабул итү бер хәл, аны тормышка ашыру бөтенләй икенче нәрсә икәнен онытып жибәрәләр. Инженер буларак, Мансур белә: кыйммәтле чималны бозып юкка чыгармас өчен комбинатны туктатырга, туксан процентка якын эшчене вакытлыча ялга жибәрергә, төзүчеләрне китертергә, бәлале проектның белгечләрен чакыртырга һәм комбинат көтелгән продукцияне бирә башлаганчы жибәрмәскә кирәк.

Әлбәттә алар да шулай уйлаганнардыр. Тик төзекләндерүне нинди акчага башкарып чыгарга? Төзелешнен чыгымнары болай да инде комбинатның исәп-хисап бәясеннән ике тапкырга артып киткән. Яңадан эшләтеп жибәрү өчен өстәмә акча эзләргә туры киләчәк. Акчадан тыш, материаллар һәм белгечләр дә кирәк бит әле. Планлы хужалыкта барысы да берничә елга алдан исәпләп эшләнә, шуңа да боларны табу, ай-һай, жиңел эш түгел. Тагын шунысы да бар бит әле: комбинатның даны илгә таралган, ул эшли дип санала, житештерәчәк продукция исә берничә ел алга кулланучылар ихтыяжына кертелгән. Уйлана торгач, ниһаять, комбинатны эшләп торган килеш төзекләндерергә карар кылалар. Предприятиегә елына ике, өч миллион сум — кайбер елны анысы да эләкми — бүлеп бирә башлыйлар. Башка төзелештән суырып, дүртәр миллион эләккән чаклар да була.

Акчалар сибелеп бетә, планнары болай да мулдан булган төзүчеләр комбинаттагы житешсезлекләргә бармак аша карый. Алар бу төзелешнен чи каеш кебек сузылачагын яхшы белә. Әлбәттә, эш барышында теге яки бу продукцияне житештерү мөмкинлегенә ия булалар, әмма сыйфат һәм сан турында хыялланырга гына кала. Менә шулай унбиш ел буена дәвам итә. Мәкалә авторы

«бик яхшы» билгесенә төзекләндерелгән комбинат өчен нигезеннән башлап яңа салынган комбинатка киткән чыгым тотылганын исәпләп чыгарган.

Химия, металлургия өлкәләре чистарту корылмаларыннан башка яши алмый. Билгеле, алар химик сүс житештерү комбинатында да төзелергә тиеш булган. Әлеге дә баягы чыгымнарны киметү сәясәте монда да үз эшен башкарган: акчаны янга калдырабыз дип, бик күп кисәтүләрне төзәткәннән соң гына эшләргә рөхсәт ителә торган корылма төзегәннәр. Вак хәрефләр белән бастырылган бу искәрмәләр берничә битне тәшкил итә иде. Мансур чистарту корылмасының ике тапкырга зуррак булырга тиешлеген шунда ук чамалады. Проектның кыйммәтләнүеннән курыккан институт бу адымга бармаган, ун елдан комбинат җитәкчелеге үзләре зурайтыр әле дигән максат белән әнә шулай калдырган. Комбинат яхшы гына эшләп китсә, хуҗалары үз эшенең осталары булса, әлбәттә, чистарту корылмалары игътибардан читтә калмас иде. Җитәкчелек ел саен алышынып торган комбинатта исә чистарту корылмаларына хезмәт күрсәтү өчен кем махсус бригадалар төзесен? Болай да төп житештерү аксаганлыктан, хезмәт хаклары түбән тәгәрәгәннән-тәгәри бара. Комбинат әнә шулай фаҗигале финалына якынлаша. Эшләнеп бетмәгән технология аркасында саклау урыны уйланылганнан ике тапкырга тизрәк тула. Монысын да ахырдан тикшерү барышында гына ачыклыйлар. Проект институты тарафыннан авторлык күзәтүе төзелеш барышында да, комбинатны эшләтеп җибәргәндә дә күрсәтелми.

Су басуга өч көн кала дежурдагы слесарь чистарту корылмалары янына килеп чыга һәм саклау урынының иң соңгы билгегә кадәр тулганын күреп ала. Ул язма формада үзенең турыдан-туры җитәкчесен дә, комбинат җитәкчелеген дә кисәтә. Һәлакәткә бер көн кала эшчеләр төркеме дә җитәкчелекне якынлашып килүче афәттән кисәтә, әмма аларга колак салучы табылмый. Фаҗига шимбә көнне була. Директор бу көнне туйда типтерә, баш инженер балыкка китә. Менә шул вакытта дәүләтнең йөз миллион сумлаган акчасын юкка чыгарган һәм бер генә сумлык та табыш китермәгән комбинат тагын бәяләп бетермәслек зыян китерә.

Әгәр унбиш ел буе бәла-комбинатны төзүчеләр яр буенда кармак салып кына утырсалар, аларга шул ук хезмәт хаклары түләнсә, әмма комбинат төзибез дип тотынмаган булсалар, чыгымнар әллә ничә миллион сумнарга кимрәк буласы иде.

Барысы да көн кебек ачык булган югыйсә: фаҗига, яман шеш авыруыдай әкрен генә якынлашкан. Мансур бу хәлләрне башына сыйдыра алмады. Ул башкача фикерләргә һәм эшләргә күнеккән.

«Дипломнарын тартып алырга, инженер эшләреннән мәхрүм итәргә!»— дип уйлады ул. Дәүләт алардан килгән зарардан да күбрәкне күрә алмас, ичмасам, башкаларга сабак булыр иде! Бәлки җитәкче кәнәфиенә үрмәләүчеләр дә кимер иде. Җитәкчелек бит ул — эш урыны, рәхәтлек чигү урыны түгел. Суд белән тәмамланган фаҗигәнең ахыргы нәтиҗәсе турында укыганнан соң шундый фикергә килде ул. Ә монда адәм көлкесе: директор җиңелчә шелтә белән котылган. Янәсе, ул комбинатны күптән түгел генә кабул итеп алган, шуңа эш барышы белән танышып җитмәгән. Кабул иткән һәм эшкә төшенмәгән? Анламасаң, кабул итмә! Комбинатның калган дүрт белгече үз гаебен танымаган. Шулай да аларны суд ике йөз житмештән дүрт йөз мең сумга кадәр штрафка тарткан. Тартуын тарткан, әмма суд планын үти алмый торган предприятиедә эшләүче гади совет хезмәткәренә бу кадәр акчаны кайдан алырга икәнен генә күрсәтмәгән. Ул кадәр зур сумманы түләү мөмкин хәл түгел. Кем-кем, әмма юристлар хезмәт хакының өчтән бер өлешеннән дә артыгын тотып калырга ярамавын белә.

Мансур проект авторларының судка чакырылмавына бер гаҗәпләнсә, аны

раслаган белгечләрне, проект институтын бу фаҗигагә катнаштырмауларына тәмам аптырады. Мәкаләдә кайсы институтның проект башкаруы турында искәртелмәве дә аңлашылмый. Ичмасам, киләчәктә башка оешмалар алар белән эш итмәс, шулай итеп, башка фаҗигаләр булдырылмас иде. Фаҗига булган шәһәр исеме дә телгә алынмаган. Бердәнбер исем — меңнәрчә чакрымнарга сузылган елга. Гомерлек штрафка тартылган талантсыз инженерларның фамилияләре аталу Мансурга берни дә сөйләми иде...

Кичке аш вакытында кызлар аның сөмсере коелганын күреп, сәбәбе белән кызыксынды. Ул гәҗиттәге мәкалә турында җентекләп сөйләп чыкты...

— Күңелегез шуңа төштеме? — Кызлар аны игътибар белән тыңлаганнан соң, гаҗәпсенеп,беравыздан сорау бирде.

Ксана шундук Днестр буенда шикәр заводы белән дә шундый ук фаҗиганең булуын исенә төшерде. Аларның кичәге кебек үк кәефләре яхшы. Мансур хикәяте аларга тәэсир итмәде, чөнки кызларны күбрәк бүгенге кич кызыксындыра иде. Наталья үзенә хас булганча, шаяртуга борды:

— Кәефенне бозарлык мәкаләне табар өчен көне буе актарындыңмы гәҗитләр арасында? Тапкансың шәп шөгыль, Мансур! Иң яхшысы, без көндез кинәш биргәнчә, хәтерегездә казынып берәр юбилейны исегезгә төшерергә иде. Төзегән элеваторыгыз бер генә түгелдер бит инде? Без төзеләчәген дә билгеләп үтәргә риза... Ә бу мәкаләне башыгыздан чыгарып атыгыз.

— Техник процесс өчен шулай түләнә, нишләтәсең... Көне буе кулына калькулятор тотып, ниндидер бер завод китергән зыянны исәпләп утырып, әнә, безнең кичке күлмәкләребезгә дә күз салмыйсың, Мансур. Югыйсә, иртәдән иң яхшы чәчтарашка чират торып матурланган идек. Яхшы түгел болай... — Ксана елмайды. Аның ерык иреннәреннән бу сүзләрнең шаяртып кына әйтелүе аңлашыла иде.

«Кара инде, нинди матур кызларның кәефен төшерәм, аларның бит көтеп алган яллары, бәйрәмнәре, — дигән уй йөгереп узды Мансурның башыннан. Ниһаять, аларның бәйрәмчә матур киемнәренә игътибар итте. — Мин тагын кайчан шундый чибәр кызлар белән бергә күңел ачам әле?» Күңеле күтәрелеп, аларча шаярып җавап бирде:

— Шундый инде мин, кызлар, джентльменлык мине урап узган. Эш, эш ди торгач, матурлыкны күрү сәләтем дә югалып бара икән. Ни кызганыч, бу арада гына юбилейлар күренми, бары тик елга фаҗигасен искә алыр өчен генә чакыра алам. Кайчандыр мин фаҗига булган урыннан ерак түгел, Төньяк Казакъстанда тегермән белән элеватор төзедем. Эшкә шулхәтле күмелгәнмен, әйтсәм ышанмассыз, берничә генә чакрымдагы елгага бер тапкыр коенырга бара алмадым. Хәзер менә көтәргә дә көтәргә инде...

— Пессимист! — диделәр кызлар беравыздан.

— Матәм киченә түгел, елганың яңадан тууына багышлыйбыз кичәбезне! — диде Ксана. — Алай гына түгел, сезнең абый-эне инженерлар корыткан елгаларның терелүе өчен күтәрербез бокалларыбызны. Ярармы?

Мансур аларны өске палубадагы өчесенен дә күңеленә хуш килгән ресторанга чакырды. Алар кабат ресторан ябылганчы бер-берсен шаяртты, биеде һәм иң соңгы булып кузгалдылар. Чыгышлый Мансур шампан шәрабе алды. Борттан уң якта, испан Аликантесыныкы кадәр үк булмаса да, Принц утрауларыннан яктылык бөркелә иде. Шәраб йоткалап, алар шактый озак басып торды.

Кызлар белән ничек кенә күңелле, рәхәт булмасын, вакыт-вакыт ул уйлары белән ерак-еракларга — казах, урыс авыллары, казак станицалары янынннан агып яткан елгага барып тоташа һәм нигәдер үзен гаепле саный. Тик кем алдында һәм ни өчен икәнен генә төшенми.

Кызлар аны күнелне иркәли торган шаян төртмәле сүзләре белән бу дөньяга кайтардылар... Аерыласылары килми, әмма кичке күлмәк аша әкрен генә үрмәләгән салкынлык аларны каюталарына әйди. Кызлар, читләтеп кенә Мансурга кунакка керергә теләкләрен белдерде. Бәхетенә, аның люкс каютасында кофе ясап була, суыткыч та ризыклар һәм эчемлеккә мул иде. Кызлар өстәл белән маташкан арада, Мансур чемоданыннан магнитофон һәм кассеталар тартып чыгарды. Кызлар аһ та ваһ килде.

— Таңда Босфор һәм Истанбул! Төн безнеке! — Ксана сөенеп кычкырды, үзенең мәхәббәт тулы күзләре Мансурга төбәлгән иде.

Төнге мәҗлес рестрандагыдан ким булмады: алар артыгын шауламаска тырышып җырладылар, биеделәр дә йокы сарган Принц утрауларына кул болгап, сәламләр өчен таң беленер-беленмәс палубага чыктылар.

Теплоход әкрен генә Босфорга килеп керде. Менә Истанбулны иске һәм яна шәһәргә — эшлекле һәм яши торган якларга бүлә торган Алтын Мөгез бухтасы күренде. Босфорга кергәндә төрекләр һәм грекларда берничә риваять булып телдән-телгә күчеп сөйләнелгән маяк күренде. Төрек риваятенә караганда, солтан үзенең яраткан кызын манара эчендә калдырып өстеннән таш белән ябып куйган. Менә шуна ул, янәсе, Кыз манарасы дип атала. Греклар аны лиандрова дип атый. Анысы да бәхетсез мәхәббәт белән бәйләнгән. Босфор тар, урыны белән жиде йөз метрдан да артмый, шуна да теплоход сәгатенә ун миль тизлек белән генә хәрәкәт итә. Бу хәрәкәт тизлеген тәҗрибәле төрек лоцманнары кертkән.

Нинди хозурлык! Иртәнге томанда Истанбулның йөзләгән манарасы әле калка, әле юкка чыга, алар арасында Әй-София мәчетенең дүрт манарасы һәм Солтан Әхмәтнең Зәңгәр мәчетендә алты манарасы аеруча биек булып күренә. Болар — көнчыгыш архитектурасының могҗизасы. Босфорның яр буе тәүлекнең теләсә кайсы вакытында шау-гөр килеп тора — төрек халкы бәйрәм итәргә ярата.

Мансурны барыннан да бигрәк күтәрелә торган чакрым ярымлык канатлы күпер таң калдырды. Америкалы, япон һәм алман инженерлары, архитекторлары, төзүчеләренең уртак казанышы булган бу күпер Азия белән Ауропаны тоташтыра. Сигез автомобиль рәтен үз эченә алган гигант күпер әйтерсең лә җиңел үрмәкүч сыман аяклары белән яр буйларына ябышкан: тимер канатлар дүрт бетон үгезгә тоташкан. Гади дә, ышанычлы да, шул ук вакытта кыйммәтле корылма үзенең чыгымын ике ел ярымда каплаган.

Кайбер йортлар Босфорга терәлеп үк тора. Иртәнге сәгатьләрдә су өстендә эленеп калгандай күренгән ачык балкон, лоджия, верандаларда яшь хуҗабикәләр җәймәләрен селкеп, тузанын кага. Диңгезче йөрәген дулкынландыра торган күренеш бу: иртә... ак җәймә тоткан чибәр хатын балконга килеп чыга да серле генә кереп югала.

Яктырды... Тик палубада кеше аз әле. Күбесенең иртәнге тыныч йокысын бүләсе килми, чөнки барысы да сәяхәт барышындагы иң озак тукталыш нәкъ менә Истанбулда ниятләнгәнен белә иде. Мамык шәлгә төренгән кызлар серле күренгән шәһәрдән күзләрен аера алмады.

— Әйтерсең лә әкияти шәһәр! — Ксана сөенеп шулай диде һәм, иртәнге салкыннан калтыранып, Мансур кочагына сыенды. — Мансур, таңны Босфорда каршылыйбыз дигән тәкъдимем дөрес булды бит, әйеме?

— Дөрес инде, дөрес. — Мансур кызның иркәләнеп әйткән сүзләрен җөпләде һәм, үзе дә сизмәстән, бераз иелә төшеп, аның нәфис муеныннан үбеп алды. Өскә җыелган чәче кызның муенын ачык калдырып үзенә тартып тора иде...

Соңрак ул кызлар белән шау-шулы Истанбул буйлап йөрде. Монда Мансурның алман, француз, инглиз телләрен белүе һәм, әлбәттә инде,

барыннан да бигрәк ана телендә — татар телендә сөйләшүе бик тә ярап куйды. Якты, бизәкле Истанбулдан әсәренгән кызларның күзләре җанын ни тели, шуны тәкъдим иткән исәпсез-сансыз кибет-кибетчекләр буйлап йөгерде, алар реклама плакатлары, таныш булмаган язуларны укуын үтенеп, туктаусыз Мансурга мөрәҗәгать иттеләр. Кызларның күтәренке кәефе күчтеме, егет авыр уйларыннан котылып торды.

Истанбул — туган ил белән аерып торучы соңгы тукталыш. Пирей, Тулон, Неаполь, Генуя, Барселона, Лиссабон, Роттердам, Һамбург, Плимут, Гавр — барысы да артта калды. Сәяхәтнең ахырына якынлашуын кызлар һич кенә теләми иде. Шунамы, аларның шаянлыклары кими төште. Барысы да әле алда — Аурупа портларында дип тору күнеллерәк иде дә, әмма барысы да артта калды, ял төгәлләнеп килә — ул яңа ел шәме кебек янды да бетте, алда — эш көннәре, бетмәс-төкәнмәс мәшәкатьләр. Бәйрәмнәрдән гадәттә матур истәлек-хатирәләр генә кала. Ксана, кем нәрсә уйлаганны сизгәндәй, әйтеп куйды:

— Шулай да иң истәлекле көнебез кайсы булды икән?..

Мәшһүр Истанбулда аларны әле тагын биш сәгатьлек сәяхәт көтә иде. Кызларны кинәт сагыш басты. Мансур хәзер аларның җаена гына тора, һәр кыланмышларын үтәргә тырыша. Хәер, нигә яшерергә, ике чибәркәйнең күнелен күрү үзенә дә рәхәт иде. Алар каһвәханәгә кереп төрек каһвәсеннән авыз иттеләр. Дымлы кебаб, бер метрлы шампурлардан шашлык ашадылар, Босфордагы ачык ресторанда шәраб йоткалап хәл алдылар. Менә шул ресторанда Ксана үзе дә сизмәстән әйтеп салды:

— Ярый әле, Мансур, Касабланкада сез утырдыгыз. Плимутта, Гаврда, Һамбургта, Антверпенда безгә күнелсез булды. Сезнең белән шулкадәр рәхәт, без һәр кичне көтеп житкерә алмыйбыз.... — Сүзен ул гадәттәгечә чеметтереп тәмамлады: — Сез — ниндидер элеватор турында уйланып, безнең хакта онытып җибәрсәгез дә, барыбер джентльмен, ... һәрвакыт ир-егет булып кала беләсез. — Ул кызыл шәраб салынган тар бокалны күтәрде: — Сезнең исәнлеккә тотып куйыйк монысын.

Туристлар теплоходка әйләнеп кайтканда бар да арып, хәлдән тайганнар иде. Күбесенең кәефе ташка үлчим, гадәттәге шаярту-уртәшүләр дә ишетелмәде. Барысы да сәяхәтнең тәмамланып килүенә төшенде бугай. Кайберәүләр Босфорга ыргытасы соңгы тиеннәрен дә туздырып бетергән. Имештер, шулай итсәң, Истанбулга тагын әйләнеп киләсең икән. Алда — Одесса, эш көннәре...

Күп йөреп, эсседән әлсерәгән, күргәннәреннән айнып житә алмаган кызлар Мансур белән бортка менүгә, кичке ашта очрашырга сүз куешып хушлашырга ашыктылар.

Эссегә күнеккән Мансур каютасына душта коеныр һәм киемнәрен алыштырыр өчен генә керде. Теплоход кузгалганда, Истанбул белән хушлашыр өчен, ул кабат өске палубада иде инде. Порттан сигнал алуга, лоцман бравур музыкасы яңгыраган теплоходны Кара диңгезгә алып кереп китте. «Лев Толстой» кабаттан Босфорның торак йортлары тыгыз урнашкан яр буйлап сәгатенә ун миль тизлек белән хәрәкәт итә башлады. Бар, кафе, ресторапнарда кәеф-сафа корып утыручылар аларга хәерле юл теләп кул болгады. Яшеллеккә һәм аллы-гөлле чәчәкләргә күмелгән яр буеннан хуш ис анкый иде. Кара диңгезгә чыгу юлында ике маяк күренде: Азия ягындагысы — Ана-доллу маягы, Аурупа ягында, балыкчылар бистәсендә — Румели маягы. Мансур бик озак, теплоход ачык диңгезгә чыкканчы палубада басып торды. Сау бул, Төркия!

Теплоход тынып калды. Коридорларда аяк тавышлары ишетелми, төркем-төркем булып гәп куертучылар да каюталарына кереп бикләнде. Истанбулдан соң төшке ялсыз булмый. Тирә-якта тынлык, бары тик

диңгезнең авыр кубарылып килгән дулкыннары гына теплоходның ак бортына туктаусыз суккалады. Сәяхәтчеләрнең хәленә кергәндәй, әйтерсең лә, теплоходны туган якка таба кудылар. Мансур каютасына кайтып ике сәгатьләп черем итәргә булды. Тик, нигәдер, күзенә йокы кермәде.

Күңелен ниндидер корт кимерде, йөрәге тынычсызланды. Мәкалә... Менә нәрсә борчый икән аны. Каютада ялгызы, ул кабат уйлар дәрьясына кереп югалды. Башында яңадан-яңа сораулар туды: елганы саклап калу өчен нәрсә эшләгәннәр? Мондый хәл тагын кабатланмас дип кем үз өстенә ала? Бу очракта дәүләт органнарының рәсми җавабы булырга тиеш. Мәкалә гәҗиттә дөнья күргәннән соң, редакциягә укучылардан меңләгән хатлар алынгандыр. Мөгаен, рәсми җавап та басылгандыр, чөнки гәҗит үзендә күтәрелгән проблемаларны ахыргача күз уңында тотарга тиеш.

Мансур янә уку залына юл тотты. Гәҗитләрне берәмтекләп актарып, игътибар белән рәсми җавапларны укыды. Әмма үзенә кирәклесен тапмады. Өч айлык гәҗит төпләнмәләрен актарганнан соң, тәмәке тартырга дип палубага чыкты. Әйләнеп кергәндә катгый карарга килгән иде: күпме кирәк — шуның кадәр утырыр, әмма җавапны табар! Артка юл юк — холкы шундый: бер нәрсәгә тотындымы, нокта куймыйча туктамый. Тапты: җавапны ярты елдан соң биргәннәр икән. Бернәрсә аңлатмаган гомуми сүзләрдән торган кып-кыска җавапта алай да бер җөмлә игътибарын җәлеп итте: « ...химик сүс житештерү комбинатында фаҗига булу сәбәпле, чистарту корылмасын төзекләндерү өчен өч миллион сум акча бүлеп бирелде». Алга таба табигатьне ярату, комбинат эшчеләренең армый-талмый хезмәт итүләре, кыскасы, крокодил күз яшьләре, төче сүзләр тезелеп киткән иде...

Мансурның шуның кадәрле ачуы купты, аздан гына гәҗитне ертып атмады. Аны китапханәченең аптыраулы карашы гына туктатып калды. Аңа рәхмәт әйтеп, ул палубага ашыкты. Кемдер аны юләргә чыгарып алдаган кебек сизде ул үзен. Гәҗиткә мондый тинтәк, укучыларны мыскыл итә торган җавап бирелергә тиеш түгел иде дип санады Мансур. Редакциянең шул җавап белән канәгатьләнүенә аның күңеле катты.

«Чистарту корылмасын төзекләндерү өчен өч миллион сум акча бүлеп бирелгән!» — Мансур, гасабиланып, кат-кат шул җөмләне кабатлады. — Өч миллион! Тагын өч! Эш шул корылмаларда гына микәнни?! Нәкъ уендагы кебек, башлыйммы янабаштан булган бу. Комбинат унбиш ел буена халык акчасын җилгә очыру белән шөгыльләнгән, хәзер инде аның чистарту корылмасы дәүләт казнасыннан акча суырырга тотыначак икән. Иң беренче итеп, комбинат бу халәтендә кирәкме-юкмы дигән сорауны кабыргасы белән куясы иде бит! Ни өчен комбинат унбиш ел буе дәүләт җилкәсендә булган? Кайчан да булса сафка басармы, ул эш белән кем шөгыльләнер?

Килгән зыянның күләме бер генә караклык белән дә тигезләшә алмый. Халык болай ди бит: урланган әйбер эшкә тотыла. Ә монда барысы да җилгә очкан: ни үзенә, ни кешегә.

Әлеге «гаҗәеп» проектның заказ бирүчесе һәм башкаручысы кем? Һәрхәлдә, дошманнар эше түгелдер? Мондый проектлар тагын булмас дип кем ышандыра ала? Ни өчен бер генә кыска җавап бирелгән? Ни өчен җинел һәм химия сәнәгате министрлыклары эндәшми? Мөгаен, берсе заказ биргәндер, икенчесе проектлаган һәм төзегәндер? Заказ бирүчеләр башкаручыларга җәзага тартканмы? Брак бит күзгә күренеп тора! Аны кесәгә салып яшереп булмый! Дәүләт Арбитражы дигән саллы оешма бар. Эш аның кулына эләксә, мөгаен, ул хөкем итәр иде. Ни өчен хаклыга да, гаепләнүчегә дә эндәшмәү отышлырак?» Тезелеп киткән сораулардан Мансурның башы шаулады.

Елганың хәле ничек? Аның турында җавапта телгә алуны кирәк тә тапмаганнар. Ул әшәке химик матдәләрне Иртешкә кадәр үк илтеп җиткерде

микән? Әллә барча зыянны үзенә алып, бөек елганы саклап калдымы? Язын су баса торган меннәрчә чакрымнарга сузылган болыннар белән ни булыр? Аларның агулы булу-булмавы һәм йөзләгән колхозга зыян китермәве турында кем әйтер? Кешеләргә килгән зыянны кем каплар? Теге штрафка тартылган инженерларның акчасын түләмәсләрдер бит инде? Жирнең хәле ничек? Агуланган туфракны нишләтерләр? Барысы да әйбәт буласына, мәсьәләнең төзәтеләчәгенә ышаныч бармы, әллә бу жирләр, елга киләчәктә кешеләргә сабак булып, куркыныч тыюлык булып калырмы?

Ишелеп төшкән сораулар ана тынгылык бирмәде. Мансур дулкынлануын баса алмый палуба буйлап йөренде. Ул үзе турында, Аксай, тиздән очрашачак авылдашлары, әнисе турында уйларга тырышты. Одессага да бер тәүлектән азрак вакыт калып бара. Әмма теге авыр уйлар аны ычкындырмады. Фажига үзе, хезмәттәшләре турында уйларга этәрде. Елгада булган һәлакәтне уйлагач, ул балачактагы кебек, проектлауны тормышка ашырудан аерып карамады.. «Хезмәттәшләр» дигәндә архитекторларны да, төзүчеләрне дә күзалдында тотты. Гади кеше өчен гаепнең кайда булуы мөһим түгел, аның өчен ахыр чиктә гаепле кеше бер — төзүче. Гәжитләрдән күренгәнчә, илдәге барлык өлкәләрдә дә икътисади реформа бара. Аның асылында исә ахыргы продукциягә карап түләү ята.

Мөгаен, капитал төзелештә дә реформа уздырырга вакыт житкәндер. Проектлаучы да, төзүче дә эшнең ахыргы нәтижәсе белән кызыксынсын. Проектның бәясе кәгазьдә яки макетта килеш түгел, ахыргы, корылманың чынбарлыктагы бәясенә карап исәпләнсен. Ул чакта проектлаучылар чыгымнарны киметмәс, төзүчеләр икеләтә-өчләтә арттырмас иде. Халык хужалыгы инде планда ук корылмаларның чынбарлыктагы бәясен белеп торыр һәм елдан-ел ике тапкырга кыйммәткә төшкән корылмаларга акча эзләп интегергә туры килмәс иде. Планлы хужалыкның нык, исбатланган саннарга гына таянуын аңларга вакыт. Әлегә күпсанлы проектлар зәвыксыз план үтәүчеләрне арзанлы һәм үзләрен тиз аклаулары ягыннан гына жәлеп итә. Эш исә алар уйлаганча булып чыкмый: йөзләгән предприятиеләр еллар буена проект көченә эшли алмый, димәк, үз-үзен аклау дигән сүзнең булуы да мөмкин түгел. Әлеге гаеп төзүчеләр һәм хужалык кешеләренә төшә, бичара директорлар шелтә арты шелтә, инфарктлар ала тора. Югыйсә, гаеп бит проектның начар сыйфатлы булуында, технологиянең эшләнеп бетмәвендә.

Егерме ел эшләү дәверендә Мансур беренче тапкыр шундый авыр уйга чумды: ул үзе житешсез, кимчелекле эшкә тарыганда берәр нәрсә яхшы якка үзгәрсен өчен нәрсә дә булса эшләдеме? Хәтеренә кылт итеп цемент белән бәйле вакыйга төште.

Ул Африкада эшләгән чакта төзелешкә начар сыйфатлы цемент килә башлады. Лаборатория һәр көнне аларныкыннан үзгә анализ бирә. Бәлки эш өчен аз гына кимчелек әллә ни йогынты ясамаган да булыр иде. Әмма бу — Мансур өчен түгел. Юкка гына аны «Мистер Гост» дип йөртмиләр иде. Стандарт яхшы да, начар да була алмый, ул үзе генә була ала.

Мансур складтагы цементның барча партиясен тикшерде һәм аны яраксызга чыгарды. Бу исә зур мәшәкатьләргә китерде. Тиз арада заводка очарга туры килде. Анда баргач, алар цемент заводының илледән артык цемент маркасы чыгаруын белде. Алга киткән илләрдә исә цемент маркасы биштән дә артмый. Шушы күпләгән төр катлаулылык китереп чыгарган да инде: бу кадәр марканы стандарт югарылыгында әзерләп кара син! Әлеге күпләгән төр үз эшенә жавапсыз караган житештерүчеләр өчен кулай. Цемент житешмәгәндә, теләсә нинди не алырга әзерләр барында сыйфатны кем тикшереп торсын? Һәр төзелеш оешмасының да үз лабораториясе юк.

Мансур инженерларына анализ ясарга боерды. Нәтиҗә куанычлы түгел иде: барлык маркага да күләм, күпертелгән цифр бирер өчен тиешсез рәвештә органик кушылмалар өстәлгән. Төзелешкә бит сыйфатлы цемент кирәк. Анын шикаяте буенча, әлбәттә, тиешле чараны күрделәр. Бер цемент комбинатын аеруча мөһим төзелешләр өчен үзгәртеп кордылар. Аның тәкъдиме буенча, халыкара танылган, кабул ителгән биш марканы гына калдырдылар. Хәзер Мансурга «аеруча мөһим» дигән терминны кертү оят булып тоелды. Барлык цементка да әйтәсе булган ул терминны!

Аеруча мөһим төзелеш? Хәзер генә аңлады: төзелеш башкача да була микәнни? Өй, мәктәп, күпер, завод, фабрика, балалар бакчасын, тулай торакларны начар итеп төзеп буламыни? Югыйсә, алар «аеруча мөһим»гә кертеп каралмыйлар. Әйе, биш ел элек үз төзелешенә сыйфатлы цемент кайтарткканда, Мансур аеруча мөһим төзелешләр бар дип фикер йөртә иде. Хәзер менә үкенә... Проектлаучылар да, химик сүс житештерү комбинатын төзүчеләр дә шулай уйлаган булса? Әгәр бу төзелеш баштарак «аеруча мөһим» исемлегенә кермәгән булса? «Кайдан килгән төзелеш расизмы бу, ай-һай!» — Мансур югалып калган иде.

Әйтик, футбол матчлары Красноярскида булсынмы, Владивостокта, Хабаровскида яки Ташкенттамы — аларга Львов, Ленинград, Ереван яки Тбилисидагы хөкемдарлар бригадасы чыгып китә. Әлеге бригадага Мәскәү вәкиле күзәтчелек итә. Футбол федерациясеннән дә хөкемдар-матч инспекторы катнаша әле! Нәтиҗәсе булмаган, гел борчулар гына китергән футболга никадәр игътибар бирелә! Төзелешкә дә хөкемдар-инспекторлар, белгечләр билгеләнсен иде ул! Дәүләт төзелешенең карары ачык: койрыклы төзелешләр исемлектә азрак булсын...

Мансур уйларын башка, күңелдә якты хатирәләр калдырган вакыйлар ягына авыштырырга тырышты, юкса авыр уйлардан котылам димә. Шулчак кемдер арттан килеп аның күзен каплады. Мансур хушбуй исеннән аның кемлеген шундук чамалады... Йомшак, нәфис куллардан сизелеп торган наз бөтен гәүдәсенә таралды, кызның татлы сулышыннан оеп, ул дәшәргә кыймый торды. Аннары, кулны алып, иреннәренә тидерде.

— Шактыйдан бирле күзәтәм, сине тагын нинди уйлар биләп алган, ахры? — диде Ксана.

Кызның якын күреп соравыннан аның җаны эреде, күнелен басып торган авыр уйлары таралып, юкка чыкты. Ул, елмаеп, җавап бирде:

— Шулай тоелган гынадыр. Кәефем бик әйбәт. Бүгенге кичне ничек уздыру хакында уйлана идем. Сюрпризым бар, әмма кичкә кадәр түзәргә туры килер, гүзәлем.

Ул арада палуба туристларның шат-көр тавышларына күмелде. Сагышларын Истанбул ярларында калдырган булсалар кирәк: кәефләре шәп, күнелләре күтәренке. Барысы да бәйрәмчә киенеп, соңгы, саубуллашу мәҗлесен көтә.

Озакламый Мансур белән Ксанага Наталья кушылды һәм, өчәүләшеп, палуба буйлап сөйләшеп йөрделәр.

— Сез шулкадәр сүзгә мавыккансыз, хәтта кичке ашка чакырганны да ишетмәдегез. — Наталья сәгатенә карап, аларга серле караш ташлады.

— Бүген кичке ашка барып тормаска тәкъдим итәм, — диде Мансур.

Кызлар кызыксыну чаткылары кабынган карашларын аңа төбәде. Мансур Ксанага карап елмайды:

— Сез яраткан ресторанга соңгы кичке ашка чакырам. Тик бераз гына соңрак, түзәрсезме ?.. — диде.

—Дулкынланудан бит очлары алланган кызлар: «Ай, Мансур да, һай, Мансур» — диештеләр. Очкынланып, берсен-берсе бүлә-бүлә: — Ник

безне кисәтмәден? Алай ярамый бит инде, андый тантаналы саубуллашу мәҗлесенә әзер түгелбез, киемнәребезне алыштырырга кирәк... — дип чыркылдаштылар.

Сөенечләреннән балкып, атлый-йөгерә каюталарына киттеләр.

Кызлар ресторанга килгәндә мәҗлес кызып бара иде. Мансур залдагыларның ташыган шатлыгын аңлый алмады. Туган якларына кайтуга, тиздән коры җиргә аяк басуларына шатланамы, әллә диңгез, кораб белән шулай хушлашалармы — белмәссен? Хәер, барыбер түгелмени, иң мөһиме — бар да үзләренчә бәхетле иде.

Алар гадәттәгечә көзгеле дивар янындагы крахмал эскәтер белән капланган купшы өстәлгә урнаштылар. Өстәлдә хрусталь вазага чәнечкеле, озын нечкә сабаклы розалар бәйләме куелган иде. Чәчкәләр һәркемнең игътибарын җәлеп итәрдәй матур иде. Хуш ис бөркеп торган чәчәк бәйләменең яртысы ак, яртысы ачык кызыл розалардан тора. Букет шушы үзенчәлеге белән игътибарны җәлеп итә һәм сорау туа: ни өчен ул шулай ясалган? Берәр сер яшеренгәнме монда? Өстәл янына урнашуга, Мансур белән ике кыздан зал күзен алмады диярлек.

— Нинди матур чәчәкләр...— Ксана вазага үрелде дә розаның хуш исен күкрәген тутырып иснәде һәм як-ягына каранды: башка өстәлләрдә чәчәкләр күренми иде.

Натальяның түземлеге санаулы иде, залга күз ташлап алды да, хатын-кызларга хас кызыксыну белән:

— Мансур, мондый затлы чәчәкләр ник безнең өстәлдә генә ул? — дип сорады.

Мансур җавап урынына серле генә елмайды һәм аның «сәбәбен» мәҗлес ахырына кадәр ачыкларга вәгъдә бирде. Сере исә гади генә иде. Алар Босфордагы ачык ресторанда чәй эчкәндә, кинәт егетнең башына кызларга нинди дә булса бүләк ясыйсы иде дигән фикер килде. Юл аркылы гына чәчәк кибете күренде. Ул официанттан чәчәк кибетеннән теплоходка, аның каютасына чәчәк китертүләрен үтенде. Чәчәк бәйләменең бу кадәр купшы булуына ул үзе дә гаҗәпләнгән иде.

Кич шәп үтте: күңелләре булганчы биеделәр, җырладылар, тәмамланып килгән сәяхәттә булган вакыйгаларны кат-кат исләреннән уздырдылар. Берсенең дә иртәгәсе көн турында, ләм-мим, авызыннан сүз чыкмады. Мансур кызларның теплоходтан туры аэропортка китәселәрен белә иде. Теплоход Одессага килгәч ике сәгатьтән Кишиневка самолет күтәрелә. Бу юлы рестораннан барысы бергә кузгалды — бәйрәм тәмамланды.

Мансур да, кызлар да моны тойды. Күнегелгән җылы һавалы, якты йолдызлы көньяк төнен салкынча һава алмаштырган. Диңгезнең шаулавы үзгә, аның салкын тамчылары палубаны коендыра. Дулкыннары, усалланып, теплоходны селкетә. Бу үзгәрештән теплоход читтә калмаган — музыка тынган, әерактагы утлар кисәтү утлары булып тоела.

—Шуның белән шул, мин сезгә вокзалдан шалтыратырмын... — диде әкрен генә Ксана.

—Кирәк бит, ә! Сәяхәт дәвамында беренче шторм.... — Биткә килеп сыланган салкын җилдән ышыкланып, әңгәмәне дәвам итәргә тырышты Наталья.

Әмма әңгәмә куермады... Һәркайсы үз уена чумды. Бераздан саубуллаштылар...

Инде йокыга талам дигәндә, теге мәкалә Мансурның исенә келт итеп килеп төште. Тукта, бердәнбер рәсми җавапны кем җибәргән әле? Ялгышмаса, хат астында хатын-кыз фамилиясе тора, обкомның икенче секретаре дип язылган иде.

Йокысы тынычсыз булды, берничә тапкыр саташып уянды — әллә дулкынланудан, әллә дингез шавыннан — анламассың. Дулкынланудан дисәк, дөресрәк булыр: ул бит иртәгә өйдә булачак. Актүбәгә очасы самолет Кишиневныкына караганда бер сәгатькә соңрак күтәрелә. Шунысы гаҗәп: йокылы-уяулы шушы төндә дә ул Африка, андагы төзелешләр белән саташты. Башкарган эшләренә хисап тотты бугай...

Иртә белән шаккатмалы хәл: дингез элеккечә җәйрәп ята, күктә, ягымлы нурларын сибеп, кояш балкый, шаян җил биттән сыйпап уза. Теплоход өстендә акчарлаклар бөтерелә, димәк, ярга ерак калмаган.

Кызлар иртәнге ашта күренмәде. Йоклап калдылар микән? Әллә чәчтарашханәгә киткәннәрме? Ни дисәң дә Ауропадан кайталар бит.

Мансур палуба буйлап әйләнеп килде. Су яратучылар бассейнны сырып алырга өлгергән, араларында берничә хатын-кыз да бар. Төньякта яшәүчеләрдер болар, мөгаен, теплоходта уздырасы соңгы сәгатьләрен кызынып, коенып, гомумән, файдаланып калмакчы булалар. Мансур исә рәсми хатның соңгы юлларын тәгаенләү өчен китапханәгә китте. Кирәкле гәҗитне тиз тапты. Хәтере ялгышмаган икән, кулны партия обкомының икенче секретаре куйган. Гәҗит төпләмәләрен урынына куйгач, Мансур китапханә мөдиренә рәхмәт әйтте һәм саубуллашып чыгып китте.

Кинәт...электр тогы тәэсир иттемени, барган җиреннән туктап калды. Төньяк Казакъстан! Ул бит анда тегермән белән элеватор төзеде. Вакыт ягыннан карасаң, гәҗиттәге елларга туры килә... Мансур барысын да исенә төшерде: ул комбинатны яхшы белә, бик яхшы белә! Дулкынланудан ул якындагы шезлонгка ашыкты. Аның янакларына ут капты, үзен уңайсыз хис итте...

Ул елларда Казакъстанда тегермән белән элеваторны кирәк санынча төзегәннәр иде, шуңа трест башка сәнәгать оешмаларыннан заказлар кабул итә башлады. Зур химия еллары иде, бөтен илдә әлеге сәнәгать өлкәсендә комбинатлар күпләп төзелде. Тегермән һәм элеваторны тапшыргач, Мансур да «химия» төзелешенә командировкага эләккән иде.

Менә хәзер, гәҗиттән укыгач кына, комбинатның тулы исемен белде. Ә ул чакта...

Төзелеш өченче елын дәвам итә иде инде, беренче көннәреннән үк авыр барган, әле бу, әле теге җитмәгән. Мансур бу койрыклы төзелешнең ахырына кадәр эшләргә тиеш булса да, ярты елдан китәргә мәҗбүр булды. Проект документациясе әзер булмаган төзелеш туктап калгач, Мансурны трестка чакыртып алдылар. Шаккатмалы хәл: төзелешне башлагыз, документациянең калганын аннары бирербез, дигән булганнар. Мансур комбинат төзелешенә тулысынча кереп китә алмаганга, хәтереннән җуелган булган, күрәсең. Менә ничәмә-ничә еллардан соң исенә төшерде.

Бу корылманы ул салмады һәм ул тапшырмады. Ярты ел буе Шәяхмәт Корбан улына, үзен бу сакаллы төзелештән алуын сорап, телеграмма арты телеграмма яудырды. Ул үзен гаепле санамады, чөнки теләсә дә, берни эшли алмый иде.

Эшсез һәм чарасыз узган шул ярты ел эчендә ул инженерлар белән проектны тикшереп чыкты. Әгәр төзелеш кузгалып, чын-чынлап эш кайный калса, эшчеләргә түләргә акча юк иде, чөнки бар булганы шушы эшсез утырган үле сезонга түләнеп барылган. Проект документларын тикшергәндә чистарту корылмаларын комбинат өчен яраксыз дип тапканнар иде. Химиянең көнкүрешкә ныклап керүен күздә тоткан хәлдә, инженерлар чистарту корылмаларының төп җитештерү корылмасыннан да кыйммәтрәк булачагын таныды. Бу фаразлау, уйланулар гына түгел, чынбарлык, исбатланган нәрсә иде. Шул чакта ул һәм аннан өлкәнрәк, исемле, танылган төзүчеләр нәрсә эшләде? Проект институтына, Дәүләт

төзелешенә мөрәҗәгать иттеләрме, гәҗитләрдә мәсьәләне күтәрделәрме? Юк шул, кыл да кыймылдатмадылар. Бу сөйләшүләр прораб булмасеннән читкә чыкмады. Их, дөрес уйлаган бит алар ул чакта! Заказ бирүче, генераль подрядчы «проект институты эше бу, андагы докторларның башы авыртсын» дип исәпләделәр шул. Йә шуннан? Инде сонрак, тәҗрибә туплагач, ул бу хакта сүз кузгаттымы соң?

«Ярар инде, мин эндәшмәдем ди, безнен өлкәдәге абруйлы шәхесләр, әйтик, төзелешкә җаны-тәне белән бирелгән кешеләр ник читтә калды? —дип өзгәләнде ул. — Терентий Семенович Мальцев, мисал өчен, гомере буе җирне саклау һәм аңа хөрмәт белән карау өчен көрәште, ул кайда? Вакытында ул нинди генә сүзләр ишетмәде, әмма чигенмәде һәм вакыт аның хаклы булуын раслады».

Шундый тәҗрибәсе була торып, ул чистарту корылмалары турындагы мәсьәләне күтәрергә тиеш идеме? Әйттеме, чыгыш ясадымы, яздымы ул чакта? Әйе, язды, әйтте дә, әмма үзе җаваплы булган корылмага карата гына. Димәк, үз каланчасыннан ерак китмәгән булып чыга... Үз эшенә битараф булмаган белгечләр үз бакчасыннан читкәрәк чыгып фикер йөртә, җәмәгатьчелекнең игътибарын каршылыклы мәсьәләләргә юнәлтеп, теләкләренә ирешә дә. Ул да бит төзелешнең төп кагыйдәләре турындагы мәсьәләне күтәрә ала иде. Чыгымнар аз, арзанлы, тиз аклана торган проектлар кат-кат тикшерү узарга тиеш! Коры сүзгә ышанырга ярыймы соң? Күпме кирәкмәгән проект кире кагылыр, күпме акча янга калыр иде. Булыр-булмас бер проектка ябышканчы, биш проектка акча түгеп, арасыннан берне сайлап алу дөресрәктер. Монысы — хуҗаларча эш итү дип атала...

Кем-кем, ләкин ул ил өчен капиталь төзелешнең күпмегә төшәсен һәм уңышсыз проектның никадәр зарар саласын яхшы белә. Төзелеш исә елдан-ел кыйммәтләнә бара. Хәзер гади комны да зур шәһәрләргә меңнәрчә чакрым илтергә кирәк. Комнан башка измә ясап булмый. Ком, вак таш, кызыл балчыкның чыганагы сәнәгать үзәкләре янында күптән юкка чыкты. Шулай ук урман, металл, пыяла, су һәм энергия — берсе-бер кирәк дәрәҗәдә түгел. Санаган саен саный торган заман килде...

Чит илдә аңа еш кына теге яки бу проектны бәяләү хакында мөрәҗәгать итәләр иде. Нәтиҗә ясаганда ул беркайчан да ялгышмады. Ни өчен ул үз иленең проблемаларыннан читләште? Әллә читтән караганда яхшырак күренә башладымы? Бәлки, хәзер тәҗрибә туплагач, аңа төзү белән генә түгел, исәпләү белән дә шөгыльләнә башларгадыр?.. Үз-үзенә ышанычы нык, көче күп — бу аз нәрсә түгел...

Уйлар, уйлар, бетмәс-төкәнмәс уйлар Мансурның тәмам тынычлыгын качырды...

Аның тормышка янача карашы һәм эш тәҗрибәсе барысын да янабаштан башларга кирәклеген сиздерә иде...

Еракта Одесса күренде. Теплоход өстендә, талгын музыка тавышын күмеп, һәрвакыт ач тамакларын кайгырткан акчарлакларның ачы тавышы ишетелә...

Мансурның элеваторлы һәм пычрагын елгага агызган комбинатлы туган ягына бер сәгатьлек ара калып бара иде...

*Октябрь 1985 ел, Ташкент*

**Рөстәм ГАЛИУЛЛИН** *тәрҗемәсе*



Лениза
Вәлиева

# УРАП АЛА МОҢ ДӘРЬЯСЫ

* * *

Җылы кояш никтер кинәт сүнде,
салкын җилләр исте — йөрәк туңды.
Күз яшьләре инде кипте күптән,
тар бушлыкта калды бөтен җиһан.
Офыкларга китеп югалдылар хисләр,
күңел дәрьясында калды ялгыз кораб.
Ярсып шаулый, котырынып, тик бер дулкын,
ә мин һаман горур атлыйм, алга карап.
Берәм-берәм сүнде йолдызлар да,
җиргә төште күктә йөзгән хыяллар да,
Сүнде ялкын... Сүнде өмет...
инде нишлим?
Башым имим әмма, алга карыйм.
Томан булып йөрәгемә сарыла ачы сагыш,
күңелемдә хәзер минем тик бер балкыш:
Күрергә, дим, тик бер тапкыр, соңгы тапкыр,
«сау бул», диеп әйтер өчен, нурлы йөзең...

* * *

Мин елмаям...
ярларына сыймый
Ташый хисем.
Күккә багам...
Ә кем әйткән
ай, дип,
бары җисем?! –
Лепер-лепер килгән йөрәгемнең
бер җепселе
Җанны Галәм белән тоташтырган
чор мизгеле...

---

Лениза ВӘЛИЕВА — *шагыйрә; «Диңгездә йолдыз коена» исемле китап авторы; Казанда яши.*

...Күзне йомам.
Иренемне юа тозлы тамчы.
Күк күкрәген телеп үтә гүя
утлы камчы –
Атыла да йолдыз
Юкка чыга...
Хәтер кала...
Үз рухыңны күрим дисәң әгәр,
Күккә кара...

...Чираттагы хыял–йолдызымны
учка алам...
Яшем кипте...
Мин еламыйм бүтән...
күр, елмаям...

* * *

Төнгә керә шәһәр...
чираттагы көнне
Төпсез упкын авызын ачып
йота вакыт...
Әлегә тик яралгы –
Туасы таң
тыныч йоклый күк карынында
кырын ятып...

Төн караңгы.
Ә шулай да кемдер бераү
ара–тирә киткән күккә йолдыз атып...
Әсәрләнеп калган кебек бөтен Галәм,
бу шау–шулы җирдә тынлык
тәмен татып...

* * *

Ике уй кисешкән
ноктада
күкләрдә бер йолдыз
Яктыра.
Буй җитмәс биеклек
ят аңа.
Ул бары кул сузган
арада.
Тик икәү белмиләр
бу хакта.
Карашлар һаман да
офыкта.
Килер күк зур бәхет
иртәгә...
...Таң ата. Төн күчә
үткәнгә...

* * *

**Җир белән Күк тоташкандай**
**карлар ява.**
**Ага дөнья чиксез төпсез ак дәрьяда.**
**Без дә шунда:**
**җирдә...**
**күктә...**
**Әллә кайда...**
**Тилергәннәр кебек хисләр,**
**шашкан уй да.**
**Әй йөзәбез ак дулкындай**
**кар тузгытып.**
**Бәхет үзе көтә безне,**
**маяк тотып...**
**...Мәңгелектән килгән өн бу,**
**хыял түгел.**
**Өзгәләнеп шулай кышны көтә күңел.**

* * *

**Тирән тынлык һәр тарафта тоташ.**
**Ярдан ярга йөзә-йөзә бата кояш.**
**Тыелып кына күңелем моңлы бер көй көйли.**
**Аһ-зарымны сизгер җанлы скрипкам сөйли.**
**Ташкын булып урап ала моң дәрьясы**
**һәм тирбәлә шул дулкында бар дөньясы!**
**Сихерләнеп басып торам, хәйран калып.**
**Их, бу аһәң! Булса иде сүзгә салып.**
**Татлы төер күтәрелә, җанны өтеп,**
**күзләремнән яшь пәрдәсен сүтеп.**
**Бер чарасыз көйнең колы булып калам,**
**эреп бетеп, җырга әйләнеп агам.**
**Белмим инде — ләхетемме, тәхетемме?..**
**суга салып китеп барам бәхетемне...**

* * *

**Җигүле ат ераклаша бара.**
**Сүзсез генә калам озатып,**
**арба түрендәге нәни кызны**
**Садә балачакка охшатып.**
**Нидер китә яннан кайтмаска дип,**
**гүя эреп күздән югала.**
**«Туктат! Йөгер!» — дип пышылдый йөрәк,**
**акыл тарта кулдан: «Кузгалма!»**
**Ә мин тыныч кына карап калам,**
**йөрәк сүзен читкә тибәрәм.**
**Китә... Китә мәңге кайтмаска, дип.**
**Каршылыксыз шулай җибәрәм...**

Тәлгат Галиуллин

# ЗАМАНА БАЛАЛАРЫ

ИСТӘЛЕКЛӘР

Икенче кисәк

## Бишенче хат

Авыруымны күпмедер күләмдә авызлыклап, кафедра мөдире вазифаларын үтәп, дәресләремне алып бара башлагач кына икенче афәт куып житте. Мине аякка бастыруга табиб, рухи таяныч буларак иң күп көчен керткән хатыным Галия мине ташлап китте. Күк йөзендә болытлары да күренмичә, кинәт килеп шыбырдап яуган янгыр кебек кабул ителде бу гарасат. Мин үзем истәлекләрдә, көндәлекләрдә артык шәхси, авторның гаять үзенә генә кагылышлы хәлләрне артык җәелеп сурәтләүләрне яратмасам да, адәм баласы үзенең киләчәгенә бер кәррә дә күрәзәчелек итә алмавын, кыска гомеренең һәр мизгеленә сөенеп яшәргә кирәклекне искә төшерү өчен генә бәян итәм шәхси югалтуымны.

2003 нче елның июль аенда Дәрвишләр каласында урнашкан 8 нче шәһәр хастаханәсенә чираттагы кизү дәвалануга яттым. Укытучыларның ял вакытында нигә вакытны заяга уздырырга. Үзе дә берничә елдан соң кинәт вафат булган баш врач Рәшит Вагыйз улы белән мөнәсәбәтебез дустанә. Урман янында гына табигатьнең ямьле бер жирендә урнашкан бу хастаханәне яңасын төзибез дип юкка чыгардылар. Бер атна уздымы, юкмы икән, палатага олы улым килеп керде. Гадәттә авызы ерык, юк-бардан фажига ясамый торган Илшатның йөзе карангы, күзләре эчкә батканрак күренде миңа.

—Нишләп вакытлы-вакытсыз?

—Әнине больницага салдылар.

— Нәрсә булды, авария-мазарга эләкмәгәндер бит? — дип, аптырап калып, сорау артыннан сорауны тондыра башладым.

— Юк, бернәрсә дә булмады, — дип, әйтергәме икән, соңрак аңлатыргамы диебрәк уйлап торгандай булды да:

—Ашказанында рак тапканнар.

— Әле йөгереп йөри иде бит. Мине хастаханәгә дә үзе әзерләп, кирәк-яракны барлап озатты.

— Кинәт кенә ул үзен начар сизә башлады. Ашыгыч ярдәм алып китте

---

*Ахыры. Башы узган санда.*

дә, ике көн эчендә куркыныч диагноз куйдылар. Беребезгә дә әйтмичә, бер елга якын чирләп йөргән.

–Дәвалап булырлык диме соң?

– Юк, әти, шеш иң соңгы стадиягә житкән диделәр. Өйгә алып кайтырга куштылар. Бүген төштән соң Булат белән алып кайтачакбыз. Син ничек? — дип, сораулы карашын миңа төбәде.

–Хәзер табибтан сорыйм да, өйгә кайтам.

Авыруның үзенә әйтмәсәләр дә, улларыбызга: «Торса, бер-ике атнага сузар, артыгын яши алмас», — дип кисәткәннәр. Коточкыч чире белән Галия бер ай тирәсе көрәште. Төрле дарулар юллап, киңәшебез, игътибарыбыз белән ярдәм итәргә тырыштык. Чаллыда яшәүче медицина хезмәткәре сеңелем Сәгъдия: «Петербургта ракны дәвалау ысулы тапканнар, дип ишеттем. Түләүле клиника икән. Биш йөз илле мең кирәк, ди. Безнең больниста эшләүче бер хирургны рак белән шунда жибәрделәр. Без зур нәсел, әйдәгез, кем күпме кертә ала, акча жыя башлыйк», — дигән тәкъдим кертте. Инде без акчаны туплауга керешкән идек, Сәгъдия шылтыратып, файдасы тимәгән, теге хирург үлгән, үзләре турында шундый хәбәр таратып йөрүче шарлатаннар булып чыктылар дип безнең өметне өзде. Августның урталарына чаклы Галия үзе берни белмичә, әллә безгә сиздермичә, уза торган гадәти шеш дип сөйләшеп ятты һәм кинәт аңын югалтты.

Галия бөек материяләр, ак жилкәнле шашкын хыяллар белән саташып йөрүне өнәми, иң гади, гадәти жир бәхете белән яши, шуннан тәм таба торган кеше иде. Аның бар сөенече гаилә бәхете, ике улы, аларның уңышлары дисәң дә зур ялгыш булмастыр. Галиянең ярларына кайтып төшкән инеш кебек тыныч холкы, юк-барга күтәрелеп бәрелмәве, безнең өйдәге тынычлыкны борчыган «дусларның», кызык эзләп йөрүчеләрнең әүвәл кытыгын китерә, аннан соң саруларын кайната, ачу бизләрен уята, котырту алымнарын «яңартып» торырга мәжбүр итә. Миңа бик сирәк сиздерсә дә, Галиянең жаны бәргәләнүен, телефон аша килеп житкән «серләр» ачылганда тавышын күтәребрәк жибәрсә дә, тузынып талашулардан үзебезне тыярлык эчке әзерлегебез булган, күрәсең.

Менә шул кадерле кешең күз алдында эреп, караңгылыкка чумып, күк йөзедәй аяз, зәңгәр күзләрен мәңгелеккә йомсын инде.

Галия бик чыдам кеше иде, берәүне дә борчырга теләмәде, тәненә яман чир ябышканын, аңа дәва юклыгын бер ел элек белсә дә, беребезгә дә әйтмәгән икән. Минем авыруымны яхшы белгән кеше буларак, бигрәк тә миңа сиздермәде, саклады. Хәлен бераз жиңеләйтеп булмасмы дип, төрле дарулар кулландык. Сәгъдия гел укол кадап торды, сулышы авырая башлагач, малайлар кислород мендәре табып алып кайттылар. Мәгәр аңа ярдәм итеп булмый иде инде. Августның 21ендә ул безне ташлап китте, иске татар зиратына күмелде.

Кырык ике ел бергә яшәвебез чорында төрле хәлләр булгандыр, әмма нигездә без тату яшәдек. Балалар табибы буларак та ул бар көчен улларыбызны лаеклы кешеләр булып үстерүгә бирде. Минем хуҗалык эшләренә сәләтсезлегемне белгәч, йорт мәшәкатьләрен дә (Алабугада аерым өйдә яшәдек) үз өстенә алды, зарланмады, сыкранмады. Бигрәк тә, мин әшәке чиргә таргач, мине юк-бар белән борчымаска тырышты. Әни үлгән көннәрдә мин әлеге дә баягы хастаханәдә идем. Ул шәфкать туташларына «Тәлгат Галиуллинга әнисенең үлеме турында капылт кына әйтмәгез, әлегә бик авыр хәлдә дип кенә әйтегез. Бу хакта үзе соңрак белер», дип кисәткән. Менә шулай минем турында кайгыртып, үзе фани

дөньяны ташлап китте. Теге гасырның соңгы елында ук бу гөнаһлы дөньяны ташлап китүгә бөтен мөмкинлеге булган мин, Тәлгат абый, һаман яшим, укытам, хәтта тәңкыйть мәкаләләре, фәнни хезмәтләр, әдәби әсәрләр дә язам. Беренче хатыным рәнҗеп ятмасын, бу истәлек язмаларым аңа дога булып барсын.

Галиянең еллыгын уздырганчы, минем тирәдә генә яшәгән сеңелем Сөльма, һәрдаим янымда булырга тырышып, бөтен каприземне үтәп торды. Укытудан, җыелыштан кайткан төшкә фатир пөхтә итеп җыештырылган, ашарга пешкән, киемнәр юылып үтүкләнгән булыр. Яраткан апаларының, җиңгиләренең (әти-әни вафатыннан соң ин олы бала буларак нәсел «башлыгы» вазифасы миңа калды) елын уздыруга ике яктан да, татарларда кабул ителгән гадәт буенча, бар туганнар, аралашкан, күмешкән күршекүлән, шул исәптән туган авылым ерак Кычытканлыдан хатыны Сания белән кече энем Әхәт тә килгән иде, табигый ки, Коръән укытып, аш мәҗлесен уздырганнан соң, кунарга олы абыйлары янында калдылар. Әти-әни догасы, гомернең кыскалыгы, бер-беребезнең, яшәешнең кадерен белү, туганлык хисләрен буыннарга тапшыруның елдан-ел авырлаша, кешенең кырыслана баруы турында, янәдән чәйне янартып, бик озак сөйләшеп утырдык. Гаилә нигезен саклап тору, колхоз заманында баш агроном, соңрак авыл җирле советы рәисе һәм башка шөгыльләр тәэсирендә Әхәт әти кебек авыл акылын үзенә сыйдырган философ булып бара дип сокланып утырдым. Йокларга соң гына яттык.

Иртән нәрсәдер быгыр-быгыр кайнаган тавышка һәм бигрәк тә бүлмәне хуш исе белән хозурлаган аш исенә уянып киттем. Песиләр «өйрәткәнчә», кан йөрешенә ярдәм итеп, тәмләп киерелеп-сузылып алып, киенеп кухняга чыктым. Килен бик эшлекле кыяфәт чыгарып шунда йөри.

—Сания, нәрсәдер пешерәсеңме әллә?

—Сезгә аш пешерәм.

— Соң бит кичә кунаклардан калган тәмле ризыклар белән суыткыч тулы, ике-өч көнгә җитәрлек. Бәлешнең дә яртысы шул килеш калган.

— Сөльма ападан «әзи нәрсә ашарга ярата?» дип сораган идем, «ул шулпалы ашсыз тормый», диде. Кичә токмачлы ашыбызны бүлеп бетергәнбез. Шуңа күрә сез торган җиргә кайнар ризык әзерләп өлгерим дип тырышам. Ун-унбиш минуттан әзер була.

Мин көлемсерәп кенә куйдым да, аңлатып, ачыклап тормыйча, борчылган өчен рәхмәт әйтеп, юынырга кереп киттем. Дөресен әйткәндә, шулпалы аш минем яраткан ризыгым түгел иде. Сөльманы гел борчып тормас өчен токмач, ешрак кәбестәле аш пешертеп куям да, шуны кибеттән ала кайткан азык-төлек белән аралаштырып, ике-өч көн тамак туйдыра идем. Үзенең дә исәнлеге әллә ни булмаган сеңелемне кызгану мине «шулпачы» ясаган да куйган. Үзе бу хакта миңа зарланырга җөрьәт итмәсә дә, бер сөйләшүдә кайнар плитә янында берничә сәгать басып тору авыр дип ычкындырганын миңа җиткерделәр.

Артык зур булмаган фатирымны җыештырып, ашарга пешереп торырлык кына кеше яллый алсам да, бик өлкән һәм бөтәшкән чирле генә «сиделка» тота дип, бу алымнан баш тарттым. Язмыш шундый сынау җибәргән икән, гаиләле тормышка өйрәнгән кеше янында тормышыңны бизәп яшәрдәй зат булырга тиеш. Мактанырлык яшь булып, йөгереп йөри алмасам да, үземне әле канәгатьләнерлек сизәм, тырышлыгым, үз-үзен йөртә алган гәүдәм бар, ярату, яраттыра белү гыйлемен дә аз-маз булса да үзләштердем кебек. Ялгызлыкның туктаусыз борчып, уйландырып торган сагыш икәнен дә белә идем. Буйдаклыгым хәбәре кирәк кешеләренә барып җиткәч, хәлне,

исәнлекне белешүчеләрнең, мәктәпләргә очрашуга чакыручыларның саны артты, аларның күбесе ялгыз хатын-кыз затыннан иде. Сул аякка аксабрак йөрүемә карамастан, «нигә берүзең интегеп яшисең, мә ал мине хатынлыкка», диючеләре дә булды. Элек яшертен-орынтын очрашып йөргәләгән хатын-кызның берсен дә түремә алып кайтып утыртасым килми. Эчке тоемым «абзый, ашыкма, үзенә дигән бәхетең каядыр посып, качып сине көтеп ята торгандыр», дип пышылдый кебек. Кемгә нәрсә кирәген, кемнең кемлеген шул яшькә житеп аңлый идем. Кайсынадыр минем фатирым кирәк булса, кемсәсендер минем дәрәжәм үзенә тартырга мөмкин... Бөтенләй бернәрсәгә дә дәгъва итмәгән, сине яратып кына кушылган, кемнеңдер мине зар-интизар булып көтеп торуы кебек әкияткә ышанмасам да, артык комсыз, үз ягына гына каера торган әрсезе эләктермәсме дигән уй да аң төпкелендә көйрәп ята иде.

Минем хәлгә калган, мин яхшы белгән зыялыларның беришесе дөнья бизәкләре белән бик ихтыяж булганда гына очрашып, ирекле тормышлары, бәйсезлекләре, хөрриятта яшәүләре белән мактанышып йөрсәләр дә, соңыннан балалары, оныклары фатирларын, мал-мөлкәтләрен килгән кеше белән бүлешү ихтималыннан куркып, аталарына, бабаларына өйләнергә «кинәш» бирмәгәннәре мәгълүм булды. Бөтен ил башына төшкән сугыш, ачлык, эпидемия, жир тетрәү шикелле афәтләрне күпме генә авыр булса да, бергә кичерәсең. Кешеләрнең начар сыйфатларын ачып салган, һәркемнең башына чүкеч белән суккандай килеп төшкән низаг фатир, акча, мөлкәт мәсьәләсе икәнне дөнья әдәбияты күптәннән яктырта килә. Безнең чорда ул И.Ильф белән Е.Петровның «Двенадцать стульев» һәм «Золотой теленок» сатирик романнарында, М.Зощенконың, бездә Ф.Шәфигуллин, Ф.Баттал һ.б. хикәяләрендә бик тә үтемле яктыртыла.

Киләчәк тормышымны яңа кеше белән бәйләгәндә, янә бер үзенчәлек исәпкә алынырга тиеш иде. Галиянең әнисе Әминә апа да минем белән калды. Улы белән кызын бакыйга озаткач та әле ул шактый яшәде. Миңа әби тиешле кеше дөньяның ачысын-төчесен татыган, ире сугышта һәлак булгач, ике баласын аякка бастыру, югары белем бирү өчен көчен, сәләтен кызганмаган. Аның кырык тартмачылар кебек, төрле тауарлар төялгән «ач арбасын», йә кул чанасын тартып Чаллыдан Ижауга киемнәрен онга алыштыруга барулары турында сөйләүләре Аяз Гыйләжевның «Язгы кәрваннар» бәянының тормышчан жирлеген искә төшерә иде. Ниләр генә күрмәгән ул чорда сугыш аркасында тол калган хатыннар башы. Улы Наил белән кызы Галия башлы- күзле булгач кына, үзенә күптәннән кызыгып йөргән, хатыны ирен өч баласы белән ташлап, бер журналистка ияреп, Урта Азиягә чыгып киткән Мирза абзый белән чәчен бәйли. Ике кызын бергә үстерәләр. Әүвәл ире, аннан ике баласы үзеннән иртә фани дөньяны ташлап киткәч, Әминә апа бөтенләй ялгыз калды. Пенсиясеннән кала мөлдерәп торган байлыгы, калдырыр фатиры булмаган әбинең оныкларына, киленнәренә, туганнарына кирәге юк иде... Хәтта ул үстерешкән Мирза абый кызлары да бөтенләй күренмәс булдылар. Беренче мәлне аны чиратлашып утырмага алып киткәләсәләр дә, бу уен барысын да тиз туйдырды. Әминә апа үзе дә мөстәкыйль фикерле, үз сүзен өздереп әйтә торган узаманлык — лидерлык сыйфатларына ия кеше иде. Ризыкны үзе пешереп ашарга ярата, һәрвакыт майлы, өсте жыелмаган ашка өстенлек бирә, тозлы кыяр белән помидордан башка яшелчәләрне «кешегә» дә санамый. Сенелем Сөльма белән аралары «Кубан казаклары» фильмындагы кебек, ал да гөл булып тормаса да, ачуланышып-кычкырышып яшәү дәрәжәсенә төшмәделәр. Шуңа күрә өйләнә калсам, хатыным мине дә, үзенә бөтенләй ят әбине дә

тигез күрергә тиеш иде һәм шуны искәртәсе килә: хәләл җефетем — Фәүзия әбине әнисе кебек якын күреп, мөмкин булганнын барысын да (төшке аш вакытында ашатып, асларын алыштырып китә иде) зарланмыйча башкарды. Әминә әби ана рәхмәтләр укып, 94 яшендә иске татар зиратына кызы янына кереп ятты.

Яңа гаилә кору мәшәкатьләренә баш-аягым белән кереп чумып, ниндидер бер катгый карарага килгәнче, мин ял итеп, тын алырга булдым. Ул чорда Горький исемен йөртүче парк янында, аңа сыенып утырган, күпләрнең күнеленә хуш килгән Казан шифаханәсе бар иде. Еракка чыгып китәргә курыккан яисә матди хәле чикле өлкән яшьтәге кешеләр, укытучыларны күздә тотканда, атналык сәгатен җайлый алганнар, анда бик теләп, рәхәтләнеп ял иттек. Заманча җиһазлары, бүлмәләре, заллары барысы да зәвык белән бизәлгән иде. Кызганычка каршы, кеше исәнлеге, аны саклау турында авыз суларын корытып сафсата сатырга яратсалар да, чынлыкта, хакимият дилбегәсен кулларында тоткан түрәләр, еш кына комнан аркан үрүдән узмыйлар шул. Ял итүчеләрдән дә, халыктан да сорап тормыйча, гөрләп эшләп торган, башкалабызның мактанычы булган шифаханәне юкка чыгардылар да, урынын «Ак-Барс» хоккейчыларына бирделәр. Спортны яратсак та, ошбу команданың Татарстанны дөньяга танытуга керткән өлешен таныган хәлдә дә, әзерлекле табиблары, тикшерү, дәвалау кирәк-ярагы белән тәэмин ителгән, шифалы суы агып торган оҗмах төбәген алка «тәгәрәтүчеләргә» бирү гафу итмәслек бер гамәл булды. Туктаусыз төрле шәһәрләргә күчеп йөреп, гел юлда яшәгән уенчылар өчен Казан читеннәнрәк яисә берәр буш мәйданны табып булмас идеме дигән сорауны калкытып куюдан да хәзер файда юк. Казанның мактанычы, сөенече булган университетны югалту шикелле үк, Казан шифаханәсен бетерү дә , XXI гасырның иң үкенечле, кире кайтарып булмаслык аянычларыннан дип саныйм. Бу шифаханәнең язмышын хәл иткән кешеләр үзләре чит илләрдә генә ял иткәч, бу үзәкнең кадерен бәяләп җиткермәделәр булса кирәк. Мин бу шифаханәгә рәхмәтле, чөнки ул «соңгы сулышын» алыр алдыннан миңа яраткан хатыным Фәүзияне бүләк итеп калдырды.

2004 елның сентябрендә Казан шифаханәсенә 18 меңгә юллама сатып алдым. Йөз сум акчаң булганчы, йөз дустың булсын дигәндәй, Алабугадан ук килгән танышым баш табиб Ю.Е.Сахабутдинов үземне аерым бүлмәгә урнаштырды.

Берничә көн ял иткәннән соң, дәресләргә әзерләнә башладым. Чираттагы лекциям хәзерге татар әдәбиятында яңача фикерләүгә, модернистик алымнарга багышланган һәм, шул унайдан, Зөлфәт Хәким драматургиясен дә иңләргә тиеш иде. Шифаханәдә шактый бай, шунда ял итәргә яраткан татар язучылары үзләре бүләк иткән әсәрләр белән үзенчәлекле китапханә эшли дип ишеткән идем. Ходай яраткан колына чыгарып куяр юлына дигәндәй, бәхетем шунда булуы ихтималын күз алдыма да китерә алмыйча, аяклар мөмкинлек биргәнчә, җилфер-җилфер атлап, китапханә ишеген киереп ачып, эчкә үттем. Ял итүчеләрнең күнел сихәтләрен күрергә чакырылган зал миңа шактый иркен тоелды. Уң якта тәртип белән китаплар тезелгән тимер стеллажлар тора, түрдә, өстәлләрдәге газета-журналларны караштырып, берничә кеше утыра. Буйдакның акылы — ике күзе диләр. Ишектән берничә адымда гына сул якта урнашкан өстәл артында утырган ханымга күзем төште. Мин килеп керүгә ул да торып басты. Өстендәге бәйләнгән зәңгәрсу свитерын төртеп торган күкрәкләрен, коңгырт чәчен, түгәрәк битен иңләргә дә өлгермәдем, китапханә хуҗабикәсе (мин шулай

дип фаразладым, анда баш хисапчы утырмас бит инде) өстәл янынннан чыгып, миңа таба берничә адым ясады:

— Тәлгат абый, рәхим итегез, ни йомышыгыз төште безнең китапханәгә, — жөмләсе, аннан да бигрәк, исемем белән мөрәҗәгать итүе кәтелмәгәнрәк фал булды. Аз гына саңгыраурак тоелган тавыш та, уртачадан чак кына озынчарак буйлы, җыйнак кына гәүдәле ханым үзе дә миңа таныш түгел иде. Гаҗәп нәрсә. Алабуга, Казан пединститутларында, университетта кырык ел дәвамында миндә укыган студентларны истә тотып буламы соң? «Ми тартмасы» миңа имтихан биргән талипларның барысын да хәтерләсә, өлгергән карбыз кебек, күптәннән шартлаган булыр иде. Бигрәк тә кызлар гаилә корып, фамилияләрен үзгәртеп, балалар тапкач, дөнья куып, танымаслык дәрәҗәдә үзгәрәләр. Китапханәченең дә минем лекцияләрне тыңлаган элеккеге студентым булуына бер кәррә шиккә дә урын калдырмыйча, битараф кына сорау бирдем.

— Сез мине каян беләсез? Миндә укыдыгызмы?

— Юк, миңа сездә уку насыйп булмады. Мин мәдәният институтын тәмамладым, ләкин сезне күптәннән беләм. Онытkансыздыр инде, мин эшкә, сез Толстой урамындагы укытучыларның белемен күтәрү институтына лекция укырга бара идегез, һәрхәлдә, автобуста сөйләшкәндә шулай дигән идегез.

Әлбәттә, бу очракны оныткан булсам да, ахмак хәлдә калмас өчен «педагогик» алым кулландым.

— Шулайрак булды бугай. Искә төшкән кебек, — дип, хәрәмләдем. (Соңрак, Миллениум күперен чыкканда, автобуста сөйләшеп бару, шунда ук сөйкемлелегенә игътибар итү исемә төште).

Ханым миңа бер адым якынрак килеп, сорап куйды:

— Сезгә бирәр китап кирәкме, — диде дә, бер тын алырлык кына тукталыш ясап, астыртын киная белән өстәп куйды:

—Үзегезнекеләрнең хәлен белергә кердегезме?

Әһә, ханым чегән арбасыннан төшеп калганнарга охшамый. Дөрес, минем җавапны көтеп тә тормыйча, үзе үк сүзен дәвам иттерде.

— Сезнең «Замана балалары»гыз, «Тәүбә»гез, кайсыдыр тәнкыйть китабыгыз да бар бугай. Анысының исемен хәтерләмим.

— Миңа Зөлфәт Хәкимнең драма әсәрләре кирәк иде, — диюемә, ханым ялт итеп, шкафлары арасына кереп тә китте, тиз арада нәкъ кирәкле китапны алып чыгып, язып та бирде.

— Рәхим итегез. Санаторий кенәгәсен сорап тормыйм, бардыр дип уйлыйм.

Мин ханымның килешле гәүдәсеннән күземне ала алмыйча, пиджәк кесәсендәге шифаханә кәгаземне бирергә онытып торам икән.

Атлар кешнәшеп, кешеләр сөйләшеп таныша дигәндәй, икебезнең дә әңгәмәне өзәргә теләге юклыкны сиземләп, урында таптанып торган арада, ярдәм янәдән хуҗабикә ягыннан килде.

— Мин үзем дә шигырьләр язам, ике ел элек Союзга алдылар. Берничә хикәям дә бар. Мин бик күп олы шәхесләр биргән Олы Солтан авылы кызы. Туган авылымның исемен псевдоним итеп алдым. Фәүзия Солтан булам мин.

Үземне шигырь тәнкыйтьчесе, белгече дип йөрсәм дә, оятыма каршы, мондый тәхәллүсле шагыйрәне белми идем. Хатын-кыз шагыйрәләрдән С.Сөләйманова иҗатын, исәннәрдән Л.Шагыйрьҗан, К.Булатова, Ф.Гыйззәтуллина, С.Гәрәева, Ш.Җиһангирова, Н.Сафина, Э.Мөэминова, яшьрәкләрдән Р.Рахман, С.Әхмәтҗанова, Р.Мухиярова һ.б. исемнәрне,

Казан университеты түгәрәгеннән үсеп чыккан, үзем укыткан яна буынны санап-атап китә алам.

Оятымнан кызардыммы, юкмы — хәтерләмим. Мәгәр «кызганычка каршы, сезнең иҗатыгыз белән таныш түгел», дип, дөресен әйтергә үземдә көч таптым. Аны алдау мөмкин түгел кебек тоелды миңа шул мизгелдә.

— Әле соң түгел, — дип, шигърияте белән таныш булмавыма бик исе китмичә, өстәл тартмасыннан ике китапчык чыгарып миңа тоттырды.

— Буш вакытыгыз булса, бәлки, күз салырсыз. Хикәяләрем әле кульязма хәлендә.

Тагын беркадәр уртак танышлар, юк-бар турында аяк өсте генә сөйләшеп тордык. Минем дә чыгып китәсем килми, ул да өстәле артына кереп утырырга ашыкмый. Бөтен барлыгымны ниндидер сәер хис биләде: аны янымда озаграк бастырып тотып, сулыш алган саен өлгергән грушаны хәтерләткән күкрәкләренең свитерларын тарсынып алуларын тоеп, күреп торасы килде. Хуҗасына кыен мизгелдә ярдәмгә килмәсә, зиһеннең ни пычагыма кирәге бар аның. Миемнең «пышылдавына» буйсынып, ифрат эшлекле кыяфәт белән:

— Фондыгызда ничә мең китап бар, шуларның күпмесе татар язучыларыныкы, безнең сүз осталарыннан кемнәрне күбрәк сорыйлар, кебегрәк ифрат «яңа» һәм «тозлы» сораулар тондырдым.

Мондый кизү соальләрне күп ишеткән һәм яңгырамаса да, тел төбендә ни-нәрсә ятканны, ике икең дүрт икәнне белгән ханым бик «ушлый» булып чыкты.

— Беренче ике соравыгызга, әгәр алар сезне чын-чынлап борчыса, тулы җавап бирә алам. Ә өченчесенә аңлатманы киләчәккә калдырыйк әле.

Әңгәмәбезне дәвам иттерү өчен генә:

— Өченчесе бик авыр булып тоелдымы, әллә әхлакый ягы бармы? — дип ачыкламыш кертәм.

— Бу мәсьәлә белән язучы кызыксынса, ул «сезнең китапларыгыз кулдан-кулга йөреп таушалып бетteләр», дигән җавапны гына көтә. Әсәрләрегез китап киштәсендә яталар дисәң, син гомерлек дошманнарыңның сафын гына арттырасың. Берничә ел элек телемә хуҗа була алмыйча, үземә бәрәүне өстәдем. Язучы халкының психологиясе әсәрләре турында унай фикер ишетүгә генә корылганын белсәм дә, «берәрсен үпкәләттегезме әллә» дигән булам.

Китапханәче, мәгълүм җырдагыча, әйтергәме икән, әйтмәскәме икән дип, киеренке уйланып торды да:

— Бер вакыйгадан соң салкын суны да өреп эчә башладым. Язучылар белән чираттагы кичә тәмамлангач, бездә алар атна саен диярлек булып тора, аерым алганда, Фәнис абый Яруллин, Аяз абый Гыйләҗев белән очрашулар уздырдык. Чираттагы очрашу кунагы Марсель Галиев «китапханәгездә минем әсәрләрем күпме, кайсыларын яратып укыйлар?», дип сорагач, мин уйлап житкермичә, «Марсель абый, хәзер күбрәк детектив һәм тарихи әсәрләрне якын итәләр, сезнең фәлсәфи рухлы, метафорага бай китапларыгызны сорамыйлар шул», — дип ярып салмыйммы. Минем аның иң амбициоз татар язучысы булуын ишеткәнем бар иде, әмма болай ук дип уйламаган идем.

— Сабыйларча туры әйткәнне ничек кабул итте инде безнең даһиебыз, — дидем мин көлә-көлә.

— Мыекларын тырпайтты да, саубуллашмыйча чыгып китте. Мин гаепле булып калдым. Һаман кырын карап йөри.

Шунда бүлмәгә бер укучы килеп керде, мин Зөлфәт Хәкимнең өченче

томын һәм тышлыкларына Фәүзия Солтан дип язып куелган ике шигырь китабын кыстырып бүлмәмә титакладым. «Җүләрләр йорты» драмасы урнашкан битне ачып, укырга җыендым, мәгәр күз алдымда һаман Фәүзия...

Китапханәче ханымны акшарланган Голливуд чибәре дип булмаса да, бөтен гәүдәсенә хас мөлаемлелеге, килешле киеме, үзен гади һәм матур итеп тота, сүзне ялгап китә белүе магнит кыры кебек үзенә тартып тора. Матур матур күренмәс, сөйгән матур күренер дигәндәй, аның боз күңелләрне эретердәй сөйкемле «сөяге» бар иде кебек. Шул сыйфаты белән ул «тере сыннардан» күп өстен тоелды миңа. Үз бәясен үзе белгән ханымнарга хас булганча, аның үз-үзен тотышында эрелек, һавалылык чалымнары да сизелеп тора.

Икенче көнне үк аяклар китапханә ягына тартса да, яхшы түгел, сәбәп юк, бер том драма, ике шигырь мәҗмугасын бер кичтә имтихан алдыннан студент кына җиңел чыга ала дип, үземне тыеп кала алдым.

Ир-атны тәмле ризык, хатын-кызны ямьле сүз белән яулап була диләр. Ә шагыйрә күңелен аның йөрәк җимешләре шигырьләре аша аңлау җиңелрәктер.

Шифаханә бүлмәсендәге өстәлемдә «маңгайларына» матур хәрефләр белән Фәүзия Солтан дип язып куелган «Учларымда — җиләк» (1999), «Үзәк өзелгән чак» (2003) җыентыклары... Икесен дә үземнең хезмәтләрем, проза әсәрләрем арасында кадерләп тотачакмын. Чөнки алар миңа арабызда пәрәвез җебе сузылган чорда «Тәлгат әфәндегә — автордан — үзәкләр өзелмәсен», икенчесенә җылырак — («әфәнде» сүзеннән тимер салкыны килеп torгандай), якынрак итеп, «Тәлгат абыйга — автордан — ихтирам белән», дип, кул тамгасы белән бүләк ителгәннәр. Беренчесенә сүз башын гаять таләпчән шагыйрь Нияз Акмал язган. Соңрак аның иҗаты турында шигырь белгечләре, күренекле тәнкыйтьчеләр Нурмөхәммәт Хисамов, Радик Сабировлар язып чыгачак. Әлегә Н.Акмалның бәясе, аның әсәрләрендә, С.Сөләйманова кебек бөек шагыйрәбез чалымнарын тапкан «Аланнарда җиләк — чиләк-чиләк» мәкаләсе һәм авторның лирикасы белән танышып утырам.

«Минем биографиям — шигырьләремдә», дигән бер сүз остасы. Фәүзиянең туганнары, тормыш юлы, балалары, гаиләсе, дөньяга карашы, табигатьнең кайсы фасылларын яратуы, эчке кичерешләре, ялан кыр кебек шәрә холкы, эчендә «сер тотмавы» белән танышканчы ук, шигырьләре буенча мин аны нәкъ шундый итеп күз алдыма китердем. Ихласлы күңел түрләреннән ургылып чыккан шигърият һәркем үзенә килешле кием сайлап алырдай бай кибет кебек ул. Күпчелеге безнең танышуыбызга, никахыбызга чаклы язылган булсалар да, аның мәхәббәт шигырьләрен миңа, безнең мөнәсәбәтебезгә нисбәтән иҗат ителгәннәр дип кабул итеп укыдым. Табигать баласы-шагыйрь күңеле — мәхәббәт кебек хиснең киләсен («предчувствие любви») алдан ук сизенә күрәмсең.

Алгарак китеп булса да, әйтим инде, бергә тора башлавыбызга бернichә ел узгач, Васильево шифаханәседә ял иткәндә, иҗади очрашу вакытында интим шигырьләренең бер гөләндәмен Фәүзия сәхнәдән яңгыратты. Минем янымда утырган, XX йөз башы хатын-кыз хәрәкәтенең үзенчәлекләрен, сәләтле вәкилләре иҗатын өйрәнүгә гомерен багышлаган галимә Альта Мәхмүтованың «әле күпме генә бергә торасыз, Фәүзия сезгә багышлап ничаклы шигырь язарга өлгергән», диюенә аның кәефен җибәреп, мәхәббәтнамәләрнең туган елларын искә төшереп тормадым. Йодрыгым

белән күз яшьләремне сөртеп, Хужа Насретдиннын турылыклы ярдәмчесе кебек, ризалашып,башымны селкү белән чикләндем.

Фәүзия Солтаннын шигырьләре, кульязмадагы хикәяләре (алар анын «Баллы миләш» (2012) исемле җыентыгында урын алдылар) белән танышкач кына, мәгълүм мәзәктәге эчкече кебек «барга кермим дигәч кермим» дип, сыраханә яныннан 50 адым узып киткәч, «йөрәгем, түземлелеген өчен син 100 граммга лаек» дип, үзен-үзе хуплаган исерекбаш кебек, Зөлфәт китабын, кульязмаларны култык астына кыстырып, аягымны күтәребрәк атларга тырышып, китапханә бусагасын атлап уздым. Ханым кампитр артында нәрсәдер басып утыра иде. Хуҗабикәнең өстендә шул ук гәүдәсенә сыланып торган кофтасы, өстәлләргә куелган гәзит-журналларны караштыручылары да элеккеге абзыйлар кебек тоелды миңа. Сораулы карашым буенча ук фикеремне төенләп алган мөдир аңлатмасын да бирде.

— Процедуралары тәмамланугa яңалыклар белән танышырга, үзара аралашырга дип күбесе уку залына килә. Берише көнне эш сәгатем беткәч тә көчкә чыгарам үзләрен. Казанда яшәүчеләре ял сроклары тәмамлангач та кереп-чыккалыйлар. Вакытым булганда минем белән сөйләшеп утырырга яраталар. «Син безнең өчен психотерапевт шикелле, биш-ун минут аралашып алсак, бар кайгы-хәсрәтләребез онытыла», дип сайрыйлар. Берсе хәтта миңа багышлап шигырь кебек нәрсә язган, икенчесе аны көйгә салган. Дәгъвага бернинди хокукым хакым булмаса да, көнчелек бизләрем баш калкытып, көтелмәгәнрәк сорау биреп ташладым.

—Чәчәк эзләп йөргән бал кортлары кебек бәйләнмиләрме соң?

Кетердәп торган кияү коймагын искә төшереп торган иреннәрне көлемсерәү бизәде.

— Бу абзыйлар миңа бал кортларыннан бигрәк кая кунарга белми миңгерәгән көзге күбәләкләрне хәтерләтәләр. Күбесе бит ялга чыкканчы зур урыннарда эшләгәннәр, кирәкле кишер яфраклары булганнар. Ә хәзер заманалар үзгә...

Ханым коңгырт күзләрендә шаян дулкыннар уйнатып, дөрес аңларсызмы дигәнрәк мәгънәдә миңа карап алды да, дәвам иттерде:

— Бер мөхтәрәме «хатыным үлде, бик кайгылы вакытым, чәй эчәргә кереп чык, бәйләнмәм дә, кагылмам да», — дип чакыргач, шаяртасым килеп китте.

— Бәйләнәсе дә булмагач, нишләп мин сезнең янга керим, чәем өемдә дә бар, — дигән идем, ул чын-чынлап үпкәләде. — Алар бит уалырга гына торган бәллүр савыт кебек, бик үпкәчелләр.

— Ну, сеңелем, хур иттең, кеше күзенә күренерлегемне калдырмадың, — дип саубуллашмыйча ук чыгып киткән иде, авызын салындырып йөрүе озакка бармады. Бер-ике атна узгач, тагын шул сөйләшүне исемә төшерде.

— Бу хакта өлкәннәрне чәйгә җыйган мәҗлестә Рөстәм Миннехановка да сөйләгән идем, «шул кирәк сиңа бозык картка», дип рәхәтләнеп көлде. — Хәзер үзең керим дисәң дә, чакырмыйм, ишекне эчтән биклəп куям.

Ханым, көрсенеп алды да, дәвам итте.

— Без Балык Бистәләре шундыйлар инде. Сүзебез акылыбыздан алданрак йөри. Соңыннан үкенәбез, тик терсәкне тешләп булмый. Бу абзый турында шаяртып сөйләсәм дә, көндәлек тормышта мин ирләрнең төрттерү-кинаяләреннән, әрсезләренең тәкъдимнәреннән гарык булдым, гафу итегез, майлы күзләрдән косасы килә. Кайвакыт картлар йортыннан

берәр гарип-горәбәне алып, коляска тәгәрәтеп йөрсәм, берсе дә бәйләнмәс иде дип тә уйлап куям.

Артык ачылып китүен аңлап, ханым җинелчә генә кызарып алды да, тиз арада бер көйдән икенчесенә күчә алган җырчы кебек, сүз агышын бөтенләй икенче якка борып җибәрде:

– Кстати, бүген сугыш ветераны, пединститут доценты Рой абый Гатауллин белән очрашу була, сезне дә чакырам.

–Ул тарихчыны мин яхшы беләм, әлбәттә киләм, — дидем.

Мин ипле генә халык арасына кереп утырган идем, Фәүзия ханым Рой абзыйның колагына нәрсәдер пышылдагач, ул мине кызыл үгез тиресе төсле җәймә җәелгән өстәл янына чакырып алды. Сез сугыш ветеранының фронтка яшьли китеп, берничә тапкыр яраланып, пуля башын тишеп, бер күзенә зарар китереп чыгуын һәм башка хәттән ашкан батырлыклары турында гына тыңлап утырган дип уйласагыз, бик нык хаталанасыз. Юк, шәкли яктан миңа бәйләнеп булмый. Абзыйны хуплап һәм мактап нотык та тоттым.

Күзләремә «нур көлтәләрегезне китапханәченең айдай йөзеннән, бил сыгылмаларыннан, ирек таләп итеп торган күкрәкләреннән читкәрәк алыгыз», — дип кат-кат әйтеп карадым, мәгәр һич кенә дә файдасы тимәде. Алар өчен кич буе оялып утырдым. Очрашудан соң, кунаклар өчен чәй мәҗлесе каралган иде. Мине дә калдырдылар. Чакыруны кабул итеп, Фәүзия янынарак утырырга тырыштым. Максатыма ирешсәм дә, ул чәйләрне даими янартып, безне аягүрә сыйлады. Сирәк кенә урындыгына кунаклаган мизгелләрдә булса да, бармакларына, кулларына орынып алу әмәлен эзләп интектем. Үзе әйткәнчә, арзанлы дәгъвачыларны күп күргән («ач күзләр» сафын да тулыландырасы килми бит әле) ханым, мине тупас кире какмаса да, минем кайнар хисләремне уртаклашырга ашыкмады. «Чәчәннең теле уртак, чибәрнең кулы уртак» дигән мәкальнең «сөткә киткән» очраклары да булгалый икән. Мине ошатуында шигем юк кебек. Битараф булса, мин китапханәнең ишеген ачып керүгә, «Тәлгат абый» дип, куркытылган урман тавыгы кебек пырхылдап, алдыма килеп чыкмас иде. Мин сезне күптәннән беләм ди түгелме? Язучыларның корылтаенда йә ел йомгакларында күргәндер, соңрак автобуста да сөйләшеп барганбыз икән.

Хәер, шифаханәдә ял иткәндә буш вакыт күп була, араларында «мәхәббәткә сусап» йөрүчеләрнең китапханәчене ошатып, үзләрен тәкъдим итүчеләре дә аз булмагандыр дип уйлыйм. Үзем чын-чынлап гашыйк булып, балавыздай эреп барам түгелме? Мәгълүм җырдагыча, кабат килде, сөю көтмәгәндә, кинәт килеп яуган янгырдай дип, хисләреңә теләктәшлек тапмыйча, буш чиләк кебек шылтырап, кеше көлдереп йөрсәң? Мавыгулар, женси тартылулар туып торса да, мәхәббәт бер генә була диюләре хакмы икән? Кагыйдәдә искәрмәләр, чигенүләр, сөртенүләр каралмаганмы? Бу кануннарны кем урнаштырган да, кем сынаган? Башка берәүнекенә охшаса ул чын сөюгә керми, мавыгу, соклану, ымсыну, теләк яисә хайвани хис кенә була торгандыр. Степан Злобин без яшь чакта яратып укыган «Салават Юлаев» романында каһарманынын күп мәртәбәләр гашыйк булуын, һәр яңа мәхәббәтендә беренче мәгъшукасының хәтерем ялгышмаса, Әминәсенең чалымнарын таба дип яза. Мин дә беренче хатыным Галия белән Фәүзияне (тьфү, ашыкканның ашка пешкәнен белә торып, чак кына «икенче хатыным» дип ычкындырмадым) чагыштырып карыйм. Күз, чәч, бит төсләрендә үзгәлекләр булса да, гәүдәләрендә, йөрешләрендә, үзләрен житди тотышларында якынлыкны инкяр итүе кыен.

Алдагы көннәрдә дә шигырьләре, хикәяләре турында фикерләрем белән уртаклашып, уку залына кергәләп-чыккалап йөрдем. Шигырьләрен ошатсам да, проза үрнәкләренә пессимизмга барып тоташкан «сантиментларның» артык көчле булуын, инверсиянен еш кулланылуын әйттем. Шигырьләре, алдарак бирише күзәтүләремне әйткәнчә, самими лиризмнары, күнел түрендә төенләнгән тирән серләре белән «уртаклашулары», тар мәйданда тәгәлләнгән хис-кичерешне сүз-гыйбарә очкынында уйната белүләре илә ошадылар.

Шәхесенә килгәндә, Фәүзия ханымның китап укучылар белән уртак тел таба белүе, өлкәннәрне жылы сүзе, игътибары белән тынычландыруы аның үз вазыйфаларын үтәүгә җаваплы каравыннан бигрәк, кешелеклелеге турында сөйли иде кебек. Кайберсе белән бакчада сөйләшеп, аралашып йөрергә дә туры килде. Фикерләрен сорамасам да, китапханәгә йөрүемне күргәннәре, үзе котыртыпмы, әзерләпме куйгандай, Фәүзияне мактап туймадылар. Шул арада минем ял вакытым тәмамланып та килә иде. Шифаханәнең санаулы көннәре кеше тормышының кыскартылган манзарасы кебек: башлануын көтеп аласын, үтеп киткәнен, гомер шикелле, сизми дә каласын! Дәвалануымның соңгы көне «Мәдәни җомга» гәзитәсе хезмәткәрләре белән очрашуга туры килде. Мөхәррир З.Мансуров, аның урынбасары Г.Морат һәм тагын берничә кеше буласы икән. Яраткан шагыйрьләрем, дусларым, каләмдәшләрем белән күрешүдән баш тарта аламмы соң мин? Әлбәттә, килдем, чыгыш та ясадым. Халык белән шыгрым тулы залда уздырылган кичә чын шигырь бәйрәменә әверелде. Казан шифаханәсен бетерү татар мәдәниятенең бер учагын сүндерү икәнен кичәдә бик ачык сиздем.

Фәүзия Солтан да үз шигырьләрен укыды. Мин аны бик якын, газиз кешемне тынлагандай, дөньямны онытып, шатланып та, борчылып та, үзеннән күзләремне ала алмыйча утырдым. Мина ул шул мизгелдә сөйкемле, якын, хисләремне, язмышымны уртаклашырдай ханым булып тоелды. Һәрхәлдә, шул фикер минем башыма каккан кадак кебек кереп утырды.

Өйгә алып кайтырга күрше йортта гына яшәүче аспирантым Радик Сабировны сораган идем. Татар көрәшенә бирелгән егетнең якташы, бөек шагыйрь Хәсән Туфан иҗатында лирик герой образы гәүдәләнеше кебегрәк темага кандидатлык диссертациясе сырлап йөргән көннәре. Студентлык вакыты кебек үк, аспирант еллары да, иркен, бар хыялларның гамәлгә ашасына ышанып яшәгән бәхетле чор. Милли җанлы, артыгын сөйләшмәс, үзенә тиешлесен ычкындырмас Радик күрше керештә генә әбисе белән яши. Анысы оныгына дәрвишләрчә бирелгән, оныгы өчен җанын фида кылырга әзер чын мишәр карчыгы. Урамда очратса да, Закира апаның сүзе гел туруны хакында.

— Радигым төн ката сәдәфле шайтан янында утыра. Чистый тамактан калып, ядауланып бетте инде. Ата-анасына ницекләр йауап бирермен.

Радикның зур спорттан читләшкәч, аспирант харчасында, әбисенең затлы ризыкларыннан тулыланып, тынычланып киткәнен белсәм дә, ихластан борчылган гаять сөйкемле апаны тынычландырырга ашыгам.

— Күрше, борчылмагыз, мин аны әбиең әзерләгән ризыкның граммын да калдырмыйча аша дип ачуланырмын.

Ә чынлыкта Радикның «әби ашарга кыстый-кыстый үтерә инде» дип, сөенечен яшерә алмыйча «зарланганы» хәтердә. Минем «ачуланырмын» дигән сүзләремнән курка ук калды әбиебез.

— Кьанатым, мин атьканны атьа күрмә.

Шунда ук исенә төшереп, «Радигым кайтканчы өлгертим дип, аш куйган идем, каньап беткәндер инде», — дип бүлмәсенә ашыга.

Мин җыйнак бәдәнле, житез, оныгын карап торудан көч, яшәү дәрте алган, якын кешесенә мәхәббәте күзләренә, йөзенә, йөрешенә чыккан карчыкка сокланып карап калдым. Аспирантыма йомышым төшкәндә, өй телефоннарыннан берүк җавап ишетәм.

— Радикның качан катьасын атьа алмыйм. Иртүк житәкчесе Тальгат белән (ул мин булам инде) чыгып киткәннәр иде.

Инде изге җан әбиебез гүр иясе. Радик үзе дә ике бала атасы, галим, тәнкыйтьче, доцент. Ә мине шифаханәдән алырга килгәндә япь-яшь аспирант иде. Мин чәй янында беркемгә дә сиздермәскә тырышып, Фәүзия ханымның колагына, «безнең белән кайтырсыз», дип әйтергә өлгердем. Ул, йөрәгемне яшен телеп алгандай, күз карашын минем якта уйнатып алды да, сүзсез генә, ризалыгын белдереп, башын иеп алды.

«Мәдәни җомга» бу шифаханәдә китапханә хуҗасы, шагыйрә, иҗтимагый актив шәхес Фәүзия ярдәмендә укучылар белән очрашуларны еш уздыра һәм аны өенә үзләре кертеп калдыра торган булганнар. Егетләр ханымны үз машиналарына чакыргач, ул, озын керфекләрен туфли очларына төшерде дә, бурычын түли алмаган гаепле кеше кебегрәк, «мин Тәлгат абый белән кайтам», диде.

Әлбәттә, сизгер җанлы шагыйрьләр Фәүзиянең минем машинага утыруы тикмәгә генә булмаганны аңлаганнардыр. Соңрак миңа шул хәтлесе мәгълүм булды. Тәртипле, итагатьле әдипләребезнең берсе Зиннур Мансуров Фәүзияне очратып болай дигән: «Тәлгат Нәбиевич безнең бик мөхтәрәм шәхесебез. Аның белән шаярырга, уйнарга ярамый. Мөнәсәбәтең житди булса гына аның башын катыр».

Радик белән кунагыбызны Мусин урамы чатына китереп куйдык, мин ханымны озатырга чыккан идем, башым әйләнеп китте һәм кияү коймагыдай иреннәренең тәме йөрәгем, тәнем аша аяк бармакларыма житкәч кенә, айнып киттем. Ул да артык каршы килмәде кебек хәтердә калган, һәрхәлдә яңакта шартлау ишетелмәде, күзләрдән очкын чыкмады. Шул көннәрдә үк Пирамидада язучылар берлегенең 75 еллык бәйрәменә чакырулы идек. Фәүзия белән бергә утырырга килешкән булсак та, үз кадерен белгән хатын-кыз буларак ул соңга калу сәбәпле, мин Ренат Харис, Равил Файзуллин, Флера Тархановалар белән бер өстәлгә туры килдем. Күзләр гел ишек ягында. Нәрсә ашаганны, эчкәнне дә хәтерләмим. Килеп кергәнен барыбер күрми калганмын, киттем аны эзләп. Ул Татарстан китап нәшриятының элеккеге һәм хәзерге хуҗалары белән бер өстәлдә утыра икән. Мин шыпырт кына янына килеп, йөреп керергә чакырдым һәм шул зыярәтебездә без яшертен-орынтын дуслашып йөрергә өлгерә дә алмыйча, «иҗтимагый пар»га әйләндек тә куйдык. Мәрмәр баскычтан тотынышып аска төшеп барабыз, аннан ипле генә атлап, исе китмәгәндәй генә, әмма күзлек астыннан безне бик игътибар белән багып, депутатлар Разил Вәлиев, мыек астыннан хәйләкәр елмаеп Роберт Миңнуллин өскә менеп киләләр. Аскарак төшсәк, халык шаугөр килә. Татарстан Президенты М.Ш.Шәймиев белән аның яраннарын каршылыйлар икән. Безнең дә, колларның кулда икәнен дә онытып, шул төркемгә килеп кушылудан башка чарабыз калмады. Аннан инде, залга кереп, урын табып, беткән баш беткән инде дип, артык кылтаймыйча, бергә утырдык. Шул ук Радик безне өйләргә таратканда, мин Фәүзиягә:

— Без якынлыгыбызны җәмәгатьчелеккә, шул исәптән халык

депутатларына гына түгел, Илбашына да күрсәттек, барысы да хуплады кебек, иртәгә эштән соң үзенне Гаврилов урамына кунакка чакырам, — дидем.

Икенче көнне, изге ният белән, тукталышка каршы алырга чыгып, аны туры китерә алмыйча авызымны салындырып, өемә кайтсам, шул арада якын булып киткән кешем, безгә кереш ишек янында көтеп тора иде.

Әминә әби Чаллыда чак. Чәйләр-мәйләр куйган булдым. Кочаклашып ятакка егылганчы, киләчәгебез, уртак тормышыбыз турында бик җитди итеп сөйләшкәндәй иттек.

«Минем ике улым бар, берсе югары белемле, эшли, икенчесе әле тугызынчы сыйныфта гына укый, әти-әниемне күмдем, хәзер кияүдә түгел, теге көнне сез калдырган төштә өч бүлмәле фатирым бар», дип Фәүзия үзе белән таныштыра башлады. «Кечкенә улынны бергә үстерербез, минем дә үз гаиләләре белән торучы ике малаем бар һәм вафат булган хатынымның әнисе янымда», дип җавап бирдем.

«Миңа яшәргә күчеп киләсеңме», дигән соравыма иртән, «инде кусаң да китмим», кебегрәк җавабы белән сөендерде, канатландырды, киләчәккә өмет чаткыларын уятты.

Соңрак Фәүзия «мин сезне күптәннән күзәтеп, кызыгып, яшерен мәхәббәт тотып йөри идем», дип мине үсендереп җибәрде. Менә без шулай табышып, яшәп тә киттек.

Тора-бара мин аның холкын да өйрәндем. Аны тормыш «типкәләп» күп нәрсәгә өйрәткән. Миңа ул ваклану, көнләшү (элеккеге дусларым белән «саубуллашуга» барып кайтуымны хупламаса да, аңлады), күпсенү, саранлану, акчага табыну кебек хөсетле гадәтләрдән өстен торгандай тоелды. Акрынлап Фәүзия белән күпсанлы туганнарымны, эне-сеңелләремне таныштырдым. Күбесе аны кабул итсәләр дә, барысы да минем зәвыгымны, бу адымымны сикереп төшеп хупладылар дию бик үк дөрес булмас. Элек таныш булмаган, аның дөньяда яшәве турында ишетмәгән дә ханымның минем түр башыма килеп утыруы кемнеңдер эчен тырнады, араны бозарга тырышып йөрүчеләре, гайбәт таратучылары, улларымны котыртып караучылары да табылды. Фәүзияне кабул итмәүчеләр арасында Галиянең туганнары булуы табигый булса да, бер сеңелемнең аны өнәп бетермәве бераз сәеррәк тоелды. Минем барыбер үземчә эшләячәгемне белә торып, «олы абыебыз тиңен тапты, аның авыр чир кичергән булуына да карап тормаган», дип сөенеп, хуплап, киңәшләрен биреп кенә торасы иде дә, нишләтмәк кирәк, һәркемнең үз холкы, үз акылы...

Фәүзия белән бергә тора башлавыбызга шактый вакыт узгач, урамда Татарстан курортының һәм Казан шифаханәсенең элеккеге баш табибы Юрий Сахабутдиновны очраттым. Мине киң кочагына алып:

— Ишеттем, ишеттем, минем заманның китапханә мөдиренә өйләнгәнсең икән. Минем белән киңәшәсе булган.

—Нәрсә, әллә зур хата ясаганмынмы?

— Юк, юк. Фәүзия начар хатын түгел. Тәртипле, тәрбияле, тик син белеп торырга тиеш, ул балаларына артык бирелгән, аларның һәр капризын үтәргә, кирәк булса, җанын ярып бирергә әзер. Шуны истә тот, — дип өстәде, борын очына ук төшеп җиткән калын пыялалы күзлеген өскә күтәреп.

Әлбәттә, мин аңа «мәхәббәт килсә, ул уңны-сулны уйлап торырга ирек бирми, куеныңа кинәт килеп кергән елан кебек, йөрәгеңә, бөтен барлыгыңа хуҗа була», дип, үземнең халәтемне аңлатырга уйласам да, кинәт «рәхмәт» белән «саубул» арасында торган нindидер сүз мыгырдап, үз юлым белән киттем.

Фәүзиянең балаларын шулай мәҗүсиләрчә яратуында, алар өчен яшәвендә безнең мөнәсәбәтләргә зарар китерерлек берни күрмәдем мин. Берәүне дә якын итә алмаган, үзе өчен генә яшәгән кешедән курык, диләр. Юрийның сүзләрен мотлак хакыйкать дип кабул итмәсәм дә, алар һавадан алынмаганнардыр, җирлекләре бардыр. Шунда күңелемә Ф.Солтанның улларына багышлап язган шигырьләре искә төште.

Ай, бик туңдым, әни, җылыт!
Кулларың бит боз икән.
Җан җылымны бирер идем,
Туңдырмас идем, бәпкәм.

«Газизләрем» (1997) шигыреннән алган бу юлларда самими аралашу, якынлык кичереш үзәген тәшкил итә.

Шул ук 1997 елда язылган «Ана хыялы»нда гомерлеккә бергә була алмауны сиземләгән фаҗига төсмере, гомернең фанилыгы алга чыга.

Яннарымнан китеп барсагыз сез
Ничек түзәр икән йөрәгем?
Күрми торсам — сезне сагынам бит,
Күз нурларым, газизкәйләрем. –

кебек төчерәк юллар һәм «күз нурлары»на багышланган «Туган көнең котлы булсын...» (улым Рәсимгә), «Булат улыма» һәм башка шигырьләре баш табибның сүзләрен раслыйлар кебек. Аларның барысы да халык җырлары, татар хатын-кыз шигърияте йолаларында, ананың балаларына иксез-чиксез мәхәббәтен эпитетлар аша чагылдырган шигырьләр. Асылларында ана эгоизмы, кадерлеләренә бәхет теләү ята.

Ихласлыклары шик уятмаган ана хисләре туган иленә, милләтенә, кавеменә хезмәт итү, халкыбызның гореф-гадәтләренә тугрылыклы булып үсүгә чакыру мотивлары белән баетылса, шигырьләре тар интим тирәлекне җиңеп, офыкларын киңәйтеп җибәрерләр иде дип тә әйттем үзенә.

Юрий Ефимович белән юл чатында очрашуыбыз, сөйләшүебезнең эчтәлеге турында Фәүзиягә дә җиткердем.

— Элеккеге баш табибыбызның сүзләрендә дөреслек барын инкяр итмим. Бөтен көчемне, исәнлегемне биреп үстергән улларым миңа бик кадерлеләр. Мин аларга әни дә булдым, аталарын да алыштырырга тырыштым. Үскәндә балаларга әти кирәк. Минем «Әти, диеп кемгә дәшәргә?» исемле шигырем дә бар. Шул ук вакытта алар үз урыннарында, миңа исә бөтенләй башка мөнәсәбәт.

Ана күңеле балада, бала күңеле далада дигәндәй, газизкәйләреңне гелән үз яныңда гына тотып булмый шул. Фәүзиянең олы улы Рәсим гаиләсе белән Краснодар краена китеп, курортлар системасына җаваплы эшкә урнашты. Җәмил исемле сөйкемле малай үстерәләр, кечкенә оныкчыгы — Рузанна да дөньяда яшәргә хакы барлыгы турында хәбәр бирде.

Икенче малае — Булат (минем дә кече улым — Булат) беренче елларны тиз кызучан холкы, тәртәгә тибүчән гадәтләре белән мәшәкатьләр тудырса да, яше егермене узгач акылга утырды, хәзер аерым яшәсә дә, хуҗалык эшләре аның карамагында.

Тормыш тарихын соңрак Фәүзия үзе дә сөйләде, башкалар да «рәхәтләнеп» тулыландырды. Иренең хыянәте, бергә яшәгән бүлмәләренә чит хатын алып кайтуы, соңрак туган авылларында, күрше йортта гына гөрләтеп туй уздыруы яшь ананы тетрәндерә һәм йокымсырап яткан

шигъри сәләтен уятып, кулына каләм алырга мәҗбүр итә. Хәзерге татар шигърияттенен иң фаҗигале шигырьләреннән берсе — «Туй бара» — эчке тетрәнү, рәнҗү, хыянәтне гафу итмәү, кире кагу, чистарыну — катарсис җимеше.

Юлында ялгызы яшь ана...
Күзләреннән әче яшь тама.
Хәтерендә — үз туе. Теләкләр
Теләнгән иде бит аңа да.
Бүген ул — ялгызы.
Кулында — сабые.
Ә йортта — җыр гөрли. Туй бара..
*(«Туй бара», 1999)*

Киләчәген минем белән бәйләгәнен белгәч, аның да күңелен болгатырга тырышучылары, кинәшчеләре, «хәленә керүчеләре», яңгырдан соң күтәрелгән гөмбәләр кебек, табылып тордылар.

Киңәш дискурсы шундыйрак җөмләләргә «төреле»: «ничек инде син курыкмыйча шул мишәргә кияүгә чыктың, ул усал тәнкыйтьче (укы: кеше), сөяркәләре дә аз булмаган, диләр. Галиядән соң үзеңне туганнары да кабул итмәс, инсульт кичергән кешенең холкы да бозыла, диләр...».

Фәүзия гайбәтләрне колагына элсә дә, миңа артык сиздермәде. Киресенчә, игътибарлы булуы, һәр теләгемне әйткәнче үк сиземләп алып, үтәргә тырышуы, назы белән күңелемне кинәт җылы кояшка тарган боз катламыдай эретте. Кичләрен мин урамга йөрергә чыккач, ярты сәгать узар-узмас, «өшемәденме, аягына салкын үтмиме, кергән җиреңә нәрсә пешереп куйыйм», диеп килеп җитәр, яисә телефоннан хәлне белешеп торыр. Өйгә кергәч, кичке дастархан янында сәгатьләр буена, бер-беребезне кыстый-кыстый чәй эчүләр, киләчәккә планнар кору, әдәби барыш, яңа әсәрләр турында фикер алышулар — мәңге онытылмас хатирәләр булып күңелдә калырлык.

Чирләгәннән соң машина йөртүе кыенлашу сәбәпле, бу һөнәрне Фәүзиягә үзләштерергә туры килде. Ул моңа бик теләп алынды.

Әүвәл иске алтылы «Жигули» белән гараж капкаларының ныклылыгын тикшереп, тиешле урынга утыртылмаган баганаларга «сәлам» биреп, машиналарны алыштыра-алыштыра Фәүзия югары кимәлле, бәйгеләрдә катнашырлык йөртүче булып җитеште. Җәяү йөрүне онытып ук бара бугай.

Әй, гомер агышлары... Без дә инде ун елга якын гаилә булып яшәп ятабыз икән. Бәяләр туры килмәү, тарткалашкан чаклар, ул үз ягын каерган, мин үземнекен тугылаган вакытлар булгаласа да, соңынан алтын урталыкны әлегәчә таба белдек. Кешенең канын тулысы белән алыштырып булмаган шикелле, аның холкын, дөньяга карашын, ата-баба салган геннардан килгән үзгәлекләрен кире якка борып куеп булмый. Ул — гайре табигыйлеккә генә китерер иде. Фәүзия хис кешесе, шагыйрә җанлы, эчендәгеп йозакта озак тота алмый, теленә чыгара, турысын яра. Миндә мантыйк, тормышны күбрәк белү өстенлек итсә дә, барыбер дуганы үз ягыма бөгәргә тырышам. Гогольнең борынгы алпавытлары кебек гел төчеләнеп, бер-береңне ашарга кыстап, салпы якка сәлам кыстырып кына яшәү кызык булмас, саруны кайнатып, тиз туйдырыр иде. Безгә ул куркыныч янамый кебек.

Кешенең холкы да, дөньяга карашы да үзгәрми тормый. Заманабыз үзе дә шуңа этәрә. Бер мәлне Фәүзия интернет дигән зәхмәт белән тилереп

чирләп алды. Ул сиздермичә генә кешенең вакытын ала, уйларга, укырга тиешлесен дә йота бара. Интернетта да яхшы кешеләрнең утыруын инкяр итмәстән, һәммәсе дә әхлакны ныгытуга, гаилә нигезләрен саклауга ярдәм итәләр дигән фикер тумый миндә.

Мин үземне техник һәм фикри яңалыклардан артта калган ретроградка санамыйм. Интернет акыл һәм чама белән файдаланганда сәяси, икътисади, мәдәни хәлләрдән бик күп мәгълүмат бирә ала. Фәүзиянең бу мавыгуы бер узар, һич булмаса билгеле бер тәртәгә керер дип уйлыйм. Шунда утырганда, онытылып китеп, плитәдәге бәлешләр яну, кәтлитләр көю очраклары да була, шул хәтлесе дә колакка керер тора: яңа танышлар-вәгъдәләр аркасында, күпме гаиләләр таркала. Мин әйләнәм-тулганам да, аның китапханәдә «Тәлгат абый», дип, каршыма атылып чыккан, минем «жимеш», аның «матурым» булган чорыбызны сагынып куям. Берүк суга ике тапкыр кереп булмаса да, кеше хәтере, хисе барысыннан да көчлерәк дип саныйм. Шуларны саклый алсак, без бер-беребезне беркайчан югалтмабыз кебек! Хәер, язмыш йомгагының очы Ходай Тәгалә кулында.

P.S.

Кемдер: «нишләп әле бу абзый ике кешегә генә кагылышлы серләрен кояш яктысына чыгарып, бөтен нечкәлекләре белән бәян итәргә булган», дип гаҗәпләнер дә, сәерсенер дә. Мин үзебезнең мәхәббәт вә гаилә тарихыбызны сөйләү аша язмышыбыз галәм белән идарә итүче ихтыярында икәнлегебезне генә искә төшерергә булдым. Мин элек берәр танышымның «ошбу уңышка ирешүемә, бәхетемне — яраткан эшемне, мәхәббәтемне табуыма Аллаһыбызга бурычлы, ул ярлыкасыннан ташламасын», диюенә шикләнебрәк карый идем. Раббыбызның барлыгын таныган хәлдә дә, Күкләр вә Җирләр хуҗасының әллә ничә миллиард кешенең, башка җан ияләренең яшәешенә юнәлеш бирергә, язмыш агымын билгеләргә ничекләр өлгерсен дип уйлый идем. Өлгерә һәм аның кодрәте чикләнмәгән икән шул. Мин менә ни өчен ике ятып бер төшемә дә кермәгән, гомеремдә аяк басмаган Казан шифаханәсенә үз хәләл акчама юллама алып, ял итәргә барырга уйладым. Чөнки мин анда булачак ирен көтеп кампитр артында утырган Фәүзияне очратырга тиеш булганмын. Шуннан соң инде Аллаһ һәр эшебезгә юнәлеш биреп, ялгыз йөрәкләрне кавыштыруда катнашмый дип кара!

## Бу илдә галимнәргә ихтыяҗ бармы?

«Доктор булуның ние бар...» исемле язмамда совет хакимияте чорында халыкларны югары вә түбән сортларга бүлү, берәүләрне күккә чөю, икенчеләрен бөтенләй хокуксыз калдыру нәтиҗәсендә, фән докторы булу турында хыялланып йөргән татар галиме фәнни тикшеренүнең сыйфаты югары булса да (төрки галәме, шул исәптән дәүләтле төрекләрдә бу хакыйкатьне таныйлар), диссертациясен яклауга урнаштыру өчен Мәскәү, Алма-Ата, Ташкент, Баку кебек шәһәрләрдә ачылган советларга баш иеп барырга мәҗбүр иде. Җае чыкканда бай һәм мәгърифәтле тарихы белән «масаеп» алырга яраткан татар баласы өчен иң аянычы шунда иде: XIX гасыр азагында, бигрәк тә XX гасыр башында укымышлы акмуллаларыбыз «әлпи-тисигә», әлифбага, уку-язуга өйрәткән кавемнәрнең балаларына, оныкларына, хәер сорарга кергән теләнче кебек, баш иеп, вакыты белән тез чүгеп бару булды. Ерак шәһәрләргә сәфәр чыгуларның матди һәм рухи яктан авыр гына түгел, хәтта түбәнсеткеч икәнлеген дә онытырга

ярамый. Үзбәкләргә яклауга бару аеруча кыен иде: өлкән буын вәкилләре егерменче елларда милли хәрәкәтне, советча басмачларны, канга батыруда катнашкан татбригаданы искә төшереп, коммунист бабаларыбызның кылган гамәлләре өчен кызартып алу мөмкинлеген ычкындырмадылар. Татар галимнәренә иң һәерхак расланулар Алма-Атада булды. Югарыда аталган мәкаләмдә яклау матавыклары белән казах кардәшләр мәркәзенә алты тапкыр зыярәт кылып, ябылган гыйльми берәмлекләрен янәдән ачтыру өчен югары аттестациягә йөрүләрем, ул эшли башлагач та, «яклауларны ногай баласы эше илә башлап җибәрү җарамас», дип, мине читкәрәк тибәрүләре турында, яшь аралаш күлеп бәян иткән идем. Һәр мәсьәлә хәл ителгәннән соң җинел, авырлыкларны чытыкланып күпертү кебек тоела. Минем арттан ук диярлек татар драматургиясе буенча Азат Әхмәдуллин Алма-Атада яклап кайтты. Мин инде анда оппонент булдым. Фәрит Хатипов та үзен шунда раслады.

Кыскасы, үзем шул сират күперен кичкән кеше буларак, татар факультеты аякка басуга, аның каршысында кандидатлык һәм бигрәк тә докторлык диссертацияләрен яклау советын оештыруны төп максатларның берсе итеп куйдым. Әлегә чаклы Казанда беркайчан да күренмәгән шураны гамәлгә кую, татар дөньясында гына түгел, ә бөтен төрки мохиттә гыйльми абруебызны күтәреп җибәрәчәген бик ачык күзалладым. Яклау советын ачуга Мәскәүдән рөхсәт алу өчен тиешле кәгазьләрне черки дә борынын тыга алмаслык дәрәҗәдә төгәл итеп әзерләп җибәрү лазем иде. Совет ачуның мәҗбүри үтәлергә тиешле шәкли таләпләре бар. Шура әгъзаларының, гыйльми сәркатибтән башкалары (ул фәннәр кандидаты булса да ярый) доктор булып, аларның алтмыш проценты университетта эшләүчеләр, калганнары төрле уку йортларыннан, фәнни оешмалардан, белгечлекләре туры килсә, башка шәһәрләрдән дә кертелергә мөмкин иде. Г.Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият, сәнгать, Казан педагогия институтларыннан иң абруйлы галимнәрне чакырдык, безнең шикелле әле генә оешкан филология факультетыннан күбебезнең элеккеге укытучылары Людмила Ачкасованы, Любовь Савельеваны советка әгъза итеп керттек. Әйтергә кирәк, алар бу иҗтимагый вазифаны үзләренә зур ышаныч дип кабул итеп, һәр утырышка теләп йөрделәр, хезмәтләргә бәя бирүдә актив катнашып, үзебезнең яшьләр күтәрелеп җиткәнче, берлекнең интеллектуаль дәрәҗәсен тиешле югарылыкта тотуда ярдәм итеп, «оештыру эше яхшы куелган», дип һәр җирдә мактап, абруебызны күтәреп йөрделәр. Беренчесе чирләп, урын өстенә егылганчы, Любовь Ивановна фани дөньяны ташлап киткәнче, татар советына фидакарьләрчә хезмәт иттеләр.

Татар һәм гомумән төрки филология фәненең үсеш дәрәҗәсен күтәрү өчен Казан дәүләт университеты карамагында яклау шурасы булырга тиеш дигән фикер бер миндә генә тумады, әлбәттә. Мондый хыялның бик күпләрне борчыганы ачыкланды. Күренекле фән әһелләренең барысы да совет эшендә катнашырга, яшь буынга ярдәм итәргә әзер торуларын белдерделәр. Советка рәис итеп проректор буларак оештыру эшләренең башында торган профессор Миркасыйм Госмановны тәкъдим иттек. Әмма Югары аттестация комиссиясе «белгечлеге туры килми, совет җитәкчесе филолог булырга тиеш» (ул тарихчы иде), дип аның кандидатурасын расламады. Минем белгечлегем һәм фәнни дәрәҗәләрем бәхәс уятмады. Яхшымы-яманмы инде егерме елдан артык КДУ (хәзер КФУ)ның татар һәм төрки телләре һәм әдәбиятлары буенча докторлык диссертацияләрен яклау советының

рәисе вазифаларын башкарам. Гыйльми оешмабызның акыл үзәнен җөмһүриятебезнең һәм курыкмыйча, авыз тутырып әйтәм, гомумән Русия гуманитар фәненең үсешенә зур өлеш керткән, һәркайсы бер юнәлешне җитәкләгән, дистәләрчә шәкертләр әзерләгән Ганеев Ф.Ә., Саттаров Г.Ф., Хатипов Ф.М., Юсупов Ф.Ю., Әхмәдуллин А.Г., Әхмәтҗанов М.И., Хисамова Ф.М. кебек иң катлаулы, четерекле фәнни тикшеренүләргә гадел бәя бирерлек олы галимнәр тәшкил итәләр. Инде мәңгелеккә күчкән Тумашева Д.Г., Хаков В.Х., Госманов М.Г., Савельева Л.И. кебек элеккеге совет әгъзаларын һәрдаим сагынып искә алабыз.

Яңа оешкан гыйльми берлеккә эш эзләп интегү ихтыяҗы булмады. Әзер хезмәтләрен кая урнаштырырга белми аптырап, кулъязмалары шыплап тутырылган «чемодан өстендә» утыручылар шактый булып чыкты. Аналары алып кайткан ризыкны авызларын ачып каршы алып торган кош балалары кебек, үзебездә совет эшли башлаганны зар-интизар булып көтеп торучы дәгъвачылар бу җылы хәбәрне шатланып кабул иттеләр. Читкә чыгып йөрергә матди мөмкинлеге булмаганнар, юл йөрү мәшәкатьләрен күтәрә алмаганнар, башка төбәктә фәнни тәгълиматын дөрес аңламаудан шикләнгәннәр мәсьәләнең бу рәвешле хәл ителүен аеруча хупладылар. Урысның «дома и родные стены помогают» дигән мәкале дә бу очракка тач килеп тора кебек.

Хәзерге советыбызның терәген, нигезен үзебездә яклап, докторлар, профессорлар дәрәҗәсенә күтәрелгән, шулай ук күренекле галимнәр тәшкил итә. Озак еллар дәвамында гыйльми сәркатип, аннан рәис урынбасары булып эшләгән Хатыйп Миннегулов, шул ук баскычларны үткән, Татарстан фәннәр академиясенең баш гыйльми сәркатибы, академик Дания Заһидуллина, советның бүгенге гыйльми сәркатибы, кафедра мөдире Әлфия Йосыпова, кафедра мөдире Фәнүзә Нуриева, журналистика һәм социология факультеты деканы, кафедра мөдире Васил Гарифуллин, Уфадан, ясалма аңлашылмаучанлыклар нәтиҗәсендә яклау мәшәкатьләрен шактый татыган Әхәт Нигъмәтуллин, шундый ук низагларны узган Рифкать Әхмәтҗанов, Фирдәвес Гарипова, Гөлшат Галиуллина, Илдар Низамов, Рамил Исламов һ.б. исемнәре аталмаган татар фәненең йолдызлары, КДУның таләпчән советы иләге аша үтеп, фәнни концепцияләрен расладылар. Хатип Госманнан һәм шулай ук безнең советта яклаган Хәләф Курбатовтан соң татар шигырь төзелеше буенча, заманча әйтсәк, «мастер — класс» алып барырлык белгеч Марсель Бакиров та, бик озак ялындырып йөргәннән соң, безнең советта якларга ризалашты, аның докторлыгын ВАК та сөенә-сөенә раслады. Тукай мирасын өйрәнүгә, тәхәллүсләрен ачуга зур көч куйган, хәзер аның энциклопедиясен әзерләү белән мәшгуль Зөфәр Рәмиев, аның җәмәгате, заманча, Аурупача фикерләү, язу тарафдары Резеда Ганиевалар да фән докторлары дигән шөһрәтле исемгә лаек булуларын КДУ советында расладылар; соңгысының шәкерте, «Казан утлары» журналының тәнкыйть бүлеге мөхәррире, хәзерге әдәбият кафедрасы мөдире Әлфәт Закирҗанов советта ике гасыр кисешкән чор татар тәнкыйтенең нәзари үсеш юлларын тәкъдир итеп доктор булды. Тубыл педагогия институтында татар бүлеген саклаган һәм гомумән шәһәрдә милли рухны ныгытуга зур көч куйган Флюра Сәйфуллина Сажидә Сөләйманова иҗаты буенча кандидатлык диссертациясен яклаганнан соң, Себер татарларының авыз иҗатын һәм әдәби ядкарьләрен өйрәнүне докторлык хезмәтенә мәүзугъ итеп алды. Хәзер профессор Казан Федераль университетының Филология

һәм сәнгать институтының татар әдәбияты тарихы кафедрасы һәм татар филологиясе бүлеге мөдире вазифаларын башкара.

Ә инде безнең гыйльми берлектә яклап, илебезнең төрле төбәкләрендә телебезне, әдәбиятыбызны укытып, башка юнәлешләрдә хезмәт иткән фән кандидатларының исәбен алу өчен башы саннар белән тулы Сан Санычның «ярдәме» кирәк булачак. Шуның өстенә совет барча төрки халыкларның яшь галимнәренә ярдәм итәргә тырыша. Беренче мәлне, үзләрендә мондый мөмкинлек ачылганчы, «күзне йомып», фин-угор телле хезмәтләрне дә алдык. Яклау советы Башкортстан, Чувашия кебек якын күршеләребез, Хакасия, Алтай, Дагыстан (безгә якын кумык, балкар телләре буенча), Якутия кебек еракта урнашкан кан кәрдәшләребез белән элемтәләрне ныгытырга, арабызны якынайтырга яна мөмкинлекләр бирде. Аерым алганда, мин үзем Алтай, Хакасия югары уку йортларыннан җибәрелгән аспирантларны алып, кулдан каләмне төшермичә ярдәм итеп, кафедрада хезмәтләрен, авторефератларын кат-кат тикшертеп, тиешле сыйфат дәрәҗәсенә житкереп, яклатып җибәрдем. Хәзер үзләреннән сәлам хатлары белән ул якларга барып чыккан кешеләр аша җибәргән рәхмәтләрен ишетеп, адәм баласына бәхетле булу өчен еш кына бер җылы сүз дә житә икән дип, алар өчен сөенеп яшим. Фәнни хезмәтләрне бәяләүче — оппонент буларак Мәскәү (Үзбәк Гыймадиев), Уфа (шагыйрь Равил Бикбаев), Алма-Ата (Азат Әхмәдуллин) һ.б. шәһәрләрдә нотыклар тотарга насыйп булды. Яңа Советлар ачканда үзләрендә әзерлекле галимнәр житмәгәндә, күршеләргә ярдәм итүдән баш тартмадык. Аерым алганда, профессор Фәрит Йосыпов белән Мордва дәүләт университетының советына әгъза итеп кертелеп, дык-дык, тык-тык итеп юл санаудан туймаган поездларга утырып берничә ел Саранск шәһәренә йөрдек. Кадерле кунаклар идек. Безне һәр килүебездә ул вакытта әле яшь каләм тибрәтүче, хәзер Мордва республикасының халык шагыйре Камил Тангалычев каршы алып, яклау тәмамлангач, кичен озатып калды. Һәр очрашуыбызда халкыбызның һәр зыялысы кадерле һәм исәптә дип, аның күнелендә милли рухны, сүнә барган татарлыкны ныгытырга тырыштык. Кызганычка каршы, «Звезда Поволжья» газетасында басылган мәкаләләрендә ул бердәм ил мәдәниятен яклавы, өлкән «абыйсы» ягына бөгелмәле, сыгылмалы мәдхияви кинаяләр ясавы белән аптыраштa калдырды. Күрәсең, бездән соң ми күзәнәкләрен агулаган «корткычларның» йогынтысы көчлерәк булгандыр, комфортлы яшәү ихтыяжы җиңгәндер.

Һәр диссертация советка яклауга чыгарылганчы кат-кат тикшерелә, шуннан соң әле ул шураның эксперт советының жиз иләге аша уздырыла.

Иң соңгы киртә — оппонентларның (ул грек сүзе «дошман» дигән мәгънәне аңлата) уңай бәясен алган диссертацияне яклау — карнавалны хәтерләткән бәйрәм кебек уза. Һәр яклауга укытучыларны, киң җәмәгатьчелекне, иҗатына, теленә мөнәсәбәте булса язучының үзен чакырып, мөмкинлектән файдаланып, татар филология фәнен үстерүнен милли менталитетыбызны күтәрү, саклау өчен мөһим икәнлеген, яклауга нәтиҗә ясаганда да, чәй-мәй мәҗлесендә дә катнашучыларның күңеленә сеңдерергә тырыштык. Минем яклауларда ясаган нотыкларымның әсасында, ачышка дәгъва итмәгән, төрлечә әйтелгән мондыйрак нигезләмә ятты. Олы һәм бай тарихыбыз белән масаеп, кулларны билгә куеп кына алга китеп булмый. Үткән юл трамвай рельсы кебек беръяклы, аның буенча артка, кирегә кайтып булмый. Татар халкы эшчән, тырыш, үҗәт булса да, аның ихтыяры, көрәшче рухы сындырылган, ул, әйтик, чечен лидерлары

кебек (хәер, яңа житәкчелекне «билле прәннек» белән алдадылар) кулына корал тотып мөстәкыйльлек өчен көрәшүгә әзер түгел.

Милләт буларак сакланып калу юлында Русиянең кыл уртасында яшәгән татар халкы өчен мәгариф, мәгърифәт һәм дин генә таяныч була ала. Укымышлы катламны арттыру, һәр өлкәдә фәнебезне үстерү, зыялыларыбызны күтәрү юлы белән генә милләтләр хатирәсендә үз лаеклы урыныбызны саклый алырбыз.

Яклау советларында әгъзалык иҗтимагый башлангычта, түләүсез булганга хөкүмәт «возрастной ценз» дигән зәхмәтне кулланмый. Галим хезмәткә бәя бирүдә, яшерен тавыш салуда катнаша алса, аңардан башкасы таләп ителми, чәй дастарханында катнашу-катнашмау мәсьәләсендә шәхес иреге саклана, ягъни һәркем аны үзе хәл итә. Һәр сайлаучының тавышы яклаучы өчен алтын бәясеннән дә кыйммәтрәк булганга, җаваплы кеше авыррак йөргәннәрне алып килергә, соныннан өенә озатып куярга дүрт көпчәкле арбасын да юнәтеп куя. Диссертация яклау, бигрәк тә бер утырышка берничә хезмәт чыгарылса, биш-алты сәгать буенча тынчу бүлмәдә утыру, бигрәк тә синең фәнни юнәлешеннән ерак эшләрне тикшерүнең шактый түземлелек соравын әйтеп тә тормыйм.

Ни хикмәте бардыр: диссертацияләр яклатуда катнашу күпме вакытны ала, алжыта, матди тарафтан бернинди файда китерми, дип зарланышсак та, һәр каләм тибрәтүче өнендә дә, төшендә дә үзен язучылар берлеге әгъзасы итеп күргәндәй, кесәсендә докторлык кенәгәсе, профессор таныклыгы йөрткән галим, советта тулы хокуклы шәхес булып утыру турында хыяллана. Мондый омтылыш түбәндәге мантыйк белән аңлатыла кебек. Беренчесе, гыйльми шура әгъзасы булу — сине җитлеккән фән әһеле итеп тану дигән сүз. Икенчедән, һәркем үз шәхси дөньясына, гаилә кабыгына кереп бикләнергә мәҗбүр булган, бер-беребездән ераклаша, читсенә барган четерекле заманда аена бер-ике булса да, төрле буын, фәнни юнәлеш вәкилләре, бигрәк тә хәл-әхвәлләрен белешергә зар-интизар булып яшәгән өлкәннәр советта туйганчы аралашу, зарланышу, басылып чыккан китаплары белән мактанышу, бүләк итешү мөмкинлеген алалар. Соңгысы иң мөһиме: бередә татар, өлешчә бөтен төрки филология фәненең кан басымы «үлчәнә», үсеш дәрәҗәсе ачыклана, юнәлеше билгеләнә. Советка әгъза итеп тәкъдим итмәгән өчен «дошманлашып», үпкәләп йөрүчеләре дә булды. Шулар исәбеннән, күренекле галимә Флёра Сафиуллина әгъза булуга дәгъва итеп йөрсә дә, мәрхүмәгә анда урын табылмады. Минем яктан да бераз ваклашу булгандыр инде. Хикмәт шунда: Садрый абзый кызы докторлыкка тәкъдим ителәчәк хезмәтен язып бетергәч, мин ана эшен КДУның гыйльми берлегендә яклауга чыгарга тәкъдим иттем. Ул чорда Ф.Сафиуллина факультетның «чит аудиториядә татар теле» исемен йөрткән, логатебез, тарихыбыз, мәдәниятебез белән кызыксынган кешеләрне, бигрәк тә чит илләрдән килгән галимнәрне кыска мөддәттә укытып чыгару белән шөгыльләнүче кафедра мөдире иде. Шуңар да совет җитәкчелеге (бу минем шәхси фикерем генә түгел) ханым үзе эшләгән оешмада расланган советта якларга тиеш дип фаразладык. Ул безнең тәкъдимне кабул итмәде.

Фикере катгый булып чыкты.

— Мин Мирфатыйх Зәкиев шәкерте, без аның белән энә белән җеп шикелле, гел бергә, ул кая, мин шунда. Ул Тел, әдәбият һәм сәнгать институты советы әгъзасы. Мин яклауга шунда чыгам.

Бу фәнни-тикшеренү институтында яклау берлеге безнекеннән күпкә соңрак оешу сәбәпле, анда да безнең шикелле галимнәр, байтагы ике

берлектә дә тавыш биреп утырса да, без өлкән абыйлар кебек, үзебезне «һавалырак» тоттык һәм бездә якламаган бер галимне дә гыйльми шурабызга әгъза итеп алмадык. Садрый абзый кызы өчен генә, бигрәк тә безнең кинәшне тыңламагач, искәрмә ясамадык. Флёра ханым да чегән арбасыннан төшеп калганнардан түгел иде. Савытыннан ташып чыккан чүпрәле камыр кебек, аның дәрте, җегәре аягын көчкә сөйрәп йөргән әллә ничә хатын-кызга җитәрлек иде. Аның чибәрлеге, лекция язасы урынга, авызларын ачып, укытучыга сокланып карап утырулары турында Илдус Гыйләҗев, Р.Зәйдулла кебек күренекле шагыйрьләр каткат язып чыктылар. Максатына ирешүдә ханымның үҗәтлеге баштан ашкан иде.

— Мин үзем язып чыгарган 500 китабымны бер капчыкка төяп ректорга керәм, шул чаклы фәнни казанышларым була торып Галиуллин советка алмый, дип шикаять бирәм.

— Сон, Флёра Садриевна, ректорны сайлаганда син бит ул мишәргә каршы тавыш бирдем, дигән идең. Хәзер аңардан ярдәм көтеп йөрисең.

Ул минем ихтыяҗы булмаган искә төшерүне киемгә сарган чүпкә дә санамыйча:

— Салахов ул турыда белми. Хәер, мин хаклы булганмын, аның факультетыбызга бер тиенлек тә ярдәме сизелми. Ана каршы тавыш биреп, Флорид Әгъзамов белән дөрес эшләгәнбез.

Гел аралашып, дустанә яшәгән Флёра ханым турында шаяртып, уйнапкөлеп язганнарым авыр сүз булып кабул ителмәсен. Кинәт фани дөньяны ташлап киткән кешене кызыклы, гыйбрәтле хәлләр белән искә алу аны хәтердә саклауның, онытмауның дөнья сүз сәнгатендә кин таралган алымы. Гомерен азга гына булса да озынайта алсам, билләһи дим, аны яклау советына, үземне чыгарып булса да, тәкъдим иткән булыр идем. Терсәкне тешләп булмый шул. Аны халкыбыз да, рәхмәтле укучылары да онытмый. Шагыйрә Нәҗибә Сафинаның галимәнең якты истәлегенә багышланган, «Дәүләт теле булыр татарның да,» дип, киләчәккә өмет нуры белән сугарылган, «Телем дип җан бирдең» юлламасы шуңа дәлил.

Әмма телсез калган бәгъзе әфәнделәр
Моны үлем диеп кабул итмәсеннәр, —
Мондый галимнәре булган милләт үлми,
Тел дип җан биргәнне үлем ала белми.
*(Н.Сафина, «Телем дип җан бирдең»)*

1990 елдан, көйләнгән тегермән шикелле, туктаусыз галимнәр «тарттыра» килгән яклау советыбыз белән мактауны туктатып (күкрәккә суккалап алырга да хакыбыз бар, шул арада гуманитар фәннәр буенча әллә ничә совет ачылып, үзләрен раслый алмыйча ябылдылар), безнең шурада якланган бер генә хезмәтнең дә ВАК тарафыннан расланмыйча калмавын гына искә төшерәм. Бары тик күбебезгә мәгълүм Минәхмәт Сәхапов диссертациясе буенча гына совет рәисен һәм яклаган кешене Мәскәүгә, ВАКка чакырдылар. Күренекле әдип — мөһаҗир Гаяз Исхакый иҗатын нигез итеп алган хезмәт, бәхәсләр белән булса да, уңышлы гына якланды. Мәгәр авторы имзасын куярга «оныткан» шикаять хат безне юлга чакырды.

Мәскәү, Петербург, Екатеринбург, Ростов һәм башка гыйльми үзәкләрдән җыелган, 25 профессордан торган тикшерү, бәяләү комиссиясе алдында диссертантның хезмәте һәм гомумән советның эшчәнлеге турында

хисабымны М.Сәхапов ишек ярыгыннан, үзе әйткәнчә, калтыранып тыңлап торды.

Кыскача эчтәлеге белән таныштырсалар да, хатны укытмадылар, диссертантның нурлы йөзен күрүне дә кирәк санамадылар. Советның эшен канәгатьләнерлек дип таптылар, бәхәсле диссертацияне дә расладылар. Мин үземнең чыгышымда М.Сәхапов хезмәтеннән бигрәк, советның абруен, намусын, киләчәген, ахыр чиктә, татар теле һәм әдәбияты фәненең дәрәҗәсен якладым. Дипломын алганнан соң, Минәхмәт әфәнденең «рәхмәте» бик тиз килеп житте: «Мине Түбән Новгород, Самара советларында якларга чакырганнар иде, сезгә ялынып йөрисе дә булмаган», дип, гафу итегез, сасытып йөрде. Яклау барышында М.Сәхапов хезмәтенең методологиясен тәнкыйтьләп чыгыш ясаган академик М.З.Зәкиев белән судлашып йөрүе генә житмәгән, Мирас фондын һәм шул исемдәге журналны кулына тоттырган Флүн Мусин, иң актив хәбәрчеләре Хатыйп Миңнегулов, Фәрит Йосыпов һ.б. күренекле галимнәр белән әчелешле булып бетте. Әлбәттә, Муса Жәлил батырлыгына кизәнүгә чаклы барып житкән адәм мине генә «игътибарсыз» калдыра алмады. Аның иң зур «казанышы» берничә елга укучыны «Мирас» журналыннан мәхрүм итү булды.

Яңа гасыр башына чаклы Мәскәү советлар эшенә тыкшынмады, аяк чалу булмады диярлек. Илдә өстенлек иткән демократик рух безгә дә тулы мөстәкыйльлек бирде дисәк тә зур хата булмас кебек. Ләкин тиздән галимнәрнең бу илгә артык кашык булулары хөкүмәтнең акчасын юкка «сарыф» итәргә җыенмавы яңа йөзнең беренче ун елында бик ачык сизелә башлады. Әүвәл советлар белән «уйнау» башланды: аларның эшен йә туктаттылар, йә белгечлеген үзгәрттеләр. Күбесенә янәдән фатиха бирмәделәр. Яклаучылар алдына өстәмә киртә куелды, эшләрне туктатып тору өчен ВАК исемлегенә кергән журналларда басылу мәҗбүрияте уйлап чыгарылды. Фән докторы булу өчен әүвәл Мәскәү белән Петербургта гына чыга башлаган «тамгалы» мәҗмугада 7-8 мәкалә, түбәнрәк баскычтагы дәрәҗәгә, ягъни кандидат булуга дәгъва итү өчен 1-2 мәкалә бастыру шарт итеп куелды. Берничә битлек мәкалә өчен башкала журналларында 20-30 мең түлисе булса, Чабаксар, Архангель, Барнаул кебек шәһәрләрдә зур авырлык белән ачылган басмалар 5-10 мең белән канәгатьләнделәр. Диссертацияләрнең сыйфатын күтәрүгә хезмәт итәргә тиешле гамәл акча җыю чарасына әверелде. Сәмән янчыгы калын бәндәләр эшләрен түләп яздыру өстенә, мәкаләләрен дә тиз генә бастырып чыгара алдылар. Бу юнәлештә көлкеле хәлләр дә булгалап торды. Акча капчыгы юан бер галим алтынчы сыйныф физика китабыннан бер бүлекне мәкалә рәвешенә китереп, зур акчалар түләп, ВАК журналында бастырып та чыгарган. Басманы Путинга да, Югары аттестация комиссиясенә дә җибәргән, нәтиҗәдә бик зур гауга чыккан дип сөйләделәр. Үзебездә дә шуңа якын хәлләр булгалады. Татар теле һәм әдәбияты буенча бик күп мәкаләләр Казан ветеринария академиясе журналында басылдылар. Акчаңны гына вакытында түлә, мәкаләңне беркем укып та, тикшереп тә тормый. Берничә айдан иптәш яклауга ук чыга. Ветеринар кардәшләргә рәхмәттән башка нәрсә әйтәсең!

Икенче баскычта ВАК журналлары белән совет әгъзаларын да «тикшереп» алырга булдылар. Советта әгъза булу өчен галим шул ук түләүле мәҗмугада өч мәкалә бастырырга тиеш иде. Элек аның гыйльми казанышы, ачышы саналган монографияләре, яклаган дәвамчылары, аспирантлары исәпкә дә алынмый. Чагыштырып карагыз: галимнең фәнгә

керткән яңалыгы, ачышы, концепциясе гомерен биргән саллы китапта тулырак ачыламы, әллә берничә битлек түләүле мәкаләдәме? Советта көннәр буена тирләп-пешеп утырган өчен рәхмәттән башканы (анысы да гел тәтеми, яклаучының аң үсеше дәрәҗәсенә бәйле) ишетмәгән, сукыр бер тиен алмаган, кунак-кунак «уйнаудан» да тәм тапмаган, сиксәнен ваклаган яисә шул сызыкка якынлашып килгән галим ни өчен әле пенсиясенең яртысын түләп, ВАК мәкаләсен бастырсын икән? Хохол абзан әйтмешли, «дураков нема». Ә аларның тирән белеме, гомере буена туплаган фәнни фикере, хезмәтләрне тикшергәндә, бәһалап бетергесез иде.

Соңгы елларда тагын бер яңалык уйлап таптылар. Хәзер яклау процессы башыннан ахырына чаклы видео тасмага төшерелергә һәм башка кәгазьләр белән бергә ВАКка җибәрелергә тиеш. Хезмәтне тикшерү барышында торып йөрү, бүлмәдән чыгу катгый рәвештә тыела.

Югарыда әйтелгән кысулар барлык советларга кагыла, ил галимнәре башына төшкән гарасатка бергәләп түзәрбез дип бераз тынычланган идек, буйсынган милләтләргә каршы, тез астына китереп суга торган яңа бер «бирем» уйлап таптылар. Урыстан башка телләр (укы: халыклар) яшәешенә каршы алып барылган гомуми сәясәт яклау советлары эшчәнлегенә дә китереп бәрде. Докторлык диссертацияләре баштан ук урысча язылса, кандидатлыкка дәгъва иткән хезмәтләр нигездә татар телендә тәкъдим ителә иделәр. ВАК әмерендә «диссертации пишутся, как правило, на русском языке» дип язылган булса, соңгы «төзәтмәдә» «как правило» ачыкламышы артык дип табыла һәм алып ташлана. Язмышларын фән белән бәйләргә ниятләгән яшьләрнең күбесе хезмәтләрен туган телләрендә әзерләгән булсалар, ВАК мәкаләләре өчен генә түгел, хәзер диссертацияләрен башка лөгатькә тәрҗемә иттерүгә түләүле тылмачлар эзләргә тиеш булалар. Борынгы әдәбиятның, «Тукай теле», татар фонетикасы, сүз байлыгыбыз турында башка шивәдә язып азаплан инде! Милли телнең, әдәбиятның бөтен нечкәлекләрен тәрҗемәдә чагылдырып булмаячагы көн кебек ачык. Автореферат, ВАК мәкаләләре, стенограмма, чыгышлар, рәсми кәгазьләр элек тә, дәүләт тоткан халык телендә җибәрелә иделәр, ләбаса. Мәкалә исеменә чыгарылган сорауга җавап әзер дип фаразлыйм: бу хакимияткә «әрәмтамак», илне көнендә үк баета алмаган белгечләр кирәк түгел. Укучы советлар эшли, диссертацияләр яклана тора дияргә мөмкин. Мондый күзбуяулар гына гомуми сәясәтне, нәтиҗәне яхшы якка үзгәртә алмыйлар икән шул. Матбугатта китерелгән рәсми саннарны дикъкать белән укып, чагыштырып карагыз.

«Фән өлкәсендә кадрлар мәсьәләсе көннән-көн кискенләшә: 1990 елдан 2012 елга кадәр Русиядә галимнәр саны өч тапкыр кимегән — 1 миллион 119 меңнән 370 меңгә генә калган».

Яшь галимнәрнең читкә чыгып китүе яисә эш хаклары түбән булу, белгечлекләрен алыштыру, бизнеска күчүләре сәбәпле, Русия фәненең «олыгаюы» күзәтелә. Менә икенче бер мәгълүмат. «1980 еллар ахырында галим-голәма арасында 50-70 яшьлек хезмәткәрләр өлеше 27 процентган артмаса, бүген ул 50 процентка якынлаша. Русия академикларының уртача яше 72,2гә, фән докторларыныкы 60,8гә тәңгәл.» *(«Мәдәни җомга», 2012, 19 октябрь).*

Бу саннардан янә бер нәтиҗә сорап тора: галимнәргә мөнәсәбәт үзгәрмәсә, Русия, шул исәптән Татарстан фәне «әбиләр һәм бабайлар» көненә калырга мөмкин. Киңәш бирүчеләр, акыл сатучылары арта

барган саен, фән арбасының төбенә җигелеп тартучы яшьләр, һәм җәмгыятьнең асылын, киләчәген билгеләгән зыялылар катламы кими барыр. Алардан башка бер ил дә үсешенең яңа баскычына күтәрелә алмаячак.

## Кушу аша кыскарту...

Казан дәүләт университетында татар бүлегенең факультет дәрәҗәсенә күтәрелеп кенә калмыйча, покосны киң алдырып үсеп китүе, аның газиз баласы — Гуманитар институтның җөмһүриятебездә милли рухны саклауга, икенче дәүләт теленең гамәлгә ашырылу мөмкинлегенә ышандыруга елдан-ел җитдирәк йогынты ясавы кемсәләргәдер «татарларның артыграк азынуы» кебек тоелды, саруларын кайнатты бугай.

Аз вакытка һәм даруханәдәге шикелле мыскыллап кына бирелгән демократия гонсырларыннан тулы көчкә файдаланып, үпкәсен тутырып сулыш ала башлаган татар факультетын 2000 елдан, төрле сәбәпләр табып, таркату, бүлгәләү башлана. Һәр гасыр башы кешелеккә уйламаган, көтелмәгән афәтләр, бәлаләр алып килә дип юкка гына уфтанмыйлар икән.

Милли мәнфәгатьләрне, телләрне кысудан башланган империячел рухның көчәюе, һәр шәйне үзәкләштерү нәкъ шул чорда башланды. Гөнаһка каршы, шул елда факультетның, аны яклап күтәрелергә тиешле кешесе — декан чирләп китте. Яңа берлекне таркату, бүлү өчен сәбәбе дә табыла. Теләк кенә булсын, калганын сатып алырга мөмкин дигән шикелле, кайсыдыр акыллы башы Казан император дәрелфөнүне оешкан санәдә, аның составында бик күп, шул исәптән татар телен дә өйрәнгән «Восточный разряд» булуы һәм аның XIX гасыр урталарында Петербург университетына күчерелүе исенә төшә һәм, табигый ки, бу юнәлешне янәдән торгызу нияте, балыкчы калкавычы кебек, өскә күтәрелеп чыга. Көнчыгыш телләрне өйрәнү («Востоковедение») институтының кирәклеген таныган хәлдә дә, бу гамәлне гөрләп эшләп яткан факультетны «таламыйча», чын хуҗаларча, үзенә студентлар санын биреп, беренче курска сайлап алып, үстереп җибәрү юлы да бар иде. Халык әйтмешли, әзергә-бәзер яшәве, мәсьәләне башкалар, шул ук «мескен бүрекле» татар исәбенә хәл итүе ансат бит. Нигә әле ми черетеп утырырга: кытай телен алып баруга үзләреннән чакырылган гаилә әзер, гарәп-фарсы, төрек телләрен укытырдай мөгаллимнәрен дә факультет әзерләп өлгергән. Башка уку йортларын тәмамлаган, Төркиянең үзеннән килеп, монда төпләнеп калган белгечләре дә җитәрлек. Шул рәвешле жаны-тәне илә тырышып, иркәләп үстергән бүлекне студентлары, укытучылары белән, безнең белән киңәшеп тә тормыйча, «башка» чыгардылар.

Көнчыгыш телләр бүлеген бездән аерып алуны, газиз кызыбызны мәҗбүри читкә кияүгә бирү кебек үк, сыкранып, гаделсезлек (ул конкурска да китереп бәрде), дип авыр кабул иттек. Борынгы әдәбиятыбызны, Коръән поэтикасына барып тоташкан сюжет-мотивларны, уртак мифологияне шәрехләү өчен генә дә гарәп-фарсы, төрек телләрен сукалау лазем иде. Берише гарәп илләре, бигрәк тә Төркия белән гамәли бәйләнешләр тернәкләнеп килүе дә исәпкә алынмады.

«Сезнең факультетка студентлар санын киметмибез» (20 дән артык талибыбыз, шактый укытучы яна институтка күчерелде) дисәләр дә, вәгъдә бирү капчык ташу түгел, аркада кабырчыгы калмый, бу ышандырулар бик тиз онытылды. Киресенчә, алдагы елларда «факультетыгызга конкурс зур түгел, сезгә укырга керүчеләрнең белем дәрәҗәсе түбән» дигән сылтау белән студентлар санын һәр елны кыскарта тордылар.

Үткән эшкә салават, балавыз сыгып утырудан бәрәкәт юк, килеп туган хәлдән файдалы якны таба белергә кирәк дигән карарга килдек. Йөкне бергәрәк тартырбыз дигән хыялыбызга нигез дә бар иде кебек. Ник дисәгез, яңа институтның хуҗасы итеп, хезмәт юлын безнең факультетта гади укытучыдан башлап, көнчыгыш телләр кафедрасы мөдире дәрәҗәсенә күтәрелгән, 1990 елдан эшләп килүче диссертацияләр советында докторлык дәрәҗәсен яклаган Җәмил Зәйнуллинның билгеләнүе күңелләрдә өмет чаткысы уятты. Кызганыч ки, бу ышанычыбыз акланмады, чаткы ялкынга күтәрелә алмыйча, сүнде. Ул беренче адымнарыннан ук, үзен күтәргән коллектив белән арасын өзде, яклау советына кертсәк тә (ике арада җанлы җеп булыр дип), утырышларга йөрмәде, «ялынып» чакырган очракларда да, хәерчегә сәдака өләшкәндәй генә, кулын куеп, чыгып китә торган булды. Иң аянычы: Көнчыгыш институтында татар теле сәгатьләре юк дәрәҗәсендә калу өстенә, гомумән татар балаларының саны да кыскартылды кебек. Гарәп-фарсы, бигрәк тә кытай телен өйрәнүне фәнебез, киләчәгебез өчен зарур дип җан атып йөргән, Җәмил Зәйнуллинның язмышында да мөһим роль уйнаган тарихчы Миркасыйм Госмановның бик нык гарьләнеп зарланганы күңелдә яңгырап тора.

— Мин Зәйнуллиннан моны көтмәгән идем. Аны эшкә урнаштыруга күпме көч куйдым. Ә бит директор кәнәфиенә утырганчы, чын милли рухлы кеше булып йөрде.

Тауның югары башыннан чананы этеп җибәрсәң, аны туктатам димә. Алдагы елларда университетта яңа факультетлар ачылу туктап тормады (әйтик, фәлсәфә, психология, халыкара мөнәсәбәтләр һ.б.), төрле сылтаулар табып, татар факультетын кыскарту, кысу дәвам итте, 2011 елда педуниверситет нигезендә оешкан Филология һәм сәнгать институты составына кертелеп, ул бөтенләй яшәүдән туктады.

XXI гасырның беренче унъеллыгында милли сәясәттә артка чигенешләрнең башлануы Гуманитар институт тирәсендә барган ыгы-зыгыда ачык күренде. Татар җанлы Мәгариф министры В.Г.Гайфуллинның туган телебездә аралаша, сөйләшә алуы җитәкчелеккә куркынычлык һәм куркыныч муллык булып күренде. Ректор буларак шактый эшләр башкарырга өлгергән, шелтә түгел, кисәтү дә алмаган Илдус әфәндене искәртеп тә тормыйча, азат итеп, урынны кечәге Мәгариф министры өчен бушаттылар. Әнә да институт хуҗасы булып озак эшләргә насыйп булмады. Татарстанның җитәкчелегенә татар мәктәпләре, балалар бакчалары өчен милли рухлы, иманлы укытучылар, тәрбиячеләр әзерләүче уку йорты алып ташланырга тиешле авырткан теш булып чыкты, аны Татар гуманитар педагогия университетына китереп куштылар. Гуманитар институтның дус, бердәм рухлы коллективы юкка чыгарылды.

Татар халкының озын һәм аянычлы тарихында үз лөгатебездә эшләүче берләнбер уку йортын кушудан башланган афәт, «татар» сүзе өчен генә дип уйлыйм, олы тарихлы Казан педагогия (ТГПУ) университетын юкка чыгаруга — инкыйразга алып килде. Ник дисәгез, яңа федераль университетка кушылган башка уку йортлары — Финанс-экономика, Алабуга педагогия институтлары, хәтта Яр Чаллы политехника югары уку йорты да исемнәрен, яшәү рәвешләрен үзгәртеп, филиал булып аталсалар да, мөстәкыйльлекләрен сакладылар. Молох тулысынча бер югары уку йортын гына йотты. Бу югалтуны, татар факультетын кушып юкка чыгарган шикелле, гел Мәскәүгә сылтап та булмый.

Федераль университет дигәне дә Казанга бик кирәк булдымы икән? Ул бик абруйлы, отышлы, файдалы гамәл булса, беренче чиратта Мәскәү, Санкт-Петербург университетлары «федераль» статусы алырлар иде. Әлар ашыкмый. Ике гасыр элек Русия императоры әмере белән ачылган Казан дәүләт дәрелфөнүне гаять абруйлы югары уку йорты иде. Төрле дәрәҗәдәге арбалар тагылган «федераль паровоз» шул үргә кайчан күтәрелә алыр икән?

Идел буенда Федераль исемен йөрткән уку йорты пәйда булган икән, үткән эшкә салават, ахыры хәерле булсын, яңа берәмлек үссен, яшәсен дип дога кылудан башка хутыбыз калмады дип уйлыйм. Аның ректоры Илшат Гафуровка бәяләрнен, мөнәсәбәтнең катлаулы, каршылыклы булуы шулай ук табигый. Дөреслек фикер төрлелегендә табыла, диләр философлар. Кем ничек уйламасын, минемчә, оештыру, бер сыйфаттан икенчесенә күчү, болганчык суда балык тоту чорында нәкъ Рәфкәть абзый угълы кебек каты куллы экономист, Алабуга шәһәренә яна сулыш өргәндә хуҗалык эшләренең серенә төшенгән, кискәндә-ямаганда икеләнүне белмәгән замана баласы житәкче булырга тиеш дип фаразлыйм. Мин аңа ата-анасын яхшы белгән, хөрмәт иткән, тормыш юлын Алабуга пединститутында ассистент дәрәҗәсендә башлаган өчен генә уңай бәя бирмим, эчке тоемым буенча кушу-алулар, вату-төзүләр заманы узып, анын үзенә жан, кан биргән милләт — татар мәнфәгатьләренә игътибар итәчәгенә өметләнеп, шул хакта хыялланып әйтәм. Йөрәкне корыч пансыр эченә бикләп кенә, тормыш җилләреннән, иң тирәндә, аң төпкелендә яткан милли хисләрдән ашереп калып булмый. Әле бит яшәүнең мәгънәсе, иман, үзеннән соң килгән буыннар бәясе дигән бөек хакыйкать тә бар.

Яңадан кору, кушу аша кыскартулар чорында күсәкнең иң авыр башы татар телен, киләчәген кайгырткан, зыялыларын әзерләгән берәмлекләргә эләккәнен дә истән-яттан чыгарырга ярамый. Аерым алганда, саф татар югары уку йорты — университеты булып күтәрергә бөтен мөмкинлеге булган Гуманитар институтын тәмамлап, җөмһүриятебезнең төрле төбәкләрендә эшләгән укытучылар, милли жанлы шәхесләр һәм «Гуманитар институт» дигән тукталыш — истәлек булып калдылар. Аның шулай иртәнге рәшә кебек юкка чыга алуына берәү дә ышанмый кебек. Автобуста яисә троллейбуста барганда шул исемне ишеткәч, әүвәл күңелгә талгын рәхәтлек йөгерә, чын хәлләр искә төшкәч, күңелне моңсулык баса, күзгә яшьләр килә.

Милли җанлы кешеләрне зур кыенлык белән, олы өметләр баглап ачылган татар факультетының язмышы аеруча борчыды. Бигрәк тә мәктәп укытучылары: «ул бит безнең килеп сыенып, жылы сүз ишетер почмагыбыз, караңгы төндә юлга чыккан, татар теленә гашыйк кешеләр өчен өмет чаткысы, нур бөркеп торучы якты шәм иде, шуны да саклап кала алмадыгыз», дип битәрләүгә, үпкәләүгә чаклы барып життеләр. Бар гөнаһны үз өстенә алып утыру заманасы үтеп китте, шунар да мин укны соңгы деканыбыз Искәндәр Гыйләжев тарафларына юнәлттем. Чыннан да, яшь хуҗабыз амбразураны күкрәге белән капламады, «ректор янына үзем генә керәм, факультетны саклап калу буенча тәкъдимнәрем әзер, берегез дә кысылып йөрмәгез», дип, безне, аерым алганда мине, бу шөгыльдән бөтенләй читләштерде. Ректоратта ул булуын булды, мәгәр файдасы күренмәде, күрәсең, тарихчы профессор ни-нәрсә үзгәрсә дә, хәер өстәп урамда калмасын чамалап, күтәрелеп бәрелмәгәндер, үз фикере белән кереп, бүлмә хуҗасы фикере илә чыккандыр дип уйлыйм.

Коллективка, деканны сайлаган мәлдә үк, киләчәк язмышы турында уйларга кирәк иде. Терсәкне тешләп булмаган шикелле, хәзер ни өчен теге вакытта уйлабрак эш итмәдек икән дип ухылдаудан, аһылдаудан да файда юк.

— Ярый, хуш. Ә факультет укытучылары, студентлар ничегрәк кабул иттеләр бу хәбәрне? — дигән сорауларга болайрак җавап бирдем.

— Укытучыларның зур күпчелеге бу афәт белән килешмәсә дә, курку хисе, эшсез калу куркынычы кулларны бәйләде дә куйды. Хәзер бит совет чорындагы шикелле, хезмәт кодексы, сине яклардай профсоюз юк. Без, өлкәннәр, почмакта чыш-пыш килүдән уза алмадык. Яшьләр кыюрак булып чыкты. Алдарак әйтелгәнчә, факультетның тәрбия эшләре бенча декан урынбасары Радик Сабиров бер төркем студентларны урамга алып чыгып карады. Нәтиҗә «унай»: аның факультет, милләт мәнфәгатьләрен яклап күтәрелүе гомуми сәясәткә каршы килгән диссидентлык дип бәяләнде, егетне урынбасарлыктан алып аттылар. Ул чорда әле утызын гына тутырып килгән укытучының, фәннәр кандидатының эчендә ниләр кайнаганын, Татарстанда милли ихтыяҗларны яклауның куркыныч нәрсә икәнен, хәтта эзәрлекләнүен аңлады кебек. Егет үз кабыгына кереп бикләнде, эшкә, фәнгә күнеле тартмавын да аңлап була.

— Факультет укытучылары берни кыла алмады, ди. Әле бит безнең татар депутатлары, җитмеш проценты кесәсендә татар бүлеге һәм татфак дипломын йөрткән язучылар берлеге бар. Алар сезне ярдәмнәреннән ташламагандыр шәт?

— Чаң кагучы, набат сугучы шәхесләр булды. Анда укымаса да, әрнеп, факультетны бетерүне үз шәхси югалтуы кебек кабул итеп, дошманнар арттырудан да курыкмыйча, рус телле матбугатта күтәрелеп чыккан зат — Фәндәс Сафиуллин булды, язучы, тележурналист Искәндәр Сираҗи үткен сүзен әйтте, бөтен каршылык акцияләрендә Р.Зәйдулла актив катнашты һәм шуның белән вәссәлам. Язучылар берлеге битарафлыкның югары үрнәген күрсәтте. Профессор Х.Ю.Миңнегуллов һәм мин, ул чордагы идарә хуҗасы И.М.Ибраһимовка «каләм осталарын күтәрик, хат белән чыгыйк», дип кат-кат мөрәҗәгать итеп карадык, үзебезнең мөнәсәбәтне президентка да, ректорга да җиткерик дип үтендек. Файдасы тимәде. Рәис миңа мондый аңлатма бирде.

— Тәлгат абый, мин ул хакта төрле дәрәҗәдәге кешеләр белән сөйләшеп карадым, юкка кыбырсып йөрмәгез, берни эшли алмаячаксыз, — диделәр.

Республика җитәкчелеген, депутатларны, хәтта президентны да, ректорат «киләчәктә милли компонент тагын да көчлерәк үсеп китәчәк, борчылыр нәрсә юк, тыныч йоклагыз», дип, вәгъдәләр белән туендырып, данлыклы татфак укытучыларын, талиб-талибәләрен ярык тагарак янында калдырып, дусларча, куллар бирешеп, таралыштылар. Без һаман сөйләшүләрнең нәтиҗәсен көтеп яшибез.

Безне элеккеге ТГПУ нигезендә оешкан Филология, сәнгать институтына күчерделәр дигән идем. Барчасы күптәнге танышларыбыз, фән йөген бергә тартышучы дусларыбыз. Безне яхшы каршы алдылар. Урынны яңа бинадан бирделәр, бүлмәләр якты, җылы, лифтта этеләсе-төртеләсе юк, мәгәр мөстәкыйльлеге чикле бу оешманың да мөмкинлекләре зур түгел. Институт директоры Рәдиф Җамалетдиновның, изге ниятләре күз карашыннан ук сизелеп, бөркелеп торса да, ул да артыгын булдыра алмый, тартәгә тибүнең аякны авырттырудан башка файдасы булмасын аңлый.

Күбесе үз фәнни мәктәбен тудырган, дистәләгән шәкертләр тәрбияләгән элек кайгы-хәсрәтне белмәгән профессорлар ярты, чирек ставкага калдырылдылар. Студентлар саны кыскарган саен, дәресләр кими. Ауропача кыйланып, бакалавриятка, магистратка күчү дә сәгатьләр санын югалтуга алып килде. Гаеплене табуы, кемгәдер дәгъва белдерүе кыен. Үзеннән-үзе шулай килеп чыга дигән тәэсир кала. Бу кыскарту — кушуларның нигезендә җәмгыятьтә кешелеклелек сыйфатлары тәрбияләүгә чакырылган гуманитар фәннәргә каршы эшләнгән бер гамәл дигән уй да килә, кәбестә кебек бер катлы башыма. Ник дисәгез, техник һәм төгәл фәннәр берни оттырмадылар. Физиклар, химиклар, математиклар, хәтта юристлар үз урыннарында, үз бүлмәләрендә калды, күбесе факультеттан институт дәрәҗәсенә күтәрелде, кирәк-яракка умыртып акчасын да алдылар.

«Ялгышны төзәтеп, язмышны үзгәртеп», дип җырласак та, үткәндә ирешелгән үрләргә янәдән күтәрелеп булмый икән шул. Югалтуы җиңел, табуы кыен икәнлекне татар мәнфәгатьләренә хезмәт иткән институтларыбызны, факультетларыбызны бер-бер артлы югалта баруыбыз милләтнең томанлы, өметсез киләчәгенә ишарә түгелме?

## Русиягә татар кирәкме?

Советлар Союзы дип аталган ясалма империя, 1917 елда Русия үзеннән-үзе диярлек сыгылып төшкән шикелле, берничә көндә вак-вак мөстәкыйль илләргә таркалды да куйды. Элек дәүләтчелеге булмаган мәмләкәтләр дә тулы мөстәкыйльлек алдылар. Татарлардан сан ягыннан күпкә калышкан Балтика диңгезе буе илләре, Кыргыз, Таҗик кебек халыклар үз дәүләтләрен торгызу, тудыру шөгыленә керештеләр. Яңалык авырлык белән, көрәш, тартыш аша барса да, әлегәчә берсе дә бәйсезлегеннән баш тартып, «безне кире Русиягә алыгыз» дип гариза язганы юк кебек. Чөнки азатлыктан кадерле, татлы, баен да, хәерчесен дә якынлаштырган төшенчәнең уйлап табылганы юк.

Тарих биреме буенча, Русия уртасында калган татар, башкорт, чуаш, якут, бурят һ.б. халыклар мөстәкыйльлек турында бирелгән вәгъдәләргә ышанып, элеккеге сәяси, икътисади, мәдәни хәлләрендә диярлек калдылар. Дәүләтчелек тарихы бик ерактан килгән татар халкы XX гасыр башында һәи ахырында физик җегәрен һәм рухи көчен, ихтыярын, омтылышын күрсәтеп алса да, ике чорда да тулы бәйсезлек алу димим, һич югында үз җире байлыгына тулы хуҗа булып, мәгарифен, телен саклау юнәлешендә өмет- хыялларын тормышка ашыра алмады. Татар халкы, бигрәк тә зыялылары СССР таркалуның беришe уңай җимешләреннән файда күреп калырга тырышмадылар дип әйтеп булмый. Яңа Русия эчендә калган милләтләр арасында иң күп санлысы, мәдәни, икътисади яктан алгарак киткән татар халкы һәр өлкәдә үрнәк күрсәтергә тиеш иде. Ачы телле Балтика буе илләре, кирәк чакта тешен күрсәтеп ала белгән Тарас Шевченко, Абай оныкларын башка халыклар мәнфәгатьләре борчымый, үз эчке, тышкы мәшәкатьләре үзләренә җиткән иде. Хәтта үзләре көтмәгәндә күктән иңгән бәхеткә тарган төрки мәмләкәтләре дә безгә ярдәм итәргә ашыкмадылар. Мөстәкыйльлек алган бер Илбашы: «Бу татарларга тагын ни җитмәгән, болай да артыгы белән алдылар ич», дип ычкындырган. Күрше тавыгы каз, казы күркә булып күренгән очрак шулдыр инде ул.

Халкыбыз 90-нчы еллар башында ярсып мәйданнарга чыкты, хөкүмәттән кичекмәстән тиешле карарлар чыгаруны сорады, таләп итте.

Шул көрәшнең нәтиҗәсе булып 1990 нчы елның 30 нчы августында Югары Совет зур авырлык, катлаулы көрәш, ызгыш, талаш белән булса да, Суверенлык декларациясен кабул итүгә иреште. Аның нигезләмәсе күпмилләтле җөмһүриятебезнең икътисадый, сәяси, иҗтимагый һәм рухи үсеше мәнфәгатьләрен канәгатьләндерерлек күләмдә ирекле хокукый дәүләт төзүгә омтылышны чагылдырды. Ошбу декларацияне татар халкы зур җиңү, үзен гел кыерсыта, кыса килгән тарихның мәрхәмәтле елмаюы дип кабул итте. Төрле шәһәрләрдән, район үзәкләреннән, якын-тирә авыллардан җыелган вәкилләр ул төнне Ирек мәйданында уздырдылар, җырладылар, биеделәр, ТИҮгә нигез салган тарихчы, Себер егете Марат Мөлеков әйләнешкә кертеп җибәргән «Азатлык» сүзен яңгыраттылар. Декларациядә республиканың табигате, җир асты һәм өсте байлыклары, күпчелек завод-фабрикалар халык мөлкәте дип язып куелган иде. «Татарстан халкы» дигән төшенчәгә татарлардан башка рус, чуаш, мордва, мари кебек шунда озак еллар гомер иткән яисә соңрак күчеп килгән башка милләтләр дә керә һәм ул барчасының яшәеш мәнфәгатьләренә туры килә иде.

Татарларның мөстәкыйльлек турындагы декларациясе Русия эчендә калган башка халыкларны да уятып, дәртләндереп җибәрде. Безнең арттан башкорт, якут һ.б. милләтләр суверенитетлары турында игълан иттеләр. Чечня үзен бәйсез ил буларак таныту өчен көрәш юлына чыкты. Әлбәттә, көчләр тигез түгел иде. Минемчә, анда җинелүче дә, җиңүче дә булмады.

Декларацияне кабул итү тудырган гомуми шатлык хисе, аның беренче нәтиҗәләре турында З.Зәйнуллин, Ф.Бәйрәмова, Р.Юнысов, В.Якупова, Ә.Мәхмүдов һ.б. заманында бик күп һәм тәфсилле яздылар. Шапырынулар, кизәнүләр дә аз булмады.

90нчы елларда татар халкы үзенең мөстәкыйль милләт буларак барлыгын, яшәвен, гади бер шөреп кенә түгеллеген расласа да, үзенең эчке җегәрен, йөзәр еллык коллык хәлендә кысылган сиртмәсен ачып җибәрә алмады, авыр йөкне, көянтәне җилкәсеннән алып ыргыту җаен тапмады.

Дөрес, иелгән башлар аз булса да, югарырак күтәрелде, киек каз юлларын да шәйли башладык. Чаллы, Түбән Кама, аз булса да Казан, аның тирәсендәрәк урнашкан районнар да үз табигый хокукларын таләп иткән кыймылдаулар сизелде. Мәгәр үзгә төбәкләрдә, башка халык арасында яшәгән татарларны күтәрә яисә бер үзәккә, сөт калган изге Ватаннарына җыя алмадык. «Ялкаулары, һөнәре булмаганнары яисә җинел тормыш эзләгәннәре генә кайта», кебек төрле сылтаулар табып, прапискага кертмичә, яшәү урыны бирмичә, күпләрне кире бордык. Рәнҗетелгәннәр: «Татарстан безгә мохтаҗ түгел, әби-бабайлар нигезенә кайтуны теләми», дип хәбәр таратып, җигелгән атларын кире туардылар. Шунысы үзенчәлекле: үзе дә яңа аякка баса килгән Русия җитәкчеләрен, сәясәтчеләрен союздаш республикаларның бүленеп чыгуы да, кайбер милли автономияләрнең суверенитет игълан итүе дә артык борчымады кебек. Ә менә Казанның аерылып чыгуга дәгъва итмәсә дә, мөстәкыйльлек турындагы карары куркытты, күпләрнең саруын кайнатты. Мәскәү эмиссарлары, шымчылары туктаусыз ике арадагы юлны таптадылар. Татарстан илнең уртасында урнашкан, ул чемодан түгел, аны күтәреп алып чыгып китеп булмый кебек метафора да «бердәм һәм бүленмәс» Русия тарафдарларын тынычландырмады. Җитәкче даирәләр генә түгел, ә русның сәясәттән ерак, иң гади кешеләре дә татарның «чабуына» ябыштылар.

Күренекле балалар язучысы Шәүкәт Галиевнең Переделкино иҗат йортыннан кайткач, ачынып та, көлеп тә бәян иткәне хәтердә.

– Бәйсезлек турында декларация кабул ителеп, берничә ай үткәч, иҗат йортына килдем. Мин һәр елны бер, кайсы вакыт икешәр тапкыр шунда ял иткәч, аш-су таратучы түтәйләр «теленә салынырга яраткан татарин» буларак, мине яхшы беләләр. Вак-төяк күчтәнәчен дә кызганмый идем. Дустанә мөнәсәбәттә йөргән официант, яше иллеләр тирәсендә булыр, беренче тапкыр күргәндәй, минем якка сәер-сәер карап ала, ризыкны да рәсми генә китереп куя башлады. «Мария ханым, нәрсә булды, чирләп китмәгәнсездер», дип сорап куям.

– Юк, чирләмим, исәнлегем әйбәт. Тик сезнең белән соңгы күрешүебездер?

–Нигә алай дисез?

– Сез Переделкинога артык килмәссез инде, — ди ханым, буш подносын икенче кулына күчереп.

Мин аны тынычландырырга ашыгам.

–Киләбез, киләбез. Монда шартлар әйбәт, яхшы ашатасыз!

– Сез, татарлар, бездән аерылып чыгасыз дип ишеттем. Үзегезнең иҗат йортына гына барырсыз инде.

Ашатучыбыздан да өлкәнрәк, бүлмәләрне җыештыручы түти дә, шундый ук борчуын белдергәч, өлкән агай вәкилләре арасында империячел котырту көчле куелган һәм ул гасырлардан килгән геннар дәрәҗәсендә бара икән дип уйлап куйдым. Татарлар аерылып чыгарга җыеналар икән дигән гайбәтне русның сәясәттән ераграк торган, аң үсеше әллә кем булмаган кешеләре дә катастрофа, ахырзаман якынлашуы кебек кабул иткәннәр икән.

Ничәмә йөз еллар дәвамында татарны «ач арба» тартып йөрүче, урам себерүче, игенче, содат, кушканны сүзсез үтәүче итеп күрергә өйрәнгән Мәскәү түрәләре генә түгел, үзләре дә шул ук итек астында яшәгән руслар да хәятларын «чаплашкалардан» башка күз алдына да китерә алмыйлар, күрәсең.

Буйсынган халыкның мәнфәгатьләрен үтәү, аның ихтыяҗлары турында кайгырту, ярдәм итү хакында уйлап та карамаганнарын бөтен өлкәдә шөрепләрне бора килгән XXI гасыр башы бик ачык күрсәтә. Үткән гасырның соңгы чиреген искә алып, уфтанып утырырга гына кала. Әйе шул, тарих безне туктаусыз сынап тора...

Артка чигенү, яулап алган үрләрне бирү һәр өлкәдә сизелә. Әйтик, Татарстан конституциясе татар һәм рус телләрен тигез хокуклы дәүләт телләре дип игълан иткән иде. Фараз буенча, хакимиятнең иң югары баскычыннан алып, җирле үзидарә органнарында төрле дәрәҗәдәге уку йортларында, оешмаларда, сәүдә һ.б. өлкәләрдә кулланылырга тиеш иде татар теле. Төп казанышыбыз шул булды: өлкән туган вәкилләре транспортта «урам телендә сөйләшмәгез, кеше аңларлык телдә аралашыгыз», кебек кисәтү ясамый башладылар. Гавам шунысына да канәгать иде. Шул чорда ул, автобусның аргы башындагы танышына, үз фикерен кычкырып әйтү мөмкинлеген татып калды.

– Нурзия, төнлә кич буе шалтыраттым үзенә, ник телефоныңны алмадың?

– Филармониягә якташыбызның концертына бардык. Шундый шәп булды, малай.

– Сәкинә кодагый, ял көнне базарга барам дигән идең? Бардыңмы? Сыер ите күпме тора?

– Юк, беркая да бармадым, өйдә генә утырдым. Андый эшләрне Салихҗан миңа тапшырмый. Үзе алып кайта. Сине алдыйлар, ди.

Үткән гасырның туксанынчы елларына хас мондый иркенлекне яна йөзнең икенче унъеллыгыннан, авызны колакка куеп аралашу алыштырып бара. Хәзер иҗтимагый транспортта Урта Азиядән, Кавказдан эшкә килгәннәр генә кычкырып, татар манкортлары Рәис Сөләймановларның шул мизгелендә үк Мәскәүгә житкерүеннән курыкмыйча, кычкырып сөйләшәләр. Ә татар гасырлар дәвамында барысына да күнеккән: азатлык бирсәләр дә каршы түгел, кире тартып алсалар да башын иеп риза, «сугыш кына чыга күрмәсен», дип догасын укый.

Шагыйрь Р.Мингалим халкының кушканны үтәргә әзер торган йомшак якларыннан ничек кенә көлми «Гаярь татар» шигырендә.

Онытма, Мәскәү
Татарың барын:
– Һәрчак әзер! –
Татарларың
Син:
– Сыйлыйм дисәң,
Кунак булып барачак
– Җигәм! — дисәң,
Ул ат булып барачак.
Мылтык бирсәң –
Солдат булып барачак.

Мәскәүгә һич кенә дә «үпкәләп булмый, чөнки ул кул астында татары барын, аны телен, байлыгын алып рәнжетсән дә, бер мәмләкәтнең дә аны яклап чыкмасын белеп, совет чорында эшләнмәгән кысуларга да бара. Мәсәлән, патша Русиясе, коммунистлар хакимлеге чорында да милли телләрне тыйган 309 нчыга тиң фәрман чыгарылмады. 1917 елга чаклы татарның хәлле кешеләре исәбенә яшәгән, цензорның теше үтмәслек мәгариф системасы — мәктәп-мәдрәсәләре, мәчетләр карамагындагы белем бирү учаклары бар иде. Алар дини һәм дөньяви фәннәрне яхшы үзләштергән, чит телләрне су кебек эчкән чын зыялыларны әзерләделәр. Совет чорында, шәһәрләрдә татар мәктәпләре бармак белән санарлык булса да, авылларыбыз көчле, нык, иманлы һәм күп балалы иде. Анда урнашкан татар мәктәпләре мәдәни һәм гыйльми үзәкләр буларак милләтебезгә көч, дәрт биреп, төрле өлкәдәге талантларны үстереп тордылар. Бүген авылларыбыз юкка чыгып килә, исән калган татар мәктәпләре бер-бер артлы ябыла. Шәһәрләрдә белем бирү бер теллегә күчеп бара. Үзәк бу процессны тизләтү өчен барысын да эшли.

Буйсынган халыкларга, шул исәптән татарларга ясаган зыяннарын, милли мәнфәгатьләрне кысуларын бизмәнгә салып үлчәп булса, кайсы — патша, император, генсек президент — өскәрәк чыгар иде икән? Һәрхәлдә бу юнәлешне бик тирәнтен уйлап, җитәкчелекне бик озакка кулына төшергән хәзерге Русия президенты соңгы урында калмас иде дип уйлыйм. В.В.Путин соңгы сайлауларда Татарстанда иң күп диярлек тавыш җыйды. Бу бит — без аның сәясәтен хуплыйбыз дигән сүз. Мәскәү, Петербург кебек калалар турында сүз дә катмыйм, хәтта башкорт, чуаш кардәшләрне дә «артта» калдырганбыз. Милләтебезнең аң дәрәҗәсе түбән булуы, буйсынучан, кушканны үтәргә күнеккән холкыбыз турында сөйләмиме бу?

Җирләрендә, илләрендә башка милләт вәкилләре калмаган, телен, гореф-

гадәтләрен югалту куркынычы янамаган, сугыш нәтиҗәсендә үзәктән бик күп ташламалар алган, байлыгын кая куярга белмәгән Чечня генә уңай тавыш бирүдә безне узып киткән.

## Соңгы сүз урынына...

Сонгы егерме ел эчендә үз башымнан узган һәм татар мәгарифе, мәгърифәте кичергән матавыкларны түкми-чәчми, арттырмыйча, үзем кабул иткәнчә, аңлаганча кәгазьгә төшердем. Кагылырга, авыр сүз әйтергә ярамый (бәлки, вакыты җитмәгәндер) торган шәхесләргә нисбәтән дә, курка-өркә генә булса да, тәнкыйть сүзе дә әйтелгәләде. Татар матбагасының матди хәлен вә «кыюлык» дәрәҗәсен яхшы белгәнгә, бу өлешләренең укучыга барып ирешүендә шигем зур. Үз халкыңның караңгылык базына тәгәрәвен, язмышы, теле, киләчәге кыл өстендә торганда, илдә урнашкан вәзгыятькә берни үзгәрмәгәндәй битараф булу, фикереңне әйтми калу гафу ителмәслек җинаять булыр иде. Шагыйрь Мөхәммәт Мирза «Тарихта урын юк хисләргә...» дип юкка гына әйтмәгәндер.

Югары «урындык» биләмәгән кешеләргә бүгенге яшәешебездә күп нәрсә тирән сер булып калса да, үткән гасырның 90-нчы елларында милли мәсьәләләрдә ирешкән уңышларыбызның иртәнге рәшә кебек эреп югалуы, гадәти бер өлкә дәрәҗәсенә төшүебезне яшереп булмый. Кешелек тарихыннан билгеле булганча, җыр-биюләр, сәхнәдә сикеренүләр, һәр төрле бәйрәмнәр белән мавыгулар киттеме, бу хәл итә алмыйчамы, күз буяу өченме, җитди иҗтимагый проблемалардан читләшүгә ишарә дигән сүз. Рухи борһан — кризис вакытында көлкеле карнаваллар, ясалма күңел ачулар белән халыкны алдау, сентименталь мелодрамаларның алга чыгуы күзәтелә. Халкыбыз язмышының авыр чорын кичергәндә, аңа өстәмә көч, рухи сәләт бирә, горурлык хисе, көрәшчеләр тәрбияли торган әдәби әсәрләр, кыю публицистика кирәк, сихерчеләр, албастылар, җирдән аерылып, һавада очып йөргән сәрхушләр, канатсыз акчарлаклар һәм башка «хәшәрәтләр» белән артык мавыгу тук, коллыкның нәрсә икәнен белмәгән, «симез» милләтләргә генә килешә. Реаль чынбарлыктан аерылу, берни булмагандай, бер сынык икмәккә канәгать булып, «сугыш кына чыга күрмәсен», дип яшәү һәлакәтебезне, бөек мөһаҗир Г.Исхакый кисәткән инкыйразны якынайтачак кына. Мондый авыр мизгелләрдә күзенә карап дөресен әйтсәм ачуланмасмы, үпкәләмәсме (хибескә озатмасмы) дип торсак, татарның ахырзаманы кичекмәстән ишек шакыр. Инсафлы, итагатьле, тәртипле, кушканны үтәп, җигелеп эшләүдән, кемгәдер хезмәт итүдән тәм тапкан милләтләр белән санашу заманасы узды. Прибалтика халкы кебек аз санлы булуларына (җиһанда бер миллион эстон бар!) карамастан, атом коралына ия олы илләргә тешен күрсәтүдән курыкмаган кавемнәр генә үзләрен саклап кала алачак.

Минем истәлек-язмаларым кемгәдер кирәк булырмы-юкмы дип, шикләнебрәк утырган бер мәлдә, «Звезда Поволжья» газитәсенең мөхәррире Р.Ахметов баш мәкаләсендә («Мемуарлар», 2013, 31 январь) истәлекләрнең әһәмияте мәсьәләсен күтәреп, бездә нык артта калган бу жанрның хәзерге халәтебезне аңлау, буыннар хәтерен югалтмау өчен кирәклеген исбатлый.

Советлар чоры түрәләрнең иң тирән серләрен ачып салырга омтылган мемуарларга тукталып, бездә дә ошбу юнәлешкә ихтыяҗның зурлыгына басым ясап, түбәндәге нәтиҗәгә килә: «Мемуар — үзең белән ачыктан-ачык

сөйләшү. Әмма бездә, Алладан куркуга караганда да, җәзалауга корылган дәүләттән өркү көчлерәк». Үз гамәлләренә бәя бирүдән курыккан түрәләр, милләт язмышы, киләчәге өчен җаваплы кешеләр, истәлек-мемуарлар язудан тайчыналар, ди мәкалә авторы. Чөнки бюрократиянең төп сыйфаты — сер саклау, качыш уйнау, халык каршында хисап тотуның юк дәрәҗәсендә торуы, андый хәл булганда да, аның гомуми сүзләргә төрелеп кенә эшләнүе шуның нәтиҗәседер.

Һәрберебезнең гамәле үтә күренмәле, ачык булганда гына демократик җәмгыять төзеп була торгандыр. Кызганычка каршы, бу безнең өчен бик ерактагы якты йолдыз гына шул.

«Замана балалары»ның беренче кисәгендә «хәзер без ифрат тынгысыз, хәвефле бер чорда яшибез. Иртәгәсе көннең нәрсә алып килерен белгән кеше юк. Шулай да ил халкы (ни өчен «ил халкы» өчен җаваплылыкны өстемә алганмын, күрәсең «интернационал тәрбиянең» чүбеге баштан чыгып бетмәгән булгандыр) иң начарны башыннан кичергәндер инде», — дип язганмын. Азатлык җилләре исә башлаган ул елларны, зәңгәр томанга төрелгән риваятьләр кебек, сагынып сөйләргә генә калды. Рәис Сөләйманов кебек яңа буын Шаһгалиләре үз милләтенә каршы күсәк күтәргән чорда татар һәм башка вак халыкларны күрелмәгән сынаулар, «теге дөньяда» очратырга тиешле сират күпере кичә дигән тойгы туа күңелдә.

«Замана балалары»ның икенче, ягъни хәзерге чорыбызга багышланган өлешен тарих безне кат-кат сыный дип башлаган идем. Тарих әле кабатлана, еш кына элеккеге вакыйгалар, хәлләр, иҗтимагый борылышлар әйләнеп тә кайталар икән. Шагыйрь Ф.Сафин нәкъ шул хакта уйлана:

Тарих тарих булмый!
Булмаса кабатлану.
Терелеп килгән тамырга
Ут төртеп, кабат ягу.
*(«...Җомга көн, кояш чыкканда»)*

Шайтан гына өметсез диләр. Мин исә бу истәлек язмаларымны тарих халкыбызга янә бер мәрхәмәтлелек күрсәтеп, XX гасыр башындагы һәм ахырындагы бәхетле мизгелләрне кабатлар әле дигән хыял, өмет һәм ышаныч белән тәмамлыйм.

*2011-2013*



Руслан
Сөләйманов

# ЯЗМЫШ — ХОДАЙ КУШКАНЧА

## Тәүге сөйгән ярлар каргаган

**Сизмичәрәк калдык икебез дә,
Кара мәче үтте арадан.
«Әллә, — дисең, — безнең мәхәббәтне
Тәүге сөйгән ярлар каргаган».**

**Нокта куйдык сөю кыйссасына.
«Башлыйбызмы әллә яңадан?»
«Юк, — дисең син, — безнең мәхәббәтне
Тәүге сөйгән ярлар каргаган.»**

**Икебезне бергә очраштырып,
Әллә инде язмыш алдаган?
Юк, бары тик безнең мәхәббәтне
Тәүге сөйгән ярлар каргаган.**

## Урын тапмыйм синнән аерылгач

**Урын тапмыйм синнән аерылгач,
Авыр бигрәк, авыр күңелгә.
Вулканнарга кереп яныйм микән,
Әйләнгәнче тоташ күмергә?**

**Әллә дәрьяларга чумыйм микән,
Әверелеп тәмам тамчыга?
Болай да бит коңгырт күзләремнән
Һаман саен тозлы яшь чыга.**

**Әллә чиксез күккә ашыйм микән,
Күк тузаны булып яралып?
Болай да бит җаным өзгәләнә,
Телгәләнә меңгә ярылып.**

---

Руслан СӨЛӘЙМАНОВ (1985) — *яшь шагыйрь; «Уйларымны салдым сандалларга» исемле китап авторы. «Таян Аллага», «Иделем акчарлагы» әдәби конкурсларында призлы урыннарга ия. Башкортстанда яши.*

Әллә туры җиргә керим микән,
Балчык булып инде мәңгегә?
Болай да бит югалырга торам,
Түзә алмый йөрәк әрнүгә.

Урын тапмыйм синнән аерылгач,
Авыр бигрәк, авыр күңелгә.
Күмерләргә каласымны белсәм,
Аерылмас идем гомергә.

## Елыйсыңмы?

«Елыйсыңмы?» — дисең,
еламыймын.
Керфегемә карлар коелган.
Алар эреп, синең күзләреңә
Күз яшьләре булып тоелган.

«Елыйсыңмы?» — дисең,
еламыймын.
Керфегемә тамчы эленгән.
Яңгыр тамчысы да күзләреңә
Күз яшьләре булып күренгән.

«Елыйсыңмы?» — дисең,
еламыймын.
Керфегемдә тамчы — чык кына
Синнән аерыласын алдан сизеп,
Еласылар килгән чак кына.

## Паромнар

Йөрәкне йөрәккә бәйләгән
Күперне җимерде ташкыннар.
Без хәзер читләрбез дисәң дә,
Безләрне бәйләгән нидер бар.

Күңелләр салкынлык сизсә дә,
Безләрне яндырган нидер бар:
Йөрәктән йөрәккә туктаусыз
Ашкынып агыла паромнар.

## Хатын-кызның табигате

Әллә язмыш галәмәте,
Әллә Ходай кодрәте?
Суга охшаш була икән
Хатын-кызның табигате:

Кайныйм, дисең, мине күрсәң,
Мин кочаклап, суырып үпсәм;
Бетә, дисең, мизгелләрдә
Миңа булган барлык үпкәң.

Туңам, дисең минсез, җаным,
Кар-боз була, дисең җаның.
Эремәс тә идем, дисең,
Мин килмәсәм сиңа тагын.

Әллә язмыш галәмәте,
Әллә Ходай кодрәте?
Суга охшаш була икән
Хатын-кызның табигате.

## Нокталар кадере

Өчпочмаклы хатың килде,
Хатта — өч нокта.
Ни әйтергә теләдең соң
Син шушы хатта?

Сагынам диеп язарга
Әллә кыймадың?
Оялдың да хисләреңне
Язып тормадың?

Саргаям синсез дияргә
Кодрәтең җитмәдеме?
Йөрәктән чыккан сүзләр дә
Хатыңда китмәдеме?

Яратам диеп язарга
Әллә шүрләдең?
Белмәсен дидеңме әллә
Күңелең серләрен?

Өчпочмаклы хатың килде
Хатта өч нокта.
Шул нокталар да кадерле
Син янда юкта.

## Өмет

Элек өмет — песи күзе,
Ялтыр-ялтыр яна иде.
Ирек дигәч, күңелләр дә
Тик яктыра бара иде.

Ирек диеп күкрәк кактык,
Ирек диеп күккә бактык
Әмма беркөн коллык дигән,
Без капканга килеп каптык.

Хәзер өмет — тычкан күзе,
Бар һәм дә юк кебек үзе.
Ирек дигәч, күңелләрдә
Төн. Караңгы. Курку хисе...

## Язмыш — Ходай кушканча

Юл чатында кара таш,
Кара ташта татарча:
«Кай тарафка юллансаң да,
Язмыш — Ходай кушканча.»

Уңга барсаң — туңарсың,
Сулга барсаң — сулырсың,
Алга барсаң — бер мизгелдә
Шах-падишаһ булырсың.

Артка киттем, мәрәкә,
Шагыйрьмен мин — хәерче
Дусларыма — ачы кайгы,
Дошманыма — сөенче.

Юл чатында кара таш,
Кара ташта татарча:
«Кай тарафка юллансаң да,
Язмыш — Ходай кушканча.»

## Белмимен нишләргә?

Ул керде. Ул керә
Төннәрен төшләргә.
Онытыр чарам юк,
Белмимен нишләргә?

Ул керсә төшләргә,
Күңелдә өермә.
Үкереп елыйммы,
Белмимен нишләргә?

Ул керсә төшләргә,
Күңелдә зилзилә.
Шаркылдап көлимме,
Белмимен нишләргә?

Ул керсә төшләргә,
Күңелдә ут-кырау.
Көл итә күңелне
Җавапсыз бер сорау.

Ул керде. Ул керә
Төннәрен төшләргә.
Онытыр чарам юк,
Белмимен нишләргә?

Ахир

## КӘБИСӘ ЕЛЫ

САТИРИК БӘЯН

*Күпме дуслар китте соң елларда,*
*бу җирләрнең асыл уллары!*
*Сылу каеннарның шәүләсендә*
*күрәм сыман йөргән юлларын...*
Р. Фәйзуллин

1

Байраш үләргә булды.

Артта упкын, алда тәмуг иде.

Байраш Барый углы Талмасов әлеге упкыннан чыгунын башка юлын күрмәде.

Кәбисә елы башланырга да өлгермәде, аның берничә яхшы танышы, дусты якты дөнья белән хушлашты. Һәм һәрберсенең үлеме үзенә бер төрле сәер, чишә алмаслык серле табышмак булып калды. Берсен урам малайлары чәнчеп үтерде. Бу кичкырын өенә кайткач, подъезд каршында өелешеп торучы яшь шпаналарга акыл өйрәтеп маташкан. Әзрәк салган да булган, күрәсең. «Мин олы кеше, билгеле кеше, минем алда нишләп шулай әшәке сүләнеп торасыз!» — дип, үгет-нәсихәт укыган бу боларга. Тик хәзерге яшьләр, бигрәк тә кала этләре акыл өйрәткәнне өнәмиләр, артык күп сөйләнсәң, шундук кыйнап, үтереп тә китәргә мөмкиннәр. Аларга син язучы булдың ни дә, фәйләсуф булдың ни! Алар өчен син барыбер: «чмо»[1] .

Икенчесе...шагыйрь...Авыр туфрагы җиңел булсын. Гомер айнымаслык эчкече иде мәрхүм. Үлгән кеше турында начар сүз сөйләү килешмидәдер. Ләкин дөресе шул, күргән саен ун, егерме тәңкә сорап, теңкәсенә тиеп бетә иде ул аның. Бирмәсә, каһәрләп, сүгеп чыгып китә, бирсә дә рәхмәтен әйтә белми. Үгет-нәсихәттән узган иде ул. « Мин — шагыйрь! Дөнҗага ачуым зур!» — менә аның тормыш манифесты. Хатыны белән аерылышкач, бер ялгызы малосемейкада яшәде. Үлеп, соңыннан биш көн бүлмәсендә сасып яткан. Беркем бернәрсә белми, беркемгә дә берни кирәкми. Язу өстәле кырында торган чүп савытына, ялгышып, тәмәке төпчеге ташлаган, ә савытны кәгазьдән бушатмаган булган. Салмыш хәлендә мәрткә киткәнен сизми дә калган, — төтенгә тончыгып үлгән. Соңыннан янгын сүнгән сүнүен, көле дә очып беткән, тик менә шагыйрь генә юк, шагыйрь генә үлгән. Ә бит нинди шагыйрь иде!

[1] Кеше түгел! — дигәнне аңлата. Автор.

Өченчесе турында сөйлисе дә килми. Анысы бөтенләйгә югалды: ни җәсәде, ни кабере...

Ә үзе, үзе ни хәлдә соң бүген? Үзе дә аяныч хәлдә түгелме соң!? Житмеш яшен тутырган көннәрдә генә Галиясе, кырык ел бергә гомер кичергән хатыны үлеп китте. Биш яшькә үзеннән яшьрәк тә иде юкса. Хатыны үзеннән алда китәр дип анын уена да кереп карамады. «Үлсәм, авылга апкайтып күмәрсез!», «Үлсәм, архивны чыгарып атма!» — дип сөйләнеп йөргән иде, ә менә шунын киресе килде дә чыкты. Галиясен (үзенең авылына!) алып кайтып күмде. Яшь чагында ул нигәдер хатынынын үлемен көтеп яшәде. Чирле дә иде ул. Менә хатыны үлеп китәр дә, ул икенче берәүгә өйләнер! Ул әле таза, асыл ир. Сылу кызларнын, ялгыз хатыннарнын ана күзе төшә. Елмаеп чакырсалар, шундук алар янына чаба. Өйләнгәнче кая йөргәннәрдер алар, Алла белсен!? Көтүләре белән йөриләр! Ә андый вакытта законлы хатын һәрчак артык товар, йә сикереп узалмаслык киртә булып тоела. Шул вакыт: « Югалсаң иде күземнән!» — дип юраган чаклары күп булды анын. Ләкин чын ярату Байрашка хәләл җефете белән кырык ел бергә гомер иткәч кенә килде, комы коела башлагач, ягъни. Гомере буе каядыр ашкынган, иҗатка, илһамга табынган язучы шуны аңлады: бу дөньяда хатыннан да якын кеше юк икән! Һәм ни кызганыч, бары тик шуны аңлагач, шуны башыннан кичергәч кенә ул хатынын югалтты: өч бүлмәле иркен фатирда бер ялгызы утырып калды. Хәер, анын бер кызы бар, Альбина исемле, тик ул янда түгел, Мәскәүдә яши, урыста кияүдә. Ул бик тиз мөстәкыйльлек алды: ана атасы да, анасы да кирәкмәде. Үз гомерендә ул атасынын бер генә китабын да укымады, аны язучы итеп белмәде дә. Әнисе үлгәч тә әллә ни хафаланмады кебек. Ясалма елаулар, дежур сүзләр белән генә анасын ничек яратканын ышандыра алмады. Ә бит (Байраш уенча!) алдан Галия түгел, ә ул китәргә тиеш иде. Юк шул, дөнья син уйлаганча гына бармый, алдан берни уйларга да, берни юрарга да ярамый икән, барысы да Аллаһы кулында!

Язучы яшәгән йорт «сталинка» иде. Өч катлы. Үзәктә урнашкан. Диварлары калын, түшәмнәре биек. Өендә евроремонтлар ясап ятмады ул, фатир (ничек күчкән!) шулай калды. Имәннән ясалган калын ишекләрне әвәл ике елга бер мәртәбә ак эмаль белән буяп чыга иде, быел исә анарга да кагылмады, кыскасы, кирәк дип тапмады. Хатын үлгәч, иркенләп язар, иҗат белән онытылып торырмын дип уйлаган иде, юк, хәзер инде анарга да күнеле тартмый. Ә нәрсә язасын? Кемгә кирәк ул язу? Совет заманында очерк-романнар язган, җәмгыятькә тәнкыйть сүзләре яудырмаган, бер адым кырыйга тайпылмаган һәм озак еллар шунын рәхәтен күреп яшәгән каләм иясе өчен хәзерге тормыш та бар да кыргый, бар да аңлаешсыз кебек иде. Дөньяда барган чуалыш анын тормышын гына түгел, ә башын, уй-фикерләрен дә чуалтты. Заманга ярарга теләп, ул зур булмаган ике-өч әсәр бастырып караган иде, ләкин алар аңа акча да, уныш та китермәде. Шулай итеп ул язудан туктады. «Москва» машинкасын (гомере буе шунарда бастырды!) калын тузан каплады. Башкалар кебек кампитрга күчеп тормады, аны хәтта ачарга да өйрәнә алмады. Пенсиягә чыккач, вакыт узсын, көн үтсен өчен генә ул университетта атнага ике тапкыр тарих дәресләре укытты. Хатынын җуйгач, инде анда да йөрми башлады. Эштән кайтканда, чәй куеп, каршы алучын да калмагач, яшәүнең ни мәгънәсе бар? Әле сина соң түгел, башка хатын табып кара дип кинәш итүчеләр дә булды. Тик бу яшьтә кем килер икән аңа? Килсә дә, шул фатир бүләр өчен генә килер инде. Әгәр дә бүлдермәсән, өметләндермәсән, бик озакламас ул монда! Чит хатын чит шул инде: барыбер үз хатынын кебек була алмый. Әйе, эшләр харап: дуслар китте, хатын юк, иҗат туктады. Монардан да аяныч нәрсә буламы соң дөньяда!? Хәер, анын исеме

бар, аны белмиләр түгел, беләләр. Дәүләтнең нинди мактаулы исемнәре, нинди премияләре бар, аларның барсын да алып бетерде кебек инде. Вагын да, зурысын да. Кайсын бик җиңел генә каптырды ул, ә кайсын шактый авыр алды. Күрәшергә туры килде. Кайвакыт югарыдагыларга ялынды, ә кайчак көндәшләрен терсәге белән этәргә дә мәҗбүр булды. Ул яктан әрсез иде ул, үҗәт. Иҗатын белмәсәләр дә, исеме билгеле иде аның. Соңгы вакыт аны бик каты бер яшь язучы мокчый башлады. Исеме дә, җисеме дә юк үзенең. Үткен, оятсыз, кыскасы, җир бит! Үзен алдынгы, авангард язучы дип саный. Әле яңа гына бер әсәрен бастырып чыгарды, ул аны укып чыкты да шаклар катты. Аның шул кыска кыйссасы Байрашның бөтен иҗатын бәреп егарлык иде. Ул гына да түгел, кайда гына күрешсәләр дә, шул җир бит аны үтереп мактарга тотына. Язучының үзен түгел, ә аның бер аерым китабын. Әллә белеп, әллә юри мактый. Чөнки ул үзе язган китап түгел, ә урланган нәрсә иде. Гыйльми хезмәт: афоризмнар, мәкальләр тупланмасы. Җәгъфәр атлы бер галим (фән дөньясында бигүк билгеле шәхес түгел!) туплаган аны, шуны гомере буе җыйган. Соңыннан дөньяга чыгарырга уйлаган. Ләкин китап итеп бастырганчы аны карап чыгарга, эшкәртергә кирәк. Ул аны Байрашка бирде. Юк, алар таныш-белешләр түгел иде, Җәгъфәр абзый аны кеше аркылы эзләп тапты. Байраш бу эшкә бик теләп алынды, тупланма, чын мәгънәсендә, фәнни әһәмияткә ия иде. Шулай итеп ул әлеге китапның мөхәррире булды. Ләкин кульязманы эшләп, аны кире авторга тапшырырга гына торганда абзый (яше бар, сиксәннәрне узган иде!) кинәт кенә дөнья куйды. Китапка түккән хезмәтен җилгә очырырга теләмәгән мөхәррир, аны җыеп, бер шәхси нәшриятка илтеп тапшырды. Нәшрият хуҗасы китап өчен башта акча сорап интектерде, ләкин абзый аңар бер тиен дә түләмәде. Ул аны оныткан да иде инде. Бер елдан соң кибеткә керсә, күрә бу —китап (чыккан!) ялтырап киштәдә ята. Алгы битендә Байрашның исем-фамилиясе тора, ә Җәгъфәрнең анда исе дә, исеме дә юк. Башта бик аптырады. Ләкин ул ошбу хезмәтне чыгарган нәшриятка ул рәхмәт әйтергә дә, шелтә белдерергә дә курыкты. Бармады. Почта аркылы аңа (зур күләмдә булмаса да) гонорар акчасы килде. Барып алды, ләкин ике-өч ай шул акчага орынырга курыкты. Хатынына тунлык акча житмәгәч кенә кулланды. Шуның белән ул тынычланды. Ләкин тынычланырга иртәрәк булган икән шул. Җәгъфәр китабы укучылар һәм шулай ук тәнкыйтьчеләр күңеленә дә хуш килде. Ярты ел эчендә китапны сыпырып алдылар. Тәнкыйтьчеләр китапның авторын күккә чөеп, мактап чыктылар. Автор җавапсыз калды. Зыялылар арасында Байрашның әлеге хезмәтне үзе язмаганлыгы турында сүзләр йөрсә дә, кычкырып, аның битенә бәреп әйтүче табылмады. Хәзер инде менә ул (җир бит!) пәйда булды. Юк, ул фаш итми, ул аны гел мактый. Ләкин ул төче мактауда ни хәтле киная һәм мыскыл ятканын Байраш бер үзе генә белә.

Язучының үлем турындагы игъланын шәхси гәҗит бастырып чыгарды. Анда болай дип язылган иде: « Киләчәктә яшәвемнән мәгънәсен күрмим. Мин 20...елның 10 октябрендә дөньядан китәргә булдым. Язучы Байраш Талмасов.» Ышандырырлык килеп чыксын өчен, кырыйга язучының фотосурәтен дә урнаштырдылар. Билгеле, моңа бик күпләр ышанмады. Сары гәҗитнең чираттагы «үрдәге» дип кенә кабул иттеләр. Нәтиҗәсе төрлечә булды: кемдер көлде, кемдер аңламады, ә кемнәрдер җитди итеп кабул итте. Ә бит өченчеләре (язучы фикеренчә) дөрес уйлаган, чөнки монда бернинди дә уен-муен юк, белдерү аек баштан, төптән уйланып язылды.

Шушы игълан чykканнан соң, өйдәге телефон тынып тормады. Таныш-белешләре, туганнары шылтыратты. Игълан турында сүз чыгуга ук Байраш телефонны шапылдатып, өзеп куя иде. Бер ике-өч көннән соң ул аны бөтенләй алмас булды.

## 2

Ә бер көнне...

... бер көнне анар телевидение бәреп керде. Ниндидер «...тиви» каналы. Урысча күрсәтә. Егетләргә охшаган, шулар сымак чәчен кыска итеп кистергән ябык кына бер яшь кыз шактый үҗәт нәрсә булып чыкты. Әңгәмә төшерергә дип килгән кыска итәкле бу кыз, рөхсәт-ни дә сорап тормыйча, түргә, түгәрәк өстәл янына барып утырды. Хуҗа аптырап, каушап калды. Сакал-мыек баскан, үзеннән дәү камерасын аскан оператор аңа шундук объективын төбәде. Байрашка чигенер урын калмады, ул җинелүен таныды. Әллә үзе шундый башлы, әллә алдан әзерләнеп килгән, хәбәрче кыз мәкерле сорауларын, автоматтан аттырган сымак, бер-бер артлы сиптерде. Ул җинел сөйләшергә өйрәнгән, биргән сораулары да кыска һәм төгәл иде:

— Сез безнең каналны карыйсызмы?

— Юк, карамыйм.

— Сез зур язучы, мактаулы исемнәрегез күп, ә үзегез шундый иске «сталинка»да утырып калгансыз!?

—Мин бер ошаган җирдән башка урынга күчеп йөрергә яратмыйм.

— Әйе, фатир да хуҗасына охшарга тиеш, шулай бит!?

— Шулай...

— Газетта чыккан игъланыгызны нәрсә белән аңлата аласыз?

— Мин аны бер генә нәрсә белән аңлата алам...

— Сенсация кирәк булдымы?

—Юк, мин сенсация артыннан кумыйм! — дип кисте язучы. — Сенсация сезгә кирәк булды, ахрысы!

—Безнең канал андый сенсацияләргә мохтаҗ түгел! — диде кыз һәм ул аны ниндидер горурлану хисе белән әйтте. — Инде сорауга кире кайтыйк...

— Әйе, мин аны бер генә нәрсә белән аңлата алам...

— И..?

— Яшисе килмәвем белән.

— Әйе, мин сезне аңлыйм, — дип килеште кыз. — Чорыгыз узган, хатыныгыз үлгән, иҗат уты сүнгән...Ләкин суицид игълан итәр өчен болар гына аз...

— Ә тагын ни кирәк?

— Сез авыру түгелме?

— Бу яшьтә бар да булырга мөмкин.

— Психбольницада ятканыгыз булмадымы?

— Җүләр түгелме икән дип сорыйсызмы!?

— Ну, да...

— Юк, мин анда ятмадым. Һәм...

— Әйе...

— ... учетта да тормыйм.

— Шундый сорау: сез совет чорын сагынасызмы?

— Сагынам, ә нишләп сагынмаска ди! Минем яшьлегем бит ул. Анда хет кеше турында, иҗат кешесе турында кайгырту бар иде. Хәзер кешене кешегә санаучы да юк. Бар нәрсәне дә акча билгели...

— Ә партия!?

— Әйтмим...Ул заманның да минуслары булгандыр, ләкин плюслары күбрәк иде. Дәүләт кеше турында уйлый иде. Ә хәзер синең беркемгә дә кирәгең юк. Кая барма, шунда мыскыл итәләр...

—Үз-үзләренә кул салучылар күбәйде, суицид, как говорится, сплошь и рядом! Ләкин фәлән вакытта мин үземә кул салам, дип игълан бирүчеләр әлегә булмады... Сез беренче!

—Әйтәм бит, мин сенсация ясарга теләмим! Кешеләр уйлансыннар өчен шулай итеп яздым мин аны! Уйлансыннар өчен! Нинди җәмгыятьтә яшибез без?! Кемдер олигарх, бай, кемдер акчасын кая куярга белми, ә кемдер хәерче, кемдер чүплек базында казына... Кая тигезлек!?

— Тигезлек беркайчан да булмаган.

— Әйе, булмаган, ләкин бу кадәр үк түгел иде.

— Әйтегез әле...

— ?

— Сез үлемнән куркасызмы?

— Ә кем аңардан курыкмый икән!? Бар микән бу дөньяда андый кеше, әйт әле син миңа, сеңлем!?

— Сез хаклы...

Кисәк кенә башланган әңгәмә шулай тиз генә тәмамланды да. Хәбәрче кыз өстәл янына торып, абзыйның кулын кысты. Аннан җиңелчә генә беләгеннән кагып, балаларча аның битеннән үбеп алды. «Ныгыгыз!» — янәсе. Сакал-мыек хәтта шул моментны да төшереп алды һәм, соңыннан, яхшы чыкты дигән булып, баш бармагын өскә чөйде...

Байраш аларны подъезд төбенә хәтле озата чыкты. Урамда аларны телевидение машинасы көтеп тора икән. Ул: «Бәлкем, чыгармассыз!» — дип тә әйтергә өлгерә алмый калды, алар, эх иткәнче, машинага утырып китеп тә бардылар. «Да, — дип уйланды язучы, — болар бик оператив эшләргә өйрәнгәннәр, дөресрәге өйрәткәннәр!»

3

Баскычтан икенче катка күтәрелгәндә, Байраш каршы якта яшәгән күршесен очратты. Ул илле яшьләр тирәсендәге Гаяз атлы бер бәндә иде. Кайчандыр химиядә эшләгән, эшче булган, хәзер сәламәтлеген җую аркасында, каядыр паркта кизү тора иде. Фатирны ул заводтан алды, башта бер авылдан килгән татар хатыны белән торды. Аңа бала ясап, аны каядыр куып җибәрде. Хәзер бер яртылаш татар, яртылаш марҗа белән гомер итеп ята. Бу марҗа менә чит ирдән тапкан ике ир баласын өстерәп алып килде. Үз баласын карамый Гаяз, кыскасы, кеше баласын үстерә. Марҗа ярады, ә үзенә бала бүләк иткән татар хатыны белән нигәдер эшләре пешмәде.

Көненә ике-өч пачкы тәмәке ашаган Гаяз, кара янып, кояшта киптерелгән балык сыман, шакраеп кипкән. Явыз да тагын үзе, кеше яратмый, ә инде зыялыларны, акыл эше белән мәшгуль адәмнәрне бөтенләй җене сөйми. Бүген аның эше дә уңмаган, кәефе дә юк, ә шуның үчен кемнән дә булса алырга кирәк иде. Байрашны күргәч үк, ул мыскыллы гына елмаеп куйды. Бу елмаюда: «Игъланыңны укыдым, җә, эшлексез нәмәстә, тагын нинди мөгез чыгарырга булдың инде!?» — дигән тирәнтен уй ята иде. Язучы аны шундук сизеп алды, һәм ул нидер әйткәнче:

—Мөгез чыгару түгел ул, энем, ә күңел таләбе! — дип әйтеп куйды.

— Сиңа оят түгелме, абзый!?

— Нәрсә өчен оялырга тиеш мин?

—Олы кеше бит син, үзең безгә акыл өйрәтергә тиеш, ә син шуның урнына, җуләр сатып йөрисең!

— Минем аңа хакым бар...

—Юк синең хакың! — дип күкрәк какты Гаяз. — Менә минем кебек егерме биш ел вредный цехта ывкалывать итсәң, халык алдында шулай җуләр сатып йөрмәс идең! Үләргә җыенган имеш... Үл! Кемгә кирәк соң син!? Кемгә кирәк синең писанинаң! Ничә ел без синең белән күршеләр булып яшәдек, ә мин синең бер генә китабыңны да укымадым...

— Кызганыч...

— Берсен укый башладым, үзен бүләк иткәч... Ташладым!
— Нигә?
— Чушь, патамушты! Завод турында роман язган, имеш! Сон син үз гомерендә бер генә мәртәбә заводнын прахаднуе аша узганын булдымы!?
— Ана калса... Жюль Верн...
Ул аңа фантаст язучының беркайчан да дингез белән океанда йөзмәгәнен, ләкин дингез һәм океандагы мажараларны ничек шәп итеп тасвирлаганын әйтеп, аңлатырга теләгән иде, вакытында туктап калды. Белә микән әле ул Жюль Вернның кем икәнен!?
Баскыч яныннан фатир ишегенә житкәнче шактый күп пычрак атарга өлгерде ана Гаяз. Язучыны тирән сагыш биләп алды. Кем өчен язган сон ул? Анын язганнарын йотылып укыйлар дип уйлаган язучы ялгышкан микәнни сон? Димәк, юкка өметләнгән ул! Ансы бер нәрсә, монда бит хурлау бара, чын хурлау! Шактый еллар бер этажда күрше булып яшәгән, хатыны исән чагында кунакка кереп, чәен-мәен эчкәләгән Гаяз күрше абзыйсына катырак әйтеп ташлаганын аңлады булса кирәк, ул кинәт кенә киселеп: «Ярар ачуланма инде!» — дип дәшсә дә, күрше абзыйсы ана йомшармады, өметсезләнеп кул гына селекте...
Көне буе ни ашый, ни эчә алмады. Гәжиткә кирәкмәгән игълан биргәненә ул чын-чынлап үкенә башлады. Ә бит ул аны бирергә уйламаган да иде. Шайтан котыртты, шайтан! Акыллы кеше шундый гакылсыз гамәлгә ничек итеп бара диген син!?

4

Гел телефон шылтырады. Анын күнелсез чыңы бер генә минутка да тынып тормады. Ул аны сүндереп куярга уйлаган иде, ләкин шунар кулы бармады. Аннан ничектер түзмәде...алды...
—Әйе... — Чыбыкның икенче башында бер ханымның чытырдавыклы тавышы ишетелде, тавышына караганда, ул инде шактый олы яшьтә, дөресрәге, әби кеше булырга тиеш. Ул шул тиклем ашыгып сөйләшә, әйтерсен, анын өендә зур янгын чыккан һәм аны рәхимсез, аяусыз ялкын камап алган...
— Алу, алу...исәнмесез...
— Исәнмесез!
— Мин Айбатова булам...Тәслимә...
— Тынлыйм сезне, Айбатова Тәслимә !
— Сез мине белмисез, кәнишне!
— Юк, белмим.
— Мин сезнен укучыгыз...
— Фанатмыни...жанатар?!. — Байраш моны ничектер киная белән әйтте, ләкин әбекәй аны ишетми, аңламый калды. Анын берни дә аңламавы әйбәт тә булды, билгеле.
— Ә!?
— Тынлыйм сезне!
— Нишлисез сез, ә! — дип чәрелдәде ханым.
— Нишлим сон мин!?
— Сезгә...
— ...юк, оят түгел!
— ...кояштай зур гомер бирелгән! Сез бик зур талант! Сез бөек язучы! Жөмһүриятебезнен атказанган эшлеклесе! Мин сезнен китапларыгызны укып үстем. Сезнен һәрбер әсәрегезне яттан беләм, понимаете! Мин бит аларны кайчандыр...жылый-жылый укыган кеше... беләсезме сез шуны, юкмы!? — Ханым бу кадәресен шыттырып әйтте шикелле, ә шулай да аны тынлавы күнелле иде. — Ни булды сезгә, егетем!?

— Моны мин сезгә...
— Ийе...
— Берничек тә аңлата алмыйм...
— Депрессия...апатия...
— Юк, юк...сәбәпсез...
— Кемнәр кыерсытты сезне, әйтегез!? Әгәр андый әзвирләр бар икән, без укучылар, сезне укучылар, берләшеп, аларны фаш итәчәк, аларга суд ясаячакбыз! Әдәби суд, ишетәсезме, ә-дә-би... Чөнки әдәбият — әдәп сүзеннән алынган... Әдәпсезләр дөнҗа тулы...

Гауғалы ханым чын әдәбиятчыларны хурлаучы әдәпсезләрнең чәен түгеп, аларга ачы ләгънәтләрен яудырып арыгач, якты тормыш белән хушлашырга ашыккан хөрмәтле вә гыйззәтле язучыга берничә акыллы киңәш бирде — башына нәрсә туры килсә шул түгел, ә һәр сүзен ассызыклап, ягъни пунктлап:

— Беренчедән, — диде ул, — сезгә сручны яна убявление бастырырга кирәк, сүзегезне кире алып, халыктан гафу үтенергә һәм дә киләчәктә яшәргә теләвегезне исбатларга кирәк. Икенчедән, әйдәгез, без сезнең белән очрашу уздырыйк. Ни өчен дисезме? Сезне яраткан, сезне хөрмәт иткән әдәбият сөючеләре өчен мөһим ул. Теләсәгез, мин аны үзем оештырам. Беләсезме, мин бит үзем дә шигырьләр язам. Ие...дүрт йөзләп шигырем, өч йөзләп җырым бар минем. Көен дә үзем язам. Сезнең гүзәл әсәрләрегез, сезнең зур иҗатыгыз этәргеч булды мона...ие...
— Өченчедән? — дип кычкырды Байраш, түземсезләнеп.
— Өченчедән!?

Телефон тынып калды. Ләкин андый «әби-чебиләр» бер генә сүз белән туктап кала белмиләр, алар шигырь-мигырь турында көн-төн сөйләшергә дә әзер. Хатын-кыз ике очракта гына шигырь яза: кияүгә чыкканчы, йә кияүгә чыгып та иреннән уңмаса». Дөрес, әле моңа шуны да өстәргә була: «пенсиягә чыккач!». Тик бусы хатын-кызларга гына түгел, ир-атларга да кагыла. Гомер буе каядыр хезмәт итеп йөриләр дә, пенсиягә чыккач, шигырь язарга тотыналар. Шигырьләре дә гел бертөрле, бер-берсенә бик охшаш, әллә бер-берсеннән күчереп язалар инде. Төзәтеп торыш юк: язалар да аталар, язалар да...

— Карагыз әле! — дип ачу белән бүлде ул аны, — сез минем телефонымны каян, кемнән алдыгыз?

Телефон шундук өзелде. Әби-чебинең чәрелдек тавышы каядыр китеп, төшеп югалды. Телефон номерын каян алганын ул аңа әйтмәсә дә, Байраш яхшы белә иде: Язучылар берлегеннән. Берлектә шундыйлар белән бик нык аралашырга яратучы бер мөлаем генә секретарь кыз эшли һәм ул язучыларны туган көннәре белән котлап, очрашуларга, утырышларга гына чакырып калмыйча, теләсә кемгә аларның телефон номерларын да өләшеп утыра иде...

## 5

Алар кафеда очраштылар. Кафе дигәннәре зур базар янында урнашкан иде. Чехов базары диләр аны. Шуның каршында «М.Эль» дигән ашханә бар. Аны хатынсыз калган олы яшьтәге ялгызак ир-атлар үз итеп өлгергәннәр. Алар кайчандыр барсы да зур урыннарда утырганнар, ә хәзер оныклары белән мәш килүдән туеп, билгеле бер вакытта шушы якты, җылы кафеда күрешәләр иде. Монда рәхәтләнеп ашарга да, кәеф өчен бер ике-йөз грамм кәгергә дә була иде.

Байраш кафе ишеген атлап кергәндә, аның дусты Мәргән Гәлләм түгәрәк өстәл артында, тирләп-пешеп, чәй эчеп утыра иде. Кызыл чырайлы, тәбәнәк буйлы, дәү борынлы, кыска муенлы, дөньяда бернигә дә исе китмәс яштие тормышны ничек бар шулай кабул итәргә өйрәнгән иде. Заманында дөнья

шаулаткан, хатын-кызларның күңеленә үтеп керерлек нечкә әсәрләр иҗат иткән Мәргән дус, үзгәреш чоры башланып, язган әсәренә бер тиен дә ала алмагач, язудан бөтенләй туктаган иде. Совет заманында бер яхшы китап чыгарып, шуның акчасына өчәр ел михнәтсез гомер кичергән язучы анда да югалып калмады, тиз генә дәүләт эшенә авышты. Дәүләт хезмәткәрләре пенсияне яхшы алалар, ул, бәлкем, шунсын да уйлагандыр. Пенсиягә чыккач та мемуарлар гына язды, әсәр язып, юк-бар белән башын катырмады. Кичәләргә, очрашуларга йөрмәде, җәен урманда җиләк, гөмбә җыеп, кышын Казансуга балыкка йөрде. Тормышы җай барды. Ләкин моннан бер биш ел элек аңа зур кайгы килде: хатынын инсульт бәрде. Инде менә ничә еллар хатыны урын өстендә ята, ул аны үзе карый. Улы өйләнгән, кызы кияүдә. Билгеле, аларның үз тормышлары, үз планнары. Балалары да Аллага тапшырып, әниләрен әтисе кулына калдырдылар.

Дуслар айга бер мәртәбә күрешмичә калмыйлар: уртак уйлар, уртак фикерләр. Бер-берсен яхшы аңлыйлар һәм иң мөһиме — бер-берсен тыңлый беләләр иде...

— Караштыргалыйм бүгенге матбугатны, — дип башлады сүзен Мәргән, — дөресен әйтергә кирәк, сөенерлек нәрсә тапмыйм. Юк, әдәбиятны юкка чыгарып, әсәр мәтәштергән язучыларны түбәнсетеп әйтәсем килми. Бар, яхшы әсәрләр дә бар, бөтенләй юк дип әйтеп булмый. Тик, беләсеңме, ачыш юк, ачыш! Әдәби процессны җанландыра алган бердәнбер нәрсә — ул да булса ачыш. Чын әдәбият белән һәвәскәрләрне һәм кыйбласыз беллетристиканы бутарга ярамый. Беллетристика ул шул ук графоманлык чире, ул бит тутыру, һәм ни әйтергә теләгәнне аңламыйча, белештермичә, өстән-өстән генә язу. Ә чын әдәбият ул бөтенләй икенче нәрсә, ул ачыш, ул кыйбла, аның һәр җөмләсендә үткен фикер, тирәнтен хис һәм тормыш фаҗигасе чагыла. Һәм иң мөһиме, ул иң элек хәят суына манчылган була. Аңсы ни димәкче буласыңмы? Бер легенда бар, тыңла, сиңа шуны сөйләмәкче булам, тик дикъкать белән тыңла!

— Тыңлыйм!

— Бер хан була. Ханның туган көнендә олы улы аңа, агачтан юнып, атасына күгәрчен бүләк итә. Шәп ясалган була, ләкин хан аны нигәдер ошатмый. Уртанчы улы абыйсыннан да уздыра, ул инде күгәрченне алтын төстәге каурыйлар белән бизи, хәтта томшык та ябыштырып куя. Кыскасы, могез чыгара. Тик ханга ул да ошамый. Төпчек улы да күгәрчен ясый, тик ул аны атасына бирер алдыннан хәят суына манып ала. Күгәрченгә җан иңә һәм ул канат кагып очып китә... Моның белән мин нәрсә әйтергә телим!? Безнең күп кенә язган әсәрләребезнең җаны юк, алар хәят суына манып алынмаганнар... Кыстати... минем сүзләр түгел бу, Әмирхан абыйныкы...

— Да! Әйбәт әйткән!

— Дөрес әйткән! Бу сүзләрне без васыять итеп кабул итик...

— Аңсы шулай! — дип чыраен сытты Байраш. — Хәят суына манчылган әсәр тудыру өчен талант кына җитми, күрәсең, аңа Ходайның ярдәме кирәк. Ләкин медальнең икенче ягы да бар. Шедеврлар көн саен тумый. Аларның туганын көтеп утырсак әдәбият бишеге буш калачак, аны тирбәтер кеше дә булмаячак. Әдәби журналлар, гәҗитләр чыкмаячак. Контроль кулдан китәчәк, укучылар бизәчәк. Әгәренки без укучыны әле генә син сөйләгән хан дип күз алдына китерсәк, без аңа тере түгел, кәгазь күгәрчен дә бүләк итә алмаячакбыз. Пушкин чорында да, Тукай заманында да урта кул иҗатчылар булган, алар хәзер дә бар һәм алар киләчәктә дә булачак. Алар вакыт сынавын узалмыйча, бодай чүбе сыман коелып калганнар, ә бөекләр бүген дә исән. Чагыштырыр өчен, алтынны ялтыравыктан аерыр өчен кирәк ул...

— Да... син дә хаклы, — дип килеште Мәргән. — Тик шулай да бер эксперимент ясау зарур дип уйлыйм...

— Нинди?

— Шедеврлар язылмыйча, әдәби журнал, гәҗит чыгармаска...

Дуслар көлештеләр. Мәргән әле бу турыда шактый озак сөйләшеп утырырга ниятләгән иде, ләкин дустының башка нәрсә ишетергә теләгәнен аңлап, туктап калды. Дусты аның сүзен көтә, аның фикерен ишетергә тели. Башкалардан аермалы буларак, ул аны сәер гамәле өчен гаепләмәде һәм шелтә дә белдермәде. Ул сүзен, гадәттәгечә, ерактан башлады:

— Мин хәзер әдәби әсәрләр язмыйм, хәер, син моны үзең дә яхшы беләсең. Тиктомалдан сюжет чыгарып утырырга минем фантазиям дә житми, теләгем дә юк. Мине хәзер дөньяви мәсьәләләр борчый. Шуларның берсе... э... э... мордарлык... Яңа гына шул темага мин зур мәкалә яздым, әлегә бастырмадым, карап чыгасы урыннары бар. Кстати...

— Әйе...

— Моңа синең игъланың этәрде...

— Шулайдыр дип уйлаган идем...

— Кеше ни өчен үз-үзенә кул сала? Мин шуңар инандым: моңа төгәл генә җавап юк. Әйе, сәбәпләр төрле булырга мөмкин. «Соңгы тамчы» синдромы мәгълүм, ягъни дөньяга булган канәгатьсезлек җыелып килә, килә дә, соңынан каты итеп «ата»...

— Син миңа язган мәкаләңне сөйли башладың бугай! — дип ризасызлык белдерде Байраш. — Мин аны басылып чыккач та укый алам...

— Әйе, әзрәк кенә, — дип елмайды Мәргән. — Мин, беләсеңме, бер әйбергә игътибар иттем. Татар зыялылары арасында үз-үзенә кул салучылар бөтенләй юк. Сүз, билгеле, зыялылар турында гына бара. Башка милләт халыкларында алар бихисап. Асканнар, атканнар, кискәннәр татар зыяласын, ләкин ул барыбер мордарлыкка бармаган. Аларны эшелон-эшелон сугышка, фронтка озатканда, Мәскәү язучыларын Чистайга кайтарып яшергәннәр...

—Татарлар үз-үзләренә кул салмыйлар, дисең инде!? Тукай әйтмешли: «изелгән... мискин халык...»

— Әйтәм ич, сүз гади халык турында түгел, ә зыялылар турында бара... Билгеле шәхесләр... Урыс шагыйрьләрен генә ал! Марина Цветаева үз-үзенә кул салган Есенинны һәм Маяковскийны гаепләп чыга. Хәтерләсән, Маяковский да Есенинны гаепләп шигырь яза. Ләкин шул ук Марина үзе дә әлеге бөекләрнең ачы язмышын кабатлый. Кстати...

— Әйе...

— Татарны яратмаган хатын.

— Алай дип кенә әйтеп тә булмый. Аның инде чигенер урыны калмаган...

— Ә син беләсеңме соң аның нинди бау белән асылынганын?

— Юк, белмим.

— Пастернак Маринаны Алабугага озатканда, аның юл төенчекләрен тыгызлап бау белән бәйли. Озатыр алдыннан: «Бу бау шултиклем нык, хәтта асылынырга да була!» — дип шаярта. Ә Марина Алабугада нәкъ шул Пастернак биргән бауга асылына. Моны ишеткәч, Борис үзен гомер буе кичерә алмый...

— Ә Алабугага җибәргән бит әле, кызганмаган!

— Аны ул җибәрмәгән, НКВД җибәргән, дустым...

Кафега кеше керә торды. Шулар арасында дуслар бер таныш кешене дә шәйләп алдылар, ул кайчандыр вузда студентларга «Кече җир», «Чирәм җир» кебек бөек әсәрләр укытып, шулар белән аларның башларын катырып

бетергәч, гыйльми эшкә күчкән, диссертация яклаган, ә үзгәреш чорлары башлангач милләтпәрвәргә әйләнеп, дәһи милләтче булып өлгергән иде. «Милләт» дип кичен йокыга тала, «милләт» дип иртән уяна торган иде ул. Әлеге метаморфозалар аның гыйльми эшчәнлегенә генә түгел, холкына да бик нык үзгәреш ясаган иде. Холкы тыныч, бу сабыр һәм дә куркаклыгы белән дан тоткан, каушый калса парланган калын күзлеген күлмәк изүе белән сөртеп изаланган галим абзый. Тора-бара, көчле шәхескә, милләте өчен җанын бирергә дә әзер торган сугышчыга, яугиргә әверелгән иде. Бүген аңа тагын бер кеше тагылган (ул шулай зыялыларга ияреп йөрергә күнеккән!), сөйләүләре буенча, ансы КГБда хезмәт иткән, хәзер исә банк саклый, ягъни кизү тора икән. Ике тәүлек эшли, ике тәүлек ял итә. Ял иткәндә — «чиртеп» алырга да ярата. Кафега керүчеләр аларны бик тиз таныдылар. КГБ егете, ялтырап, аларга сәлам бирде. Галимнең сәламе төксе килеп чыкты — ияк кенә какты. Алар күршедәге өстәл янында урнаштылар. Ялкау гына селкенгән официант хатын аларга җәлт кенә хезмәт күрсәтеп алды. Кунаклар тиз генә бер-ике рюмка аракы җибәреп, кызу гына гәпләшергә тотындылар...

— Игъланыңны укыдым, — диде Мәргән. Ул мөмкин хәтле тыныч һәм сабыр сөйләргә тырышты. — Беләсеңме, мин аңа бер дә шаккатмадым, бер гадәти әйбер сымак кабул иттем. Хәтә...бөтен кала шаулый, бөтен халык сине сөйли. Юк, минем сине үпкәләтәсем килми, һәм аны арзан трюк дип тә әйтергә теләмим. Мин бит җүләр түгел, мин барсын да беләм, аңлыйм...

— Нәрсә беләсең?

— Син беркайчан да үз-үзеңә кул салмаячаксың. Фәлән числода, фәлән вакытта дөнья белән хушлашам, имеш... хе! Бу сүзләреңнән минем нигәдер көләсе генә килә. Мин бит сине яхшы беләм: үзеңә-үзең чыгарган үлем карарыңны син беркайчан да башкара алмаячаксың. Мине бу түгел, ә бөтенләй икенче нәрсә борчый. Син бит тик торганнан гына үз-үзеңә үлем юрыйсың. Менә монысы инде куркыныч әйбер! Безнең яшьтә үлем белән шаярырга да, аны чакырырга да ярамый, аның турында хәтта язудан тыелып торырга кирәк. Шаярма, дустым, кирәкми! Чакырма... Ул китерә дә бер бәрә...

Күрше өстәл янында утырган кунаклар да, күрәсең, анда Байрашны чәйнәргә тотындылар: һаман да аңа карап, аның ягына ишарә ясап сөйләштеләр. Байраш алар ягына таба усал гына карап алды һәм шуны сизеп алган галим өстәл артыннан сикереп үк торды...

— Әйе! — дип кычкырды ул Байрашка. — Сине чәйнибез! Чөнки чәйнәмичә мөмкин түгел! Оят! Син язучы кеше, син безнең милләтне хур итәсең! Динебезне мыскыллыйсың! Игълан биргән, имеш! Берәр урыс, берәр яврәй язса, әле бер хәл. Юк бит! Татар! Татар зыялысы! Тфү! Битеңә бер лачкылдап төкерәсе синең, җир бит!

—Төкер! Ә ник төкермисең!? — Байраш урыныннан торып басты. Гәүдәсе белән ул галимгә караганда дәүрәк иде, торып баскач галим-голәмә аның янында бөтенләй кечерәеп калды. Татар барда хәтәр бар, диләр. Ә инде ике татар тарткалашса кара-каршы торып сугышса, аннан да хәтәр нәрсә була да алмый торгандыр! Галим чәрелдәп Байрашның муенына килеп ябышты. Буе артык кыска булганга, сикереп-сикереп ябышты. Әгәр дә арага КГБ егете килеп кермәсә, алар һичшиксез бер-берсен буып үтергән булырлар иде...

## 6

Байраш почта ящигеннән повестка кисәге табып алды. Аны фәлән числода, фәлән сәгатьтә полициягә чакыралар. Яратмый иде ул полицияне. Аларга аның гомердә дә эше төшкәне булмады. Ләкин закон тыңлаучан, законга буйсынучан пенсионер билгеләнгән көндә, билгеле сәгатьтә эчке

эшләр бүлегенә килде. Керүгә үк, беренче катта пыяла артында утыручы карт лейтенантка повестка кәгазен күрсәткәч ана өскә, дүрт йөз дә унжиденче бүлмәгә менәргә куштылар. Ул дүртенче катта урнашкан икән. Анда менгәндә (жылы киенгәч!) тирләп-пешеп бетте, әле менеп житкәч тә тиешле бүлмәне озак кына табалмыйча интекте. Агач тамыры сымак укмашкан лабиринт бина эчендә ул тәмам адашты. Кыска итәкле бер милиционер туташ аңа әле юл күрсәтеп маташты. Ул шунар игътибар итте: бу бинада ир-ат хезмәткәрләргә караганда хатын-кызлар күбрәк эшли икән.

Дүрт йөз дә унжиденче бүлмәдә аны ябык гәүдәле, озын буйлы бер адәм каршы алды. «Дядя Степа — милиционер!» — дип көлеп куйды ул эчтән генә. Ләкин «дядя Степа» сорау алучы булып чыкмады, ул аңар котәргә кушып, бүлмәдән чыгып китте. Тәмәке исе сеңгән, жиһазлары искергән, түшәмдәге пластмасс плафоннан янар-янмас сыек уты төшеп торган күнелсез бүлмәдә ул берүзе утырып калды. Котсыз бүлмә иде бу. Дәү, калын имән өстәл өстендә сулы графин тора, аның төбе яшелләнгән. Аннан су салып эчсәң, авыру гына түгел, «кәжә бәтиенә әйләнүең» дә бар. Тәрәз төпләренә таянырлык түгел, бурсып, каралып беткән, буяу дигән нәрсәнең эзе дә калмаган. Сул як тәрәзәдә шыксыз бер гөл төбе тора, ул тәмәке төпчеге белән тулган, ә гөле шиңгән, алай дию генә аз, пачти үлгән. Бу кечкенә тәмуг эчендә Байраш үзен дә нәкъ шул гөл сымак хис итте. «Ни өчен чакырдылар икән? Мөгаен, игълан өчендер!?» Ул шулай дип уйланды.

Шактый вакыт узганнан соң, бүлмәгә урта яшьләрдәге бер ир-ат керде. Гражданский киемнән: полициядә эшләүчегә охшамаган да үзе. «ФСБдан бу!» — дигән уй йөгерде аның башыннан. Карап торырга шактый күренекле, төс-кыяфәтләре дә күркәм — бар да тәртип, бар да үз урынында иде. Тик менә борыны, борын очы гына нигәдер китек иде аның. Әллә травма алган, әллә инде дошман пулясы эләккән!? Ул, исәнләшмичә-нитмичә генә, өстәл янына утырды һәм кырлы графинны кырыйга этеп, тамак кырды. Аннан, сыек кына елмаеп, абзыйга текәлде...

—Талмасов сез буласызмы? — дип сорады китек борын. Байраш аңа чак кына: «Так точно, иптәш!» — дип честь биреп ташламады.

— Әйе, мин. Байраш Бариевич...

—Мин сезне... — Борын астыннан гыжылдаган тавыш чыкты. Гыжылдау багана башында улаган жил тавышын хәтерләтте.

— Әйе...

— Газетада чыккан игълан буенча чакырдым!

— Шунын өчендер дип уйлаган идем инде.

— Ялгышасыз, бу бик житди нәрсә!

— Мин монда бернинди дә криминал күрмим.

— Әйе, әлегә юк. Без куркынычсызлык сагында торабыз, илебезнен, дәүләтебезнең иминлеген саклыйбыз. Үлем турында мондый сәер игъланнар чыгарып, җәмгыятебезнең тынычлыгын бозабыз. Әгәренки мондый игълан совет заманында чыккан булса...

— Совет заманында аны чыгармаслар да иде!

— Ансы дөрес. Чыккан очракта да сезне райкомга чакыртып, адәм мәсхәрәсе итәрләр иде. Сезне элек бәйдә тоттылар...

— Кемнәр ул без?

— Интеллигенция. Хәзер сезне ничек диләр әле!?

— Зыялылар!

— Бәйдә тотып дөрес эшләгәннәр сезне! Сез хәзер бөтенләй бәйдән ычкындыгыз! Сезгә ирек бирергә ярамый! Ни язганыгызны, ни кылганыгызны үзегез дә белмисез! Сез бит билгеле, танылган шәхес. Бик күп дәүләт бүләкләренә ия булган язучы. Ни житми сезгә, әйтегез әле!?

— Мина барсы да житә!

— Житкәч! — дип акырды китек борын. — Ниемә дип...

Офицер, каты итеп сүгенә-сүгенә, бар көченә акырырга тотынды. Күп нәрсәдән арынды полиция. Ләкин менә шул акырудан һич кенә дә арына алмады. Закон сагында утыргач, кешеләр өстеннән власть алгач, акыруны алар табигый нәрсә дип саныйлар, күрәсен. Әгәр ул әйткән икән, димәк, аның сүзе дөрес, аның сүзе закон! Каршы дәшәсен икән, рәхим ит — ике ятажлы мат өстенә таш булып явар!

— Иптәш офицер, мина акырмавыгызны сорар идем!

Язучының нык, тыныч тавышы тикшерүчегә шактый матур тәэсир итте булса кирәк, ул әзрәк тынычланып калды, йомшады. Аның каршында әйбер урлап тотылган мескен урам карагы, яисә аракы эчеп, урамда үткән-сүткәннәргә бәйләнеп йөрүче исерек-мусрык түгел, ә китек борыннар белән генә сөйләшә алган, үз-үзенә нык ышанган язучы кеше, күренекле шәхес утырганын ул яхшы аңлый иде.

— Хәзер нишләргә уйлыйсыз?

— Көтәм.

— Нәрсә көтәсез?

— Билгеләнгән көнне көтәм.

— Сез шуны тормышка ашырырга җыенасызмы?

— Мин ике сөйләмим.

— Ни өчен һәм нигә?

— Аңламадым?

— Ни өчен сез үзегезгә кул салырга телисез?

— Бу минем шәхси эшем.

—Ансы шулай, — дип килеште китек борын. — Тик игълан бирмичә генә ярамыймы?

— Юк.

— Нигә?

— Аның эффекты булмый.

Офицер кабат чыраен сытты. Абзый кеше анардан көлеп утыра кебек тоелды. Баядан бирле үгезнең мөгезеннән каптыра алмыйча интеккән мент тактиканы алыштырырга булды. Әйе, монда өстәл сугып кына эш чыгарып булмый, әзрәк хәйлә дә кирәк иде.

— Яхшы, мин сезнең белән килешәм, — диде ул. — Тик шуны онытмагыз, сез бу уегызны тормышка ашыра алмаячаксыз.

— Ни өчен?

— Без сезгә ирек бирмәячәкбез.

— Ничек итеп?

— Шул көнне безнең спецбригада сезнең ишегегез каршында басып торачак! Бу операция белән мин шәхсән үзем җитәкчелек итәчәкмен!

— Сез ялгышасыз!

— Мин ялгышмыйм, мин дөресен сөйлим.

— Ә кем әйтте әле сезгә мин шул көнне өйдә булам дип!?

— Ә кая буласыз соң?

— Соңгы көнемне, соңгы сәгатемне кайда һәм ничек каршылавым турында мин сезгә сөйләмәячәкмен. Ул сер, һәм аны беркем дә белергә тиеш түгел!

— Ә була калса...күмәргә!?

— Курыкмагыз, күмүчеләр табылыр. Әле беркемнең дә күмелмичә җир өстендә калганы юк, барсын җиренә җиткезеп, тәртип белән җирләп баралар. Шуңа күрә отрядыгыз белән килеп, минем ишекне саклап торудан бернинди дә мәгънә юк.

— Анладым, димәк, өегездә сез андый нәрсә эшләмәячәксез инде?!

— Юктыр, мөгаен.

— Яхшы. Ә ничек китәргә уйлыйсыз? Ничек итеп үз-үзегезгә кул салырга телисез? Асылынасызмы? Агу эчәсезме? Әллә газны ачып калдырасызмы? Ваннада тончыгып үләсезме?

— Ә сезгә мин ничек үлсәм дә барыбер түгелме?

— Юк, бер түгел! — дип кычкырды китек борын. — Дәүләт органнары мондый башбаштаклыкка юл куя алмый!

Байраш полиция бүлегеннән кичкә генә кайтып житте. Урамда ишеп кар ява, язучының гына күңелендә буран дуламый, гүзәл һәм кырыс табигатькә дә, илебезнең тынычлыгын саклаган дәүләт органнары эшчәнлегенә дә ул инде күптән битараф иде.

## 7

Әлеге вакыйгалардан соң ике көнләп вакыт узгач, аңа авылдан абыйсы килеп төште. Миңнулла аңардан өч яшькә генә олы булса да Байраш аңа барыбер абый дип эндәшә иде. Абыйсы килеп төшкәч ул әллә нишләде — ыгы-зыгы килеп, кухня эчендә кайнашты, бәрәңге ярып, ит салып, аш куйгандай итте. Авылга кайтырга яратмаса да авылдан килүчеләрне сыйларга күнеккән иде ул. Хатыны да (Казан кызы булуга карамастан!) иренең авылдагы туганнарын бик тә ярата, үз итә иде. Абыйсы буш кул белән килмәгән: яңа гына суйган тана ите кыстырып килгән.

Миңнулла гомере буе авылда яшәде, эшләде, балалар үстерде. Хатыны Җәүһәрияне Ходай урнына күрде. Хәзер инде менә ул да картайды: дәү буйлы, таза кыяфәтле Миңнулла да тартылган, суырылган, мөчәсе бөкрәеп, җилкәләре кечерәеп калган. Ул энесе пешергән ашны мактый-мактый ашады. Юлдан килгәндә ачыккан, күрәсең, ашханәгә кереп тормаганнар. Байраш өйгә кайтканда ул подъезд төбендә басып, катып тора иде. Малае Рафил джипта китергән икән үзен. Тана тушын икесе көч-хәл белән өстерәп менделәр...

—Укыдым! — Миңнулла, ашап туеп, түрдәге кызыл кәнәфигә килеп утырды.

— Нәрсә укыдың?

— Гәҗиттәге игъланыңны.

— И...

— Мин ул гәҗитне алмыйм. Миңа аны Рафил алып кайтты.

— Кулдан кулга таралды инде?!

— Халык кызыксына бит... Аннан... телевизорда да күренеп алдың.Анда да шул нәстә!

— Халык ни ди?

— Дөресен әйтим, халык берни аңламады. Шаяру дип кенә кабул итте.

— Ә син ничек уйлыйсың?

— Мин дә шаярасың дип уйлыйм.

— Ялгышасың, абый, шаяру түгел бу, ә чын нәрсә!

Миңнулла агарынып китте. Ул бик читен, бик тә кыен хәлдә калды. Бик нык каушап, аптырап:

— Менә шуны белергә килгән дә идем инде, — дип кенә эндәшә алды.

— Җәүһәрия ни ди?

— Хатын ни дисен инде... Ул да аптыраган...

— Шулай да!?

— Авылга кайтып килсен әле, ди. Бер сөйләшеп, мунчалар кереп китәр, ди...

— Белмим шул, кайчан гына кайтырга инде...

—Ә нәстә! Бер эшен дә юк! Син пенсиядә! Үзен генә яшәп ятасын, ыслушай! Күнелсездер монда сина!?

— Төрле чаклар була...

— Күреп торам: күнелсез сина. Хатынын үлгәннән бирле бөтенләй бетерештен, ыслушай. Ир кеше берүзе генә яши алмый шул. Хатын-кыз яши әле ул, шөгылен таба шунда, оныклар, бала-чагалар үстерешә. Ә ирләргә кыен. Менә син дә ялгыз калдын. Шуна күрә башына әллә нинди начар уйлар керә. Авылга кайтып, бер бездә кунак булып китсән, шул хәтәр уйларын бик тиз таралыр иде. Кайт! Ул бит синен туган нигезен! Туган нигездән аерылырга ярамый, энекәш! Нигезеннән аерылган кеше бәхет күрми бу дөньяда, юк, беркайчан да күрми...

— Анысы шулай...

— Юк, инде кайтмыйсын син, беләм. Авылны яратмадын. Әткәй ат жиктереп жанына тиде. Ялкау иден, колхоз эшен яратмадын. Беләм, авылдан туеп киттен. Язучы булдын. Авыл турында язалмадын инде син. Төзелешләр, завут-мазутларны язып чиләнден...

— Мине жүнле язучы була алмадын дип әйтәсен киләме!?

— Юк, алай димим. Авылны язсан, халык белер иде хет үзенне, халык яратыр иде. Башында мондый хәтәр уйлар да уйнамас иде. Авыл бит ул калкан сыман, кешенен жанын, рухын саклый...

—Картайгач, матур сүләшергә өйрәнден син дә, каян укыдын боларны? — дип төрттерде аны Байраш.

— Укымадым, шулай дип уйлыйм...

Сөйләшә-сөйләшә вакытнын узганын да сизми калдылар. Ул арада калага эш белән килгән Рафил да күренде. Хушлашканда абыйсы:

— Әнине төштә күргәнен юкмы? — дип сорады.

— Юк, күрмәдем, ә син?

— Күрдем, берничә тапкыр... Яшь чак, имеш. Без манка малайлар инештә су коенабыз. Ин сай жирендә, билгеле, юшкында. Ә син тоттын да инешнен ин тирән жиренә йөзеп киттен. Мин борыл дип сина кул болгыйм, ә син йөзәсен дә йөзәсен. Бетә, мәйтәм, бу хәзер, бата! Карыйм — инде бата да башладын! Шулчак, ак фәрештә сымак, яр кырында әнкәй пәйда булды. Ул кулларын жәйде дә сине чөеп алып, һавага күтәрде. Һәм син каядыр китеп югалдын. Икенче күргәндә, син инде исән-сау яр кырына төшеп утырган иден. Әнкәй ярнын икенче ягына чыгып баскан да безгә ачуланып бармак селки...

— Нәрсәгә юрадын?

— Кисәтә ул безне, нигәдер кисәтә...

Хушлашу озакка сузылды. Рафил берничә тапкыр урамда машинасын кычкырткалап алды. Ә Миннулла һаман да энесе белән хушлаша алмады.

— Язлый минем юбилей, житмеш биш яшь тула, кайтырсын бит!? — диде ул энесенә.

Байраш берни дә эндәшмәде, кулларын гына жәйде. Янәсе, исән булса кайтыр! Шунардан рәхәтләнешеп көлештеләр. Инде фатирдан чыгып бусаганы ары узгач Миннулла:

— Син ул игъланынны, энекәш, кире ал инде, яме!

— Нигә?

— Кешеләр бар бит, алар ни уйлар... Син мин әйткәннәргә үпкәләмә, яме...

— Аны кире алып булмый!

— Ә нишләп була?

— Опровержение бирергә!

— Нәрсә ул?
— Юкка чыгарсак кына инде...
— Менә, менә, — дип килеште Миңнулла, — юкка чыгарырга кирәк аны... юкка...

Миңнулла киткәч, Байрашның җанын ачы сагыш биләп алды. Менә авылдан аның абыйсы килде, чын авыл кешесе — сүкмәде, гаепләмәде, авыр сүз әйтмәде, эчендәгеген күңелгә сеңәрлек итеп әйтеп китте. Байрашка башка юл калмады: кулына каләм алып, алдагысын инкар итәрдәй яңа игълан язасы гына калды.

**8**

Ул ашкынып үзенең кабинетына керде. Кабинет аның горурлыгы иде. Бер караганда анда шаккатырлык берни дә юк кебек: хан заманындагы дәү имән өстәл, бу — аның язу өстәле, аның шатлыгы һәм күңел юанычы. Язу өстәле аның өчен дус, иптәш, сердәш, дусларын, туганнарын, хәтта хатынын да алыштыра алган җиһаз. Анда ни генә юк, ни генә аунамый: таслап тезелгән китап өемнәре, башланган караламалар, кульязмалар, белешмәләр, журналлар, гәҗит теләгелмәләре, язу әсбаплары (авторучкалар, карандашлар, бетергечләр), фотолар, көндәлекләр һ.б. Язу өстәле аның өчен дөньяның үзәге, тормышның бердәнбер зур мәгънәсе булып калды, фәкать иҗат кына тудыра ала торган олуг бәхет бирә алды. Күпме әсәрләр язып, һәм күпме ачышлар ясап ул шунда балаларча сөенде, әгәр дә язалмаса, әсәрен башлап та ахырына җиткерә алмаса, өметсезләнсә, ул шунда чын-чынлап көенде. Бервакыт язучы дустына кунакка барып, аның өендә язу өстәле күрмәгәч, ул бик нык гаҗәпсенгән иде. Язучы хәтле язучы исемен йөртеп тә язучы кешенең язу өстәле юк! «Мин өйдә язмыйм, редакциядә, эштә язам!» — дип акланган булды тегесе. Эштә язып кына язучы булып була микәнни соң? Нишлисең бит, күпләр шулай югары уку йортларын бетерәләр дә, редакцияләргә кереп утыралар. Тормышны бөтенләй белмиләр, язарлык темалары юк. Утыралар шунда бер-берсенең гайбәтен чәйнәп, язалар бармактан нидер суырып. Байраш производствода эшләмәсә дә завод тормышы белән гел кызыксынып килде. Төрле җыелышларда катнашты, эшчеләр, инженерлар белән аралашты, завод кичәләренә йөрде. Кызыксыну да юк бит хәзерге яшьләрдә, алар бөтен нәрсәгә битараф кебек. Хәер, сүз әйтеп булмый, җинел түгел, аларга да яшәргә кирәк. Совет заманында иҗат кешесен рухи яктан кыссалар да, яшәр өчен шартлар тудыра беләләр иде. Күбесенең кабинеты гына түгел, торыр урыннары да юк бит хәзер. Алдагы чорда язучының аерым бүлмәсе булсын дип аңа өстәмә торак мәйданы бүлеп бирәләр иде. Менә шул чакта алып калган иркен, киң бүлмәсендә тирән сагышка бирелеп, бик нык уйланып утырды ул. Элегрәк язганнарын машинкада бастыра торган иде, ләкин андый нәрсә хәзер модадан чыкты. Компьютерда язарга өйрәнә алмады. Хәер, әллә ни теләге дә булмады. Авторучка, менә шул шариклы авторучка аның мәңгелек дусты булып калды. Ул, кабаланмыйча гына, өстәл каршында торган зур кабарынкы урындыкка килеп утырды. Мондый урындык бу фатирда бер генә, ул аны мебель фабрикасына махсус заказ биреп ясаткан иде. Һәм, әйтергә кирәк, ул шактый кыйбатка төште. Үзенчә бер горурлык иде инде бу, амбиция! Өйдәгеләрдән аның урындыгы да аерылып торырга тиеш, янәсе! Ләкин аны ул теләгәнчә ясый алмадылар, әзрәк кенә тәбәнәк килеп чыкты, өстәл биек, ә бу бер башка тәбәнәк. Хәер, хуҗа җаен тапты: күт астына урындык эченә сыешлы гына мендәр салып утыра торган итте. Элегрәк барсы да кызык иде: язу, иҗат итү. Хәзер исә ул иҗаттан әллә ни тәм дә тапмый инде. Анардан гына түгел, бөтен нәрсәдән күңеле кайткан иде аның. Байраш өстәл тартмасыннан бер чиста кәгазь кисәге тартып чыгарды һәм иркенләп язарга тотынды.

Энгер-менгер чак иде. Бүлмәгә бик тиз карангы төште. Байраш өстәл лампасын кабызды. Лампасы да яшел төстә — иҗат төсендә. «Тик иҗат кына юк!» — дип көлемсерәде ул. Инде язасы текстының башын, уртасын сырлап, ахырына күчәргә торганда гына, арттан бер тавыш килде. Ирләр тавышы. Ишектән кергәч үк чатта кара күн кәнәфи тора. Байрашның шул кәнәфидә беркайчан да ятып йоклаганы булмады, утырып ял итәр өчен генә куелган иде ул. Тавыш шул яктан килде:

— Ни язасың?

— Опровержение.

— Язма!

— Нигә?

— Курыктыңмы!?

— Юк, курыкмадым, ялгышканымны аңладым.

— Юк, син ялгышмадың. Үз-үзенә кул салу турындагы ниятенне шәрехләгән игъланың бу тормышта синең бердәнбер кыю адымың булды. Син гомер буе куркып яшәдең. Куркып эшләдең, куркып яраттың. Алдын-артын гына карап яздың. Син иҗат итәргә яраттың, ләкин укучыны яратмадың. Син алынган теманның төбенә төшеп, тирәнтен язарга тырыштың, ләкин укучы сине кабул итмәде, чөнки язганнарың ихлас түгел иде. Ә ихлас булыр өчен ирекле булу, курку белмәс җан кирәк. Ниһаять, син, үзеңне җинеп, үз гомереңдә беренче мәртәбә кыю адым ясадың, укучы сине күреп алды, сиңа тартылды, ышанды. Инде менә булдырдым, ирләрчә хет бер чын эш эшләдем дигәндә генә, син дингез дулкыныннан куркып калган ташбака сымак, тормыш яры буйлап кабат артка сөйрәлергә булдыңмы!?

— Уйламыйча, ашыгып язганмын...

— Әгәр дә син шул карарыңны ахырынача җиткерә алмасаң, синнән бөтен халык көләчәк!

— Юк, көлмәс!

— Нишләп?

— Динебез мордарлыкны тыя.

— Хе...хе...хе! — Аның хетхелдәп көлүе йөрәкне өшетерлек иде. — Юк, дустым, син дингә ышанмыйсың. Сылтау гына ул. Син хәтта үзеңнең милләтеңне дә яратмыйсың, аңардан читләшәсең. Татар булуыңнан да ояласың. Милләт дип шапырынып яздың, ә күзең гел маржаларда булды. Юк инде, дин дә, милләт тә комачауламый сиңа. Ә ни соң?

— Намусым кушмый...

— Кем алдында?

— Абыем, авылдашларым...

— Намусың бармы соң синең? Намусың булса, син кеше әйберен урламас идең. Син бит карак!

— Мин! Карак!?

— Әйе, әдәби карак!

— Минме!?

— Әйе, син! Бу бүлмәдә синең белән миннән башка беркем дә юк. Чын ир булсаң үз сүзеңдә тора бел! Үләргә дип кул куйгансың икән, эшеңне ахырына җиткер! Син — шуңа лаек!

— Кем соң син!?

Баядан бирле йөрәгә өшеп, борылып карарга да куркып утырган Байраш башын әкрен генә артка борды һәм иманеп китте: бу — Җәгъфәр иде.

— Ха-ха-ха! Ха-ха-ха!!!

Гомере буе халык авыз иҗатын туплап, шуны китап итеп чыгара алмыйча калган мәрхүмкәй иде бу. Бик нык ябыккан, чыраена сары суккан, сөйләгәндә

сөякле куллары калтырангалап ала. Әрвах иблис кыяфәтен алган иде. Бәлкем әле ул галим Җәгъфәр түгелдер, ә аның кыяфәтенә кергән бер иблис заты гынадыр. Чөнки диванда кара шәүлә сымак шомраеп утырган шайтани зат Байраш борылып карауга ук күз алдында эреп юкка чыкты. Аның артыннан бүлмәдә сәер шом һәм жан өзгеч, күнел кайтаргыч көлү генә утырып калды. Нигә килгән ул? Ни кирәк аңа? Хезмәтләрен кире кайтаруын, аның үз исеме белән чыгаруын сорап килгәнме? Чыгарсын! Бүген үк үз исемен куеп чыгарсын! Ул аны бүген үк биреп җибәрергә дә риза! Бастырсын... ахирәт нәшриятында...

## 9

Билгеләнгән көн дә килеп житте.

Шайтан коткысына бирелмәде Байраш, исән калды. Үз-үзенә кул салу түгел, ул аның турында уйларга да курыкты. Онытты. Этаж эчендә ниндидер чит кешеләр (ул аларны ишек йозагы ярыгыннан шәйләп алды!) күренгәләгәч кенә хәтәр көнен исенә төшерде. Бу чит кешеләр аның ишек кыңгыравына да басып киттеләр. Байраш ишекне ачып этажга атылып чыккач, тегеләр сибелделәр. Алар көне буе шулай йөреп тордылар. Боларның «китек борын»нар командасы булуын ул яхшы аңлады. Тикшереп йөриләр! Исәнме ул, янәсе, каядыр балконда асылынырга уйламыймы, йә ваннада кан тамырын кисеп ятмыймы!? «...кан тамырын кистем, исем китте: шигырь агып ята!» — диярсең аннан.

Телефонга кабат җан керде. Монысы да бер тикшерү сымак нәрсә иде. Кемдер сәбәп тапкан булып нидер сораша, кемдер Байрашның тавышын ишетүгә үк трубканы куя. Шигырьләр сырлаучы әбекәйнең телефоннан: «Безнең сөекле язучыбыз!» — дип кычкыра-кычкыра дәшүе дә бу сүзләренең ихлас түгеллегенә бер дәлил. Авылдан абыйсы да шалтыратты. Хәтәр көн турында бер ләм-мим сүз дә дәшмичә, ул бутала-бутала авыл яңалыкларын сөйли башлады. Аржак Пытыр Хәтимәсе ике баласы белән Шиап Мансурына (кырыкка хәтле өйләнмәгән) кияүгә чыккан икән! Кирәкме соң аңа Пытыр Хәтимәсенең ике баласы белән исерек буйдакка кияүгә чыгуы!? Байраш җүләр түгел, абыйсының ни өчен шалтыратканын бик тиз аңлады. Шунар күрә дә ул: «Абый, борчылма, мин исән!» — дигәч, Миннулла, бакчада алма урлап тотылган карак малай сыман, ирексездән кеткелдәп көлеп куйды. Бер Мәргән Галләм генә шалтыратмады. Дустының андый хәтәр адым ясамаячагына ул инде күптән инанган ахрысы. Төнгә каршы бер башланган яртысын күтәреп Гаяз күрше килеп керде. Лаякыл исерек. Бертуктаусыз гафу үтенә. Байраш аның белән эчмәде, аңа закуска гына салды. Алып кергән яртысын берүзе дөнкеп, Гаяз җырлый-җырлый урамга төшеп китте. Карлы урамда аның исерек әче тавышы әле озак кына яңгырап торды, аннан суга төшкән кебек тавышсыз гына каядыр китеп югалды. Әллә берәр дустына кергән, әллә хатыны табып алган...

Хәтәр көн узгачтын да чәйнәүләр тынып тормады. Төрле гайбәт сүзләр килеп ирешә. Фикерләр икегә бүленде. Дуслар, туганнар: «Маладис, акылына килгән!» — диештеләр, дошманнар исә: «Хурлык!» — диеп арттан өреп калдылар...

## 10

Алар барыбер очраштылар.

Ул, күзенә туры карап, аңа дөреслекне әйтеп салды. Ул дигәнебез Байрашны афоризмнар китабы өчен күкләргә чөеп мактаган әрсез яшь язучы иде. Әйфетдин атлы иде ул. Әллә ата-анасы кушкан, әллә үзе уйлап таккан, шайтан белсен, тик андый исемне Байраш үз гомерендә беренче ишетә иде. Дуслары аңа шаяртып Айфон дигән кушамат та такканнар. Битенә сакал-мыек җибәргән, кара тутлы, кыска чандыр буйлы бу егет тулай

торакта малосемейкада яшәп ята икән. Урамда бер ялгыш кына очрашкач, егет аны кунакка чакырды. Тулай торак Байрашлар йортыннан якында гына, шуна күрә ул бик тиз ризалашты. Бер уйлаганда, аларны берләштерердәй нәрсә юк — икесе ике төрле, икесе ике формат кешеләре. Ләкин монда бер кечкенә генә сер, аңлашасы бер сүз бар иде. Менә шул сер, шул сүз аны бу йортка, кер һәм аш исе, бала-чага тавышы белән тулы тулай торакка алып керде. Соңыннан ул монда керүенә үкенде үкенүен, бик нык үкенде, ләкин аның чарасыз нәрсә икәнлеген, шунсыз мөмкин түгеллеген аңлау хисе генә аны тынычландыра алды. Ул алдашу, ул гаеп кайчан да булса бер фаш ителеп, ул сер кайчан да булса бер тишелергә тиеш иде бит инде. Ә сер менә шушы Әйфетдин яшәгән малосемейкада чишелде дә инде.

Әйфетдин утызга якынлашса да әле һаман буйдак булып йөри иде. Язылышмыйча, никах белән генә бер мәртәбә өйләнеп караган ул, ләкин хатыны белән ике-өч ай гына тора алган. Ул үзе аерылышу ягында булмаган, ләкин хатыны нигәдер язучы кәмәше белән яшәргә теләмәгән. Язучылык һөнәре белән җенләнгән, аны Алла урнына күргән, тормышнын рәтен-чиратын белмәгән, иҗаттан тыш дөньяның мәгънәсен, тормышның ямен күрмәгән язучы егет аны гаиләбәхетеннән өстенрәк күргән, димәк.

Унтугыз квадратлы бүлмәсен Әйфетдин аннан-моннан җыйган иске мебель белән тутырган. Бүлмәнең бер чатын аш ягы иттереп чолан ясаган, аны пәрдә белән корып куйган. Материалы кызыл бәрхеттән, клуб пәрдәсен хәтерләтә, өстәл урнында — гади мәктәп партасы! Мәктәп укучылары белән очрашуга баргач бирәр гамәлдән чыккан партаны күтәреп кайткандыр инде. Тик шунысы кызык: бүлмәдәге ярлылык, хәерчелек аның хуҗасын бизи һәм әсәрләрендә һаман да шул үлем, бәхетсез мәхәббәт турында язучы егеткә ниндидер бер шарм да өсти кебек. Шунын өстенә әле ул мәче дә асрый икән. Шуңа күрә дә бүлмәгә мәче исе, нәҗес исе сеңгән иде. Кап-кара үзе — шайтан күзе! Нәселле түгел, урам мачысы. Шук, җитмәсә. Шкаф һәм өстәл өстендә йөреп кенә тора. Бертуктаусыз. Байрашның алдына да килеп утырды. Байраш мәчеләр яратмый, ул аларны беркайчан да өендә тотмады. Ул аны берничә мәртәбә идәнгә бәреп төшерде, тик тегесе үч иткәндәй сырпаланып, кабат анын алдына менәргә маташты. Байраш, ачуы килеп, чыраен сытты.

— Мәчеләрне яратырга кирәк, абзый! — дип көлде егет. Үч иткәндәй киная белән көлде.— Теге дөньяга баргач иң беренче булып мәче каршы ала икән безне! Перес, заразы! — Әйфи аягы белән тупылдатып идәнгә тибеп алды. Хуҗасыннан шикләнә тагын үзе! «Заразы» шундук эреп югалды: каядыр коридорга чыгып чапты. Исеме дөрестән дә Заразы иде, ахрысы.

— Яшь язучыларга яшәве җиңел түгел шул хәзер! — дип сүзен башлады Байраш. — Безнең чакта, ывчу-тыки, дәүләт тарафыннан игътибар бар иде. Берлеккә керсәң, фатирын да бирәләр, ял итәргә юлламасын да тоттыралар иде. Бер юка гына китап чыгарып, шунын акчасына өчәр ел мәшәкатьсез яшәп була иде. Премиясен дә, бүләген дә ала идек. Коммунистларны сүгәбез сүгүен, ләкин алар иҗат кешеләренә һәрвакыт игътибарлы булды...

— Зату хәзер сүз иреге!

— Ә син аны бездә бар дип уйлыйсыңмы?

— Бар, нишләп булмасын! Син минем әсәрләремне укыганың бармы?

— Бар...берничәсен...пессимизм...

—Әйе... ярылып ята! Үлем...суицид...Разве Совет заманында чыгара алыр идем мин аларны!? Якын да китермәсләр иде! Кем партияне мактаган, шул яхшы яшәгән, тик кемнәрдер Соловкида черегән, кемнедер диварга терәп атканнар... Бурнашларны, Тинчуриннарны гына алыйк... Так шту... барсы да чагыштырмача, абзый, тәк кенә беркемне дә, бер генә системаны да мактарга ярамый...

Егет озак сөйләде. Ашыгып, тотлыгып сөйләште. Билгеле, ул абзыйны

әдәбият турында сөйләшер өчен генә чакырмаган, һәм аңа тиздән башка төрле сүз житкереләчәге көн кебек ачык иде. Нәрсә, нәрсә, ләкин бу жирбитнең эчендә Байрашка карата ниндидер этлек кайный иде. Ул сөйләгән арада бер ир кеше керде. Баш белән ым кагып сәлам биргәчтен, тәрәзә янына, түргә узды. Кем ул? Нишләп монда керде? Күршеседер, бәлкем? Урамнан керсә, киенеп керер иде! Ни гажәп, ул кемгәдер бик нык охшаган да иде. Тик кемгә!?

— А всё это ерунда! — дип сүгенде сүз сөйләп арыган егет. — Күпме сүләсәң дә шул инде ул!

— Ә нәрсә...ни ерунда? — дип кайтарып сорады Байраш.

— Абзый! — дип сүзне шундук икенчегә борды тегесе. — Син бу адәмнең кем икәнен беләсенме? — Әйфи бармагын бөгеп түрдә утырган ир кешегә күрсәтте.

— Юк... әйтәлмим... Болай үзен кемгәдер охшатам да кебек, ләкин тәгаен генә... — Байраш күзен чекрәйтеп, аңа кабат бер мәртәбә карап куйды. Ә түрдәге кунак селкенмичә статуя сымак утыра бирде.

— Бу, беләсеңме кем?

— Кем инде?

— Жәгъфәр аганың энесе.

Байраш сүзсез калды. Егетнең ачыктан-ачык уйный башлаганын аңлап алган язучы, монсуланып:

— Әйтәм аны...— дип кенә эндәште.

— Охшаган бит, әйеме! — дип елмайды егет ( ул зәһәр, астыртын тантана итте!) — Төрекмәнстаннан кайтты. Гаиләсе белән. Рәсәй яңа закун чыгарган: йә син яшәгән урыныңда каласың, йә Рәсәйгә кайтасың... Менә Азамат та безнең янда! Общагадан бүлмә сатып алды. Хәзер шул кечкентик кенә бүлмәдә хатыны, үзе һәм шулай ук малае белән килене яши. Ике кечкенә оныгы да шунда чабышып йөриләр. Әле хәзер калганнары да кайтырга торалар икән! Кызык, билләһи... Аны Жәгъфәр аганың энесе дип башыма да килмәде... Карап йөрим... ыслушай... гел шуңар охшаган...

— Ул гел миңа карагач, мин курка да башладым! — диде Азамат. Татарча аңлый, сөйләшә, ләкин үз телендә артык күп сөйләшмәгәч, аңарда бик нык шәрык акценты көчәйгән иде. — Мин аны башта КГБ шымчысы дип торам...

— КГБ түгел, ФСБ!

— Ие... ие... КГБ...

— Ә бер көнне тоттым да сорадым моңардан! — дип күтәреп алды Әйфетдин. — Син Жәгъфәр аганың туганы түгелме, мәйтәм!?

— Мәйтәм, ие...туганы, бертуган энесе...

— Жәгъфәр ага белән мин, укуны бетергәч, фәнни-тикшерү институтында эшләп алган идем. Шунда ике папка материал жыйнап, ул аны институт житәкчелегенә кертеп тапшырды. Бик зур хезмәт. Сүз ни турында барганын аңлыйсыңдыр инде, абзый!? — дип төрттерде егет. — Ул папкалар анда саклангнмы, юкмы, ансын белмим, ләкин ул, Ходайның рәхмәте, нәшриятта китап булып чыкты. Шунысы куанычлы, гомерлек хезмәт югалмады. Сиңа, абзый, бик зур рәхмәт! Син аны ышкылап чыгармаган булсаң, ул хәзер әллә кая архивларда тузан эчендә аунап яткан булыр иде, киләчәк буынга олуг мирас булып ирешмәс тә иде. Рәхмәт сиңа, абзый...

— Үзеңә рәхмәт, — диде Байраш, һәм шуңа уңайсызланып жилкәсен сикертеп алды.

— Ни өчен?

— Рәхмәтең өчен рәхмәт...

— Рәхмәт... тик... бер читенлек бар, име... кыенлык... Менә шул нәрсә эчне пошыра...

— Нәрсә? — Байраш болай гына сорады, сүзнең ни турында барганын ул

инде күптән аңлап өлгерде һәм хәзер эченнән шуңар җавап эзләп, уйланып утыра иде. Килеп туган хәлдән җиңел чыгар юлны эзли иде ул.

— Алайса... белмисең инде?

— Шулай да...

— Хе-хе! — дип көлде егет. — Китапны чыгаргансың, име, үз исемеңне куеп, акчасын да алгансың, тик менә чын авторның, ягъни Җәгъфәр аганың исемен куярга онытканСЫҢ. Ни өчен?

— Эш монда болай, — дип аңлатты Байраш. — Беренчедән, Җәгъфәр ага китап чыгаруны үзе миңа ышанып тапшырды, ни кызганыч, ул шул елны үлеп тә китте. Икенчедән, мин китап өчен бер тиен дә акча алмадым, ул шәхси нәшриятта дөнья күрде, ә нәшрият банкротка чыкты, ябылды ягъни ...

— Китап чыккач кына, име!?

— Теләсәң ничек уйла, аңсы синең эш! — дип кырт кисте Байраш. — Акчасын түләмәделәр, бусы бер... Китапны чыгарганда шул ахмаклар чын авторның исем-фамилиясен төшереп калдырганнар...

— Аныкы юк, ә синеке калган! Ни өчен?

— Әйтеп торам бит: шәхси нәшрият... тәртип юк... бардак...

— Абзый, җитәр сиңа, яме! — дип ярсыды Әйфи. — Менә син Азаматны күрдеңме!?

— Күрдем...

— Җәгъфәр аганың гаиләсе булмаган, хатыны да, бала-чагасы да юк. Бөтен гомерен фәнгә багышлаган. Азамат аның бердәнбер энесе. Аның гаиләсе зур, Төрекмәнстаннан кайткан. Ул хәзер шушы бүлмәне сатып, Казан кырыннан бер йорт сатып алмакчы була. Тик акчасы җитми. Аңа хәзер йөз илле мең сум акча кирәк...

— Ие, ие... йөз илле мең! — дип раслады Азамат, бармакларын җәеп.

— Ә ул акчаны аңа син бирергә тиеш!

—Ие... ие... син... сез! — дип тәкрарлады Азамат.

— Мин!?

— Әйе, син!

— Бирмәсәм!?

— Бирмәсәң, — диде Әйфи. — Азамат сине судка бирәчәк! Ә суд аны яклаячак! Чөнки ул хаклы! Син кеше әйберен, кеше хезмәтен урлагансың! Ул вакытта инде син йөз илле мең генә түгел, ә биш йөз илле мең түләячәксең...

— Ие... ие... дөрес... биш йөз илле мең...ие...

— Аңсы әле бер хәл, — дип дәвам итте язучы егет. — Репутацияң бөтенләй юкка чыгачак. Җиңел дан эзләп, сәер игълан язып, халыкны алдап, халык алдында бер җүләргә калдың бит инде. Пьедесталга менден, ә элмәккә менәлмәден. Курыктың! Инде бу эшең дә фаш ителгәч, барлык җәмәгатьчелек әдәби карак икәнлегеңне дә белгәч, син, абзый, хәзер бөтенләй адәм страмына калачак бит! Ишетәсеңме, адәм страмына...

## 11

Байраш икенче көнне генә аңына килде. Больничный палатада. Кичәге хәлләрдән соң аңа микроинсульт булган. Аның каршында ач күзле Әйфи дә, җылы яктан кайткан төрекмән татары Азамат та түгел, ә аның үз кызы Альбина утыра иде. Атасына инсульт булганын ишеткәч, кичен самолетта очкан һәм төне буе әтисенең баш очында утырып чыккан. Кызын күреп, якын кешесен күреп Байраш бик нык сөенде. Ничек анасына охшаган бит, әй! Ул күз карашлары, ул елмаеп караулары! Әнисенең борын очында гына миңе бар иде, баксаң, кызында да бар икән бит нәкъ шундый ук миң!

— Ничә көнгә кайттың, кызым?

— Бөтенләйгә, пап!

— Бөтенләйгә!? — дип аптырады атасы.

— Борис белән аерылып йөрибез, әгәр каршы килмәсәң, без синең янда торыр идек!?

— Юк, юк, син нәрсә, мин ничек каршы килә алам! Аерылышу әйбәт түгел, кәнишне, ләкин синең кайтуыңа мин шат, кызым, бик тә шат! Ә балалар... оныклар нәрсә?

— Мин аларны да алып кайтам...

— Ә Борис?

— Борис каршы түгел...

— Шулай да ни булды соң арагызда?

— Әле моңа хәтле сорашканың булмады.

— Шулай да!?

— Борис миңа хыянәт итте.

— Кем белән?

— Ирләр белән...

— Ә!? Ул шундый... иде... мени!?

— Әйе, пап, ул шундый булган!

Байраш бер айдан соң хәстәханәдән чыкты. Икенче көнне Мәскәүдән аның оныклары кайтып төште. Аларны әнисе барып алып кайтты. Аңа хәтле балаларны Борисның анасы, ягъни Альбинаның каенанасы карап торган. Аерылышу процессы башланган, икесе дә гариза язган. Мәскәүдәге өч бүлмәле фатирны сатып, акчасын икегә бүләчәкләр икән. Бер өлеше Альбина белән балаларга, икенчесе Бориска. Хәзер анда беркем дә тормый, фатир пичәтләнгән. Кияү анасы янына күчкән. Маржа каенана елый да елый икән, Борисын түгел, билгеле, оныкларын җәлләп елый.

Кызның балалары белән Мәскәүдән кайтып төшүе Байраш өчен бер яктан бәхет булса, икенче яктан шактый мәшәкатьле эш булып чыкты. Хатыны үлгәннән соң өйдә бу кадәр күп халыкка өйрәнмәгән иде ул. Тупылдап торган көдрә чәчле ике ир бала. Байрашлар нәселендә көдрә чәчлеләрнең булганы юк, димәк, ирнен, яһүднең орлыгы төшкән монда. Олысы Моисей, кечесе Иосиф исемле. Берсенә ун, икенчесенә җиде яшь. «Шатлан, сөен, Байраш, болар бит синең оныкларың!» — дияр иде дә, тик әллә ни сөенер нәрсә генә юк шул әле. Татар баласы түгел инде болар, ә урыс-яһүд токымы. Әнисе юмаланып: «Иосиф гел сиңа охшаган инде, пап!» — дигәләсә дә, язучы алар арасында әллә ни охшашлык тапмады һәм табасы да килмәде. Ул башта аларга ияләшә алмыйча интекте. Шау-шу, чыр-чу. Олыны олы димиләр, гел нидер сорап кына торалар. Оныклары кабинетның астын-өскә китергәч, ул аны ачкычка бикләп куйды. Балаларны башта мәктәпкә алмыйча интектерделәр, Байраш авыру килеш, директорлар янына барып, мәктәп турында саллы очерк язарга вәгъдә иткәч кенә оныкларны алырга риза булдылар. Альбина музыка укытучысы, ул да тиз генә эш табалмады. Югары уку йортында Байрашның таныш ректоры бар иде, аңа ялынгач кына кызын университетка ярты ставкага эшкә алдылар. Яңа гына хәстәханәдән чыккан, үзен һаман да начар хис иткән олы яшьтәге кешене бу тормыш мәшәкатьләре шактый зур йөк булып басты. Ләкин анардан гына үлмиләр, кеше иң элек авыр сүз күтәрә алмый.

Бер көнне ул кызы белән талашты. Яшь вакытта анасы Альбинаны музыка мәктәбенә укырга кертте. Фортепиано бүлегенә. Кыз укый башлауга ук хатыны өйгә пианино алдырды. Шуңар шактый тавыш купты: кызның көн-төн пианино акыртуы Байрашның җен ачуларын чыгарды. Җүнләп уйнаса бер хәл, уйный белми бит, шакмакка басарга өйрәнә. Укучы кызның инструмент клавишларына басып, көй сымак нәмәстә чыгарырга тырышып утырулары уйга чумган язучының башына чүкеч белән суккан сыман була

иде. Шуннан бирле ул пианиноны яратмады. Кызы кияүгә чыгып Мәскәүгә китүгә үк, ул аны арзан гына бәягә сатып та җибәрде. Хәзер анар шул инструмент тагын кирәк булган: университетта музыка укыта бит! Һәм менә шуның аркасында өйдә кабат тавыш...

— Пап! — дип безелдәде кызы. —Нигә дип саттың инде аны? Нәрсә, комачау иттеме, урын күп алдымы? Нәрсә, акча кирәк булдымы!?

Кызының соңгы сүзләре Байрашның бик нык ачуын чыгарды. Ул тәмам котырынды:

— Син үзеңне кем дип белдең соң әле!? Мәскәүдән кайтып, атаңа акыл өйрәтмәсәң! Менә хәтле атаңны бар дип тә белмәдең, хәлен дә белмәдең, ә хәзер, күтенә килеп терәлгәч, туган ояңа кайтып егылдың. Мин сине чын күңелдән, син теләгәнчә кочагым җәеп каршы алдым! Ә син...

Байраш эчендә булган бар сагышын, үчен бердәнбер якын кешесеннән, яраткан кызыннан ала кебек. Альбина моны яхшы сизсә дә, ана карата дорфа кыланып, аның болай да яралы күңелен рәнҗетәсе килмәде. Кешегә актык сүзне беркайчан да әйтергә ярамый, актык сүз ул кешене каргау белән бер. Ул көнне алар бер-берсенә үпкәләшеп, рәнҗеп, хәтта елашып та беттеләр, тик шуннан соң Байрашның өендә тыныч, матур көннәр башланды. Татарча бер авыз сүз белмәгән оныкларын: «Исәнме, бабай!» — дип эндәшергә өйрәткән, оныкларының башка милләт халыкларын тулыландырудан йөрәге әрнегән Байраш соңрак аларны да үзенчә сөяргә, үзенчә аңларга өйрәнде. Ни әйтсәң дә, аларда бабасының каны, алар бабасының дәвамы бит.

## 12

Әйфи акчаны алды. Пенсионерның кара көнгә дип саклап җыйган акчасы бар иде, зур банкта, яшел тышлы кенәгәдә ята иде — шуннан алып бирде. Акчасы җәл түгел, бирәсе, тиешлесе иде. Ләкин шул әрсез җир бит карт кешенең башына басып, мыскыл итеп алганы өчен бик нык хурланды ул. Моның турында ул һичкемгә бер сүз сөйләмәде, хәтта кызы да белмәде. Бер көнне ул урамда җылы яктан кайткан сыерчыкны — Җәгъфәрнең энесен очратты. Ул ике сетка ипи төяп, тулай торакка кереп бара иде.

— Ну, нәрсә, йорт алдыңмы? — дип сорады Байраш.

— Кая йорт! Ыстенка белән телик алдым! Ник алганыма үкенәм: үдә кысан хәзер, гаилә зур, сыешып булмый. Айфун миңа акчаның иллесен генә бирде...

— Ничек иллесен?

— Менә шулай: илле меңне бирде дә, калганын кесәсенә салды.

— А! — дип гаҗәпсенде язучы. — Кая соң ул хәзер?

— Фатир сатып алды! — дип көлде сыерчык. — Акчасы булган, шул җөзе генә җитмәгән... Хазер миңа нишләргә? Акчасыз калдым...Судка бирсәм инде...

— Кемне?

— Икегезне: аны да... сине дә...

Байраш Барый улы Талмасов август башларында үлде. Үз үлеме белән. Әллә үлгән хәбәрен ишетмәгәннәр, әллә ишетеп тә ышанмаганнар, матәм тантанасында язучы белән хушлашырга килүчеләр аз иде.

*2013*

# «ШАШ, РУХЫМ — ДУЛАСЫН ҖАН!»

## Р.ФӘЙЗУЛЛИННЫҢ 1960-1980 ЕЛЛАР ИҖАТЫ: ФӘЛСӘФИ ҮЗЕНЧӘЛЕГЕ ҺӘМ ПОЭТИКАСЫ

Татар әдәбият белемендә 1960 еллар янарышының шигърияттән башлануы хакында күп язылды. «Әгәр без алтмышынчы елларда татар поэзиясендә яңарыш, яңа бер сыйфат үзгәрешләре башланды дип әйтәбез икән, бу очракта әлеге процессның төп көчләре, ягъни әйдәп баручылары күз алдына килә. Равил Фәйзуллин — әнә шундый шагыйрьләрнең берсе. Шигърияткә язгы ташкындай яңа сулыш өргән шагыйрьләр алтмышынчы елларны әдәбиятка тулы бер буын, көчле бер төркем булып килделәр: Р.Харис, Р.Мингалим, Р.Гатауллин, Г.Рәхим, Рәш.Әхмәтҗанов, бераз соңрак — М.Әгъләмов, Зөлфәт... Талант дәрәҗәсе, сарыф ителгән көч, хезмәт микъдары һәм, ниһаять, табигый сайланыш нәтиҗәсе буларак, Р.Фәйзуллин хаклы рәвештә бу буынның лидеры дип танылды. Тулы бер әдәби күренеш буларак, «Фәйзуллиннар буыны» дигән төшенчә туды»[1], дип язды Гариф Ахунов. Шунысы кызык, әдәбиятның поэзия, проза һәм драматургия кебек төрләре һәрберсе үз юлы буйлап үзгәрде.

Авангард сәнгать теориясе буенча язылган күпсанлы хезмәтләрдә аның төп сыйфатларыннан берсе итеп нинди дә булса традиция белән тыгыз бәйләнештә мәйданга чыгуы ассызыклана. Әйтик, иртәрәк аваз салган рус авангардының символизм традицияләре белән «сөйләшеп», шуларны үзенчәлекле чагылдырып формалашуын билгелиләр. Европа һәм рус әдәбиятыннан соңарып килгән 1960 еллар татар әдәбиятындагы авангард исә XX йөз башында үзе хакында хәбәр иткән, 1930 елларның ахырына кадәр олы бер хәрәкәт төсендә яшәгән татар модернизм әдәбияты белән бәйләнештә күзаллана. Шушы бәйләнеш алымнар һәм темалар күчешен тәэмин итә, татар поэзиясендәге кискен үзгәрешләрнең, читтән китереп кертелгән кебек түгел, «үз» кабул ителүенә китерә. Инде татар шигъриятендәге авангард алымнарны шушы хәрәкәтнең әйдаманы Р.Фәйзуллин иҗаты мисалында күзәтүгә якынрак килик.

«Р.Фәйзуллин шигъриятендәге яңалыкларның иң мөһиме, әлбәттә, аның лирик герое. Лирик геройның шигырьдәге тормышы — тынгысыз җан тормышы, барыннан да элек, көрәшче, гражданин тормышы. (...) Шагыйрьгә яшәү кыйбат түгел, ә «ни өчен яшәү» кыйбат»[2],— дип яза Ф.Зөлкарнәй. Чыннан да, Р.Фәйзуллин тудырган гражданин-лирик геройның романтик табигате, бер яктан, 1960 еллар татар шигърияте өчен яңача тоела. 1930 еллардан башлап социалистик реализм таләпләре поэзиядә лирик герой образының «җиргә якынаюына» сәбәп була: чөнки шагыйрьләрне «күз күргән» тирәлекне сурәтләргә өндәү, илдә төзелә торган тиңдәшсез яңа тормыш турында җырларга чакыру тенденциясе урнаша. Хәтта романтизм активлашкан Бөек Ватан сугышы чоры татар поэзиясендә дә урын һәм вакыт ягыннан чиклелек шушы рамкаларны үтеп чыгарга мөмкинлек бирми. Бары тик 1960 елларда гына милли әдәбиятыбызга көрәшче, тормышка, кешеләргә таләпләр ягыннан максималист романтик герой әйләнеп кайта. Һәм ул Г.Тукай, С.Рәмиев иҗатларында формалашкан, Һ.Такташ шигъриятендә янарыш кичергән

[1] Ахунов Г. Яңарыш // Равил Фәйзуллин: Заман. Иҗат. Шәхес / Төз. һәм кереш сүз авторы З. Мансуров. Казан: Мәгариф, 2002. Б. 13.

[2] Зөлкарнәй Ф. Күзләрем һаман шулмы?..// Равил Фәйзуллин: Заман. Иҗат. Шәхес / Төз. һәм кереш сүз авторы З. Мансуров. Казан: Мәгариф, 2002. Б. 79.

гыйсъянчы лирик герой образын хәтерләтә, хөрлеккә, камиллеккә, чиксезлеккә омтылуы белән сискәндерә. Р.Фәйзуллин лирик герое белән татар шигъриятенә кабат «күкләр инләү» тәмен кайтара. Менә бер мисал:

*Курыкма, биек оч, кошым –*
*Күк чикне беләмени?!*
*Көл, күңел! Дөньяның моңы*
*бер безгә генәмени?!*
*Оч, оч, кошкай, кис җилләрне!*
*Шаш, рухым — дуласын җан!*
*...Егылсак — белгән-күргәннәр*
*яхшыга юрасыннар![3]*

Шигырь кеше күнелендәге омтылышларнын чиксезлеге, рух ныклыгы хакында. Ул XX йөз башы татар әдәбияты өчен традицион кош һәм җан янәшәлегенә корылган, шул чор шигъриятендәге кебек үк, шәхеснең зур омтылышлар белән, зур максатлар куеп яшәргә тиешлеген раслый. Шигырьгә салынган идея кешеләргә зур үзгәрешләр вакытында тормыш дулкынына эләккән йомычкалар кебек караган, «меңнәр» турында сөйләгән заман идеологиясе белән полемикага керә: «күк»/тормыш — чиксез, шәхес югарыга омтылырга, егылудан курыкмаска тиеш дип белдерә. Аерым кеше рухынын күкләрне буйсындырырлык көченә дан җырлый.



Хәсән Туфан университет студентлары янында кунакта. Шигырь турында бәхәс бара. Уртада — Равил Фәйзуллин. Казан, 1964 ел.

Шулай итеп, Р.Фәйзуллин шигъриятенен 1960 еллар татар әдәбиятына алып килгән яналыгы кеше шәхесенә мөнәсәбәт үзгәрүдә иде. Шагыйрь турыдан-туры кеше шәхесенен бөеклеге, анын тормышны үзгәртә алырлык иң олы көч булуы хакындагы фикер белән әдәбиятка керде. Гыйсъянчылык тәгълиматына аваздаш бу караш шәхесне тарих агымындагы меңнәрнең берсе итеп карауны соцреализм концепциясе фонында янача янгырады һәм җепшеклек шартларында күпләрнен күнелендә уянган омтылышларга аваздаш булды. Бер яктан, шагыйрь гади кешегә мәдхия җырлау юлын сайлады. «Гадиләргә гимн» (1963) тибындагы шигырьләр гади кешенең иҗат герое — тормыш герое булырга тиешлеге фәлсәфәсен белдереп килде. Икенче яктан, шагыйрь кешене үзенең бөек рухына тәнгәл килерлек биеклекләргә чакыра башлады. «Җанынның ваклыгын...» (1967) шигыре — Р.Фәйзуллин иҗатынын «визит карточкасы» — шушы фәлсәфәне дәвам итә, үстерә, «вөҗданын саклаган» шәхесләрнең тарихтагы ролен билгели:

*Җаныңның ваклыгын*
*сылтама заманга.*
*Куркырга, өркергә*
*җай бар ул һаман да.*
*Ә бит бар кешеләр –*
*Шәхесен ватмаган,*
*Вөҗданын саклаган[4].*

[3] Фәйзуллин Р. Кошлар юлы: шигырьләр. Казан: Татар. кит.нәшр., 1981. Б.16.
[4] Шунда ук. Б.95.

Лирик герой, укучысына, халыкка мөрәҗәгать итеп, кыю, нык һәм вөҗданлы булырга, хаклык өчен көрәшергә чакыра. Шигырь шәхес культы фаҗигасендә гаеплеләрнең 1960 елларда заманга сылтап акланырга омтылуына җавап булып яңгырый. Кешенең теләсә нинди чорда, теләсә нинди шартларда хөр һәм бөек булып калу фәлсәфәсе горур яңгыраш ала. Буыннар дәвамчанлыгын, ил-халыкның яшәү-яшәмәвен шушы сыйфат — кешелекне саклау тәэмин итә дигән фикер әйтелә.

Кеше — мәрмәр, теләсә нинди авырлыкны җинә, киртәне вата алырлык көч дияче шигырьләр шагыйрьнең «Мәрмәр» (1969) китабында туплап тәкъдим ителә. «...Кешелек язына йөз төбәп» (1968), «...Азмы кирәк яшәү өчен» (1967), «Үзем кадәр» (1968) кебек шигырьләрдә кешенең кешелеклелек сыйфатларын зурлау үзәккә куела, кеше рухын камилләштерү хөрлеккә ирешү өчен бердәнбер юл кебек карала. Һәм бу мотив авангард әдәбият сыйфатына әверелә.

Әгәр рус әдәбиятында авангард күренешләр чикләүләрдән котылу юлы эзләү буларак каралып, шагыйрьләр иҗатында кешенең, идеологик тар кысалардан азатлыкка омтылуы, шуңа бәйле чынбарлыктан «качуы» доминанта төсендә аерып чыгарылса, татар шигъриятендә исә кешенең кешелеклелеген саклау, көчәйтү, гыйсъянчылык поэзиясе традицияләрендә, чикләүләрдән котылу мөмкинлеге кебек тәкъдим ителә. Без моны Р.Фәйзуллин, аннары мәйданга килгән «Фәйзуллин мәктәбе» шагыйрьләре иҗатында ачык күрәбез.

Р.Фәйзуллин шигъриятендә әһәмиятле тагын бер яңалык заманга бәя бирүдә иде дисәк, ялгышмабыз. Чорны, идеологияне бәяләүдә шагыйрь «яшерен эчтәлек» алымына мөрәҗәгать итә. Бу алым татар шигърияте өчен шулай ук традицион: суфичылык поэзиясе шушы алымга корылган да. 1917 елдан соң аерым шагыйрьләр (бигрәк тә Г.Кутуй, Һ.Такташ, соңрак Х.Туфан поэзиясе) шулай ук шигырьдә икенче эчтәлек тудыру алымын кулланалар. Моның өчен янәшәлек тудырырлык образ сайлап алына, шул образ беренче эчтәлеккә янәшә тагын бер, икенче, яшерен эчтәлек барлыгын хәбәр итә. Р.Фәйзуллинның беренче шигырьләрендә үк шушы алым еш кулланыла башлый. Әкренләп шагыйрь «яшерен эчтәлекнең» беренче планга чыгуын тәэмин итә: «эзоп теле» дип аталган алым дәрәҗәсенә үстерә.

«Вакыт» (1958) шигырендә янәшәлек «вакыт» сүзенең идеологик тотрыклы «башкалар бәхете өчен сарыф ителгән» сыйфаты ярдәмендә хасил була. Шулай вакытның икенче — «чор» рәвешендәге — мәгънәсе калка. «Яшьнәгән» чорның — яшьлекнең, илне яңа нигезләргә кору вакытының һ.б. — төрлечә бәяләнә торган мәгънәләре ачыла. Йә булмаса «Капка» (1958) шигырендә капка образының «яңа тормышка инкыйлаб ачкан юл» мәгънәсе пәйда була һәм «Белми сабый: бер заманны, терәп монда, кешеләрне атканнарны...»[5] юллары әлеге яшерелгән эчтәлекне бәяли. Яңа тормышка ачылган капканың кан кою чиге булып торуы инкыйлаби үзгәрешләрнең тискәре дулкында бәяләнүенә китерә.

Алга таба идеологик эчтәлек алып килә торган образлар шигырьдән шигырьгә төгәлләшә бара, тиз таныла башлый, автор ассоциатив тәэсирләр уятырлык детальләргә мөрәҗәгать итә. Әйтик, «Яр буенда» (1963) шигырендә иске көймә белән «җилкән киереп ерак ярга барырына»[6] ышанган карт сурәте инкыйлаб идеясенә ишарә ясый. Бер үк вакытта көймә-ил образы янәшәсендәге «җилкән киерү» детале милли әдәбияттагы кораб образы белән бәйләнеш урнаштыра. «Ят ил карап» давылга кергән Дәрдемәнд «корабыннан» аермалы буларак, «иске көймә» суга төшә алмый, ул яр буенда гомер уздыруга дучар ителгән!

Шагыйрь иҗатындагы шушы тенденциягә Н.Гамбәр дә игътибар итә. «Бу нәүбәттән «Метаморфоза» (1963) шигыре аеруча характерлы. Шагыйрь биредә бер деталь, бер кинаяле образ аша тулы бер халык язмышын, ул кичергән трагизмны сурәтли алган. Сарайда аунап яткан иске, тутыккан колун балта образы — ул («түтәсе ингән — күп сугудан, йөзе тонган — тутыгудан») кулда көч-власть бар вакытта ярты дөньяны тетрәтеп торган («бар иде колунның ялтыраган чагы, — йөзәр яшьлек имәннәрнең калтыраган чагы»), хәзер инде картайгач, хакыйкать

[5] Фәйзуллин Р. Кошлар юлы: шигырьләр. Казан: Татар. кит.нәшр., 1981. Б.20.
[6] Фәйзуллин Р. Ажаган. Казан: Тат.кит.нәшр., 1966. Б.62.

каршында җавап бирер вакыт җиткәч, үлеме белән тартышып ятучы теге еллар (һәм бүгенге көннәр!) героеның — димәк, тулы бер эпоханың — фаҗигале күләгәсе»[7].

Ләкин шагыйрь идеологемалар белән уйнау дәрәҗәсендә калмый. Аерым бер шигырьләрдә идеологик бәя күпсанлы детальләрне янәшә куюу аша бирелә, шагыйрь чын мәгънәсендә «эзоп теле» алымын гамәлгә кертә. Соңрак бу алым татар шигъриятендә күп кенә шагыйрьләр иҗатында кулланыла башлый, бигрәк тә Гамил Афзал шигъриятендә активлаша.

Мисал өчен Р.Фәйзуллинның бу яктан иң кызыклы «Җилфердәүче керләр җыры»н алырга була. Бу озын шигырьдә идеологик танылa торган образ-детальләр юк. Шигырьнең башында, уртасында, ахырында бераз гына үзгәреп кабатлана торган тезмәләр игътибарны тоткарлый:

*Без сансыз күп төрле,*
*ә җырыбыз — бер:*
*Кояш турында гел,*
*Җил турында гел.*
*...Безнең җыр — мәңгелек,*
*безнең һаман бер:*
*Кояш турында гел,*
*Җил турында гел.*
*...Без авыр булсак та,*
*яшькә мул булсак та,*
*елый белмибез,–*
*бары җырлыйбыз без.*
*Ә җыр һаман бер:*
*Кояш турында гел,*
*Җил турында гел*[8].

Әлеге кабатлау керләр/кешеләр янәшәлеге тудыра, әлеге янәшәлек идеологик кысаларда кешеләрнең «яшькә мул» вакытта да «кояш турында, җил турында» җырлау мәҗбүриятен эчтәлеккә әйләндерә, шигырьдәге һәр деталь шушы тормыш сурәтен төгәлләштерә башлый. «Кыштырдап куйсак та, бары җырлыйбыз», «пуля тишә безне, сода кисә безне...», «кешеләр мәңгегә киткәндә бездән, яшь агызып түгел, — кул болгап калабыз, җырлап калабыз» кебек тезмәләр инде совет чоры хакында калыплашкан күзаллауларга ишарә бирә. «Юылган кешеләр», «яшькә тулган кешеләр»нең ирексез көнитешен бәяләүче әлеге эчтәлек табылуга, ул яшеренеп кала алмый: беренче урынга чыга.

Шагыйрьнең беренче китабындагы «Яр карлыгачы» (1963), «Көмәч пешерүчеләр җыры», «Аҗаган» (1963) кебек шигырьләр дә шулай укыла. Алга таба шагыйрь «эзоп теле» алымына еш мөрәҗәгать итә башлый. Шагыйрьнең шушы юнәлештәге иң кызыклы шигырьләреннән берсе — «Ах, тау юклыклар!...» (1968). Әлеге шигырьдә кабатлаулар ике мәгънәви үзәк аерылып чыгарлык итеп уйланылган. Беренчесе шигырьне башлый һәм йомгаклап куя:

*Ах, тау юклыклар!*
*Кыя юклыклар!*
*Үзән, калкулыклар –*
*күз текәмә кая...*[9].

Әлеге кабатлау вазгыятькә бәя бирә, лирик герой күңелендәге үкенеч хисе дә тормыштагы чикләүләр китереп чыгарган хис булып аңлашыла. «Мескен җилләр»,

[7] Гамбәр Н. Шигъри дөньяга сәяхәт, яки 3 томлык фонында иҗади портретка штрихлар// Равил Фәйзуллин: Заман. Иҗат. Шәхес / Төз. һәм кереш сүз авторы З. Мансуров. Казан: Мәгариф, 2002. Б.41.
[8] Фәйзуллин Р. Аҗаган. Казан: Тат.кит.нәшр., 1966. Б.33-34.
[9] Фәйзуллин Р. Кошлар юлы: шигырьләр. Казан: Татар. Кит.нәшр., 1981. Б.94.

«карсак калкулык» кебек төгәлләштерүләр тормыш картинасын тулыландыру өчен хезмәт итә. Беренче карашка, икенче кабатлау беренчесен дәвам итә кебек:

*Бөркетләр түмгәктә*
*канатларын кага...*
*Тырнаклары чумган...*
*Ә күзләре яна!*
*(...) Бөркетләр түмгәктә*
*канатларын җилпи.*
*Басар кыя җитми,*
*менәр күге җитми*[10].

Ләкин ачыклаучы детальләр («күзләре яна», «таңнарын бөркетләр, һай, ничек очына»), бер яктан, шушы шартларга куелган кешеләрнең зур омтылышлар белән яшәвен искәртә. Шул омтылышларны тормышка ашырырлык шартлар булмау үкенеч хисен фаҗигагә әйләндерә. Шигырь чикләүләр шартларында яшәгән буыннар фаҗигасе булып аңлашыла башлый.

«Эзоп теле» алымын шагыйрь гражданлык лирикасында гына түгел, бәлки күңел лирикасында да гаять отышлы куллана. Бигрәк тә «Монологлар һәм диалоглар» җыентыгындагы күп кенә шигырьләр шушы юнәлештә иҗат ителгән. «Алма» (1966), «Яран гөл» (1966) кебек шигырьләрдә кеше фаҗигасе турында сөйләүче автор аллегорик янәшәлек аша әлеге фаҗигане тормыш закончалыгы, мәҗбүрияте кебек кабул итүгә алып килә. Мондый юнәлештә язылган аерым шигырьләрдә фаҗигалелекне капма-каршы ике караш бәрелеше, аларның тәңгәл килмәве китереп чыгара: үзенең җиргә сикерүенә «алма»ның «мактанучанрак» һәм ул эндәшә торган «кешеләр»нең «шикчел» мөнәсәбәте укучыны уйландыра торган сәбәпкә әйләнә. «Р.Фәйзуллин бер төр шигырьләрендә еш кына хисләр фикерне түгел, ә бәлки фикер хисләрне тудыра һәм бу фикер аның җанын шулкадәрле биләп ала ки, алар, ахыр чиктә, аңны яктыртып җибәрерлек хискә әвереләләр»[11], дип яза Г.Ахунов. Без тикшерә торган шигырьдә хисне алма яки кеше язмышындагы бер күренеш яки шуңа кагылышлы фикер тудырмый, бәлки хис тормыш закончалыгына бәйле хасил була. Әлеге сыйфат шагыйрь иҗатындагы поэтик үсеш-үзгәрешкә дә тәэсир итә.

Р.Фәйзуллин иҗатындагы төп алым — янәшәлекләрне үзәккә кую шагыйрьне модернизм, аерым алганда символизм һәм сюрреализм традицияләренә алып килә. Шигырьне тирән эчтәлекле, күпмәгънәле ясый торган бу мөмкинлекләр татар поэзиясендә шулай ук катлаулы сурәт тудыруның милли традицияләренә кире кайту кебек кабул ителә. «Булчы, зинһар, зәңгәре син...» (1966), «Үсә алган һәрбер нәрсә яна ала...» (1968), «Син — гүя бер кучмә шәһәр» (1966), «Гомер агачы» (1967), «Кипкән инеш» (1966) һ.б. шушы чор шигырьләрендә генә түгел, бу тенденция шагыйрь иҗатында бүгенге көнгә кадәр килә. (Шунысы кызык, чуаш шагыйре Г. Айги иҗатында да символизм һәм сюрреализм белән «сөйләшү» урын ала, тәнкыйтьчеләр фикеренчә, бу сөйләшү аның әсәрләренә милли төсмер бирә. Р.Фәйзуллин иҗатында да шулай бу). Мәсәлән, шагыйрьнең бу яктан кызыклы «...Күкне индереп...» (1966) шигыре 4 строфадан гыйбарәт. Һәр строфада берәр сюрреалистик рәсем тудырыла:

*Күкне иңдереп,*
*Башымны идең.*
*Мин бит — тургай!*

*Төннәремне кудың.*
*Яктыртучы бөҗәк мин!*

[10] Фәйзуллин Р. Кошлар юлы: шигырьләр. Казан: Татар. Кит.нәшр., 1981. Б.94.
[11] Ахунов Г. Янарыш // Равил Фәйзуллин: Заман. Иҗат. Шәхес / Төз. һәм кереш сүз авторы З. Мансуров. Казан: Мәгариф, 2002. Б. 15.

*Җырларымны будың.*
*Мин бит — аваз!*

*Миннән барысын алдың.*

*Мародерның күзе төшмәгән*
*үлек кулындагы сәгать кебек,*
*ялгыз калдым...*[12]

Мәхәббәткә яки аның сыны — яраткан кешесенә эндәшүче лирик герой бу хисненә үз иреген, үз омтылышларын чикләвен сөйли: тургайга — күк, яктыртучы бөҗәккә — төн, авазга — җыр кирәк булган кебек, гашыйк кешегә җавап хисе кирәк! Әлеге рәсемнәрнең кабатлануы сагыш, үкенеч хисен көчәйтү чарасына әверелә. Ләкин бу хис тургай, бөҗәк, аваз образларының символик мәгънә алуы аша гомумиләшә. Аерым бер кеше тормышындагы очраклы туган хис булудан туктап, тормыш закончалыгы тудырган нәтиҗә төсен ала.

Нәкъ менә сюрреализм һәм символизм үзенчәлекләренә мөрәҗәгать итү шагыйрь иҗатында кыска шигырьләрнең поэтикасын, аларның милли тоелуын тәэмин итә. Чөнки мондый диалог милли әдәбиятка үз юлындагы элегрәк узган этаплар белән тоташырга, аларның алымнары, образлылыгы белән ассоциатив бәйләнешләр урнаштырырга мөмкинлек тудыра. Р.Фәйзуллин шигырьләрендә дә сюрреалистик-хыялый сурәт, еш кына символ белән янәшә килеп, тормышка гомумиләштереп бәя бирү кебек янгырый. Менә «Чынлык» шигыре:

*Чия чәчәкләре пышылдашты иртән:*
*«Бизәк булсаң иде күккә!»*
*Төне буе кара туфракка*
*нәни ак йолдызлар яуды*[13].

Шигырьдәге сурәт вакыт ягыннан ике өлешкә аерыла: иртән күккә омтылу, төнлә җиргә коелу. Чия чәчәкләре образы аллегорик табигатьле: кеше гомеренә дә, яшәештәге һәр нәрсәнең туудан-үлемгә хәрәкәт итүенә дә ишарә ясый. Ләкин әлеге образдан тыш, «бизәк» һәм «ак йолдызлар» детальләре дә символик табигатьле. Алар кешенең матур омтылышлар белән яшәвен дә, матур омтылышларның аклык булып хәтердә саклануын да ассызыклый. Шул рәвешле, образлардагы символик табигать эчтәлеккә кабат әйләнеп кайтырга, мәгънәләр эзләргә мәҗбүр итә. Тагын бер шигырь — «Үҗәтлек»:

*Кырмыска саламын сөйрәп*
*түмгәгенең очына менде.*
*Кояшка тәки якынайды!*[14]

Өч кенә тезмәле шигырь аллегорик образлылык, сюрреалистик сурәт ярдәмендә өч мөстәкыйль фикерне калкытып куя. Беренчедән, ул һәркемнең үз максатына ирешү юлы барлыкны ассызыклый. Икенчедән, кешенең зур омтылышлар (кояшка якынаю!) белән тормышка аяк басуын искәртә. Өченчедән, шәхеснең һәр җиңүне кояшка якынаю буларак караучы көчле рухына бәя бирә.

Аерым бер очракларда шагыйрь бер нәтиҗәне үзәккә ала, аны афоризм дәрәҗәсендә гомумиләштерә («Аңладым да...», «Җинел түгел» һ.б. шигырьләр). Бу бигрәк тә берьюллыкларда күзәтелә. Икеюллыклар арасында сюрреалистик сурәт ярдәмендә фәлсәфи тирәнәйтү матур тәэсир калдыра. Әйтик, «Тарих» шигыре:

*Кыны тулы кан.*
*Тышында чәчәк сурәте*[15].

[12] Фәйзуллин Р. Кошлар юлы: шигырьләр. Казан: Татар. Кит.нәшр., 1981. Б.158.
[13] Шунда ук. Б.222.
[14] Шунда ук. Б.223.
[15] Шунда ук. Б. 283.

Әлеге сурәт тарихның символына әверелә. Ләкин кыска шигырьләрдә ешрак ниндидер күренешне тергезү аша фәлсәфи нәтиҗә ясау актив кулланыла. Әйтик:

*Төркем-төркем кошлар күктә!*

*Шуларның берәрсе*
*Минем телдә сөйләшәдер күк...* [16] —

тезмәләрендә һәр кешенең үз телен газиз санавы турындагы фикер алга куела. Яки «Кайту» шигырендә:

*Инеш яңа юл алган.*
*Иске эздә миңа таныш*
*бер таш калган...* [17] —

дигәндә тормыш үзгәрсә дә, хәтернең үткәннәрне саклавына игътибар ителә.

Шагыйрьнең кыска шигырьләре тупланган җыентыгы[18] басылып чыгуга, андагы форма эзләнүләренә карата әдәби тәнкыйтьтә көчле бәхәсләр булып уза. «Р.Фәйзуллин һәм гомумән ул буын шагыйрьләр шигърияттәге эзләнүләре үзенчәлекле булу белән, яңалыкларны үз элгәргеләреннән үзгәрәк эзләүләре белән аерылып торалар. Алар иҗатында укучыларны да, тәнкыйтьчеләрнең дә игътибарын иң беренче җәлеп иткән як шушы булды. Яңача шигырь формасы, ритмикасы, традицион шигырьдәгегә охшамаган яначa фикерләү башта кемнәргәдер ошамады, традицияләрне җимерү шикелле тоелды. «Кунакны киеменә карап каршы алалар» дигән кебек булды бу. Шуннан соң мәкальнең икенче яртысы да хак икәнлеге ачыкланды. Беренче тәэсирләр шаукымы үтүгә шуны аңладылар: яшьләр үзләре белән яңа «акыл» да, — яңа эчтәлек тә алып килгәннәр ләбаса»[19]. Бер яктан, кыска шигырь, иркен шигырь, ак шигырь, интонацион шигырь традицияләрен тергезү шунда ук милли шигърияттә урнашып кала, классик шигырь белән янәшә бик актив кулланыла башлый, үз укучын таба. Икенче яктан, шагыйрьнең кыска шигырьләрендә чит поэзия, аерым алганда, урта гасырлар япон поэзиясендә формалашкан жанрлар тәэсире булу хакында фикерләр яңгырый.

Европа мәдәниятендә япон шигърияте белән кызыксыну XIX–XX гасырлар чигендә барлыкка килә. Күп кенә милли әдәбиятларда япон поэзиясе жанрлары тәэсирендә форма үзгәрешләре хасил була. Шул ук вакытта япон поэзиясендәге хокку һәм танканың шигъри үлчәмнәрен саклау (хоккуда — 5-7-5; танкада — 5-7-5-7-7) милли телләрнең лексик-фонетик үзенчәлекләре белән һәрвакытта да ярашып бетми. Шуңа аерым бер әдәбиятларда япон шигъриятенә охшатып жанрлар тудыру да мәгълүм (әйтик, америка әдәбиятында синквейн, Россия алманнарындагы дрезейлер кебек).

Форма ягыннан иркен шигырьнең төрле үлчәмнәрен татар шигъриятендә «сынап караган» Р.Фәйзуллин иҗатында классик хокку яки танкадагы кебек аерым бер табигать яки тормыш күренешен күзәтү-тергезү аша сагышлы хисләр бәйләме тудырган үрнәкләр бар. Япон жанрларындагы кебек үк, татар шагыйре рифма һәм ритм төрлелегенә корылган 3 һәм 5 тезмәле строфалар төзи, «ел фасылы детале»нә мөрәҗәгать итә, үткән-хәзерге яки үткән-киләчәк заманнар тудыра. Ләкин аларның үлчәме классик япон жанрлары үлчәменнән аерыла, поэтик алымнар ягыннан да шигырьләр үзенчәлекле килеп чыга: классик япон шигърияте өчен мәҗбүри сакланырга тиешле хисси төсмерләр (моно-но-аварэ, саби, ваби, сибуми, каруми) иркен урнаша, шуңа аларның көчеше-үзгәреше

[16] Фәйзуллин Р. Кошлар юлы: шигырьләр. Казан: Татар. Кит.нәшр., 1981. Б.290.
[17] Шунда ук, Б.292.
[18] Фәйзуллин Р. Кыска шигырьләр. Казан: Татар.кит.нәшр., 1978.
[19] Зөлкарнәй Ф. Күзләрем һаман шулмы?..// Равил Фәйзуллин: Заман. Иҗат. Шәхес / Төз. һәм кереш сүз авторы З. Мансуров. Казан: Мәгариф, 2002. Б. 77

«төзелеп бетмәгән күпер» концепциясеннән читкә китә. Алар урынына, еш кына, сурәтләүче детальләр файдаланыла, хәтта беренче затка мөрәҗәгать итеп, кичереш төсмерләрен шулай ачыклау актив. Шуна күрә шагыйрь иҗатындагы, гомумән милли әдәбиятыбыздагы бу үрнәкләрне шәркый жанрларга охшатып стильләштерү буларак бәяләү дөрес булыр. Р.Фәйзуллин аларнын жанрын «кыска шигырьләр» дип атый, шушы исем милли үзенчәлекләрнең өстенлек алуына да ишарә итә. Берничә мисалга мөрәҗәгать итик. «Көзге яңгыр» шигыре 7-8-8 үлчәмендә язылган:

*Торналар китеп бара.*

*Кош канатлары орынгач,*
*болытларның күңеле тулды*[20].

Эчтәлек ягыннан, шигырь чынлап та хоккунын кайбер сыйфатларын тергезә. Аз гына сүзләр ярдәмендә тирән эчтәлекне бирү, ассоциативлык шундыйлардан. Беренче тезмәдә табигать күренеше хәбәр ителә; аннары шул күренеш тудырган монсу халәт табигать һәм кеше янәшәлеге ярдәмендә белдерелә. Тормышны ашыкмыйча гына күзәтүче, гаҗәпләнмичә генә нәтиҗә ясаучы лирик геройның күңелендәге монсулык гомернең агышы белән бәйләнгән. Шигырьне укыгач хасил булган сагыш хисе кабат текстка әйләнеп кайтырга мәҗбүр итә. Болытларнын гына түгел, лирик геройның да «күңеле тулы» булу хакындагы күзаллау беренче тезмәнең яшерен мәгънәсенә ишарә ясый: торналар китеп бару — җәй узу, кеше гомеренең бер елы узу, яшьлек узу икән. «Таулар иленда» шигыре 6-6-9 үлчәмендә:

*Яралы кыялар...*
*Яшеннәр оясы...*
*Бөркетләр очыра баласын*[21]*!*

Монда да беренче карашка гади бер табигать күренеше бәян ителә. Ләкин үлчәмнең монсу интонация тудыруы, беренче ике тезмәдәге куркыныч дип бәяләнерлек урын рәсеме янәшәсендә, лирик герой күңелендәге борчу, хәвефләнүгә ишарә ясый. Бөркетләрнең «яралы кыялар» арасында, «яшеннәр оясы»нда бала очыруы шул хәвефләнүнең сәбәбе булып аңлашыла, бөркет/кеше янәшәлеге уздырырга ярдәм итә.

Аерым бер очракларда, япон шигъриятендәге шикелле үк, лирик-монсу интонациянең сәбәбе дә ачыкланмый. Чөнки ул мөһим дә түгел. Менә «Этюд» шигыре, ул Р.Фәйзуллин яратып һәм еш куллана торган 8-8-4 үлчәмендә язылган:

*Су төбендә көмеш тәңкә*
*камыш аша якты сузган*
*ай йөзенә*[22].

Бу очракта шагыйрь фәлсәфи нәтиҗәне алга куя: һәр асылнын — күләгәсе яки дәвамы белән бәйләнеше тормыш кануны кебек белдерелә. Айның чагылышы (көмеш тәнкә) Айга «кулын сузган» дигән сурәт укучы күңелендә төрле ассоциация уятырга мөмкин: баланың — ата-ана назына, кешенең — милли тамырларга, укучының — остазга мохтаҗлыгыма ул, йә булмаса иҗатның чынбарлык белән мөнәсәбәтләреме, боларын һәркем үзе уйлап бетерә. Ләкин әлеге бәйләнешләрнең барлыгы шәхси хатирәләрне янарта, узганны сагыну дигән монсу хисне кузгата. Шундый ук төзелешне «Йорт нигезенә сукбай сугалар», «Кышкы бакчада» һ.б. өчьюллыкларда очратабыз.

[20] Фәйзуллин Р. Җил — вакыт ул... Казан: Мәгариф, 1996. Б.43.
[21] Шунда ук, Б.50.
[22] Шунда ук, Б.54.

Шагыйрьнең бишьюллыклары арасында танкага охшатып стильләштерү күзәтелсә дә, классик япон үлчәме кабатланмый. Әмма фәлсәфәнең үзенчәлекле, очраклы табигать рәсемнәре ярдәмендә тәкъдим ителеше, сүз белән уйнаулар, аерым сүзләрнең ассоциатив мәгънәләре ярдәмендә эчтәлекне гаять тирәнәйтү шәркый шигъриятькә ишарә ясый. Менә «Март ахыры» шигыре (4-6-9-10-9):

*Яна Кояш!*
*Соңлап яуган карлар*
*эри-эри ялмый күз явын!*

*Очкан кошлар күләгәсе буйлап*
*нәни гөрләвекләр кузгалды...*[23]

Шигырь яз килү күренешен сурәтли. Беренче карашка, эчтәлек табигатьтәге үзгәрешләр белән чикләнә кебек. Ләкин «гөрләвекләрне очкан кошлар күләгәсе кузгату» үзгә тәэсирләр уята. «Гөрләвекләр» — карны алып китүчеләр, яз хәбәрчеләре. Аларны күктә очучыларның уятуы хакындагы фикер төрле эчтәлек белән тулыландырылырга мөмкин. Шул исәптән, илдәге-тормыштагы кискен үзгәрешләрне хыялый-романтик кешеләр уйлап, «җир кешеләре» тормышка ашыру хакындагы эчтәлек тә укыла ала.

Өчьюллыкларда һәм бишьюллыкларда табылган монсу-лирик интонацияне япон поэзиясенә хас образлар белән янәшәлектә шагыйрьнең күләмлерәк шигырьләрендә, алтыюллыклар, җидеюллыклар, сигезьюллыкларында да куллана. Әйтик, «Тау башында синең тәрәзән» шигыре шундыйлардан. Сөйгән кешесе белән бергә була алмау сагышын читләтеп, табигать образлары ярдәмендә белдерүче лирик герой аның сәбәбенә кагылмый. Монысы мөһим дә түгел. Шигырьдә бергә була алмый торып та, ярату хисен саклау әһәмиятле:

*Синең сынны миннән яшереп, –*
*җәен өер кошлар оча;*
*көзен яфраклар аралый, –*
*сары-кызгылт челтәр ясап;*
*яңгыр каплап, толымын төшерә;*
*кышын, котырып, буран томалый...*
*Язын –*
*дөнья аяз чагында да,*
*күзләрдәге сагышлы дым*
*томанлата*
*синең*
*тәрәзәңне...*[24]

Ел фасылларының дүртесе дә кабатлану, әдәбиятта сөю вакыты булган язның да бергә була алу өметен бирмәве моның мәҗбүрият икәнлегенә ишарә ясый. Шушы драматик хис укучы күңелендә дә сагыш уята.

Аерым бер очракларда шагыйрь татар шигърияте яки татар халык җыры белән бәйле ассоциацияләр тудыру алымына мөрәҗәгать итә. Әйтик, «...Синең белән үткән гомер, гүя» шигырендә — Дәрдемәнднең «Без», «Синең өчен җан атмасам...» шигырендә — халык җырына охшатып стильләштерү күзәтелә. Аерым бер очракларда халык җырыннан тезмәләр шигырьгә кереп урнаша:

*Җырлады читләргә китүче*
*яшь, таза, сөлектәй бер егет:*
*«Безнең җир — сыктар-елар җир!*
*Безнең җир — шүрәле каргар җир!...»*

[23] Фәйзуллин Р. Җил — вакыт ул... Казан: Мәгариф, 1996. Б.153.
[24] Фәйзуллин Р. Мәңгелек мизгел: шигырьләр. Казан: Татар. кит.нәшр., 2012. Б.262.

*Жырлады читләрдән кайтучы*
*ак йөзле, чал чәчле бер бабай:*
*«Безнең җир — уйнар-көләр җир!*
*Безнең җир — сандугач сайрар җир!»*[25]

Халык жырыннан өзекләр фикерне үзенә туплаган үзәкләргә әверелә, бер үк вакытта шигырьгә халык жыры интонациясен алып килә. Мондый алымнар шагыйрьнең кыска шигырьләрдә милли нигезне халык жырлары үлчәмендә, халык моңында тапканлыгы турында сөйли.

1970 еллар урталарыннан Р.Фәйзуллин шигъриятендә яна үзгәрешләр башлана. Шагыйрь, башлангыч чор ижатын йомгаклап, яна этапка атлый. Шигырьләрдә, авангард алымнар сакланган хәлдә, психологизмның үзгә формасына мөрәҗәгать итү күзәтелә. Лирик герой белән автор образын тәнгәлләштерү монын бер чарасына әверелә. Мисал өчен «...Туфрагында сөрелгән зиратларның...» (1978) шигырен алыйк:

*Туфрагында сөрелгән зиратларның,*
*көлләрендә яндырылган китапларның,*
*«аһ»ларында чыга алмаган сүз-уйларның –*
*Һәммәсендә без бар.*
*Җиңүчеме, җиңелүчеме –*
*барыбер...*[26]

Шигырь Р.Фәйзуллин өчен традицион кеше фәлсәфәсен тергезә, кешенең һәрнәрсә өчен жаваплы булуын билгели. «Без бар» дигән гыйбарә әлеге халәтне авторга бәйли, хәзер инде лирик герой үзенең күпләрдән берәү булуына ишарә ясый. 1960 еллардагы рухи нык булырга, намуслы яшәргә һ.б. чакырган кешеләрдән (потенциаль укучыдан) үзен аерып куйган көрәшче-романтик лирик геройны 1970 еллар урытасыннан лирик-сызланучан (экзистенциалист), халыкның, гомумән кешеләрнең бер вәкиле буларак чыгыш ясаучы лирик герой алыштыра бара. (Дөрес, шагыйрьнең беренче чор ижатында төркем (милләт, халык, кешеләр) исеменнән сөйләүче лирик герой очрап тора, ләкин ул барыбер башкаларны үз артыннан иярткргә, аларга яна караш, рух бирергә, юл күрсәтергә омтыла. Әйтик, «Без» (1967) шигырендә милләтнең бер вәкиле буларак чыгыш ясаган лирик герой үз кавемен катырак, биегрәк, «мәңгелек» булырга чакыра.) Экзистенциаль табигатьле фәлсәфә еш кына лирик геройның үзе куйган сорауларга жавап эзләве, шул жавапны формалаштыруы төсен ала. Менә «Биеклектә» (1976) шигыре:

*Кыя — текә. Җилләр — йолка.*
*Кузгала таш... Кая басыйм?*

*Колакта өн: менгәнсеңме –*
*«Егылам!»... дип,*
*ярдәм сорап кычкырма син!*[27]

Беренче тезмәдәге шәхсиләштерү («кая басыйм?») лирик герой белән автор образын тәнгәлләштерүгә китерә. Һәр кеше үз биеклеген үзе яуларга, шул биеклектә калу өчен үзе көч салырга тиеш дигән автор әлеге фәлсәфәне, шәхси мәйданга күчереп, психологик яктан тирәнәйтүгә ирешә. Еш кына лирик герой үзенең төп максаты итеп милләт-халык җанын аңлауны билгели:

*Ни исәп, ни гамь бар бу ярда?*
*Ни сагыш, ни моң-зар бу талда?*
*Ни хикмәт, ни акыл бу ташта?*
*Ни төен, ни сер бар бу тауда?*

[25] Фәйзуллин Р. Мәңгелек мизгел: шигырьләр. Казан: Татар. кит.нәшр., 2012. Б.78.
[26] Фәйзуллин Р. Кошлар юлы: шигырьләр. Казан: Татар. кит.нәшр., 1981. Б.319.
[27] Фәйзуллин Р. Җил — вакыт ул... Казан: Мәгариф, 1996. Б.153.

*Ни көй бар, ни җыр бар инештә?*
*Ни бөек мәшһүрләр бу төштә?*
*Ни мәзәк, ни җорлык бу якта?*
*Ни үлән, ни һава, ни дым туфракта?*

*Әгәр дә шуларны белмәсәм,*
*ничек мин*
*үткәнен, бүгенен*
*аңлыйм бу Илнең?*[28]

Халык рухын тоярлык сизгер, халык җырын бәяләрлек зәвыкле, туган җир гамен үз күңеле аша уздырырлык булу кебек сыйфатлар иҗатчы өчен мөһим дип күрсәтелә башлый. Шигырьләрдә милли-мифологик образлар матур янгыраш таба. Әйтик, «Кайтсын иде!» шигырендә «тырнакка күгәрчен сөте төшү» белән бәйле ышану уйнатыла. «Яшь чак» дигән кыска шигырьдә «елан мөгезен күрү»гә нисбәтле ышану файдаланыла. Мондый образ-детальләр шагыйрьнең форма ягыннан халык иҗатына якынаю юлларын эзләве хакында сөйли.

Гомумән, шигырьләрдә иҗат темасы тагын да активлаша. Ләкин иҗатчы — күккә омтылучы, көрәшче булудан бигрәк, самими, эчкерсез кеше булып калырга тиешлек ассызыклана башлый:

*Диңгезгә аккан чишмә суыдай*
*буталды яшьләрем*
*Гомер дәрьясында...*
*Энҗе ташлар булып бер чыгар!*
*Күрерсез!*[29]

Яки «Илһам» (1977) шигыре:

*Күңелнең салават күпере!*
*Әй, шагыйрь,*
*саклап йөртә аласыңмы*
*тузанлы юллар, давыллы чатлар,*
*базарлар аша үткәндә*
*җуймыйча бер генә төсен дә!..*[30]

Бу чор лирик герое ялгызлыкны, балачактагы чисталыкны, матурлыкка сокланган вакытны сагына («Күзен йом да...», 1976). Ул ашкыну-омтылышларның бушка булуына, вакытның аяусыз хәрәкәтенә сызлана («Эчке диалог», 1976). Тормыш фәлсәфәсе туудан үлемгә кадәр юл, шуны аңлау мәҗбүрияте («...Жил ул нәрсә?», 1978) һәм шул юлда кеше булып кала алу хакында сөйли («Юллар», 1977), яшьлектәге олы омтылышларны «күкләр күкрәү» кебек бәяли («Хәтерләтү», 1978). Шул рәвешле Р.Фәйзуллинның 1970-1980 еллар шигърияте͏ндә экзистенциаль башлангыч көчәя бара һәм бу сыйфат татар әдәбиятындагы XX йөз башы әдәбияты белән сөйләшеп мәйданга чыккан авангард алымнарның берсе буларак бәяләнә ала. Әйтик, «Эчке диалог» (1976) шигыре кинәт тормышның мәгънәсен җуйган кешенең психологик халәтен ваклыкларда, детальләрдә, кабатлаулар ярдәмендә тергезә. Экзистенциягә сәбәп — гомернең картлыкка, үлемгә таба хәрәкәт итүен аңлау. Шуңа төшенү кешенең күзаллауларын, яшәүгә мөнәсәбәтен үзгәртә, ул үзенең югалтуларын аңлый башлый диелә:

*Гизгән чакта (поездларда, корабтамы)*
*Сизмәгән күк меридианнарны,*
*үтәбез сизмичә,*

[28] Фәйзуллин Р. Мәңгелек мизгел: шигырьләр. Казан: Татар. кит.нәшр., 2012. Б.106.
[29] Фәйзуллин Р. Кошлар юлы: шигырьләр. Казан: Татар. Кит.нәшр., 1981. Б.306.
[30] Шунда ук, Б.308.

*Гомернең иң газиз,*
*иң мөһим,*
*иң кирәк чикләрен!*[31]

Шагыйрь ике тапкыр «барабыз, барабыз, барабыз» сүзләрен кабатлый. Беренче очракта, «чыгар юл — кояшлы, бәхетле» фразасы белән янәшә килеп, ул совет идеологиясендәге иң билгеле шигаргә ишарә ясый кебек тоела. Ләкин икенче тапкыр кулланылганда тулысы белән фәлсәфи мәгънә — кешенең туктаусыз омтылышлар белән яшәве, туктап тормышына күз салырга, уйланырга вакыт таба алмавы ассызыклана.

Шәхеснең көндәлек тормышы да шагыйрь тарафыннан экзистенциаль ноктадан бәяләнә. Бу яктан, «...Күзен йом да...» (1976) шигыре аеруча кызыклы. Тукайның экзистенциаль фәлсәфәсенә аваздаш фикер кешенең бары тик балачагында гына бәхетле була алуы турында сөйли. Аның көндәлек тормышы исә — аска тартучы «чергән тамыр»:

*Чергән тамыр кебек, калсын аста –*
*вак борчулар, гайбәт, бурычлар,*
*җыелышлар, фани тетрәүләр...*[32]

Әлеге ваклыкка шагыйрь «әкиятләрне», «табигатьне, матурлыкны, өметхыялларны, «китапларны» каршы куя. Шуларга якынаеп кына ваклыктан арынып була. Мондый омтылыш «Күңел тели күкнең үз өнен...» (1977) шигырендә гомумән теләсә кайсы заманда кешегә хас теләк кебек формалаштырыла:

*Күңел тели,*
*ерак бабайларча,*
*Күктән иңгән табигыйлекне –*

*Күк күкрәвен,*
*кошлар тавышын,*
*яңгырлар шавын...*[33]

Лирик герой сызлануының сәбәбе гомумән кеше характерында да табыла. «Үтеп барышлый» (1977) шигырендә, тормышка бәя биреп, аның камил булмавын шагыйрь «мәхәббәт белән нәфрәт туглашкан, елмайганда яше беленеп торган безнең тормыш»34 белән бәйләп аңлата.

1980 еллар ахырында гомумән татар әдәбиятында да, Р.Фәйзуллин шигъриятендә дә яңа сыйфат үзгәрешләре башлана. Ул үзгәрешләрне илдәге үзгәртеп кору гына түгел, 1960 елларда милли әдәбиятта аваз салган авангард, шулай ук сәнгатьнең милли нигезләргә кайту хәрәкәте дә әзерләгән була. 1960-1980 еллар авангард эзләнүләре татар әдәбиятын өр-яңа баскычка күтәрү, социалистик реализм кысаларыннан чыгу юлларын билгеләү, шигърияткә милли образлылыкны, милли моңны кайтару кебек бәяләнергә лаек. Бу эзләнүләрне поэзия әйдәп бара, татар шигъриятендәге яңарыш хәрәкәтендә исә Р.Фәйзуллин иҗаты юл сала, яңа сукмаклар билгели. Аның артыннан «шаулап» күтәрелгән шагыйрьләр шушы юлга үз табышлары, үз ачышлары белән киләләр.

«Р.Фәйзуллинның барлык шигырьләре дә тыгыз фикер нагрузкасы алып килә»[35], дип яза Ф.Хөсни. Чыннан да, беренче шигырьләреннән үк шагыйрь интеллектуаль тенденциягә, фәлсәфилеккә йөз тота. Фәйзуллин шигъриятендә тәкъдим ителгән романтик-көрәшче лирик герой, шәхеснең хөр рухын,

[31] Фәйзуллин Р. Кошлар юлы: шигырьләр. Казан: Татар. кит.нәшр., 1981. Б.350.
[32] Шунда ук, Б.348.
[33] Шунда ук, Б.360.
[34] Шунда ук, Б. 362.
[35] Хөсни Ф. Мәрмәр чүки безнекеләр // Равил Фәйзуллин: Заман. Иҗат. Шәхес / Төз. һәм кереш сүз авторы З. Мансуров. Казан: Мәгариф, 2002. Б.131.

биеклекләргә омтылучы холкын зурлау ягыннан, XX йөз башы татар поэзиясендәге гыйсъянчы-геройны хәтерләтә. Кешенең кешелеклелеген, хөрлеген саклау — теләсә нинди чикләүләрдән котылу, азат булу мөмкинлеге кебек күрсәтелә. Р.Фәйзуллин алып килгән шәхес концепциясе 1960-1980 еллар татар авангард әдәбиятының нигезен тәшкил итә.


*Сибгат Хәким алтмышынчы елларның яшь шагыйрьләре арасында. Сулдан уңга – Гәрәй Рәхим, Рөстәм Мингалимов, Равил Фәйзуллин, Сибгат Хәким, Ренат Харисов, Рәдиф Гатауллин. Казан, 1970*

Шуның белән янәшә, шагыйрь яшәп килүче идеологиягә, илдәге тәртипләргә карата кискен-тәнкыйди бәя белдерү юлы итеп икенче, яшерен эчтәлек тудыру алымын, эзоп теле алымын сайлый. Бу алым аерым бер образ яки детальнең мәгънәви кырын киңәйтү, символик мәгънәләргә алып чыгу ярдәмендә тормышка ашырыла. Эзоп теле алымы татар шигъриятендә 1990 елларга кадәр мәйдан тота. Ул башка төр һәм жанрларда да күзәтелә, татар авангард әдәбиятының милли үзенчәлеге төсен ала, XX-XXI гасыр чигендә гаять көчле белдерелгән тәнкыйди башлангычка нигез әзерли.

Р.Фәйзуллин татар поэзиясенә башка сыйфаттагы форма яңалыклары да алып килә. XX гасыр татар әдәбиятында сынап каралган символизм һәм сюрреализм сыйфатларын тергезү, символик һәм сюрреалистик сурәт аша мәгънәне тирәнәйтү, ассоциатив фикерләү алымнарын активлаштыру, иреклe шигырь, ак, интонацион шигырь формаларын, күләгәдән чыгарып, классик шигырь белән бер югарылыкка кую, шәркый әдәбиятлардагы кыска, бигрәк тә япон поэзиясендәге аерым жанрларга охшатып стильләштерүләр шундыйлардан. Бу эзләнүләр милли шигърияткә яңа сулыш, яңа иҗат мәйданы ача, нәкъ менә авангард формалар кече жанрларны да, поэма кебек олы жанрларны да тамырдан үзгәртә.

Р.Фәйзуллинның 1960-1980 еллар иҗатындагы авангард эзләнүләрне бербөтен күренеш итеп карарга мөмкин. Ләкин 1970 еллар ахырыннан шагыйрь иҗатында үзгәрешләр пәйда була. Лирик геройның, көрәшче булудан бигрәк, эчкерсез, якты һәм чиста күңелле шәхес сыйфаты көчәя бара. Лирик герой һәм автор образының якынаюы, хис-кичерешләрнең, тормыш күренешләренә мөнәсәбәтнең махсус субъективлаштырылуы психологизмны тирәнәйтә. Тормышны, яшәешне, кешеләрне бәяләүдә экзистенциаль башлангыч алга чыга. Халык иҗатындагы көй-моң, фольклордагы образлылык, үлчәм шагыйрьнең әдәбиятта милли нигезләрне тирән тамырлар арасыннан барлавы турында сөйли. Форма өлкәсендә авангард тәҗрибәләр сакланган хәлдә, аларның классик шигырь традицияләре белән үрелеп китүе, тоташа баруы күзәтелә. Һәм 1960-1980 еллар татар шигъриятендә авангард эзләнүләр шулкадәр куәтле, йогынтылы була ки, шулар татар шигъриятенең «постмодернистик сынаулар» уздыручы проза һәм драматургиядән аермалы буларак, XXI гасырда, бүгенге көндә дә модернизм баскычында калуын тәэмин итә.

**Дания ЗАҺИДУЛЛИНА**

# ЙӨРӘК ҖЕБЕ ӨЗЕЛГӘН ҖИРДӘ

ЭССЕ

Елга ага да ага...

Ничә миллион сүзләр ага икән бу агымнарның дулкын-дулкын томнарында? Юк, миңа бернинди томнар да, бу томнардагы сүзләр ташкыны да кирәкми. Сүзләрдән арыганмын. Мин алардан туйдым. Миңа шигърият кенә кирәк. Ә нәрсә соң ул шигърият? Шигърият — җанның тормышка гашыйкый халәте. Шатлык-куанычта яшәгән чагы. Мин шулай аңлыйм. Шулай да, кеше гел дә гашыйк, шат, даими гашыйклык халәтендә тора аламы? Тора алса, мондый кешегә, гадәттә, бу — тиле, диләр. Әйе, мондый «тилелек» шагыйрьлеккә тигез була, ди миңа аваз. Андыйлар күпме, ничәү? Бу урында Чеховның «Гашыйклык — кешенең табигый халәте. Бу аның тормышта нинди булырга тиешлеген аңлаткан халәт» дигән сүзләре искә төшә. Димәк, кешелек мондый гармоник халәттә яши ала, әгәр бар кешелек шагыйрь булган булса. Бу мөмкин түгел, чөнки Җир шарының бер ягында якты булганда, икенче ягында караңгы; алар яктыдан караңгы, караңгыдан якты дан даулап, Җир шарын күчәреннән кузгаткан булырлар иде. Ә кем ул, шагыйрь? Күкрәгендәге мәхәббәтен нәфрәткә, нәфрәтен мәхәббәткә әйләндереп эретә һәм кешелеккә бүләк итә алган кеше, ди теге аваз. Кеше «генә»ме? Шагыйрь «генә» булып кала аламы? Бу урында үзебез сүз алып барасы замандаш шагыйребез Равил Фәйзуллинның унбиш яшендә язган шигыреннән ике юл искә килә:

*Шагыйрь булып, китабыңны тотып,*
*кайтсаң иде туган ягыңа!..*

Аһ, бәхетле булу өчен китап чыгару да җитә, димәк?! Димәк, сабыйчак максимализмына ташлама ясаган очракта да, китап чыгара алган тулаем «гашыйк» булып кала ала? Ул гына мәхәббәтле? Ул чакта янә сорау: шигъриятнең икенче аерылгысыз канаты — «нәфрәт» төшенчәсе белән нишләргә? Нәфрәттән башка мәхәббәт юк, диләр бит әле. Шагыйрьнең нәфрәте — ул шул ук мәхәббәт. Мондый тигезлеккә шагыйрь ирешә аламы, ирешә алса, кайчан? Ирешә ала, әгәр шагыйрь (бу урында «шигырьче, шигырь язучы» дип әйтү урынлырактыр) «кеше генә» булудан ары узып, «шәхес» намына ия була алса. Шигырь язып, «шигырьче» булып, китап чыгару һәм чын шигърият тудырып, чын шагыйрь булып калу — икесе ике нәрсә. Аларның чиге адәмчек, «кеше генә» булу белән «шәхес булу» төшенчәләре арасындагы Сират Күпереннән үтә. Минемчә, татар шигъриятендәге «чын шигърият һәм чын шагыйрьлек коллизиясе» менә шунда ята. Шигъриятнең соңгы чорларда биеклекләрдән түбәнлеккә төшеп, бер урында таптануы, үзен-үзе кабатлавы, үзенә-үзе соклану белән чикләнеп, «ләззәттән канәгать» яшәве менә шушы таләпкә туры булмавыбыздан киләдер кебек.Лев абзабыз Толстойның «Безнең әдипләребезнең вөҗданлы сүзләре белән вөҗданлы гамәлләре арасында бик зур ара саклана» дигән фикере белән ничек килешмисең?

Бүгенге авыл, безгә канат куйган авыл кичергән кризис турында без, өч йөздән артык язучы, барыбыз да беләбез. Эчтән генә сыкрану, сабантуйга кайтып, бер оя карт-коры белән чәй-мәй эчеп килү белән чикләнәбезме? Нигә барыбыз бер булып татар авылын яклау-саклау өчен рухи ачлык вахтасына басмыйбыз?! Нигә без авыллар буйлап әдәби рейдлар үткәрмибез?! Нигә без, Равил Фәйзуллин кебек,

жанны көйдерә торган менә мондый дүрт кенә юллык Шекспир трагедияләрен язмыйбыз?!

*...Тыкрык чатында*
*әйтте сәрхуш түтәй:*
*«Авыл — кабыгы сау,*
*эче — аккан күкәй...»*

Натурализм, диярсез. Хактыр. Сез башкасын язгыгыз. Ләкин миңа мондый кыска кичереш, мондый эмоция гына аз. Миңа татар шигъриятендә мин тәрбияләнеп үскән Йосыф-Зөләйха сюжетлары, тирән кичереш, тетрәткеч образ, метафора-чагыштырулар, фикер һәм хис бердәмлеге кирәк. Һәм — кинәт!

*Башны салларга салып*
*китәсе иде агып.*
*Дәшәр иде дулкыннар*
*бер шагыйрь җанны танып...*

Мин тетрәнәм. Биредә мин эзләгән сюжет та, аяктан егарлык образ-сурәт тә, тынсыз калырлык яңа фикер дә, хис тә юк кебек. Тагын да... шул «шагыйрь җанына» гына ишарә бар. Тик нигә, нидән тетрәндем?! Ник җылыйсым килде? Минем йөзләрчә тапкыр шундый халәтне кичергәнем булды бит, югыйсә. Үземнең дә «башны салларга салып, китәсем килде агып!..» Әмма бу юллар миңа түгел, аңа, замандаш «шагыйрьҗанга», ингән. Әмма кайда, татар тарихының кайсы тәнгәлендә, татар географиясенең кайсы төшендә килгән? Миңа, мәсәлән, һәрвакыт бер урында — үземне дошманның Идел буендагы бөек дәүләтемне яулап алу өчен, милләтемнең борын астындагы Зөя утравында төзелгән Зөя кальгәсе каршында басып торган итеп хис иткәндә килә иде ул «башны салларга салу» тойгысы. Һәм бүген дә шулай. Киләчәктә дә шулай булачак!..Тик, миңа бу гына да җитми: башны салларга салып агып китү өчен күп акыл да кирәкми кебек, тик менә салны... кай тарафларга юнәлтергә? Кая барыр минем башым салынган салым? Кемнәр көтә? Әстерханмы, андагы дустанә дәстарханмы, әллә... дошманмы? «Сал» дигән нәрсәм «дошман казнасына керер «салым»га әйләнмәсме?

Формаль логика күзлегеннән караганда, сал алдагы, без көткән «коммунизм»га пропуск-программа сорый һәм кызыл семафор кабыза», чөнки безгә, Пушкиннан калган теге мәңгелек «Йөзәргә. Тик кая йөзәргә?» дигән сөальгә җавап бирәсе бар. Бәлки, бу «иске төрдәге мәңгелек шигъриятебезгә» яңа төрдәге шигърият альтернативасыдыр? Бу, бәлки, сурәт шигъриятенә алмашка килгән «цифрлы» шигърияттер? Карагыз әле: нинди тетрәткеч сурәт: ничә гасыр таш астында, ничә гасыр томан астында, ничә гасыр камчы астында, ничә гасыр өшү, туну, сискәнү, дарларда асылынып тору — һәм, ниһаять! — сызылып кына таң ата... Таң эчендә «Тукай маршы» яратыла һәм аннан алсу каурыйлы, алсу томшыклы, муеннары алсу ефәк ыргакларны хәтерләткән, карашларыннан энже койган газиз җан иякләре йөзеп чыга һәм кинәт, җанны ярып, йөрәкнең берданбер җебен өзеп:

*Китәсез дә мени, аккошлар?!..*

Һәм бу таңда әле килеп тә өлгермәгән аккошларның инде нинди дер безгә билгесез, әмма фаразланган сәбәпләр нәтиҗәсендә китеп тә баруларын, бәлки, бөтән беркайчан да кайтмаячакларын тотып алган шагыйранә даһилык күршесендә гомер кичеп яткан икенче бер моң-зарчылык даһилыгы белән кушыла. Бу илаһи моң безнең барча «Зөяләрдәге югалтуларыбызга» бөек бер реквием — кайгылы моң һәйкәле булып яратыла — мәшһүр җыр туа да, алдыбыздагы ак кәгазебезгә, кара туфрагыбызга, бәгыребез сөлгесенә кайнар яшь булып тама: «Китәсез дә мени, аккошлар?!»

Биредә без үзебез күреп-укып өйрәнгән «чын шигырь»не эзлибез, ә ул

— чынлап та күренми. Дәвам итәсегез килсә, һаман да шул сыкраулар — «китәсез дә мени, аккошлар...» Һәм тагын да! Һәм тагын да!.. Сез аңлыйсыз, шушы бер юл — шигырьнең үзе. Бүтәне кирәкми дә. Әгәр шагыйрь шушы бер юлдан ары таба монардан ничек кенә булса да «шигырь ясыйм» дип сюжет «төзегән» булса, үз пычагы белән шигърияттебездәге шушы бер генә юллык җәүһәр аккошның җанын кыйган булыр иде. Менә шушы бер юл, менә шушы бер «аһ!» татар гасырларының үкенечләрен әйләндерә дә сала. Ләкин шунысы кызык, салның бик тә кырыс сурәте көтмәгәндә романтик бизәктән романистик образга әверелә, аннан алынган кечкенә импульсив этәргеч фаҗигале сюжетка, эчтәлеккә әйләнеп, сине кайгылы сагышка сала. Мондый метаморфозага тарихи нигездә яткан чын шигъри импульс кына чыганак була ала. Аның көчәнеше бик киеренке, көчәнеш трансформаторы поэма-романнар бирмәгән токка дучар ителеп, янып чыгуы мөмкин. Бу — безнең өчен яна нечкәлекләр шигърияте. Ул безнең шигърияттебезгә тирә-яктагы даирәнең бүре куганда янгырый торган һау-һавы астында тарихыбызда беренче тапкыр берьюллыклар, икеюллыклар, өчьюллыклар, дүрт вә бишьюллыклар алып килде. Ул әдәбият тарихыбызда булмаган кыскалыкка омтылды. Бу урында һаман да шул Чеховның «Әгәр мин миллионер булган булсам, кул яссуы кадәр генә әсәрләр язган булыр идем», дигән «кытыгы» искә төшә. Яшь шагыйребез Такташтан соң утыз биш ел үткәч, силлабо-тоник системада биле каткан татар «шакмак шигырен» янадан ватып, безне «иркәле шигырьгә алып керде. Һәм үзе дә, үзе тудырган «иреклекне» «Бу кадәр утынны мин ваттым микән?» дип аптырап торганнан соң, «иркле»дән янадан классик татар шигыренә кайтты һәм ул биргән мөмкинлекләрдән файдаланып, байтак ачышлар ясады. Житмешенче елларда иҗат ителгән «аккошларын» алдан күргәндәй, шагыйрь әле үткән гасырның алтмышынчы елларында язган мондый «ике-өч юллык» миниатюраларын «нюанслар иле» дип атаган иде. Андагы кошларның канаты тиюдән елаган күзгә болытларны, кефир шешәсендә таң каршылаган чәчкәне безнең «борынгы буын» шагыйрьләребез генә түгел, хәтта ана буындаш булган байтак яшь шагыйрьләребез дә «бу шигырь түгел, кроссворд-башваткыч» дип, зур тырышлык салып коллектив тукмауда катнашканнар иде...

Равил Фәйзуллин шигърияте турында берничә тапкыр язганым булды. Сәер хәл иде: язган саен, аңламагандай, язасым килде. Гүя аңлаган саен аңламаганым арта барды. Гүя офык офыкларга, хәтер хәтәргә илтә иде. Әйе, әдәбият мәйданы — хәтерләләр һәм хәтәрлекләр сабантуе. Мин дә, язганымда хәтерсез һәм хәтәр булмыйм, дип борчылам. Тәнкыйтем, булган очракта, кешене түбәнсетмәсен, мактавым — авырсындырмасын иде. Әлеге язмаларымны да энә өстендәге ләззәт белән язам. Чөнки бу шигъриятне танууга мин катлаулы, бик тә катлаулы юллар белән килдем. Әүвәлдә мөкиббән китеп кабул иттем. Аннан, айнып, инкяр иттем. Аннан янә дә кабул иттем. Аннан янә инкяр, янә кабул... Һәм ул бу хакта шагыйрем үзе дә белә. Мондый шигъри үзгәрешнең табигатен бик аңлап та бетермим, чөнки без бүген дә икебез бер идеал, әмма ике төрле чишелеш, икебез ике төрле образлар системасы, икебез ике эстетик концепциядән чыгып иҗат итәбез. Шуна күрә, бу язмаларым тәнкыйть мәкаләсе булудан ерак тора. Мин шагыйрьнең берсеннән-берсе саллырак булган биш, алты томлыкларын, башка барлык китапларын, публицистикасын, мәкаләләрен янадан энәсеннән җебенә кадәр укып чыгып, ниндидер академик бәяләр биреп, рецензия, иҗат портреты язарга җыенмыйм. Әйткәнемчә, Р. Фәйзуллин иҗаты әллә кайчан тиешле бәясен алган һәм бу бәяләмәләргә күпмедер күләмдә мин дә өлеш керткәнмен. Бу язмаларым заманыбыз һәм замандашларыбыз, шагыйрьнең иҗаты, иҗат юлындагы моңа кадәр күренмичәрәк, сөйләнелмичәрәк торган сыйфатлар турында сурәтләмәдер. Европа теле белән әйтсәк, сагышлы язмалар. Эссе, димәк. Равил Фәйзуллинның замандашым гына түгел, гомерлек фикердәшем, якын дустым икәнлеген дә онытмыйк. Яшь ягыннан карасак, ел ярымга соңрак туган энекәшем. Равил белән 1965 елның көзеннән таныш. Әтисе Габдрахман абзыйны, әнисе Әминә апаны яхшы беләм. Күнелгә яшь сыман буылып истәлекләр килә. Аларның Әмәт тавындагы кош оясы кебек мөлаем йортларына барып йөргәнем хәтердә. Ишек алларындагы «татлы» кар базы да хәтердә. Әминә

апа бик тәмле итеп вак кәбестәләр тозлый иде. Без аларны тустаганга тутырып алып менеп, аякларны бөкләп, умыра да башлый идек. Ул чакта Равилнең ике генә кеше сыярлык кечкенә бүлмәсе (күз алдына китерәсезме, үз бүлмәң булу өчен никадәр «һәлле даһи» булырга кирәк!) бар иде. Ә Равил ул чорда чынлап та бик зур «даһилык», без исә кечерәк даһилык чоры «чоры» кичерә идек. Зур «даһи»ебыз бүлмәсенең диварлары ана килгән «даһи фикерләр» язылган һәм һәркайсы энә белән кадап куелган кәгазь кисәкләре белән тулы иде. Монда безнең буынның Вольтеры яши иде. Укучыларыбыз, бәлки, хәтерлидер, алтмышынчы еллар уртасында Равил белән төшкән бердәнбер фотобыз бар. Без аның бүлмәсенең ишек тупсасында утырабыз. Фотоны минем аппаратта автоспуск белән төшереп алган иде... Әйе, дусларым күп булды, әмма гомерлекләрен санарга бер кул бармагы да җитә. Равил үзе әйтмешли, мин дә «дусларны чәчеп җыйдым». Алар арасында Равил Фәйзуллин кебекләр берәү генә. Ул «Дәү Әниле». Ул — юмарт, Дәү Әнисен, мина, тома ятимгә дә, «биреп» тора. Дәү Әниебезнең аяк очында аякларыбызны бөкләп, йомгакны тотып торабыз:



*Равил Фәйзуллин һәм Айдар Хәлим. 1965 ел. Казан.*

*Син бәйләрсең оек. Ә мин каршыңда –*
*уйлап яңа туар җырымны,*
*сабый чактагы кук, аяк бөкләп,*
*йомгагыңны тотып торырмын...*

Әйе, бүгенге татар шигърияте безгә нәкъ менә шул Ак Әби-Дәү Әни һәм без, шагыйрьләр, аның каршында аяк бөкләп, йомгагын тотып торабыз. Күрәсез, бу язмаларда гүя мин үз-үзем һәм Дәү Әниебез белән сөйләшәм:

– Кышкы суыкларда чират торып, аякларда утын җылысы да калмады, Дәү Әни. Нишләргә?

– Зарланма. Аякларыңны көн саен каен күмере кайнаган суга, спиртта төнәгән сирень төнәтмәсенә тыгып утыр.

Монысы бик гади хәл ителде, ярар. Бәхәсләшәм.

– Мөстәкыйльлекне җинел генә кире бирдек, Дәү Әни. Нишләргә?

– Сез аны бирмәдегез, ул сездән үзе китте, чөнки сез корбансыз гына мөстәкыйль булырга теләдегез.

Мактыйм һәм сугәм. Чорныйм һәм сүтәм.

– Нигә без болай бөек һәм болай вак, Дәү Әни. Нишләргә?

– Бөек тарихыбыздан бөек китап тудырмыйча, аны бер көнлек тормыш-көнкүреш мәнфәгатьләргә алыштырганга вакландыгыз. Эрерәк, батыррак булыгыз.

Һәм мина рәхәт. Бу минем үткәнем. Һәм эчемнән тагын да бер тапкыр: «Әле дә бар бу кеше, әле дә ул исән! — дип куанам мин Дәү Әниебезнең турыдан-туры «оныгы» Равил Фәйзуллин турында. — Оеклар бәйләп аны үстергәнең, ир-ат күнелле итеп тәрбияләгәнең өчен рәхмәт, Дәү Әни! Ходай аңа безнең барыбызның сурәтләрен нур аша үткәрә торган риясыз, үпкәсез, эчкерсез күнел һәм газаплы-чиста вөҗдан биргән!»

Бишектәге бишкә төрләнә, дигән сүз бар. Моны җиделәге җитмешкә төрләнә, дип тә булыр иде. Менә без җиделән җитмешкә төрләнмичә, гомумән алганда, үзебез булып калып, җитмешкә дә килеп җиттек. Ышануы кыен. Инде җитмештә арттыру-

киметүсез сорау да куярга мөмкиндер: Равил Фәйзуллин татар шигъриятендә, гомумән, илле елдан артык хезмәт иткән әдәбиятыбызда, илле ел буе дип әйтерлек язучылар оешмасын оештырып-укмаштырып торучыларның, «Казан утлары» кебек искиткеч абруйлы журналның чирек гасыр буе баш мөхәррире булып эшләгән сирәк затларның берсе буларак, язучының әдиплек әдәбендә нинди сабаклар тудыра алды? Минемчә, алар бихисап. Әмма араларында иң мөһиме өчәү кебек.

Беренче. Равил Фәйзуллин безнен шигърияттә хис чыганакларын унар мен юллы халык авыз иҗаты дастаннарыннан бер юлга кадәр кыскартты, фольклорның «озакка сузыла торган уен» заманның кыска фикеренә китерде һәм Сәгать-Вакытны үз файдабызга калдырырга өйрәтте:

*Үлеп күрсәттеләр безнекеләр!..*

Дастаннардан иң кыска дастан түгелме? Миллионлап үлдек-түшәлдек без, татарлар, империягә юл салабыз дип. «Фидирәтсияне коткарабыз» дип. Ну-с, коткардык. Коткарып, үзебез нәрсә алдык? Нәрсә, туган телдән ниндидер очраклы килмешәк Рәис Сөләймановлар көлсен өчен, туган телебездәге мәктәпләрне, мәдәният учакларын юкка чыгарсын өчен өч ай буе фашист камалышында кан койдымы Петр Гаврилов, Илдар Маннановлар, башларын салдымы Мөҗәй Хәйретдин, Җәлил-җәлилчеләр һәм рейхстаг түбәсенә Җиңү Байрагын кададымы Гази Заһитовлар?! Мин дә шушы кимсетелүләр өчен ятим үстемме?! Моннан бер ел чамасы элек интернетны ачсам, аннан әтиемнен 1945 елның гыйнварында Венгриядә барган сугышлар вакытында «За отвагу» медале белән бүләкләнгәнен һәм аның әле булса тапшырылмаганын беләм. Әмма медальне «Фидирәтсия»дән һаман да алып булмый. Минем әтием «минем әти» түгел икән. «Наградной лист»та ул туган «Бәләкәй Кәркәле» дигән авылыбыз дөрес күрсәтелсә дә, бүгенге Оборона министрлыгындагы писәрләргә сугыш вакытындагы писәрләрнен әтиемнен «Нәҗметдин» дигән «иностранный» исемендә өч, Габделвәлиевич дигәнендә биш хата җибәреп, әниемнен «Сорур Шиһаповна» дигән исемен «Соруршиль» дип кенә язып «ыргытулары» аркасында медальне ала алмавыбызны һич аңлатып булмый. Бар, бүгенге Россия оборона министрлыгы архивында исем-фамилиясе дөрес язылган татар корбанын табып кара!.. Һич арттырмыйча әйтә алам: бүген кимендә миллион татар исем-фамилиясендә җибәрелгән хата аркасында «калай медальләрне» ала алмый. «Үлеп күрсәттеләр безнекеләр!..» Әттә-тә-тә! Ничек кенә әле!.. Бу юлның фаҗигаи тарихи мәгънәсе, тарих институтларыбыз булуына карамастан, әле булса ачылмаган! Фаҗига өстенә фаҗига!.. Кем без моннан соң?

Икенче. Равил Фәйзуллин татарның хиссияти шигырендәге импульсны эчтәлеккә әвереләдереп эпиклаштырды һәм үзенең эпик шигъриятендәге (поэмаларында) социаль эчтәлекне шул ук импульсив яшьнәүләрдән тотып алып, кире кайтаруга ирешге:

*Бөтен*
*Планета буйлап*
*вакансия –*
*Көрәшчеләр кирәк!..*

***

*...Хәтерләргә телимме мин төрмәләрне,*
*лагерьләрне, яндыру мичләрен?*

*Җиңел дисезме язу боларны?*
*Миллионнарны*
*аткан,*
*буган,*
*ыслаганнар — тән өченме?*

*Аскан,*
*чапкан,*
*тураганнар —*
*тән өченме?*
*Кирәк булганмы әллә*
*туфля баулары?*
*Юк!*
*Җан өчен!*
*Җан!..*

*...Кеше җаны өчен көрәш бара!*

Өченче. Равил Фәйзуллин, әйткәнемчә, илле елдан артык әдәби мәйдан тотып, һәм әдәби процесста, әдәби даирәләр, басмаларда зур-зур хуҗалар булып калып, беркайчан да үз мәртәбә-маркасын вакламаган, хөсетлекне, үч алу, астан интригалар уты йөртү дигән нәрсәне белмәгән, сәяси уйнаштан ерак торган Кеше, димәк, Шәхес булып калды. Бу Сталин, Булганин, Маленков заманнарыннан баш төртеп чыгып, Хрущев «җепшеклеге», Брежнев «баткагы», Андропов, Черненко «турытаяклыгы», Горбачев демократизмы, Ельцин «сәрхушлеге» аша үткән, аннан, тагын килеп, Путин тоталитарлыгы шартларында яшәп-көрәшеп яткан шагыйрьгә, әдәби житәкчегә, иҗтимагый-җәмгыять эшлеклесенә жинел эш түгел иде. Нәтиҗәдә, ана якты көннәрдә генә түгел, караңгы төннәрдә дә килеп сыенырга мөмкин иде. Бу ана Тукай бүләкләреннән алда Аллаһтан төшкән иң югары бүләк иде. Шагыйрь холкының шушы сыйфаты — минем өчен иң якты, беркайчан да үтмәячәк истәлек булып калыр дип ышанам:

*Җаныңның ваклыгын*
*сылтама заманга.*
*Куркырга, өркергә*
*җай бар ул һаман да.*
*Асылыңны яшереп*
*кыланма ни генә, –*
*буыннар хәтерендә*
*бары да чигелә!..*


*Нәкый Исәнбәт һәм Равил Фәйзуллин. 1981 ел.*

Кемгәдер болар барысы да, бәлки, сүз-күз уйнату гына, кайберләре сәяси ялтырау-шалтырау булып күренер. Шуңа күрә, автор «Көрәшчеләр» поэмасында, алдан күреп, безнең барыбыздан «Жинел дисезме язу боларны?» — дип аваз сала. Шагыйрь — хикмәт иясе, шигырь үзе — хикмәт. Хикмәтле сүзне бер укыганда аны «атып бәреп», икенче тапкыр жирдән күтәреп, елап укырга мөмкин. Алар арасында бер адым. Түмәр яра торган тупас йөзле балта-колын да ялтыравык нәселдән. Тик аны күрә белергә кирәк. Равил Фәйзуллинга кадәр мондый «гүзәл колынны» күргәнебез булмады: «түтәсе ингән — күп сугудан, йөзе тонган — тутыгудан». Әмма «бар иде колынның ялтыраган чагы, — йөзәр яшьлек иманнәрнең калтыранган чагы...» Без күргәннәрне Фәйзуллин да күрә, тик шундый аерма белән: без күреп чикләнәбез, ул аларны укып сурәтли:

*Гөмбәзләре — кояшмыни!*
*Сары алтын — чиркәү.*
*Бабайларның күз яшьләре*
*менә кайда икән!..*

Шагыйрьнең биштомлыгына язган аналитик мәкаләсендә безнең бик тә яхшы шагыйребез һәм тәнкыйтьчебез Наис Гамбәр Равил Фәйзуллинны «шигъриятебезгә җиңүче булып килеп керде», ди. Наис инде мәрхүм, мин, кызганыч ки, аның белән бәхәсләшүдән мәхрүммен, әмма аның ташта басып калдырган фикере белән бәхәсләшә аламдыр кебек. Минемчә, Наисның биредә хрестоматияләр өчен раслаучыл җөмлә калдырасы килгән булуы мөмкин. Чынбарлыкта бер генә чын шагыйрь дә шундук һәм шул сәгатьтә шигърияткә җиңүче булып килеп керә алмый. Һәрхәлдә, дөнья әдәбияты тарихында андыйларның булганы юк әле. Чын шагыйрьләр шигърияткә, гадәттә, җимерүче булып килеп керәләр. Алар җимерәләр, төзиләр һәм җиңәләр. Чөнки һәр талант үзеннән алдагыларны инкяр итеп килә. Дөрес, инкярда түгел, раслауда туган шагыйрьләр дә бар. Әмма беренчеләре күбрәк. Равил Фәйзуллин кебек «постмодернист» аеруча шундый. Ул үзенең «нюанслары» белән иске шигъриятне күпме кирәк, шулай җимерде, аннан, гомере буе, яңа шигъриятне төзеде һәм җиңүче булып чыкты. Чөнки мондый җимерү савaплы гамәл иде. Язмышының шагыйранә логикасы да шуңа корылган иде. «Аһ, бу тау юклыклар!..» дип уфтанды ул милләтнең идеологик кына түгел, географик чикләнгән мескенлеген акларга тырышып. Акламыйк һәм акланмыйк. Милләт, халык үз ирке өчен тигезлектә дә көрәшә ала, әгәр аның чын лидерлары һәм иманы сау булса. Халкыбызга географик Ил-Борыслар, биек таулыклар таләп итүнең артында безнең тәнкыйть әле булса читләтеп үткән икенче бер яшерен мәгънә дә бар иде. Безнең һәм бездән өлкәнрәк буыннар хәтерли булыр: үткән гасырның Хрущев «җепшеклеге» чорларында Үзәк Комитет бер тар гына төркем халыкларның Эдуардас Межелайтис, Чыңгыз Айтматов, Рәсүл Гамзатов, Кайсын Кулиев, Давид Көгелтинов, Мостай Кәрим кебек вәкилләреннән «даһилар экспрессы» ясаган, әмма анда татарлардан гына беркемне дә кертмәгән иде. Үзәк Комитеттагы белгечләр фикеренчә, Тукай-Такташтан соң саегып калган татар шигъриятендә һәм әдәбиятында «тегеләр» рухын күтәрә алган татар шагыйре вә язучысы «табылмаган», «төрмәдән чыккан Туфан», сугыштан имгәнеп кайткан Ржев солдаты Сибгат Хәким, диссидент Салих Батталлар исә теге экспресска утыртылырга лаек булмаган «уртакуллар» иде.

*Аһ, бу тау юклыклар!*
*Кыя юклыклар!*
*Күз тегәмә кая –*
*үзән, калкулыклар...*

Болай дип уфтанган заманнарда «Равил Фәйзуллин буыны» теге экспресска утыртырга теләмәделәр, ул яшь, яшьтән бигрәк... һаман да шул... татар иде. Аңа татарга хас тар гына мәйдан бирделәр. Аңысын да шикләнеп кенә. «Фәйзуллин буыны»дигәннән. Бу хакта күңелемдә йөргән фикеремне әйтим әле. Мин аңа күптән түгел чыккан бер мәкаләмдә кагылып та үткән идем. Бүген килеп анык кына әйтүе дә кыен: өлкән шагыйрьләрдән кайсысы беренче тапкыр кулланды икән бу «Фәйзуллин буыны» дигән канатлы әйтемне? Сибгат Хәким әйтте кебек. Минемчә, бу төшенчә дөрес тә, түгел дә. Безме «Фәйзуллин буыны»ннан, әллә Фәйзуллин үземе безнең буыннан? Без дигәнем, утызынчы еллар азагы — кырыгынчы еллар уртасына кадәр туган шагыйрьләр: Рәшит Әхмәтҗан, Кадыйр Сибгатуллин, Айдар Хәлим, Булат Сөләйман, Зиннур Насыйбулин, Салисә Гәрәева, Эльмира Шәрифуллина, Рим Идиятуллин, Разим Вәлиуллин, Харрас Әюпов, Эдуард Мостафин... Шунысы кызык, бу исемлектәге авторлар «Фәйзуллиннар буыны»на кертелмәде. Юк, биредә Фәйзуллинның гаебе юк. Фәйзуллиныбыз мондый «буын җитәкчесе званиесенә» беркайчан да омтылмады. Аны күрмәде дә, чөнки ул намус төшенчәсеннән килә иде. Юк, безләрне дә талантсыз булган өчен күрмәделәр түгел. Киресенчә,

халыкчан һәм талантлы булган өчен. Ул елларда, илленче еллар башындагы «Җәлил чакыруыннан» соң, татар шигъриятенә СССРдагы бер генә халыкка да килмәгән шагыйрьләр ташкыны килде. Бу Партия Үзәк Комитетын, аның җирле штабы — Татарстан Өлкә Комитетын куркуга салды. Әгәр безне үстергән булсалар, без дөнья әдәбиятын «басып алган» була идек. Шуңа күрә, бу ташкыннан берничә генә талантны сайлап алып, башка талантларны «шәһәргә» һәм «авылга», Түбән Камага һәм Әлмәткә, Лениногорскига, Яшел Үзәнгә һәм Зәйгә, данлаучыга һәм хурлаучыга, интернационалистка һәм милләтчеләргә аерды. Миннән, мәсәлән, әле 1965 елда язучылар җыелышында яшьләргә журнал таләп иткән өчен «милләтче» ясадылар. Мин «Фәйзуллиннар буынының» «политбюросына» керергә тиеш идем кебек. Укучы белә: бу «буын»ның иң милли тал тамыры, матбугатта актив басылган, әдәби мохиттә катнашкан автор идем. Ләкин шул буын баласы була торып, буыныма якын да китерелмәдем. Шагыйрь буларак танылмадым, публицист ителдем. Алар, минем өстән чыбыркы шартлатып, төчкелтем депутатлык әдәбияты һәм публицистикасын тудырганда, мин шигъри телем белән тормышның кытыршы идәнен ялап, үземә бер әдәби буын булдым да калдым. Ә бит мин тарихи үз буыныма гел тартылдым. Алар турында яздым, алар белән бергә яндым-көйдем. Әмма алар утыртылган чана-арбага утыртылмадым, алар исемлегеннән төшеп калдым. Утыртылганда да, тегеләрнең йөз җыеруларына төкереп карап, мине ул чана-арбага бары тик шул кешелекле шагыйрь Равил Фәйзуллин гына утырта иде. Юк, мәсьәлә, гафу итегез, башкаларны һәм мине бу исемлеккә кертү-кертмәүдә түгел иде. Моның сәбәбен тирән һәм нечкә аңлаган Равилебез «Ил мантырга теләмәсә, халкыннан дошман эзләр» дип язган иде. Әйе, «милли түрәләребез» милләттән дошман эзләде. Бурыч органнарның сәяси уеннар уйнап, татар шигъриятен көчсезләндерү, аңа тиешле юл бирмәү, аны берничә исем белән чикләп, үсешен чикләп торуда иде. Сез карагыз, әгәр безнең барыбызны тигез үстергән булсалар, без бер «Равил Фәйзуллин» гына түгел, ун-унбиш Фәйзуллинга тиң бердәм фронт тудырган булыр идек. Менә бит эш нәрсәдә! Әмма зур куаныч та бар: менә шушы режим шартларында кайсыдыр шагыйрь, мактау-иркенлектән азып-тузып, кешелегеннән ваз кичкән булса (без андыйларны да күп күрдек!) Равилебез исә зур шагыйрь булып житеште, милли шигъриятебезгә, милләткә, һәр каләмдәшенә тугры калды, кем әйтмешли, барыбызны сагындырып яшәде, сагындырып яши һәм яшиячәк әле, Алла боерса!..

Мәкаләм озынгарак китте бугай. Бая әйткәнемчә, язган саен язасым килә. Язган саен янача аңлыйм. Асыл шигъриятнең табигате һәм нәселе шундый. Кыскасы, милләтен сөеп, сөендереп һәм үзен дә сөйдерә белеп яшәгән шагыйрь дустыма, аның гаиләсенә, балаларына, авылдашларына, якташларына — аларның барлыгына куанып! — рәхмәт әйтәм һәм озын гомерләр телим.

Чын шагыйрьнең ярасы да сагыш. Сагышы да яра. Ярату һәм яраттыру менә шушы хис-тойгыларны берләштерә. Болар барысы да йөрәк җебе өзелгән җирдә ялгана. Бу хакта шагыйрьнең үзеннән дә остарак әйтеп булмас кебек:

*Син теләп алган сагышым.*
*Син теләп алган ярам.*
*Туеп кем дә китәр, ә син –*
*яратып китеп кара!..*
*...Ярамы? Анысы минем эш.*
*Ул теләп алган ярам...*

**Айдар ХӘЛИМ**

# УЙЛАР, УЙЛАР, УЙЛАР...

Күпгасырлык милли әдәбиятыбыз олы шәхесләргә бай булып, аларның иҗаты кешелекнең якты идеалларына хезмәт итеп, рухыбызны даими сугарып килә. Әнә шундый шәхесләрнең берсе — халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге Татарстан дәүләт премиясе лауреаты Равил Фәйзуллин. XX гасырның икенче яртысы — XXI гасыр башы татар сүз сәнгатен аның кинкырлы бай иҗатыннан башка күз алдына да китереп булмый.

Равил Фәйзуллин иҗаты һәм шәхесе белән таныш булган һәркем бер үзенчәлеккә игътибар итми калмыйдыр: шагыйрь турында әдәбиятка аяк атлап кергән дәвереннән бүгенгәчә бихисап мәкалә-язмалар дөнья күргән. Әлеге язмалар төрле характерда. Кемдер әдипнең иҗаты хакында яза, кемдер шәхесен ачарга омтыла, кайберәүләр иҗатының башка тармагына — публицистик уйлануларына күзәтү ясый, берәүләр Фәйзуллин шигъриятен башка авторлар белән чагыштырма планда өйрәнә... Гомумән, Равил Фәйзуллин иҗаты һәм шәхесе инде ярты гасыр дәвамында җәмәгатьчелекнең игътибар үзәгендә. Мина калса, горурланып һәм сокланып, татар әдәбиятында «Фәйзуллин феномены» хакында сүз алып барырга мөмкин һәм кирәк.


*Равил Фәйзуллин һәм Зиннур Мансуров. 2005 ел.*

Ә менә Равил Фәйзуллин эшчәнлеген фәнни нигездә тикшеренүләр күп түгел, берничә генә. Бу нисбәттән шәхсән үзем 2002 елда «Мәгариф» нәшриятында чыккан «Равил Фәйзуллин: Заман. Иҗат. Шәхес» (төзүчесе һәм кереш сүз авторы Зиннур Мансуров) дигән басманы теләсә кайсы монографиядән дә дәрәҗәлерәк хезмәт дип саныйм. Биредә әдипнең иҗатташ-каләмдәшләре, әдәбият галимнәре, сәнгать белгечләренең (барлыгы житмешләп автор) төрле чор-заман фонында олуг Шәхеснең беркемне дә битараф калдырмаган иҗаты хакында уйланулары, эзләнүләре урын алган. Ин мөһиме, төрле елларда дөнья күргән, иҗтимагый-сәяси чорлар яктылыгындагы язмалар бергә тупланган. Зиннур Мансуров үзенең кереш сүзендә болай дип яза: «Аның турында язылган мәкаләләр шулкадәр күп, алар инде гомуми күләмнәре ягыннан Шагыйрьнең үз язганнарын да күптән узып киттеләр. Авторлар бик тә төрле: әдәбият галимнәре, тәнкыйтьчеләр, әдипләр, сәнгать белгечләре, шигырь сөючеләр. Равил Фәйзуллин иҗатына мөнәсәбәтләрен белдерүчеләр милләтләре белән дә аерылып торалар – татар, рус, украин, белорус, латыш, үзбәк, казакъ, башкорт, чуваш, төрек һ.б. Төрле әдәбият, төрле буын вәкилләре, төрле караш, төрле идеология, төрле «реализм» тарафдарлары. Кызганыч ки, аларның шагыйребез турында язганнарын бер басма кысаларына һичничек тә сыйдырып булмый. Тау кадәр материалдан, мөгаен, берничә том төзеп чыгарырга мөмкиндер».

Әлбәттә, киләчәктә әдәбият фәне Равил Фәйзуллинның шигърияттәге олуг хезмәтләре белән бергә, аның публицистика өлкәсендәге эшчәнлеген ныклап өйрәнергә тиеш булачак. Шагыйрь ошбу өлкәдә гаҗәеп зур эш башкарган. Әдипнең төрле елларда язылган мәкалә-уйланулары 1984 елда «Җырларда — ил гаме», 1998 һәм 2001 елларда «Сайланма әсәрләр»енең дүртенче һәм бишенче томнарында, 2004 елда Татарстан Язучылар оешмасының 70 еллыгы уңаеннан фундаменталь

хезмәтләрдән саналырлык «Гыйбрәтләр алырлык үткән юл», 2005 елдагы «Сайланма әсәрләр»енен дүртенче, бишенче, алтынчы томнарында урын алган. 2011 елда исә Р.Фәйзуллинның соңгы дәвердә язылган публицистик мәкаләләрен туплаган «Илбагар уйлар» китабы дөнья күрде.

Равил Фәйзуллинның соңгы еллардагы публицистик эшчәнлегенә билгеле бер йомгак булып торган «Илбагар уйлар» китабының «Гыйбрәтләр алырлык үткән юл» дип аталган тәүге бүлеге Татарстан Язучылар берлеге тарихын ачыклауга багышланган. Бу хакта, миңа калса, Р.Фәйзуллиннан да күбрәк белүче, төпле фикер әйтүче юк та сыман. Шагыйрьнең фәнни дәрәҗәләре юк, әмма ошбу басма теләсә кайсы фән эшлеклесенең хезмәте белән тиңләшә ала (бу очракта, заманында Р.Фәйзуллинның аспирантурага керүен, ләкин диссертацияләр белән «вакланып» тормавын искә төшереп китү урынлы булыр. Күрәсең, Шагыйрь үзенең кемлеген эчтән сизенгәндер: 2007 елда ул Татарстан Фәннәр Академиясенең почетлы академигы итеп сайланды). «Илбагар уйлар»да фактик материалдан бигрәк, шагыйрьнең фәлсәфи уйланулары күбрәк урын алган. Киң җәмәгатьчелек өчен җавап бирә алмыйм, әмма филология белгечлеге буенча белем алучылар өчен бәһасез хезмәт бу. Күпме төгәл саннар, күпме исем-фамилия, стенограмма язмалары... Мәктәптә булмасын, институт-университетларда булмасын, без конкрет әсәрләр һәм авторлар турында күбрәк сөйлибез, шул ук вакытта әдәби тормыш, илдәге вазгыять, теге яки бу шәхес, фактлар арткы планда кала. Аерым затларның, җитәкчеләрнең, хакимиятнең әдәбиятка, аерым алганда, татар сүз сәнгатенә караш-мөнәсәбәте хакында Р.Фәйзуллин тәфсилләп яза. Чыннан да, «татар әдәбияты дигән зур дәрья турында фикер йөрткәндә, гыйбрәтләр алып уйланыр нәрсәләр җитәрлек». Шунысы мөһим, автор Татарстан Язучылар берлегенең оешуыннан алып бүгенгесенә кадәр аерым бер чор-дәверләргә җитди анализ аша килә. Әлбәттә, һәр чорның үз үзенчәлеге. Ләкин нинди генә заманалар булмасын, нинди генә иҗтимагый-сәяси катаклизмнар борчып тормасын, татар әдәбиятының дөнья-ил күләмендә үз урыны булуы, татар язучыларының СССР масштабында авторитеты, дәрәҗәсе барлыгы хакыйкый факт буларак раслана. Р.Фәйзуллинның бу юнәлештәге өйрәнүләре әнә шул яктан да бәһале.

Милли сүз сәнгатенең тарихы һәм бүгенгесе, киләчәктәге перспективалары хакында уйланулар икенче бүлектә дә дәвам итә. Чыннан да, яшисең икән, уйланмый хәлең юк. Уйланган саен, тормышның ал да гөл булмавы, проблемаларның гаять күплеге ачыклана. Р.Фәйзуллинның уйлар дәрьясы да киң планда: ул тарихның иң борынгы катламнарына да кереп китә, галәм киңлекләрен дә айкап чыга, СПИД, наркомания кебек зәхмәтләргә дә туктала, сәясмәннәр генә фикерләргә тиеш тоелган мәсьәләләрне дә күтәрә, неомальтусчылык кебек төшенчәләрне дә читләтеп үтми. Ләкин фикер йомгагы барыбер милли яшәешебезгә, Галиҗәнап Әдәбиятыбызга, телебезгә килеп тераләя. Ахыр чиктә, кискен нәтиҗәләр ясарга да ятсынып тормый. Әйтик, «татар китабының, гомумән, матбугатының, бүгенге хәле күңел күгәртерлек дәрәҗәдә мөшкел. Үзеннең кирәксезлеген тою — һәр талант, гомумән һәркем өчен, иң авыр тойгыларның берсе», дип яза автор.

Юк, Равил Фәйзуллинның күңелен һич кенә дә өметсезлек хисе басып алган дип әйтеп булмый. Ул бары тик хакыйкать (кызганыч ки, еш кына ачы хакыйкать) хакында яза. Китаплар укылмавы, татар мәктәпләре ябылуы, яшәешебездә башка кыйммәтләр (шуның иң-ине — акчага табыну, акча колына әверелү, бар нәрсәне, хәтта язучылык белән шөгыльләнүне дә бизнеска гына кайтарып калдыру) барлыкка килүе, иҗат кешеләренең мөшкел хәле, хәтта ки мескенлеге — хакыйкать түгелмени? Шул ук вакытта авторны өмет яшәтә. Барлык диярлек мәкаләләрнең ахыры өметле (кайчак хыялый?) җөмләләр белән тәмамлана.

Шагыйрь-гражданин парадокслар дөньясы турында күп яза. Бер яктан, китап гасыры узып баруын искәртә, икенче яктан Казаныбызда гына күпме нәшриятлар барлыкка килүе, китапларның күпләп чыгуын да таный. Араларында затлы, югары кыйммәткә ия булганнары да җитәрлек, ләкин «алар, кызганыч, азрак кирә йорт төрләренә». Күпчелек исә «иң аз дигәндә, өчтән икесе — псевдокитаплар, полиграфик ысул белән кәгазьгә төшкән опуслар...». Тагын бер парадокс: «җәмгыятьтә акча

күп тә, акча юк та! Галәмәт күп баскычлы, күп пирамидалы идарә структурасы кешеләренә акча бар һәм мул бар, гади игенчегә — юк; хоккей, машина куу ярышлары өчен акча бар, милли университет ачарга, күп кенә талантлы әдипләрнең китапларын чыгарырга — юк; башкаладан килгән ярымшәрә, ярымнаркоман «поп-йолдызлар»га астрономик суммалар бирер өчен акча бар, ә өлкән бер хөрмәтле язучыга каләмхак түләргә — юк...». Автор шул тискәре күренешләрне бәян итеп кенә калмый (барыбыз да күреп тора ич!), ә аларның сәбәбе, алшарты, ниләргә китерәчәге хакында ныклап уйлана.

Туган тел турында язылган аерым мәкаләләрендә дә («Иле барның теле бар», «Тел бирмәк — җан бирмәк»), башка язмаларында да татар теле Р.Фәйзуллин өчен иң бөек кыйммәт икәнлеген аңлавы кыен түгел. «Ананың балага биргән иң зур бүләге — тел. Шуңа да ул байлык, хәзинә санала». Яки: «Тел — диңгез. Бер ясканып кына аның тирәнлегенә төшеп, кинлекләрен иңләп бетереп булмас». Савыктыру һәм дәвалау турында уйлана икән, димәк, Р.Фәйзуллин телебез халәтенә үз диагнозын куйган. Шулай ук хакыйкый диагноз. Чыннан да, хәлләр әллә ни шатланырлык түгел. Төрле дәрәҗәдәге сәясмәннәрнең телебезгә мөнәсәбәтен дә өйрәнә, Илбашы В.Путинның Казан юбилеенда татарча сөйләшүен дә искә алып уза. Шуннан чыгып автор хәлнең гаять аяныч, хәтта ки куркыныч икәнлеген яшерми: «халкың тулысы белән үз телендә сөйләшә икән, ул — тулы милләт, яртысы сөйләшә икән — ярты-йорты милләт, ә биштән бере сөйләшсә...». Ахыр килеп, Р.Фәйзуллин тел язмышы халыкның дәүләтле булуына бәйле дигән катгый хөкемен чыгара. Кызганыч, дәүләтле булу — ул әле дә татлы хыял гына. Шуңа бәйле шагыйрьне борчыган сорауларның тагын берсе калкытып куела: телен кирәкми икән, язучылар-шагыйрьләр, матур әдәбият, китапларның кемгә хаҗәте бар соң? Хәлне үзгәртү нисбәтеннән милләт шагыйре үзенең конкрет тәкъдимнәрен дә яңгырата. Бар да конкрет, бар да аңлаешлы. Халкыбызны, телебезне таныту өчен мөмкинлекләр дә чыгып тора, ләбаса. Универсиада кебек планетар масштабтагы чараларда татар теленә лаеклы урын табылмаса, бу, һичсүзсез, гафу ителмәслек гөнаһ, хата булачак. Р.Фәйзуллин инде бөтенләй башка рәвешкә килгән Казан дәүләт университеты юбилее һәм Казанның меңъеллыгы хакындагы уйлануларында да, «Болгар» номерларының җир йөзеннән юкка чыгарылуына багышланган, исеме үк («Сүтеләбезме?») уйланырга мәҗбүр иткән язмасында да әнә шул хаталарны кабатламаска чакыра. Ә алар, кызганыч, һаман кабатланып тора...

«Илбагар уйлар»ның өченче бүлеге аерым шәхесләргә багышланган. Өйрәнү объектлары гына да кемнәр бит: Тукай, Җәлил, Н.Исәнбәт, Г.Афзал, С.Хәким, Г.Ахунов, Ш.Хөсәенов, Ф.Яруллин, М.Әгъләмов, Ә.Еники... Язмаларның аерым берәүләре әдәби портретлардан бигрәк фәнни-тәнкыйди мәкаләләрне хәтерләтә. Бу нисбәттән, бигрәк тә Гамил Афзал, Рабит Батулла, Рауль Мир-Хәйдәров, Рәшит Әхмәтҗанов, Ренат Харис, Айдар Хәлим, Рәмис Аймәт, Салих Баттал (без бөтенләй белмибез икән әле), Тәүфикъ Әйди (галимнәр дә тотынырга курка), Лирон Хәмидуллин иҗатлары, Зиннур Мансуровның «Балкыш» поэмасы хакындагы уйланулары филолог-галимнәр дә әйтә алмаган фикер-карашлары белән кыйммәтле. Автор язучылык цехы буенча аркадашларының шәхси үзенчәлекләрен дә, иҗатларын да әйбәт белә, ул аларны укыган, ул аларны өйрәнгән, шуңа да алар



*Бакый Урманче һәм Равил Фәйзуллин. 1985 ел.*

төгәллеге белән аерылып тора. Шушы бүлектәге мәкаләләрне теге яки бу шәхеснең иҗат дөньясын, иҗат лабораториясен өйрәнгәндә дә рәхәтләнеп кулланырга була. Н.Җиһанов, Ә.Кәримуллин, М.Госманов, Р.Фәхретдинов, Ә.Фәтхетдинов кебек башка өлкәдәге «йолдыз»ларыбыз турындагы язмаларны укыганда, шагыйрь-әдәбиятчының ул өлкәләрдә дә үзен судагы балыктай хис итүенә сокланмый мөмкин түгел.

Китапның дүртенче бүлеге Р.Фәйзуллинны журналист буларак ача. Милли матбугатның флагманы саналган «Казан утлары» журналын чирек гасыр җитәкләү өчен, әлбәттә, яхшы шагыйрь (Халык шагыйре!) булу гына җитмидер. Кешеләр белән сөйләшә-аралаша, уртак тел таба белү осталыгы да, әңгәмәләр кору, кирәк чакта гражданлык позицияләренне күрсәтә белү һәвәслеге дә булырга тиеш. Р.Фәйзуллинның әңгәмәдәшләре дә килде-китте кешеләр түгел. Аңлашылганча, ошбу әңгәмәләр дә татар халкы, милли вазгыять, әдәбият-сәнгать, матбугат хакында. Әлбәттә, әңгәмәдәшләрнең аерым фикерләре белән килешү-килешмәү дә бар.

Шул ук бүлектә Халык шагыйренең үзе белән дә әңгәмәләр урын алган. Рәфикъ Юнысның кереш сүзе, сораулар һәм җаваплар без белеп бетермәгән Р.Фәйзуллинны шәхес ягыннан күбрәк ача. Р.Вәлиев белән әңгәмәсенең ахырында героебыз «вакыт җитте бугай — истәлек-хатирәләр дә язасы килә» дип белдерә. Бик кирәкле гамәл булыр иде. Татар дөньясында документаль-биографик характердагы язмалар азрак. Китапның соңгы бүлегендә Равил Фәйзуллин укучыны Табигать-Анага якынайта. Даңлы (һәм шаңлы) Чулман елгасыннан ерак түгел бер авылда туган җир һәм су кешесенең, аерым әдипләр язганча, Идел һәм Казансуны буйга инләгән шагыйрьнең табигатькә елышуы, табынуы гаҗәп түгел. Шагыйрь сәфәре барышында туган фәлсәфи уйлануларын көндәлек рәвешендә, «сәяхәтнамә» жанры үзенчәлекләренә тугры калып, гаять кызыклы, мавыктыргыч итеп бирә алган. Сәяхәтнамә дигәннән, Равил Фәйзуллинның бу өлкәдәге хезмәте дә өйрәнүгә лаек дип саныйбыз. Бу исә «Фәйзуллин феномены»н билгеләүдә янадан-яңа ачышлар булачагына янә бер ишарә.

Равил Фәйзуллин публицистикасы жанр ягыннан да төрле. Югарыда аталган җыентыкларда аның төрле темаларны яктырткан фәлсәфи язма-очерклары, нәсер-парчалары, әдәби портретлары, хатирә-уйланулары, әңгәмәләре, сәяхәтнамәләре урын алган. Аларда шагыйрь узганыбызга, бүгенгебезгә һәм киләчәккә багып, әдәбиятыбыз, сәнгатебез, тарихыбыз, матбугатыбыз, күренекле шәхесләребез..., кыскасы, милли яшәешебез хакында уйлана. Һәр язмасында диярлек нәрсәнедер чагыштыра, кемнәр beләндер бәхәсләшә, җитди нәтиҗәләр ясый, өметләнә, хыялллана. Иң мөһиме, китап укучыны үзе белән тиң күреп сөйләшә һәм ышандыра! Ахыр чиктә, публицистикасында Равил Фәйзуллин дигән олы Шәхес тагын да тулырак ачыла.

**Радик САБИРОВ**

Хәлил
Шәриф

# КҮҢЕЛ АВАЗЫ яки МЕҢ ДӘ БЕР СОРАУ

ЭССЕ

Менә ничә еллар инде мин төшемдә бер үк төрле күренешләр күрәм: имеш, эңгер-меңгер. Мин җәяүләп район үзәгеннән туган авылыма кайтам. Сазтамак дигән урынга җитү белән каршымда авыл өйләре, күп катлы корылмалар пәйда була, әллә нинди шомлы авазлар ишетелә башлый. Мин яшеренәм, урман сукмакларында буталып бетәм.

Кайвакыт шулай адашып йөри торгач, Сазтамакта үз өебезгә юлыгам, анда ниндидер эшләр белән мәшгуль булган әниемне, апаларны, энемне күрәм. Әмма шулай булуга да карамастан, һаман да туган авылыбызга омтылам, анда да өебез барлыгын онытмыйм.

Киресенчә дә булгалый. Мин туган авылыбыздан район үзәгенә барам. Әмма шушы Сазтамак дигән урынга җиткәч, кабат әлеге хәлләр башлана. Мин берничек тә ошбу җирне тыныч кына үтеп китә алмыйм, яңадан эңгер-меңгер шомлыгыннан, билгесез кешеләрнең эзәрлекләвеннән качып йөрим.

Төшемдә Сазтамакны Тол елгасы ягыннан урап үтәргә дә омтылып караган бар. Тик бередәге тауларда да зур-зур авылларга очрыйм.

Сазтамак безнең авылдан ике чакрымнар төньяктарак урнашкан, янәшәсендә калкулык та бар. Аның аша үтә торган юл буенда борынгы зиярат саклана. Истәлекләргә караганда, башта авылыбыз шул урында урнашкан булган. Әмма елга юнәлешен үзгәртү сәбәпле, ул хәзерге урынына күченгән. Ә елганың элеккеге эзеннән хәзер язларын бары тик кар сулары гына ага.

Бу хакта еш кына уйланам: ни өчен соң мин бер үк эчтәлектәге төшләр күрәм икән? Мондый хәл минем тормышым, эчке кичерешләрем белән бәйләнгәнме? Алай дисәң, минем Сазтамак турында берни дә уйлаганым юк бит. Үз гомеремдә аңа бәйле куркыныч хәлләр, маҗаралар да кичермәдем. Дөрес, район үзәгендә эшләгәндә аның аша караңгы чакларда җәяүләп үтәргә туры килә, калкулыкның урман ягыннан Тол елгасына кадәр сузылучы агачлык өлешендә төлке, куян да очраштыргалый иде. Һәм, билгеле, андый көтелмәгән чакларда сискәнеп тә китәсең. Әмма бу шул мәлдә үк онытыла да иде.

Берчакны район үзәгенә Пермьга чыгучы автомашина юллап бардым. Авылда яңа йорт җиткерәбез. Акчага кытлык чак. Шул сәбәпле, базарга бәрәңге илтергә уйладык. Кайтканда район үзәген чыгып Әрҗән авылына керүгә мотоциклның арт тәгәрмәче әйләнмәс булды. Аны якындагы йорт ишек алдына кертеп калдырдым. Октябрь ае иде. Кич. Бераз түңдырган. Караңгы төште. Сазтамакка җитәрәк арттан ат чабып килгән тавыш ишеттем. Туктап көтеп торам. Караңгылыктан алмачуар атка атланган бер агайны шәйләдем. Мин нилектәндер сискәнеп киттем һәм, куркуымны сиздермәс өченме, үзем дә сизмәстән: «Мине дә атландыр», — дип кычкырдым. Ул берни дәшмәде. Һәрхәлдә, истә калмаган. Ул ничек килеп чыккан булса, шулай тиз генә

Сазтамак әрәмәлегенә кереп тә югалды. Мин: «Малларын эзли, ахры», — дип уйлап куйдым. Әмма күңелдә сәерсенү дә калды: мал эзләсә, нигә миннән сорамады икән?

Сүз артыннан сүз чыгып, шул хакта хәстәханәдә булганда әбиләргә сөйләгән идем. Алар моны яхшыга юрады.

Яши-яши уйландыра икән. Кайбер хәлләрне хәтердә яңартасың да, ул минем тормышымда очраклы гына булмаган, ахры, дип уйлап куясың. Чөнки бу вакыйга еш кына моннан алдагы хәлләргә бәйләнгән була.

Ә минем төшләремә нәрсә сәбәпче? Күңелемне борчыган уй-фикерләрме? Эчке халәтемме? Әйтик, мин туган авылымны, яшәгән нигезебезне сагынып яшимме? Юктыр. Һөнәрем башлыча шәһәр белән бәйләнгән. Көннәрем йөз төрле мәшәкать белән үтә, кайвакыт авыл турында уйларга да вакыт калмый. Аннары мин авылны сагынырга да өлгермим кебек. Чөнки әни янына еш кайтам. Язын бакча эшләренә, җәен печәнгә, көзен бәрәңге җыярга. Кышын исә сугымга.

Әмма авылда булганда, ни сәбәпледер, шәһәр онытыла башлый. Анда яшәвем төштә генә күк тоела. Ә шәһәргә кире килгәч, кабат мәшәкатьләргә күмеләсең, барсы да кире үз урынына кайта.

Шулай да мин шәһәрдә үземне вакытлыча итеп тоям, ахрысы. Чөнки минем табигатемә авыл тормышы күбрәк туры килә кебек. Шәһәрдәге тыгызлык, кызу темп мине тиз йончыта. Ә шәһәрдә мин мәшәкатьләр булганга гына яшим, чын-чынлап авылга кайткач тормыш итә башлармын төсле тоела. Әмма көннәр үтә. Мин шул җайланган тормыш агымына каршы бара алмыйм, аның буенча агуымны дәвам итәм. Һәм тирә-ягымда да шуңа охшаган хәлләр күрәм. Авыру халәтенә төшкән, гаиләләренә газап булып яшәүче эчкечеләр моны юри генә эшлидер, килер бер көн — алар сискәнеп китәрләр һәм аек тормыш белән яши башларлар төсле. Әмма көннәр үтә, эчкечелеккә сабышучылар шул хәлдә дөньядан китеп тә баралар.

Кеше булачак хәлләрне, үзенә юнәлтелгән кисәтүләрне сизә аламы? Минем төшләрем бүгенге тормыш, киләчәк белән ни дәрәҗәдә бәйләнгән? Алардан мин үземә нинди дә булса нәтиҗә ясарга тиешме?

5-6 ел элек печәнгә кайтуыбыз сузылды. Шул чакны төш күрдем: әни мине ачулана. Бу хакта энемә сөйләдем. Ул да нәкъ шундыйрак төш күргән икән. Кайткач, әнидән: «Безне озак кайтмыйлар дип ачуланган идеңме әллә?» — дип сорадык. Әни: «Болытлап тора, куркыта. Әйе, бик борчылган идем шул», — диде.

Әлбәттә, бу очракта төшне юравы әллә ни кыен түгел. Аны әлеге хәлгә бәйләп аңлатырга була. Ә менә әледән-әле төшкә керүче авыл турында ни дияргә? Әллә аны геннарга салынган бабаларыбыз истәлеге, аларның авазы дип кабул итәргәме?

Дөрестән дә, үткәннәр бездә ни дәрәҗәдә чагыла? Киләчәкне без бүгенге халәтебездән чыгып билгели, күзаллый алабызмы?

Вакытсыз вафат булган балачак дустым Ильясны уйлыйм да, бу сорауларга күпмедер җавап тапкан кебек булам. Ул кечкенә вакытында агач башларына, өй түбәләренә менәргә курка иде. Казанның бер фабрикасы цехына ремонт үткәргәндә биектән егылып, 35 яшендә ошбу фани дөньядан китеп барды.

Без үткәнәрдән килүче һәм күңелебездә сакланучы күп хәбәр-серләргә битараф яшибез ахрысы. Аларны аңларга, хәл итәргә омтылмыйбыз. Бары эш узгач кына буласы хәлне күңелнең ничектер сизгән булуына төшенәбез.

Инде олыгая төшеп шактый тормыш тәҗрибәсе тупласам да, балачакта кичергән кайбер хәлләргә әле һаман җавап таба алмыйм. Алар, шул сәбәплеме, онытылмыйлар, киресенчә, башка сораулар белән бергә күңелдә яңаралар.

....Безнең өйдән ерак түгел әрәмәдә кап (мунчала капчык) сугучыларның барагы урнашкан иде. Әни шунда җыештыручы булып эшли. Мич ягарга төн уртасында ук керә. Еш кына: «Куркыта, төн уртасы үткәч, чаң кага башлыйлар», — дия иде. Берчакны мине — сигез яшьләрдәге малайны уятып үзе белән алып керде. Барак эчендә мунчалаларны, сугылган капларны карап йөрим. Әни мичкә

яга. Бер заман ап-ачык итеп чаң каккан тавыш ишетә башладым. Нәрсә бу? Баракта радио юк. Булса да ул төнлә сөйләми. Ерактан ишетелә дияр идең, безнең күрше-тирәдә татар авыллары гына. Районның читләрендә урнашкан урыс авылларында да чиркәү юк. Бу ишетүем әнием сөйләгәннәр тәэсирендә куркудан тугандыр дияр идең, әмма мин ул чакны куркырга да өлгермәдем. Әнисе янында кайсы бала курку турында уйласын инде. Җитмәсә, мин чаң тавышын әнидән алдарак ишетә башладым.

Юк, мин бүгенге көндә бу вакыйгага җавап та эзләмим кебек. Аны фәкать алдагы вакыйгаларга бәйле рәвештә генә искә төшердем. Чөнки еллар үткән саен күңелдәге сораулар кимеми, яңалары исә өстәлә тора. Аларның күбесенә җавапны вакыт та биреп бетерә алмый, ахрысы.

Мин узган тормышымнан, туплаган тәҗрибәмнән чыгып киләчәкне ни дәрәҗәдә күзаллый алам? Яшәвем барышында миңа алга омтылыш, үрнәк булып нәрсә хезмәт итә? Бездән алдагы буыннарның яшәү рәвешеме? Ата-анаммы, әллә аерым шәхесләрме? Шул хакта уйласам, картәтине искә төшерәм. Ул мин белгәндә инде ап-ак сакаллы, шаяртыбрак сөйләшергә ярата торган уртача буйлы бер карт иде. Зур ихласлылык белән дин тотты. Әни еш кына аның хакында, ул хәзрәткә тапшырылган, дия иде. Мин бу сүзнең мәгънәсен соңрак кына аңлый алдым: картәти тәрикат юлында булган икән. Суфыйлык аның көнкүрешендә дә ачык чагылды. Чөнки картәти бик тыйнак тормыш алып барды. Ул яхшы агач эше остасы иде. Теләсә, тормышын мулрак та алып барган булыр иде. Әмма ул моны теләмәгән. Тормыш итү дәрәҗәсенең күңеле рөхсәт иткән бер кимәлендә тукталган. Әлбәттә, картәти моны аңлы рәвештә нәфсесен тыеп, күңелен фәкыйрьләндермәс өчен эшләгән булырга кирәк.

Әни дә яшәеше, холкы белән картәтинең тормышын кабатлады. Ул бер гади авыл хатыны. Әмма шул ук вакытта бик гади дә түгел иде. Дин тыелган елларда да авылыбызда курыкмыйча дини йолалар үтәде. «Азатлык» радиостанциясеннән дини һәм милли тапшыруларны гел тыңлап бара иде. Картая башлагач, тәрикат юлында булуы хакында ачыктан-ачык әйтә башлады, аның үзе ирешкән дүрт баскычын — рухи калеб, рухи зекер, рухи сер, рухи хафый дәрәҗәләрен атый иде.

Аларда булган сыйфатлар миндә ни дәрәҗәдә чагыла? Мин дә миллилекне, динне алар аңлаган кебек аңлыйммы? Әллә замана тәэсирендә генә бу кыйммәтләргә омтыламмы? Күңелемдә аларга ихтыяҗ бармы? Әйтик, мин милли җанлымы? Телем, гореф-гадәтләрем кыерсытылганда үземдә аларны якларлык көч табаммы? Әллә мондый чакларда төрле җәнҗалларга кереп китәрмен диеп үз-үземне тыеп тораммы? Моңа эчтән генә ризасызлык белдерәмме? Гомумән, мин миллилекне дөрес аңлыйммы? Ни өчен мин милләтчеләрнең акцияләрендә бик пассив катнашам? Әллә татар телле газетада эшләвем җитә дип нәтиҗә ясыйммы? Мин үзем болай да милли дип тынычланаммы? Әгәр шулай икән, 1982 елны ук мин ни өчен КПССның Пермь өлкә комитетының җитәкче кадрлар секторы мөдире белән конфликтка кердем? Ул миннән исемемнең урысчага ничек тәрҗемә ителүе хакында гына сораган иде югыйсә. Ә мин моны үземне кимсетү итеп кабул иттем. «Исемнәр тәрҗемә ителми, бу башка милләт вәкиле өчен кыерсыту булып тора», — дип җавап бирдем. Сектор мөдире, күпне күргән өлкән яшьтәге хатын, бу сүзләрне ишеткәч тонын үзгәртте, минем адреска шактый гына авыр сүзләр әйтте. Ул вакытта әле милли уяну да, милли хәрәкәт тә юк иде. Югыйсә мин — Ленинград Югары партия мәктәбенең журналистика факультетын яңа гына тәмамлаган яшь белгеч, бу урында бөтенләй башкача сөйләшергә тиеш идем. Бу адымыма нәрсә сәбәпче булды? Күңелнең әллә кайсы почмагына яшерелгән шул миллилек хисеме? Әллә үз-үземне күрсәтү теләгеме? Миндә аларның кайсысы өстенлек итә? Мин үз милләтемне чын-чынлап ярату югарылыгына күтәрелгәнме? Үз милләтемне генә яратып, башкаларны өнәмимме? Аларга һәрчак сагаеп, ышанмыйча карыйммы? Юктыр. Чөнки миңа төрле шартларда башка милләт вәкилләре, шул исәптән урыслар белән якыннан аралашырга туры килде. Аларның кайберләре белән

бик җылы, эчкерсез дуслык җепләре урнашты. Мин әле аларны хәзер дә күңелемдә матур хатирәләр итеп саклыйм. Мондый дуслык шул сәбәпле урнаша алды: мин алар ягыннан үземә тигез, ихтирамлы караш тойдым. Башкача булганда, ул берничек була алмас иде. Минемчә, һәр кеше үз милләтен яратырга, башкаларны исә ихтирам итәргә тиеш. Мин милләтче дионе шулай аңлыйм, шулай күз алдына китерәм.

Бу урында шундый бер мизгелгә тукталасым килә. 80нче еллар уртасында Мәскәүнең Ленинград вокзалында төнге поезд көтеп утырам. Янымда очраклы пассажирлар. Берсе тумышы белән Украинадан иде булса кирәк. Монголиядә прапорщик булып хезмәт иткән. Икенче ягымдагы пассажир Ростовтан ниндидер институтка командировкага килгән. Әмма эш көнендә өлгермәү сәбәпле кунакханәгә урнаша алмаган. Юк, без бер-беребездән кем булуы, кая баруы турында сорамадык. Бу үзеннән-үзе килеп чыккан әңгәмәбез вакытында очраклы рәвештә генә ачыкланды. Без нәрсәләр хакында гына сөйләшмәдек. Вакытның узганы сизелмәде дә. Читтән караганда безне бик якын дуслар дип уйларга мөмкин иде. Моңа нәрсә дияргә? Милли культура кешедә башка милләт вәкилләренә карата шундый тигез, ихтирамлы мөнәсәбәт тудырырга тиештер, минемчә.

Милләтчелек үзенә тагын нинди сыйфатларны берләштерә? Әйтик, динилек миллилектән аерыламы? Әллә ул милли культураның бер элементы булырга тиешме? Безнең бабаларыбыз бу ике төшенчәне бер-берләреннән аерып караганнармы? Әллә алар күзаллавында милли җанлы кеше дини дип тә кабул ителгәнме? Безнең бүгенге көндә диндә милләт юк диюебез үз теләгебез белән урыслашуыбызны аклау өчен генә кирәк түгелме? Яки ул наданлыктан әйтеләме? Әллә бу — замана таләбеме? Миллилек белән динилек бер-берсеннән аерым-аерым яши аламы? Мондый хәл рухи фәкыйрьлеккә, берьяклылыкка китермиме? Бу безнең милли тамырларыбызны зәгыйфьләндермиме? Без милли киләчәгебезне ни дәрәҗәдә фаразлый алабыз? Әллә бүгенге көн агымы, мәшәкатьләре моңа ирек бирмиме? Ә бит тормыш бер мизгел генә. Мин аны шигырь юлларында болай дип искә алган идем:

*Бер мизгелдә*
*Очкан кар,*
*Искән җил,*
*Шаулаган инеш*
*Баксаң –*
*Ул минем*
*Бөтен бер тулы*
*Гомер имеш.*

Без шул тормышның кадерен беләбезме? Кая омтылабыз, кая шул кадәр ашыгабыз? Үзебезне көтеп торган картлыккамы? Бүгенге көндә иң төп максатыбыз шул киләчәк картлыкны тыныч кына уткәрүгә әзерләнүме? Әллә яшәгән тормыш рәвешебез белән нәселебезгә бер үрнәк калдырумы? Аларга ата-бабаларыбыздан калганны түкми-чәчми тапшырумы? Без моңа ни дәрәҗәдә әзер? Гомумән, без тормышны күзәтәбезме? Аның аерым бизәкләренә тукталып уйланабызмы? Ни өчен картлык кергәч кешедә әллә кайчан онытылып беткән балачак, яшьлек вакыйгалары яңара? Ни өчен 86 яшькә җиткән әнием 50 ел буена яшәгән бүгенге нигезен ят итә? Ул нигә көн дә әллә кайчангы, бала чагындагы өенә кайтырга омтыла? Картәти белән дә шундый ук хәл иде. Ә минем күңелемдә нинди вакыйгалар өстенлек итә? Мин нәрсәләрне сагынам? Балачагымда кичергән бәхетле мизгелләрнеме? Әллә тормышка мөстәкыйль аяк баскач башымнан кичкән күңелле минутларнымы? Минем бәхет төшенчәсен аңлавым еллар дәвамында ни рәвешле үзгәрә? Энем белән офыкта рәшәләр уйнаган җылы язгы бер көндә, кулыбызга тәмле крендельләр тотып, авыл читендәге сулыкта салда йөзүебез ул чакта иң бәхетле бер мизгел булып истә калган. Янсә әнинең больницадан кайтып килүе. Әти миңа 6 яшь чагында ук дөнья куйды. Без өйдә дүрт бала. Минә

берчак әнине дә район больницасына салдылар. Мин көн дә урамга чыгып әнинең кайтуын көтәм. Күңелсез, хәтта уйныйсы да килми. Берчак шулай олы юл ягына баксам, өстенә иске плащ кигән әни кайтып килә. Мин тиз генә каршына йөгердем. Әни мине күргәч түзмәде — елап җибәрде. Ахры, минем балачакның иң бәхетле мизгелләре шулай әни белән бәйләнгәндер. Хәзерге яшемдә дә мин әни белән аралашып, фикерләшеп, «әни», дип дәшеп яши алуыма куанып бетә алмыйм. Бу миңа тормышта насыйп булган иң зур бәхетләрнең берседер.

Әлбәттә, тормышымда борчулы чаклар да күп була. Аларның бер өше теге яки бу максатка ирешә алмау белән бәйле. Еллар үткән саен ул уй-хыялларымның тормышка ашмый калган сәбәпләре ныграк ачыла бара кебек. Мин тормышта бер үк ялгышлыкларны берничә мәртәбә кабатламадыммы? Еллар үтсә дә кешенең фикерләү рәвеше үзгәрмиме, ул шуңа күрә бер үк хаталарны кабатлыймы? Ул ялгышлар яңа формаларда булып торганга, без аларны таный һәм үткәннәре белән чагыштыра алмыйбызмы? Тәкъдир шул буламы? Кешегә салынган холык-фигыль аның киләчәк язмышын билгеләүче факторга әйләнәме?

Еллар үткәч, шул да аңлашыла: сиңа кайчандыр ялгышлык булып күренгән кайбер хәлләр соңрак хәерлегә булып чыга. Шулай булгач, без үзебезгә килгән һәр сынауны сабыр гына кабул итәргә тиешме? Әллә эзләну, бу хәлдән чыгу өчен хәрәкәттә булу кирәкме? Мин тормышта ясамыйча калган ниндидер адымымны ул вакытта ясаган булсам, минем хәзерге язмышым күпкә үзгәрер идеме? Әллә барыбер бүгенгесенә охшаган агымыннан агачак булганмы ул? Минем бер туганым бар: аңа бер эшнең 9 дөрес чишелешен тәкъдим итеп, шуларга бер ялгышын өстәсәң, ул һич тә буталмыйча нәкъ шул ялгышын сайлап ала. Шунлыктан аның бар тормышы диярлек гел ялгышлардан тора. Моны да язмыш дияргәме? Әллә бу фәкать уйланмаудан, фикерләмәүдәнме? Үткәннәргә нәтиҗә ясый белмәүдәнме?

Мин бу сорауларга җавап эзләп артка — үткән тормышка күз салырга тиешме? Әллә киләчәккә төбәлгән уйлар белән генә яшәргә бурычлымы? Узган тормышымны, яшәү рәвешен анализламыйча киләчәкне күзаллый аламмы мин? Гомумән, мин аны күзалларга тырышаммы? Ни өчен кайбер мәлләр еллар үтсә дә күңелдән җуелмый? Яшьлектәге җавапсыз мәхәббәт хакында ни әйтергә? Акыл инде аны күптән онытырга теләсә дә, ул ни сәбәпле хәтердә яңарып тора соң? Нәрсә, ул минем өчен шундый зур тетрәнү булганмы? Әллә мин шул вакыттагы ясамаган адымнарым, кыюсызлыгым өчен үкенәмме? Яки ул минем үзем өчен уйлап чыгарылган реаль тормыштан аерылган, хыялда гына яшәргә тиешле ярату образымы? Мин шуның тәэсирендә үземнең янәшәдәге чын мәхәббәткә лаекларны күрә алмадыммы? Яки бүгенге көндә дә аларны күрмиме? Ул образ миңа сөю чынбарлыгын гадәти тормыштан югарырак күтәрү, хисләнү өчен кирәк идеме? Ни өчен мин ул вакытта аның өчен көрәшмәдем соң? Көрәшеп мин аңа ирешкән булсам, күңелемдә тагын шундый бер яңа образ туа алыр идеме? Кеше аларны ясалма рәвештә уйлап чыгармыймы? Тормышның һәр көне шулай эзләнү, көрәшме? Алдыбыздагы ниндидер максатка ирешергә теләвебез, мәшәкатьләрне җиңүебез шуның белән бәйләнгәнме? Әллә без тыныч кына шул җайга салынган тормышыбыз буенча гына агарга, гадәти булмаган адымнар ясамаска, язмыштан узмыш юк дип тыныч кына яшәргә тиешбезме? Алга омтылыш булмаса, ул безнең яшәү энергиясен сүлпәнләндермәсме? Гомумән, еллар үтү белән тормышка мөнәсәбәт тә үзгәрәме? Яшәешебез чорында безне иң гаҗәпләндергәне һәм сокландырганы ни? Табигатьнең искиткеч төзек һәм матур булуымы? Әллә башка нәрсәме? Әйтик, хатын-кыз гүзәллегеме? Сабый балалар матурлыгымы? Яки матди байлыкмы? Аерым шәхесләрнең рухи дөньясымы? Дөньяга алар күзе белән карауммы? Минем үз тормышым, рухи дөньям башкаларда нинди тәэсир тудыра? Мин бу хакта уйланаммы? Әллә ул минем өчен барыберме? Минем үз яшәү фәлсәфәм, юнәлешем башкаларга комачаулык итмиме? Яки, киресенчә, үз проблемаларыма, уй-хыялларыма артык бирелеп көндәлек тормышта мин туганнарыма, якыннарыма игътибарсызлык күрсәтмиме?

Тормышта мин омтылган төп максат нидән гыйбарәт? Сабыр гына картлыкны каршы алып, аны күңел тынычлыгы белән үткәрүме? Әллә инде яшь барса да һаман яңа мәшәкатьләргә күмелеп бик тирән уйланмыйча яшәүме? Яки киресенчәме? Үземнән соң ни дә булса калдырумы? Ирешелгән уңышларымны күбәйтергә тырышумы? Минем бу уй-хыялларым тормыш агышына карап үзгәрәме? Мин дөньяны һәрвакытта да бер үк төсле итеп кабул итәмме? Яки аның да үзгәрүен тояммы? Моны табигатьтә дә күрәмме? Мәсәлән, безнең балачак үткән Тол елгасы буйлары хәзер дә минем хәтеремдәгечә сакланамы?

Юк шул. Без уйнап үскән әрәмәлекләр мелиорация программасы буенча юкка чыгарылды. Авылыбыз янындагы без суга чума торган Тол елгасының биек ярлары да юк инде — җир белән тигезләнде. Чөнки язгы ташкыннар йогынтысында ул җимерелә бара иде. Тол да үз агымы юнәлешен үзгәртте. Хәзер аның элеккеге урынында ерып чыккысыз булып таллар гына үсә. Мин Тол буенда йөрим. Тол елгасы шулай безнең балачактагы шикелле тыныч кына ага. Әмма ул миңа хәзер ятрак, әллә ничек уйчан булып тоела. Ваемсыз үткән балачагым калган болыннар буйлап үтәм. Әмма күңелгә әллә ничек ямансу. Тол елгасы да, аның ярлары да, яр буендагы агачлары да мине танымаган кебек. Мин үземне бередә әллә ничек ялгыз тоям. Шигырем юлларындагыча:

*Тол буенда:*
*Балачагым,*
*Шатлыкларым,*
*Шуклыкларым –*
*Барсы истә.*
*Тик Тол үзе*
*Башка инде –*
*Мине таный*
*алмый*
*Һич тә.*

Һәм иң аянычы — бередә бергә уйнап үскән Ильяс дустым бу дөньяда юк инде. Әйе, вакыт үтү белән тормышта шулай югалтуларны күбрәк тоясың кебек. Алар йөрәкне әрнетә. Яшь чагында сискәндергән күренеш-бизәкләр дә, аерым сүзләр дә инде күңелне ул кадәр кузгатмый. Искитәрлек маҗаралы балачак вакыйгалары да инде әзләп-әзләп күңелдән җуела. Мин аларны үсмер егет чагымда сәгатьләр буе энемә сөйли идем. Ул аларны тыңларга бик ярата торган иде. Аның киңәше белән мин аларның кайберләрен язып та карадым. Әмма энем аларны укыгач: «Син сөйләгәндә бик кызыклы чыга. Мин үзем андый хәлләрне бер дә хәтерләмим. Ә менә язганнарың ул кадәр тәэсир итми», — дия торган иде. Ә минем бик тә берәр зуррак әсәр язып карасым килә. «Таң»газетасы редакциясендә эшләгәндә берчак шул максат белән ял йортына путевка алдым. Анда бер үҗәтлек белән шул эшкә тотынып карадым. Тик нигәдер язганнарым үземә ошамый иде. Алар артык ясалма булып чыга. Мин шул вакытта кешенең башкаларга сөйли алмый торган, үзе өчен генә булган серләре бар икәнен аңладым. Әмма мин бик яшь идем, шуңа күрә бу каршылыкны үтә алмадым, шушы хәлдә язудан тукталып торуны өстен күрдем. Әмма ял йортына баруымның файдасы булды: бередә танышкан бер нефтьче-геолог җитәкче ярдәмендә өебезне эшләгәндә бер машина цемент ала алдык. Ул вакытта кибетләрдә төзелеш материаллары сатылмый иде әле.

Әни колхоз әгъзасы булмаса да, аны кыр эшләренә чакыралар. Ул андый чакларда утау һәм йолку өчен җитен җире ала. Ә анда без эшлибез. Үземнән өч яшькә яшь булган энемә күңелсез булмасын дип шундый чакларда мин аңа үзем уйлап чыгарып әкиятләр сөйли идем. Алар ни дәрәҗәдә кызык булгандыр, әйтә алмыйм, әмма энем көлә-көлә тыңлый иде. Шулай аңа

әкиятләр сөйләү моннан элегрәк башланды. Кышкы салкын көннәрдә энем белән мич башында утырабыз. Һәм мин аңа күңелсез булмасын өчен шулай әкиятләр уйлап чыгара торган идем. Ул бик күңелле итеп көлә. Безне ишетеп әни дә килә: «Миңа да сөйләгез әле», — ди. Мин әни алдында әкиятләр сөйләргә оялам — туктап калам. Энем моны күреп әнине куа башлый иде. Кызганычка каршы, ул әкиятләрнең берсе дә истә калмаган. Алар шулай җиңелчә генә күңелдә туып, шунда ук истән дә чыкканнар. Чөнки максат шундый булган. Хәер, моның миңа үзем өчен тәэсире булды: инде шактый тормыш тәҗрибәсе туплаганнан соң балалар өчен берничә әкият китабымны чыгара алдым. Аларның берсе Татарстанда игълан ителгән ел конкурсында икенче урынны яулап алуга да ирешә әле.

Язарга омтылу уе үзем дә сизмәстән көтелмәгәндә булды. Мин дүртенче класста укыганда нindидер көч тәэсирендә дүрт юллык шигырь яздым. Ул болай иде:

*Умырзая үсә ак кар кебек*
*Киң болыннар ап-ак булалар;*
*Әйтерсең лә ак кар яуган кебек*
*Ап-ак булган бөтен болыннар.*

Мин бу шигыремне укытучыма күрсәттем. Ул аны укып карады да: «Юк, моны син язмагансыңдыр», — диде. Шуннан соң мин укытучыларыма бер язмамны да күрсәтмәдем. Хәзер истә калмаган — кемнеңдер киңәше беләнме, әллә үзем уйлапмы, мин аны «Яшь ленинчы»газетасына юллаганмын. Аннан Рабит Батулла имзасы астында миңа өметле генә хат килде. Мин шуның тәэсирендә шигырь яза башладым. Шул шигырьләремнең берничәсе «Ялкын»ның «Чаткы»конкурсында да җиңеп чыккан иде.

Әлбәттә, ошбу беренче шигырем бүген миңа ошамый. Мин алдагы беренче ике юлда әйтелгән фикерне соңгыларында кабат әйткәнмен. Әмма аларда күпмедер дәрәҗәдә шигъри күзаллау чагылган булса кирәк. Рабит ага шуны тоеп миңа бераз өмет бирә торган хат юллауны кирәк санагандыр. Һәрхәлдә, мин аңа ошбу җавабы өчен гомер буе рәхмәтле булдым...

Артка — узылган тормыш елларына борылып карасам, бик әз эшләнелгәнен күрәм. Алар күбрәк башка мәшәкатьләр белән узган. Әни яшәгән хуҗалыкны яңартырга туры килде. Аннары үзебезнең тормышны. Хисләргә бирелеп, хыял-уйларга күмелеп утырырга һич тә мөмкин булмады. Ә мин мәшәкатьләр өстә торганда зуррак эшләргә, аеруча иҗатка тотына алмыйм. Холкым шундый. Шуңа күрә минем тормышымда күбрәк әнә шул мәшәкатьләрне хәл итү өстенлек итте кебек. Әмма болар аклану гына түгелме? Ни өчен мин пассиврак тормышны өстен күрдем? Мин активрак була ала идемме? Үзгәртеп кору елларында зур өметләр белән Чаллыга килгәч, үзем дә бик дәртле, энергияле, еллар буена җыелып килгән нәфрәт-ачуны бергә туплаган, максаты белән үзе дә ныклап аңламаган билгесезлеккә омтылган милли хәрәкәткә чумармын төсле иде. Тик миңа нәрсәдер җитеп бетмәде, комачаулады, нindидер көч мине тыеп торган кебек булды. Чаллыга яшь белгеч булып миңа кадәр урнашкан энем дә бу хәлгә бераз ризасызлыгын белдергән иде. Әйе, мин озакламый шәһәрдә оешкан татар газеталарының берсен җитәкләдем. Милли хәрәкәттә шул рәвешчә якыннан катнаша башладым. Әмма күңелдә нindидер канәгатьсезлек яшәде. Ахры, ул милли хәрәкәттәге кайбер лидерларның үземә ышанып җитмәве, шик белән каравы аркасында булгандыр. Бәлки, үзем дә аңламаган башка сәбәптәндер. Милли хәрәкәт таркалды, аның җитәкчеләре кем кая таралып беттеләр. Бер өлеше инде бу якты дөньяны да калдырып китте.

Милли хәрәкәтнең массовый акцияләрендә катнашучы милләттәшләрнең бер өлеше мәчетләргә тартылды. Алар хәзер намаз әһелләре. Менә мин дә сайлаган юлымнан һич читкә тайпылмыйча, татар телендәге «Ислам нуры» дигән дин газетасын җитәклим. Аны Русиянең 30 дан артык төбәгендә яздырып алып укыйлар. Максатыбыз — милләттәшләребезнең туган телебездә укуга

булган ихтыяҗын канәгатьләндерү, аларга дин гыйлеме бирү. Бүгенге көндә дә милләтебез мәнфәгатьләре өчен булган шундый эшләрдә катнашуым белән үземне милли хәрәкәттә итеп тоям. Минемчә, ул күтәренкелек елларында баш калкыткан милли хисләребез юкка чыкмады, яңадан күңелебезгә яшеренде генә. Килер бер заман, ул яңадан калкып чыгар, милләттәшләребезне яңа рухи эзләнүләргә, милләт мәнфәгатьләрендәге зур эшләргә этәрер.

Әмма мин бүгенге көндә миллилек турында тыныч кына уйлана алмыйм. Ошбу сүзне ишетү белән йөрәкне нәрсәдер кысып ала. Эшләмәгәннәребез бик күңелне әрнетә, үкендерә. Көчсезлегебез, үзебез теләп урыслашуыбыз күңелне борчый. «Бу бит тәрбиясезлек, милли культурабыз түбәнлеге билгесе бу!» — дип кычкырасым килә. Алай гына да түгел, бу — бабаларыбызга хыянәт, аларның гасырлардан-гасырларга югалтмыйча үзебезгә китереп җиткергән рухи байлыкларын санга сукмау. Тәкәбберләнү. Һәр кеше үз милләтен яратырга тиеш. Милләттәшләребездә милли хис, культура тәрбияләү өчен бездә кадрлар да, моның өчен җитәрлек күләмдә акча-фәлән дә юк шикелле. Аяныч. Әмма шушы шартларда да без булдыра алганча көрәшергә бурычлы. Ә бит безгә бу мәсьәләдә үрнәк булырлык милләтләр бар. Башкорт туганнарыбыз авыллардан сәләтле балаларны җыеп, махсус интернатларда тәрбиялиләр, аларны киләчәктә дәүләт структураларында эшләү өчен әзерлиләр. Бөтен яктан төпле белем бирелү белән бергә аларда милләткә хезмәт итү теләге, аны ярату, аның белән чын-чынлап горурлану хисләре дә тәрбияләнә.

Җөмһүриятебездә милли сәясәтнең эзлекле булмавы, яки аның очраклы чаралар, кампанияләр итеп күзаллануы аяныч күренеш, әлбәттә. Без 1995 елларда Чаллыда татар журналистлары ассоциациясен оештырырга омтылып карадык. Максатыбыз — урыс телле мәгълүмат чаралары өчен булган мөмкинлекләрнең өлешенә бер генә булса да ирешү иде. Мәсәлән, Татар телле басмаларның журналистларын чит илләрдә стажировкалар үткәртү, редакцияләрне заманча техника, технологияләр белән тәэмин итү һ. б. омтылышыбыз барып чыкмады... Шәһәрнең журналистлар берлеге әгъзаларын хакимияткә җыйдылар. Ул Берлекнең җыелышы дип аталды. Без, үз берлегебезне оештыру инициаторлары, Татар журналистлары берлегенең кирәклеген дәлилләдек. Әмма барып чыкмады, бездән генә тормады шул...

Әлбәттә, бүгенге көндә дә безгә хакимият белән бергә эшләү юлларын эзләү кирәк. Әмма бу һич тә милли хәрәкәт хакимият артыннан ияреп барырга тиеш дигән сүз түгел. Хәтта ул хакимият арбасына да аерым очракларда билгеле бер вакытка гына утыра ала. Чөнки милли хәрәкәт милли мәсьәләләрдә һәрчак хакимияттән бер адым алда барырга, аны алга әйдәүче, хәтта кайбер чакларда мәҗбүрләүче көч булырга тиеш. Ә без бүгенге көндә нинди халәттә? Бераз булса да ярдәм итмәсләрме дип милли лидерларыбыз өмет тулы күзләрен гел хакимияткә төбәп тора.

Бу дөньяда иң аянычы — кешенең битарафлыгыдыр. Дингә, милләткә, телгә, ата-анага, туганнарга битарафлык. Ул ни сәбәпле тәрбияләнә? Битарафлык та нәселдән киләме? Әллә кешедә кызыксынуны тәрбияләп буламы? Яки моңа тормыш авырлыклары, көндәлек мәшәкатьләр киртә булып торамы? Кеше нindидер эш, фикер белән мавыксын өчен аны тормыш мәшәкатьләреннән арындыру кирәкме? Бу мөмкин эшме? Әлбәттә, кешене күпмедер дәрәҗәдә булса да битарафлыктан чыгару өчен аны кызыксындырган өлкәләрне ачыклау, аның сәләтен белү зарурлыгы беребездә дә шик тудырмый. Шулай эшләргә дә булыр иде. Әмма, тормышта күрүебезчә, беребезнең дә мондый рольгә әүвәл алынасы килми. Чөнки үз мәшәкатьләребез дә хәттин ашкан. Ягъни безгә иң башта әнә шулай битарафлык чиреннән үзебезгә арыну кирәк була. Иң куркынычы, димәк, бер-беребезгә, дөньяга булган битарафлыгыбыз. Безнең хәтта сокландыргыч мәле искиткеч булган табигать матурлыгына да исебез китми.

Милли битарафлыгыбызның бер сәбәбе инде ул, әлбәттә, тарихыбызны җитәрлек дәрәҗәдә белмәү. Бу уңайдан мөхтәрәм шагыйребез

Гәрәй Рәхимнең «Татар кешесе»дигән шигыре искә төшә. Ул анда милләттәшләребезне чит җирләрдә каңгырап йөрмәскә, хәзерге Татарстанга кайтырга чакыра. Җыр итеп җырланучы шигырь юлларын эмоциональ кабул иткәндә, ошбу фикер белән шундук килешәсең. Әмма салкынрак баш белән уйлап карасаң, шигырьдә авторның тарихи дөреслеккә хилафлык китерүенә дә төшенәсең. Шагыйрьнең: «Болгарында болганган, Уралында уралган, Себергә себерелгән, Чиләбедә чиләнгән, Орынбурда орылган, Каргалыда каргалган — синдер татар кешесе»,— дигән юлларын ничек аңларга? Без, мәсәлән, Урал татарлары, Уралда уралмадык. Ул һуннар заманыннан бирле безнең Ватаныбыз. Безнең якларда урыс колонизациясе 16-17 гасырларда гына башлана. Татарлар Себергә дә сөрелмәгән, Орынбурда да орылмаган, Чиләбедә дә чиләнмәгән, киресенчә, ул җирләрдә көчле милли-мәдәни, дини үзәкләр булдырган. Ә Каргалыда милләттәшләребез чын мәгънәсендә чәчәк аткан, Русиягә Урта Азия белән сәүдә элемтәләренә юл ачкан. Димәк, шигырьдәге юллар Татарстаннан эш эзләп төрле якка сибелгән кардәшләребезгә генә кагыла булып чыга.

Бүгенге көндә урыс кешесендә Урал, Себер гомер-гомергә урыс җирләре булган икән, дигән фикер формалашкан кебек, татарда да борынгы тарихыбызны барлаганда, әйтик, Болгар дәүләтен телгә алганда, хәзерге Татарстанны күзаллау яши башлады. Кызганыч ки, мондый күзаллауларны журналист язмаларында да күрергә була. Җөмһүриятебезнең мөхтәрәм газеталарының берсендә бер хөрмәтле журналист болай дип яза: «Түбән Кама янында бер Болгар каласы табылды, ул X-XII гасырда Болгар дәүләтенең Көнчыгыш чикләрен саклаучы ныгытма-кала булган». Әмма мондый нәтиҗә ясаганчы тарихка күз салып киту комачауламас иде. Бөек галимебез Шиһабетдин Мәрҗани хәзрәтләре бу уңайдан менә нәрсә ди: «Болгар халкының мәмләкәте борынгы заманнарда көньягыннан Бабел-Әбваб (гарәпләр Каспий диңгезе белән Кавказ таулары арасындагы тар юлны шулай атаганнар), ягъни Дәрбәнд, Тифлис һәм Ширванга, Кавказ таулары, бәхре Хәзәр (Каспий диңгезе) буена һәм Дагыстан тарафларына, хәтта Әрмәнстан иленә хәтле сузылган булган. Көнбатышта — Нокрәт, Дон, Самар, Сура һәм Ока елгалары башы, Көнчыгышта — Урал таулары, Хәрәзм, Сыгнак һәм Шаш, төньякта Русия белән чикләнгән булган».

Әмма Кама буенда хәл кискен кала. Чөнки Нокрәт белән идарә итүчеләр Мәскәү белән Казанның икесенә дә ярау сәясәте алып баралар. Аларга Пермь кенәзләре дә иярә. Мәсәлән, алар 1471 елны урыс гаскәрләренең Казанга походында катнашудан баш тарталар. Бу юлларны мин 1976 елны Пермь китап нәшриятында дөнья күргән «Урал тарихы»ннан китердем. Менә тагын бер өзек: «Вятка җире феодаллары Мәскәү кенәзләре һәм Казан ханлыгы арасында икесенә дә ярау сәясәте алып бара. Һәм бу шуңа китерә ки, Иван III 1489 елны «төзәлмәгән өчен»бирегә кенәз Д.В.Шени һәм воевода Г.Морозов җитәкчелегендә гаскәр җибәрә. Урыс дәүләтенә кушылырга теләмәүче боярлар урыс воеводасына тотып бирелә».

Әлбәттә, чынбарлыкта хәл катлаулырак булгандыр. «Бөек Пермьга үтеп кергән татарлар»дигәнне гади генә аңларга кирәкми. Урыслар Бөек Пермь белән кызыксына башлаганчы (коми-пермяклар яшәгән җирләр), татарлар биредә инде гасырлар буе яшәгән була. Хәзерге Пермь шәһәре янәшәсендәге Болгар, Башкултай, Куян авыллары шул чорлардан башлап саклана.

Гомумән, Пермь краеның бүгенге көндә чиста урыс районнары булып саналган төбәкләрендә дә күп авыллар әле һаман төрки-татар исемнәрен йөртә. Мәсәлән, Елово районындагы исемнәргә игътибар итик: Куштамак, Ятыш, Чулпанышка, Суганка, Еланы, Иргиш һ.б.

Шул ук «Урал тарихы»ның 42 нче битендә: «1437 елны Идел буенда Кама буеның түбәнге өлешен һәм Башкортстанны үз эченә алган Казан ханлыгы барлыкка килә», — диелә. Ягъни Пермь краеның көньяк, Башкортстанның төньяк-көнбатыш өлеше инде күптән Болгарга кергән була.

Болгар чорын гына түгел, гомумән тарихыбызны начар белү милләттәшләребезне: «Без татар түгел, болгар»яисә «Безнең болгарларга

бернинди мөнәсәтебез юк»,дигән фикерләргә этәрә. Ярый ла мондый раслаулар үзара әңгәмәләрдә генә чагылып калса. Кайберәүләр үз фикерләрен РФ Фәннәр Академиясенә дә җиткерүне кирәк таба. Менә Чаллыдан бер татар кешесенең (инде вафат, шуңа күрә исемен телгә алмыйм) академик А.Фурсенкога һәм Фәннәр Академиясе бюросы исеменә юллаган хаты. Автор анда Казанның 1000 еллыгын бәйрәм итүгә һәм Кол Шәриф мәчетен төзүгә каршы төшеп болай ди: «Тарихны суверенитетка яраклаштырып язу кирәкми. Казанның 1000 еллыгын кайдан алдыгыз? 1431 елны Казанның хәзерге территориясендә Федор Пестрый тарафыннан монгол-татар ханлыгы тар-мар ителә. Тәхеткә олуг Мөхәммәд утыра. Безне Россия киңлекләренә Батый хан алып килгән. Безнең Болгар кабиләләренә бернинди дә катнашыбыз юк — тел буенча да, мәдәният өлкәсендә дә. Хотят переименовать нас в булгары, чтобы снять многовековой позор с нации за варварство».

Хатка РФ Фәннәр Академиясенең тарих бүлекчәсе секретарь- академигы Н.Макаров җавап биргән. Ул болай ди: «Исбатланган фәнни чыганаклар буенча, хәзерге Казан татарларының (шул исәптән сезнең) бабалары төрки телле Болгар кабиләләре була. Алар Идел буена Азов диңгезе буеннан 7-8 гасырларда киләләр һәм 10 гасырда оешкан Идел Болгарстаны дәүләтенең төп халкын тәшкил итәләр. Монгол яуларыннан соң Идел Болгарстаны Алтын Урдага вассал бәйлелегенә эләгә: болгар кенәзләре, урыслар кебек үк, Ханнан ярлык алалар. Алтын Урда чорында болгарларның кыпчаклар (половцы) белән кушылуы бара. Кыпчаклар көньяктан киләләр. Кушылудан хасил булган халык 20нче гасыр башында гына «Казан татарлары»дигән исемне ала.

Болгар кабиләләренең татарларга бернинди катнашы юк дип раславыгыз тарихи фактларга каршы килә».

Бередә сәер капма-каршылык килеп чыккан: бер яктан — үз тарихын кимсетергә теләүче татар кешесе, икенче яктан — сезнең тарихыгыз зур, моның белән горурлана аласыз дип исбатлаучы урыс галиме.

Әлбәттә, идарә итүче даирәләр сәясәте нәтиҗәсендә безгә тарих бозып күрсәтелә килде. Моның да зур тәэсире бар. Мин районда эшләгәндә берчакны 30нчы һәм 40нчы елларда чыккан зур энциклопедия томнарына тап булдым. Алар бер хуҗалык парткомы бүлмәсендә саклана иде. Бу көтелмәгән хәл мине аптыратты. Партком секретареннан — яшь кенә белгечтән энциклопедияләрне ни өчен саклавын сорадым. Ул аларның үзенә кадәр эшләгән өлкән яшьтәге секретарьдан калуын әйтте, макулатурага тапшырырга әлегәчә вакыты булмаганлыгын искәртте. Мин бу хәзинәне үземә сорадым. Яшь секретарь шундук шатланып риза булды. Өйгә алып кайту белән мин төрле томнарның битләренә күз төшерә башладым. Һәм көтмәгәндә энциклопедияләрдә үземә билгеле булмаган фактларны таптым. Мәсәлән, 30нчы еллар энциклопедиясендә татар-монгол яулары турында бөтенләй башкача әйтелгән иде. Урыс крестьяннары үз кенәзләре ягыннан шул кадәр каты изелгән ки, алар татар-монгол яулары килә дигәнне ишетеп үз хуҗаларына каршы баш күтәргәннәр һәм татар-монголларның килүен тизләткәннәр. Татар-монголлар кул астында яшәгәндә крестьяннар беразга тын ала. Чөнки монда инде ясак түләү табышның 10 процентыннан артмаган.

Әлбәттә, күп тарихи фактларга без үзебез мөстәкыйль төстә дә төшенә алыр идек. Әлеге дә баягы шул битарафлык комачаулап тора кебек.

Ә мин үзем битарафлык чире белән ни дәрәҗәдә авырыйм соң? Ни өчен мин кулымнан килерлек кайбер эшләрне һаман киләсе көннәргә калдырам? Бу битарафлыктанмы, әллә күңел төшенкелегеннәнме? Мин нәрсәдән канәгать түгел? Үз-үземнәнме? Ни өчен? Канәгатьсезлек кешене уйлану өчен туктатучы бер көчме? Мин нигә канәгатьсезлек кичерәм? Бу башкаларга көнләшеп караудanмы? Әллә ирешелмәгәннәр өчен сызлану, үз-үземне битәрләүме? Көнчеллек чыннан да күбрәк безнең милләткә хас сыйфатмы? Ул безне алга әйдәүче көчме? Әллә тиешле кысалардан чыгып безнең үсешебезне тоткарлап тора торган чирме? Ничек итеп аның мөмкинлекләрен милләтне үстерү юнәлешендә файдаланырга? Көнчеллек вәзгыятькә карап үзгәрәме? Ни сәбәпле Татарстаннан читтәге милләттәшләребез бер-берсен тапса

шундук дуслашалар, ә тупланып яшәгәндә дуслык җепләре йомшаграк була? Без туганлыкның, дуслыкның кадерен белеп җиткермибезме? Әллә яшәеш һәрвакытта да үзара ярышка, көндәшлеккә корыламы? Ул безнең алга таба үсешебезне тәэмин итүче бер таянычмы? Без ни рәвешле бергә булырга, бердәм булырга тиешбез? Ошбу халәтемне түбәндәге шигырем бирә алдымы икән:

*Әй, ул чебен,*
*Әй, ул черки –*
*Урман тулган;*
*Әле ансы,*
*Әле монсы*
*Чәнчә торган –*
*Тик түз генә.*
*Әй, бу серләр,*
*Әй, бу сүзләр,*
*Уңнан ява,*
*Сулдан ява,*
*Авырлары*
*Җанда кала;*
*Чебен кебек*
*Очмый тешләп –*
*Йөрәк яна.*

Әлбәттә, без гомуми сорауларга җавапны беренче чиратта үз тормышыбыздан эзләргә бурычлы. Ошбу очракта, иң беренче үзеңә кара, дигән хакыйкать алга баса. Әмма үз-үзеңә ничек тәнкыйтьчел карарга? Бу мөмкин эшме? Ягъни холык-фигылеңдәге аерым сыйфатларны үзгәртеп буламы? Үз-үзеңә ризасызлык, канәгатьсезлек шуның белән бәйләнгәнме? Ни өчен минем әти үзенә төшкән сынауларны үтә алмаган, эчкечелеккә бирелгән? Нәрсә, аның ихтыяр көче җитмәгәнме? Әллә чоры шундый булганмы? Колхозлашу елларында ул башка туганнары белән берлектә яшүсмер килеш читкә сөрелгән. Башта Үзбәкстанда Турксиб тимер юлын төзүдә, соңрак Свердловск шәһәрендә финанс даирәсендә эшләгән. Сталин репрессияләре чорында, ни сәбәпледер, төрмәгә эләккән. Андагы ачлыкка чыдый алмыйча, үз теләге белән сугышка киткән. Штрафниклар сафында сугышкан. Язмышның ниндидер гаҗәеп бер рәхимлеге аркасында исән калган, яраланып туган ягына кайткан. Мин аны әз хәтерлим. Әтигә ияреп балык тотарга баруларым бераз истә. Мин туганнарым белән аралашкан вакытларда әтине берничә мәртәбә әнә шул йомшаклыкта, язмыш сынавына түзә алмыйча сынуда гаепләгәнем бар. Туганнарым моны ничектер күпертмичә, тыныч кына үткәреп җибәрделәр. Фәкать энем генә миңа бу уңайдан ризасызлыгын белдерде. Юкса ул үзе әтине бөтенләй хәтерләми. Чөнки әти вафат булганда аңа өч яшь тә тулмаган иде. Бәлкем, ул хаклыдыр да. Безгә әти кичергәннәрне күз алдына да китерү мөмкин түгел бит. Без аларга түзә яки шул мәхшәрдән исән-сау чыга алыр идекме икән? Моның өчен тормыш тәҗрибәбез, осталыгыбыз җитәр идеме? Әлбәттә, бу хакта фикер йөртүе авыр. Без кечкенә чакта, уенчыклар булмау сәбәпле, әтинең сугышчан медальләре белән уйный идек. Шул сәбәпле аларны берәм-берәм югалтып бетергәнбез. Шулай берчакны мин иске кульязмалар арасында энемнең шул уенчыклар булмау сәбәпле әтинең медальләре белән уйнавы вакыйгасын тасвирлаган сочинениесенә тап булдым. Бәлкем, ул шуңа бәйле рәвештә исемдә калгандыр. Димәк, әтине характеры булмауда яки куркаклыкта һич кенә дә гаепләп булмый. Әмма ни генә булса да, мин әле хәзер дә һәр кеше башкаларга гына түгел, үзенә карата да таләпчән, кайбер вакытларда хәтта кырыс булырга тиеш дип исәплим. Әлбәттә, бу фәкать минем фикер. Әмма ул миңа еш кына авыр чакларда таяныч төсле тоела. Мин аңардан үземә көч алгандай булам. Чыннан

да, минем бүгенге тормышымда алга әйдәүче көч нәрсә ул? Авырлыкларны җиңә баруымы? Туплаган тормыш тәҗрибәмме?

Ирешелгәннәремме? Алга куйган максатлармы? Якыннарым, туганнарым, хезмәттәшләрем алдындагы җаваплылыкмы? Без тормышыбызны нәрсәгә нигезләп корабыз? Әллә аңа җайлашабыз гынамы? Җайлашу ул нәрсәне аңлата? Без тормышка ни дәрәҗәдә җайлаша беләбез? Бу терминны талантлы шәхесләргә карата кулланып буламы? Әллә ул урта кул кешеләргә генә хас сыйфатмы? Мин аңлы рәвештә районадагы җайлашкан тормышымны сындырып Чаллыгы күченеп килдем. Биредә барсын да яңадан башларга туры килде. Мин оттыммы, әллә оттырдыммы? Әлбәттә, нәрсәдәдер оттырдым, ә нәрсәдәдер оттым. Һәрхәлдә, мин моны вәзгыять таләп иткәнгә түгел, ә күңелем кушканга эшләдем. Һәм уңышсызлыклар булса фәкать үземне генә гаепли алам. Әмма мин шуны аңлыйм: ул чакны чоры шундый булган. Бернәрсә уйламыйча алга, белгесезлеккә омтыла торган чор. Хәзер исә мин киләчәккә бернинди әзерлексез, гарантиясез җайлашкан тормышымны сындыра алмас идем. Ахры, яшь барган саен мин тормышка саграк карыймдыр. Бәлкем, ул бүгенге тормыш хәле белән бәйледер. Өлкәннәр, күңел картаймый ул дисәләр дә, без инде тормышны башкачарак кабул итәбез кебек.

Минем күңелем бүген нинди халәттә? Кайчандыр яшь чакта мин, романтик хисләргә бирелеп болай дип язган идем.

*Болытларны әгәр моңсуланып*
*озатып калсам,*
*Белэм: алар җитә алмый безгә кадәр —*
*Әллә күңелләре нечкәрә,*
*Яшь тамчысы кебек*
*Озакламый җиргә сибәли.*
*Күңелемдәге шатлык-сөенечләрне*
*Мин сөйләсәм әгәр болытларга —*
*Алар күтәрелә биек-биек,*
*Ап-ак булып оча ераклaрга.*
*Күк йөзендә ап-ак болытлар күрсәң*
*Матур кояшлы көндә*
*Син бул тыныч —*
*Алар минем күңел.*

Энем бу юлларны япон поэзиясенә охшаткан иде. Әмма мин ул чакта япон поэзиясе үрнәкләре белән бөтенләй таныш түгел идем. Шунда язылганча мин бүгенгәчә күңелемне ак болытлар кебек саклый алдыммы икән?

Алдымда яңадан-яңа сораулар туа. Аларга җаваплар эзләп уйларым узган тормышка, вакыйгаларга кайта. Еллар дәвамында тоймаган, сиземләмәгән бик кадерле нәрсәләрне хәзер генә ачыклармын, табармын төсле тоела. Шул үткәннәрме, киләчәкме эченнән нindidер серле тавышлар ишетелгән кебек була. Мин сискәнеп шуларга колак салам, тукталып уйланам. Һәм шунда аларның күңелемнән чыккан үз авазларым икәнен аңлыйм.

# КАДЕРЛЕ ХАТИРӘЛӘР...

...дип язып куйдым да, шунда ук сүземне үзем үк төзәтәсе дә иттем: хатирә сандыгына эләккәннән кадерсезе буламы? Һәркайсы кадерле. Кешегә үзенең яшәве чорында күп «очраклар» белән очрашырга туры килсә дә, күбесен оныта; ә кайберләрен, никадәр тырышса да оныта алмый. Әһәмияте ягыннан зур роль уйнамасалар да, онытылмаган шул «очраклар»да ниндидер мәгънәләр ятуы сәбәпме – аларның тезмәсе кешеләрнең тормыш юлын күрсәтә. Шуларны искә төшереп, әлеге каһарманнарның үзләре белән очрашкандай буласың, шул мохитне хәтерлисең.

Минем профессияне кызыл дипломга акка кара белән «актер драмы и кино» дип язганнар. Гәрчә, актер чагымда сәхнәдә драмасын күрмәсәм дә, тормыш үзе театр булганлыктан, сәхнәдән тыш комедиясендә дә, фаҗигаләрендә дә катнашырга туры килде. Шуннан чыгып, режиссер булынды. Инде менә хатирәләр язып маташам. 60 еллык кытыршы иҗади гомеремдә кемнәр белән генә очрашылмады икән?! Пушкинның 3000 мең танышы булган дип язалар. Артистның танышы өч мең генә булса, ул әле артист булып өлгермәгән, дигән сүз. Кимендә өч йөз мең танышың булганда гына үзеңне артист саный аласың. Анда да әгәр тамашачы расласа.

...Кыскасы, очрашулар күп булды. Үзенә даһилык чире йоктырмаган кеше генә очрамады.

Хатирәләрем шул «даһилык» чүпрәсе эләктергән кайбер замандашларым белән булган хәлләргә бәйле.

Аларның күбесе үзләрендә нинди «чүпрә» йөртүләрен дә белмичә, инде мәңгелеккә күчте. Алардан калган «мәзәкләре», хуҗаларын хәтерләтеп, безнең белән яши. Мәрхүмнәрне искә алу – кешелек бурычыбыз, дигәннән чыгып, хәтер сандыгым ачам.

...Белгәнем, күргәнем, ишеткәнемне шәрехләмичә – комментарийсыз гына язгач, онытылмас ул шәхесләр арасына, «контрамаркасыз» гына, үземне дә кертми мөмкин булмады. «Кемнән башларга?» дигәндә, иң элек Юныс Әминев белән булган бер «очрак» искә төшә. Чөнки ул... ул мине үлемнән коткарды. Билгеле булуынча, һәркем өчен үзенә үзе кадерлерәк.

### Юныс Әминев

Юныс Әминев исемен мин беренче тапкыр Минзәлә театрында эшли башлагач ишеттем. Урта мәктәпне медальгә тәмамлаган идем. Ләкин күпме көтсәм дә, медале кайтмады; шуны көтеп ул елны югары уку йортына да керә алмый калдым.

Район үзешчәннәре бригадасы белән концертлар куеп йөргәндә, Минзәлә театрын очратып, аларга кушылып киттем. Безнең өчен ул чак Минзәлә – Голливуд.

...1955 елның декабрь ае иде. Салкын, буранлы көннәр, юллар юк. Авылдан авылга трактор чаналарына төялеп күченәбез. Гариза биреп кергәч, түзми хәл юк. Спектаклебез Островскийның «Бирнәсез кыз» әсәре буенча булса да, безне «Язылмаган законнар» килгән дип каршылыйлар. Чөнки артистлары шул ук: Хәдичә Сәлимова, Нәсимә Җиһаншина, Әнвәр Фәсхетдинов, Мөхит Кичубаев һәм башкалар. Шунда мин «Язылмаган законнар»ның авторы Юныс Әминев булуын, ул спектакльләрнең авылларда зур уңыш казануын ишеттем.

...Труппа Минзәләгә кайткач, Юныс абый театрга «Тамырлар» дигән әсәрен укырга килде. Алдылар. Анысында ниндидер бер роль дә биргәннәр иде, уйнарга

туры килмәде — Мәскәүгә укырга кителде. Бер елдан соң Минзәлә театры «Язылмаган законнар»ын декадага алып килде, Юныс Әминевнең исеме илгә ишетелде, дәрәҗәсе үсте, танылды. Ниһаять, аның әсәрләрен Г.Камал театрында да куюларын ишеттек. (1960 елда «Умырзаялар»ы, аннары «Гөлҗәннәтнен җәннәте» куелган.)

...Безнен театр студиясендә татар теле буенча укытучы штаты бар иде. Анда төрле елларда Әхмәт Фәйзи, Роберт Бикмөхәмәтов, Юлдашев, Фазылов дигән галим-голәмә укытып, һәркайсы үзе турында якты истәлек калдырды. Соңгы курста Юныс Әминев безгә консультант-хәлфәбез булып килде. Үзе әдәбият институтының югары курслары шәкерте иде.

Юныс абый килгәндә без, «биш минуттан» артист булучылар, аңа хәлфәбез-укытучы итеп түгел, ә коллегабыз-авторыбыз итеп карый идек. Чөнки алып кайтасы спектакльләр исемлегендә «Кошның да үз оясы була» дигән аның пьесасы бар иде. Музыкаль комедия иде ул. Диплом спектакльләребезгә инде «билгеләр» куелган, эш беткән, соңгы курсның соңгы айлары бара... Кошның да үз оясы булгач, һәркайсыбызның уенда Казанда ничек оялау проблемасы гына булуы яшерми сөйләнелә иде. Шуңа күрә Юныс абыйның әсәре белән әсәрләнүче юк, аңа кирәксез бер мәшәкать дип кенә карыйбыз. Мин репетицияләрне туктату коткысы таратам.

Без Батулла белән бер үк рольгә билгеләнгән идек, ул — беренче состав. Жае чыкмаса — жай чыгарып, репетицияләрдән качабыз. Әгъзам Фәттахов дигән композитордан көйләр дә яздырткannар иде. Әмма спектакльнең чыкмаячагы фактка әверелгәч, жинел генә котылдык бу эштән. Юныс абыйның безне гаепләвен хәтерләмим, ләкин кемнәргәдер үпкәләп йөрүе исемдә. (Ахрысы килешүгә кул куймаганнар.) Шуннан соң без аны очратмадык. Ул — Әгерже районы Баржы авылында яшәп иҗат итә, без Казанда кайныйбыз.

1968 нче елның язында мина, алдан йөрүче администратор булып, килешүләр төзеп кайту бурычы йөкләнде. Сатылган билеттан кергән керемнең 5% исәбенә, шатланып, Әгерже-Ижау якларына юл тоттым. Иртә килгән мул сулы яз иде. Иж елгасы боздан арынып котырынган көн. Баржы авыл клубы белән тиз-тиз килешү төзеп, билетларын калдырып, эшне бетердем дә, Ижнең теге ягындагы Салагыш авылына ашыктым. Якты көздә эшне төгәлләп, кичке поездда Сарапулга китәргә ниятлим.

Тик кире әйләнеп килгәндә Иж елгасының ярлары күренми, карлы яңгыр ява, Салагыш белән Баржы арасындагы юлны су баскан. Авыл утларына карап, су күтәрелмәгән сырт буйлап «на ощупь» кына барам.

Ул баруларым әҗәлемә таба алып барган икән: бермәлне коры җир бетте — кая карама су да су, карлы яңгыр да, әйләнәмдә юнәлешен югалткан боз өемнәре генә ага. Кайдадыр ыңгырашкан кебек тавышлар ишетелә, бозлар бәрелешеп чатный, ә минем басыр җирем кысылганнан кысыла, бик тиз арада бөтенләй югала. Биек агачлар да су эчендә, мин дә, ялгыз карама төбенә басып, әҗәлемне көтәм.

...Андый чакта үлемнең тизрәк килүен телисең икән, — моңа кадәр гөжләп күтәрелгән су кинәт тынычлана кебек, карт карама тамырына гына басып торам — сакланам, әлегә аякларым коры, күңелем сунын тизрәк күтәрелүен тели. Янәсе, «үтерсән — үтер, сузма!»

Караңгыга күз ияләшүгә, карама агачының кояш караган ягында кырмыска оясын күреп калам. Ул миңа коткаручым булып тоелды. Шуңа сикердем. Ләкин ул агып килгән чүп-чар өеме — саескан оясы булды — мин егылдым. Суык суда чылану — үлем турындагы уйларны кабат уятты, «коткарыгыз!» дип кычкыруымны сизми дә калдым. Карама ботагына ябышып, агач төбәсенә менмәк булам, үзем кычкырам. Юк, кычкырам, дип уйлыйм гына икән — тавыш чыкмый, ул эчтә югала.

...Асылынып тора-тора кулның көче бетә башлады, тундыра да. Ниһаять, үлем куркынычыннандыр, тәнгә көч кереп, ботакка атланугa ирештем. Ниятем — физзарядка ясап, жылынырга иде. Шунда кинәт «Әхтәм» дигән тавыш ишетелмәсенме?!

Әйе, «Әхтәм» ди! Ижның теге ягында. Мин «әү» дип әйтергә дә белмим, «монда» дияргә дә кыймыйм — тавышым чыкмый бит. Тәмәке тарткан чак иде — шырпы сызып карыйм — чыланган.

...Берданбер чара — ботак өстендә аякка басарга — кычкырган кеше, бәлки, күрер...

...Ничек кирәк алай, маташа торгач, бастым бит карама ботагына. Шунда, үзем дә сизмәстән, үз тавышымны ишеттем: елыйм икән ич мин! Нервный шок диләрме — үкси-үкси елыйм икән.

Ә теге яктан тагын кычкыралар: «Беркая да китмә — шунда гына тор!» Бик китәр идем дә — ничек китим, кая китим?! Дурактыр ул кычкыручы адәм...

«Саташам ахры» дигән уй-фикер чагылып китте, агач кәүсәсен кочаклап ботакта басып тору көчне алды, утырырга булдым. Утырсам — Иж өстендә тәмәке уты һәм карт карамага карап килгән көймәне күрәм!.. Шатлыгымнан чак егылып төшмәдем.

...Су котырып акса да, ишкәкче көчлерәк булып чыкты: көймәне карамага китереп бәйләде, «төш» диде. Бәй! Юныс абый ич бу! Юныс Әминев!

Ул Баржы клубы мөдиреннән минем килү һәм Салагышка китүем турында белгән, аннары Салагышка шалтыраткан, «китте» дигәннәр. Көтеп-көтеп тә кайтмагач, Иж буена төшсә — боз ага, су күтәрелә, карлы яңгыр ява, төн. Юныс абый көймә эзли. Ниһаять, балыкчы картның каегын табып, аны суга төшергәндә, карама ботагына асылынган гәүдәне күреп ала. Ишкәге сына, көймәсенә су тулып җәфалана... Бирешми — ишә бирә.

...Ул боларны көлә-көлә, җәфаланмый гына сөйләде. Күренеп тора: исәнлегемә миннән бигрәк ул шат иде.

Мин Юныс абыйларда өч көн дәваланып яттым. Тәмам терелгәч кенә юлымны дәвам итәргә рөхсәт бирде ул.

Безнен кирелек аркасында уйналмаган «Кошнын да үз оясы була»ны искә төшермәде. Юныс абый коткаручы фәрештә ролен үтәп, мине бу үлемнән алып калды. Мин ана гомерлек бурычлы. Шуннан соң булган очрашуларда бу турыда сүз чыкса, ул һаман: «Сине коткарган карт карама Каманы бугач күтәрелгән суга чыдамады, корыды!» — ди торган иде.

Карама гына түгел, үзебез дә корыйбыз, Юныс абый, бата башлаганда гына коткаручыларыбызны искә алабыз!

Күз алдымда ул гел шулай басып тора: олы гәүдәле, күзлекле, мәрхәмәтле.

## Салих Баттал

Мин анын оригиналь шәхес булуы турында хәбәрдар идем. Үзен очратканым булмаса да, шигырьләрен караштырып, пьесаларына да күз салганым бар иде. Дөресен әйтим — әсәрләндермәделәр алар мине. Ничектер, «мөгез чыгарырга» тырышып язылганнар сыман тоелды. Ә менә «Сигезенчесе кем?» дигән эпистоляр жанрдагы повесте, ничектер, эләктерде күнелне һәм мин, анын нигезендә, телевизион фильм төшерергә булдым.

Китап булып басылып чыккан әсәрнен авторы «кара исемлектәге кеше» булса да, җитәкчеләр каршы тормадылар — тотындым мин бу эшкә.

Композициясе әдәби-драматик яктан бик таркау булганлыктан, повесть сюжетыннан җай гына читләшеп, сценарий жанрындагы яна әсәр яздым. Үземә ошады. Шунысы мөһим.

Рольләрне артистларга таратып, репетицияләр башланды. Янып эшлибез. «Татарстан дулкынында» алхәбәр басылып чыккач, редактор мина телефон номеры суза: Салих Баттал бәйләнешкә чыгуымны үтенгән. Курыксам да, шалтыраттым. Безнен өчен борчыла икән, хезмәтегез әрәм китмәсен, өстәгеләрдән рөхсәт алыгыз, ди. Мин: «Алынды», — дидем, алынмаса да. Ул: «Алайса, йомшартмагыз, ничек бар — шулай уйнагыз!» — диде. Кирелек дигәндә, без дә Салих Батталдан ким түгел — үзебезчә, кирәгенчә, заманча һәм кино законнарына туры китереп куйдык без бу тамашаны. Нәтиҗәсе күренде — хуплау сүзләре күп булды.

Әллә артык куркып, сагаеп эшләүдән фильм-спектакль яхшы булып чыкты, тамашачылардан күп хатлар алынды, Салих Батталдан исә, өенә чакырган хәбәр килде: көтә. Кыюлыгымны җыеп бардым мин бу үзенчәлекле холыклы авторның өенә. Әйтүе буенча «шәрекъ өстәле» әзерләгән, әчемлеге мин күрмәгән-белмәгән шәраблар. Барысы муллан.

...Утырдык, сыйланабыз. Фильм-спектакль турында сүз юк. Абзый хакимиятне сүгә, Батыевның тетмәсен тетә. «Союз ничек карады бу эшенә?» — ди бу бераз утыргач.

«Әһә, башлана башлады...» — дим эчемнән һәм җавап эзлим.

— Мин Союз әгъзасы түгел бит, абый, аларның миңа катышы юк.

— Катышы булмаганга катышыр өчен төзелгән союз ул. Көт.

— Карарбыз, күрербез.

— Алар хәзер синең бу фильмеңне юкка чыгару эшенә керешәчәк.

— Фильм минеке генә түгел — сезнеке дә ич... хөкүмәтнеке дә.

— Юк, синеке! Фильмең әйбәт, кирәкле, бирешмә — нык тор.

...Ул кыскача гына кемнәрнең ничек каршы чыгачагына, аларга нindirәк җавап бирергә кирәклеккә тукталды. «Ярар» дигәндәй, баш кагып кына, кереп алып китүләрен көтә-көтә тыңладым. Кермәделәр. Аннары ул сүзен театр тарафына күчереп, шушы фильм сценарие нигезендәге пьесаны Академия театры сәхнәсендә әбизәтелне кую кирәклеген тәкрарлады. Тирән ышаныч белән, шикләнүләрсез. Каршы килүдән файда юк иде, бары тик «ышанычыгыз өчен рәхмәт», — дидем.

— Сиңа рәхмәт! Бу — тегеләргә пощёчина. Шулай һәр эшең дошманнарның янагына сугу булсын, энем, бу — миннән васыять сиңа!

— Минем дошманым юк бит.

— Дошманы булмаган язучы юк!

— Мин язучы түгел.

...Озак утырдык. Гел сакланып, ялгыш сүз ычкындырмыйм дип киеренке утыруданмы — ни турында сөйләшүебезнең күбесе хәтердә калмаган. Шуны гына хәтерлим: пьеса язганда кирәге чыгар, дип повестьның русчасын бүләк итеп бирде ул миңа. «Бүген үк утыр язарга, каләмең бар», диде.

«Уемда ул түгел» дип әйтергә кыймадым, күңелен төшермәдем. Ул театр мәйданының күптән бүлгәләнгән булуын белми иде, ахры. Бу очрашудан соң ничә көн үткәндер — телефоным шылтырый: — Ул!

— Син өйдәме? — ди.

— Телефонны алгач, өйдә булмый кайда булыйм?! — дип, дорфа гына җавап бирдем.

— Минем хәзер сезгә барыш, беркая да чыкма. Көт!

...Чынлап та, килеп керде бу. Өстендә дә, аягында да лётчик Чкалов сурәтендәгечә киемнәр, кулында кечкенә чемодан.

— Бу сиңа миннән истәлеккә язу машинкасы! Мәскәүдән кайтарттым, Казанда тапмадылар. Татар хәрефләре куйдыр да, әсәрләреңне машинкада бас. Ә менә бусы икенче фильмең өчен нигезгә бер хикәям — авторлык хокукларын сиңа бирәм, булган хәлләрдән алынган, эшлә! Ә... пьесаңны бетерәсеңме инде?

— Бетеп килә...

— Ашыктыр! Гомер тиз уза.

Әйе, гомер тиз узган икән шул... Салих абыйның үз фатирында янып үлүенә дә 18 ел узган.

Янып яшәгән, янып иҗат иткән кешенең янып үлүенә... 18 ел...

...Бүләк итеп биргән язу машинкасы китап шкафы өстендә тора. Янәшәсендә кирәксез фотоувеличителем. Икесе дә кирәксезләр, артыклар. Заман башка, таләпләр бүтән.

...Машинкасының маңгаена: «Зарипов Әхтәмгә — кыю режиссерга, «Ата хакы»на, 1975 ел, С.Баттал» — дигән язу.

...Шкаф өстендә бүген кирәге булмаган язу коралы ята, шкаф эчендә, шулай ук, кирәге беткән китаплар. Шуларны язу, бастыру өчен нинди генә язучылар бер-берсе белән дошманлашмаган, сугышмаган. Бүген, аларның күбесендә коры шапырыну, юкны — бар, барны — юк итеп күрсәтү, ялганга инану, иблискә табыну сүзләре икәнен белгәч, без шуңа ышануыбызга үкенәбез. Үкенмик. Саклансын ул китаплар. Аларда кешелекнең яшәү, дөнья шартларына яраклашу тарихлары...

Сократның язып калдырган бер китабы булмаса да, аны иң акыллы кеше, иң талантлы әдип булган дип язганнар һәм язалар. Сократ берәү генә. Ә язучылар күп. Китапларны ташлау ярамый.

Салих ага Батталның язганнары күп. Бүген аларның күбесе авторга карата кызгану хисләре уята, (???) нинди заманнар булган бит, дисең. Шуна күрә, әдипнең ни язганыннан бигрәк, ни өчен һәм нигә шулай язганына карарга кирәк. Ышанган ул. Талантлыгы өстенә үзе көчле дә булган, кыю да, тәвәккәл дә булган. Әмма идея колы булган.

...Салих Батталга кагылышлы сүземне шушында төгәлләмәкче булып нокта куйгач, бер бик тә әһәмиятле «деталь» төшеп калуы искә төште.

«Ата хакы» фильменнән соң нәкъ өч ел вакыт узгач, ул, өйгә килеп, «икенче фильмена нигез булыр» дип биргән хикәясен кире алып китте.

— Ник аласыз? — дигәч, «син дә шулар кешесенә әйләнгәнсең икән, мин ышанырга ашыкканмын...» — диде. Саубуллашмады. Соңгы күрүем шул булды.

Бу хәлләр искә төшкәндә ачу килә: Кем иде соң аның «шулар» дигәне?

...Һәр чорның үз «шулар»ы бар. Шуларны күрсәтә алсак, без мәрхүмнәр васыятен үтәгән булабыз. Тик аларны тану җиңелдән түгел. Салих абый заманында алар партия битлеге киеп гамәл кылганнар, ә хәзер халык-милләт исеменнән эш йөртәләр. Аз дигәндә шуларны милләткә таныта алсак, без атайлар хакын хаклаган булыр идек.

## Камал — III

Театр җене кагылган кешегә сәхнә дөньясындагы һәрнәрсә могҗизалы, серле булып тоела. Бигрәк тә, шул могҗизалы сәхнә иленә әләгергә хыялланып йөргән яшь-җилкенчәккә. Төрле сынауларны узып, ниһаять, үзе дә сәхнәгә менү бәхетен татыгач, могҗиза булып тоелганнарның күбесе томан кебек юкка чыккач, ул инде үзенә-үзе гаҗәпләнеп карый башлый: сәнгатькә хезмәтнең бөтен могҗизасы — әлеге дә баягы — эш икән ич!



*Нәкый Исәнбәт. «Рәйхан» (1952 ел).*
*Гәрәй – Камал III (уртада).*

...Мин үзем «театр» дип хыяллана башлаганда, артистларның фамилияләренә кызыга идем: «Шакир Шамильский», «Гыйлаҗ Казанский», «Фатыйма Ильская», «Мәрьям Сульва», «Сакмарский», «Камал III».

Колхозыбыз «Будённый» исемендә булудан чыгып, 9нчы класста укыганда имзамны «Будённыйлы» дип куя башладым. Яшьтәш малайларның әче телләренә чыдый алмый ул имзадан тиз арынсам да, артистларның фамилияләре белән кызыксыну үзем театрда эшли башлаганчы сакланды.

...Бермәл шулай сәхнә артындагы ял бүлмәсендә исемнәрнең җисемнәренә, җисемнәрнең исемнәренә туры килүе-килмәвен тикшереп утырабыз. Фаразлар күп. Иманскийның иманлы булуына шик тугач, Камскаяның Чулманга, Ашказарскийның Ашказар елгасына, Болгарскаяның Болгарга бәйләнеше юклыгы ачыклангач, «Сакмарский» дигән фамилиядә тукталып калдык. Чөнки артист Сакмарскийның ничек, кайда юкка чыгуын белүче юк иде.

Артистлар тормышындагы иң вак детальләрне дә хәтерләүче Хәким ага Сәлимҗановтан сорарга булып, шалтыратырга торганда Камал-III телгә килде:

— Тимәгез Хәкимгә. Ул аны күргәне юк. Аны мин күрдем, мин беләм Сакмарскийны...

— Хәзер кая ул?

— Ул хәзер сезнең каршыгызда басып тора: Сакмарский минем беренче псевдонимым!

— ???

— 1917нче елда Әстерханда татарларның ике театры бар иде. Берсе үзешчәннәр театры, икенчесе профессиональләр. Мин икесендә дә «артист», янәсе. Берсендә Сәләхетдинов булсам, икенчесендә «Сакмарский» булып йөрим. Мода!

— Соң... син бит Камал-III!

— Анысы Әстерхан театрына Галиәсгар Камалның энеләре килгәч, миңа алар тарафыннан кушылган кушамат. Буталмас өчен.

Габдулла — Камал-I, Габдрахман — Камал-II, мин театрда Камаллардан өченче булгач, шулай калды инде. Әйтегез — гаепleме мин?!

— Гаепле! — дип кычкырды Габдулла абый Фәтхуллин. — Чөнки син өченче түгел, ә дүртенчесе булырга тиеш! Сез, хәрамлашып, Галиәсгар Камалга беренчелекне бирмәгәнсез!

— Гаебемне таныйм! — дигән булды Камал-III, шаяртып һәм көлеп, — Исправлюсь!

Без — Щепкинчылар кайтып театрда эшли башлаганда Камал-III инде күптән «исправленный», тәртипле, мөмкин булган дәрәҗәләрнең барысын да алуга ирешкән, СССРның халык артисты дигән исемне тыныч кына көтеп йөрүче өлкән, ялкауланган артист иде. (Имиджы буенча.)

Элеккеге рольләреннән декада спектакле «Король Лир»дагы Эдгарын һәм Хәй Вахитның «Беренче мәхәббәт» пьесасы буенча куелган спектакльдәге «әти» роленнән башкаларын күз алдыма китерә алмыйм.

Рольләре булмаудан түгел, булганнарының спектакль сыйфатына йогынтысы юклыктан. (Дежур рольләр иде.) Үзенә ишеттерми генә Камал-III турында сөйләгәндә, аның элек романтик геройларны ничек уйнавын, Отеллоны уйнап чыкканнан соң һушын җыеп утыруларын дәлил итеп китерәләр дә, «ах-вах» килеп мактыйлар иде.

Андый рольләрен күрмәгәч, мин аның (кайбер) кешелек сыйфатларына гына тукталып узам. Юмарт иде, үшән иде. Аны бер сүз белән конфликтсыз кеше иде, дияргә була. Шул кешенең кеше буларак гүзәл сыйфатларыннан тагын берсе — үз эшенә тәнкыйть күзлеге киеп карый белү иде.

Иң макталган рольләрен хәтерләгәндә дә «шулай яраган инде, шулай кирәк табылган» дигән караштан чыгып сөйли иде. Сөйләми, сораганга җавап бирә иде.

...Хәзерге артистларның сәхнә гомере белән чагыштырганда, Камал абый чагыштырмача яшь булса да, (без кайтканда ана әле 60 яшь иде) ул үзен картка саный, «буласы булган, буявы сеңгән, шул купмаса ярый» дия торган иде.

...Аның балалары юк иде. Сәхнә артына балаларны алып кергәндә, ул, ничектер, монаеп, хисләнеп аларга карап тора да, «йә, уку ничек бара?» — дип сорап куя иде. Күрәсең, бу аның укый алмый калуын хәтерләүдән булгандыр. Наданлыгын яшереп маташмый иде ул. Хатыны Асия ханым Мәсәгутова (Масаутова булып йөри иде) театрда сирәк күренә. Икесен бергә очратканда «болар тату яшиләрме икән?» дигән сорау туса да, ямьсезләнешүләре турында ишетелмәде. Күрәсең, язмыш белән килешеп, тату яшәгәннәрдер.

Без кайткан елларда, ягъни 60нчы еллар башында, хезмәт хакларының азлыгыннан тыш, үз вакытында аны алу-алмау тенкәгә тия иде. Шул чакларда еш ишетелгән хәбәрләрдән иң «җылысы»: «иртәгә зарплата була икән, бухгалтерга Камал-III — акча биреп торачакмын дигән». Чынлап та, биреп тордымы икән, шаярту булдымы — зарплата ала идек, Камал-III абыйга рәхмәт әйтә идек. Баш иеп килүне ярата, мактауны кабул итә алмый иде. Камал-III абыйның җыелышларда чыгыш ясавын, кемнедер, нәрсәгәдер сүгүен, ачулануын — хәтерләмим. Гайбәткә катнашмый. Зарлана белми. Ул: «дәшмәү — акыллылык билгесе!» — дигәнгә ышанып яшәүче замана колы иде. Кесәсендә үзенә кирәкле даруы булса да, ничектер, хәле бетепме, тыны бетепме, гел утыру җаен карый иде. Гәүдәсенең артык калынаеп, тәненең симереп китүенә сәбәп — шул хәрәкәт азлыгы булмадымы икән.

Аның Тукай ролен башкаруы турында көлеп искә алалар иде. Ярсаң өч Тукай чыгарлык олы гәүдәле Камал-III, ахырда, шагыйрь ролен Ибраһим Гафуровка

бирергә мәжбүр булган, имеш. Бу факт анын сәнгатькә бирелгәнлеге, «мин-минлек» чиреннән азатлыгы турында да сөйли. Киенү, туклану-ашау мәсьәләләрендә гажәеп талымлы, сайланучан иде. Ягъни, киенә дә, ашый да белүче иде ул.

1964 нче елнын көзендә без Аяз Гыйләжев әсәре буенча куелган «Көзге ачы жилләрдә» спектакле белән Кайбыч—Буа якларына гастрольгә чыгарга тиешбез. Директорыбыз Рәшидә апа Жиһаншина, аз булса да өстәмә акчасы булыр дип, мина – (ике балалы, хатыны эшләмәгән иргә) бригадага житәкче булу камытын кигезде. Бу минем өчен көтелмәгән зур жаваплы вазыйфа иде.

— Бер генә үтенечем бар, — диде ул – бригадагызда ике елак артист – шуларны елатмаска тырыш. Берсе — Галимә апагыз Ибраһимова, икенчесе Камал-III. Авылларда гостиница юк. Фатирнын ин шәбен аларга бирергә тырыш. Риза булсалар район үзәге гостиницасында кунып, авылларга бара-килә уйнарсыз... ЧП булса, шунда бетерегез, алып кайтмагыз.

— Ярар, риза, — дидем, начальник булуыма куанып, — елатмабыз, алып кайтмабыз.

Аларнын елау-еламавы миннән тормый – уйланылмый гына әйтелгән, әлбәттә.

Беренче кичтән үк Галимә апа ялгызын, ягъни, берүзен аерым бер фатирга урнаштырган өчен үпкә белдерде:

— Йогышлы авыруым юк ич, нигә миннән карантин ясыйсыз?! – диде ул елый-елый көлеп...

Ә Камал-III – үзен ялгыз бер хатын гына яшәгән йортка урнаштырганга иртә белән шелтә белдерде.

— Мин бит әле көчемдәге ир! ...Төн буе үземне-үзем саклап чыктым. Чишенергә дә кыенсынам, киенсән дә унайсыз. Хозяйка... вообще йокламады.

Өченче көнне спектаклебез Кайбычнын үзендә иде. Шатлануым шуннан – Кайбычта «Дом крестьянина» бар.

...Тик анда ике генә буш урын бар икән. Нишләргә? Галимә апа әйтә:

— Ул кандалалы йортка мин үтерәм дисәләр дә бармыйм. Өченче елгы гастрольдә ут яныл торган килеш таладылар.

— Алайса... фатирга төшәрсез!

— Кем белән?

— Кем белән телисез сон?

— Синен белән дисәм?

— Риза!!!

— Оятсыз икәненне белмәгән идем.

...Ниһаять, урнашып беттеләр шикелле. «Дом крестьянина»дагы ике урыннын икесе дә аерым такта бүлмәләрдә икән. Идән шыгырдавы да ишетелми. Бүлмә дигәннен өстәллесенә Камал-III, өстәлсезенә Дамир Хәйруллин урнашты. Башкаларыбыз фатирларда. Инде ашау – ашханә мәсьәләләрен хәл итәргә кирәк иде. Кулымда бик зур «власть» бар, түрәдәй ресторан эзләп киттем. Менюларын тикшерәм, янәсе.

— Тикшерсән-тикшермәсән, әнә шул кәтлиттән башка блюдабыз юк, — диде «исполняющая обязанностей заведущей» Роза.

— Котлет булмагае – кәмфит булсын – ите генә күп булсын! – дидем мин.

— Юк итне каян алыйм мин? Әле мал суйган хужалык юк.

— «Из говядины» дигәнсез ич... Димәк, бар?!.

— Язуда ни булмас, тиле...

...Сөйләшә торгач жайладык: кәтлиткә «тушёнка» ачып кушарга, ике кешелек өстәлне «банкетный зал»да әзерләргә риза булдылар. (Кухня артындагы кысан бүлмә – «банкетный».)

— Үзем обслуживать итәрмен! – дип ышандырды «исполняющая обязанности» Роза.

— Зинһар, кәйләренә генә торырга тырышыгыз инде. Икесе дә бик данлыклы халык артистлары алар. ...

— Кайсы халык була инде ул сезненчә «данлыклы» дигән халык?

— Камал-III белән Галимә Ибраһимованы әйтәм.
— «Өченче» дигәне нәрсәне анлата анын?
— Өченче булуын!
— Иренең өченчесемени?
— Ул анын ире түгел.
— Кемнеке?
— Хатынныкы!
— Ха! Алайса нигә кеше хатыны белән банкетный залга бикләнә?
— Анысын Камал-IIIнен үзеннән сорарсыз! — дип, спектакльгә кадәр саубуллаштык. Ике кешелек чакыру билеты калдырдым үзенә, сонламаска куштым.

Кич, спектакль башланырга әле бер сәгать чамасы вакыт булуга карамастан, Камал-III клубка килгән, чакыру билеты сорый.

— Кемгә ул? Сез бит кунакханәдә!
— Ресторан директоры Розага!
— Мин аңа ике урын бирдем ич инде...
— Син биргән белән мин биргән бер түгел. Давай тизрәк...

...Нишлим — урындык куеп утыру шарты белән ике кешелек чакыру билеты язып бирдем.

...Халык агыла. Зал тулды. Артистлар әзер... Камал абый гына юк. Йоклап ятмыймы, дип тикшерергә «дом крестьянин»га барырга торганда, мыш-мыш сулап Камал-III килеп керә; ризыклар белән тулы сумкасын куя да, гримга утыра. Кәефе шәп.

...Үзе колакка катылана башлаган иде, ә безгә яхшы ишетелде: сумкасында, бер-берсенә бәрелеп, шешәләр «чыңлады». Ни дип юрарга да белмим. Эчә торган кеше түгел бит ул...

...Спектакль тәмам. Тамашачы тарала. Безнен эш, биткә вазилин сылап, гримны алу, киемнәрне алыштыру... кайту. Камал абый юк! Ул пәрдә тишегеннән карап, залны күзәтә икән.

— Нәрсә карыйсың, кемне күзлисең, Камал абый? Әйдә, кайтабыз...
— Ресторан директоры «көтәрмен» дигән иде, что-то күренми.
— Иреннән каласы килмәгәндер.
— Ире юк анын! Юк ире!
— Алайса, гостиницада көтәдер, «көтәрмен» дигән ич. Бәлки ресторанында көтәдер?!

Камал абыйны тынычландырырга тырышу нәтиҗәсез иде. Ул сүзсез генә сөртенеп, киенде дә, озатып куюымны үтенде...

— Что-то йөрәк брахлит... Кан куерды, ахры. Кечтеки генә сыекламый булмас. Син хәзер мине илтеп куй да, ресторанга бар. Анда көтеп утырса — монда алып кайт. Мин өстәл әзерли торам. Килештекме?

Килешмәсәм?.. Камал-IIIкә каршы килеп буламыни? Киттем, «исполняющей обязанности»дан директорга әверелгән Розаны эзләп.

Ресторан, әлбәттә, бикле иде. Арткы ишеге йозаксыз гына бикле, кухнясында тонык кына ут яна. Ишек шакыйм. Дәшүче юк. Тәрәзәдән карамакчы булсам — анда каравылчы бабайның башы:

— Кем кирәк?
— Роза.
— Театрда ул. Бүген килми.
— Өе, яшәве кайда?
— Чокырның теге ягындагы яшел калай түбәле йорт... Әнә — утлары сүнмәгән.

Киттем шунда. Барып җиттем дигәндә генә утлары сүнде. Капкаларын кагыйм дисәм — алабай этләре өрә, тиз-тиз качарга туры килде.

Этнен берсе өрсә, аңа башкалары кушыла. Татар авылында шулкадәр эт асрыйлардыр дип уйламаган идем. «Дом крестьянин»га кайтып керүгә, башта Дамир белән сөйләшергә булдым. Хәлне анлаттым. Ул миңа дөреслекне әйтмәскә кушты. «Әнине йоклаткач, үзем килермен!» — дип әйтте, дин» — диде.

— Аның әнисе бармы икән соң?

— Сина аның әнисе кирәкме, әллә, Камал-IIIнен тынычлануы кирәкме?

— Дөресен әйткәндә... тынычлануы кирәк.

— Монда дөресен әйтүдән файда юк, бар кер — өстәлен әзерләсен, аннары карарбыз.

Кердем, «әнине йоклаткач үзем килермен» дип әйтте дидем дә, фатирыма кайтып китмәкче булдым.

— Китмисең! Ул килгәч, сәбәп табып, китәрсең. Ә хәзер мина өстәл әзерләш! Менә бусы Казаннан килгән «Коньяк», бусы «Сухой», «ак»ны пока чыгармый торыйк. Житмәсә, күз күрер... колбасаларны тура!

Әзер өстәлгә карап ничә минут утырылгандыр, Дамир түзмәде:

— Нәрсә булды анда сезнең? ...Соң бит инде — ятыгыз! — дип кычкырды. Янәсе ул берни дә белми, ә без ана йокларга комачаулыйбыз...

Камал абый «операция»гә Дамирны да катнаштырырга булды:

— Озак яттык, бераз бодрствовать итеп алу зыян итмәс, тор, кер монда!..

Дамир, берни белмәгәндәй кереп:

— Кемнең туган көне? — диде.

Бу сорау Камал абыйны коткарды кебек:

— Минем янадан туган көн дип кабул итегез! Гастрольләрнең шушылай унышлы дәвам итүе өчен! Урра!

...Коньякны бер рюмка эчкәч, икенчесе жинел барды. Шешә бушаганда без инде «түгәрәкләнеп» килә идек. Камал абый холык күрсәтә башлады:

— Где она моя Дездемона?

Дамир: Кем, кем? Галимә апамы?

Камал-III: Как будьто белмисез... Директор кая, дим? Табыгыз!

Дамир: Монда телефон бармы соң? Казанга шалтыратып, Рәшидә апага әйтергә кирәк... «Камал абый сине сорый», — дип.

Камал-III: Рәшидә апагызга сездән башка да житкерүчеләр булыр, ә сез... (тынлык)

Дамир: Без нишләргә тиеш соң?

Камал-III: Ач әнә шул «акъегетне» и... һәм дальше...

Кыскасы, ул төнне Камал абыебыз, күрмәгәнен күргәндәй, «артыгын жибәреп» йокларга ятты. Без дә, сәхнәсез спектакльне әйбәт уйнавыбызга шатланып, Дамир белән бер караватта йокларга яттык. Иртә белән иртүк Камал абый чәй эчәргә уята.

— Нәрсә булды монда төнлә белән? Ник тормыйсыз һаман?

— Утырдык, — ди Дамир.

— Кем белән?

— Ресторан директоры белән.

— Килдемени ул?

— Син йоклауга... тут как тут!..

— Кара, нинди хәйләкәр «киек» икән?!. ...Әле мин чәйгә баргач, сораган идем — белмәгәнгә сабышкан була? Точно ничәдә килде?

— «Точно» дип әйтергә сәгатькә каралмаган... Аның вакыты безгә нәрсәгә кирәк? Важно килүе!

— Онытыгыз бу хакта! Галәмгә чыкмасын! Галимә апагыз ишетсә, Асия апагызга житәчәк! Аннары... Рәшидәгә.

...Әлбәттә, бездән сүз чыкмады. Чөнки чыгарлык сүз юк иде. Ә менә Камал-III үзе, очрашкан чакларда, күзен кысып: — Молодцы, егетләр, сезнең белән разведкага барып була, беркем берни белми, — дип шаярта иде.

Гастрольләрдән соң уздырыла торган йомгаклау жыелышында махсус сүз алып, Камал абый мине мактамакчы булды:

— Әхтәм Зариповның оештыру сәләте бар икән. Мин аның житәкчелегендә гастрольләрдә йөрергә түгел, театрда эшләргә дә риза! — дип ычкындырмасынмы!..

Шуннан соң, аның гастрольләргә чыкканы булмаган кебек, минем дә администратор булып чыгуымның ахыргысы шул булды. Директорыбыз Рәшидә

апаның һәр сүзгә, һәр очракка үз карашы бар иде. Ә Камал абый, өченче булса да, үзен беренчеләрдән санаучы иде. Бәлки аңа гомеренең соңгы елларында театр житәкчелегенең өченчегә караган кебек каравы да кире тәэсир ясагандыр — ул кинәт кенә чирләп, кеше кулына калмыйча, бик тиз генә, 70 яшен дә тутырмый, үлеп китте.

Баш ролен Н.Черкасов башкарган «Все остается людям» дигән кинофильм бар иде.

Камал абыйдан ни калды соң кешеләргә? Якты исеме! Кеше булган кеше өчен бу иң кыйммәтле сыйфат. Олы җанлы, йомшак күңелле беркатлы кеше иде. Исеме генә дә ни тора бит: Камал-III.

## Фатих Кульбарисов

Без аны үзенә ишеттерми генә «Кульба» дип йөри идек. Ишеткәндә дә ул аңа үпкәләмәс, ачуланмас та иде. Чөнки, ул... үпкәләү түбәнлегенә төшмәс горур, ачуланып вакланмас олы җанлы кеше иде.

Шәхес булып өлгергән кешенең үзенә генә хас гадәтләре, яраткан сүзләре, йолалары була. «Җаныңның ваклыгын сылтама заманга» дисәләр дә, заман мәҗбүр иткән гадәт-йолалар да буладыр, күрәсең. Фатыйх абый гәүдәгә зур булса да, көчле түгел — тиз арый, йөрүе салмак-акрын иде. Бу аның үпкә авыруы булудан гына түгел, гадәтенә дә әверелгән иде.

Тәмәкене күп тартуына күнегелсә дә, икенче бер начар гадәтенә күнегерлек түгел иде. Анысы — акчага сатып алынган гадәт — хәмергә бәйле иде. Мин аның исереп, егылып яткан чагын да, сүгенеп утырганын да күргәнем булмады булуын. Әмма, Кульбача «кульбалануын» күрсәткән чаклары белән еш очрашкаладым: йоклаганда тешен шыгырдата, яман гырлый иде.

Әлеге дә-баягы радиода режиссер вазыйфаларын үтәгәндә, текст укырга Фатих абыйны чакыра идем. Иртәнге сәгать 9га чакырсаң, 11гә кадәр ике сәгать вакыт арасында яздырып өлгерергә кирәк. Ә Фатих абый утыра, дәшми. «Нәрсә булды?» — дип студиягә керәсең. Ә ул, күтәреп, бер генә сүз әйтә: — «Кибә...» — ди, үнәченә күрсәтә. Су бирәсең — түгә: «Басмый», — ди. Аптырагач, «соңыннан», — дисең.

...Радиода язылу тәмам. Театрга репетициягә керәбез. Үзенчә Фатих абыйны алдадым, котылдым, дип уйлыйсың. Ә ул китмәгән, көткән, утыра!

— Кибә, — ди.

...Төрле чакта төрлечә котыла идек. Ул «кибә» дигән саен аны «чылата» барсак, үзебез дә «юешләнеп» беткән булыр идек. Яраклаштык: ул безгә, без аңа түздек. Берчак котыла алмадым — тотылдым! Нинди иблис котырткандыр — кредитка «Прогрес-4» дигән катер алырга булдым. Аны корып куйгач, мактатыр өчен, Фатих абыйга күрсәтәсе иттем. Олы башын кече итеп, катер карарга килде бу. Март ае иде булса кирәк, тамчылар тамган җылы көн иде.

— Күпме тора бу? — дип сорады ул катерга 10-15 адым ара калдырып, тукталгач.

— Машина хакы булмаса да, машина рәхәтен бирер хак! — дидем мин җавабымның тапкырлыгына куанып.

— Машинадан рәхәт тапкан кеше артист була алмый! — диде дә, китте Фатих абый! Шешәгә дә карамады, чакыруларымны да ишетмәде. Шакларкатып калдым...

...Шуннан соң күпме вакыт узгандыр, мин аның эчкән чагын да, махмырлап йөргән чагын да күрмәдем.

...Чын яз килде. Катерны суга төшерер чак җитте. Ә минем моторым юк. Ижевскийдагы туганнар шалтырата: «Сиңа кирәкле «Нептун-23» моторын алдык, кайчан киләсең?» — диләр. Ул чакларда кешедән акча алып тору проблема түгел — бер көн эчендә кирәкле сумманы җыйдык та, мин Ижевскига барырга булдым. Труппа мөдире Бикә апа Шакирова бүлмәсендә кайсы спектакльдә ролемне кем уйнарга тиешлекне хәл итеп утырганда Кульба килеп керде. Мин, куанып, «Фатих абый!» — дип Бикә апага пышылдадым. Бикә апа расписаниегә язганчы, Фатих абыйга телдән әйтүне кирәк тапты.

— Мин!?! Әхтәмнән калган рольне уйнаргамы?!? Ха! Никогда!

— Калган түгел: иртәгә кайтып өлгермәгән очракта, страховка өчен генә кисәтеп куюем бу.

— Ярый — риза. Тик бер шартым бар: катерын сатсын! Килешми ул ана.

— Ничек сатыйм мин аны? Шуна матор алырга барам ич!

— Маторы белән сат! Эта игрушка не для тебя, энем. Син сәхнәдә уйнарга тиеш, суда түгел!

Фатих абыйның каргышы төштеме — урладылар минем ул катерымны. Рәхәтеннән бигрәк михнәтләрен генә күреп калдым: өч ел кредит түләдем.

Ижевскига китәр алдыннан, труппа мөдире бүлмәсеннән чыккач, тимер юл кассасына билет алырга барырга тиеш идем. Китеп өлгермәдем — Кульба килеп чыкты.

— Молодец, белеп коткәнсен! — ди.

— Нәрсәне белеп көткәнмен?

— Кибә!

— Кипсә кибә инде, абзый, минем билет алып, поездга утырасы бар.

— Өлгерерсен, шалтыратырбыз.

— Кемгә шалтыратырбыз? Ничек? ...Минем әле өсне дә алыштырмаган. «Шалтыратырбыз», имеш...

— Алыштырырсын! «Горняк» аша өенә кайтабыз. Мә сина 1 сум. Хатынына чәйлек күчтәнәч, шуна өстәп бер «бомба» алырсын. Шунын белән солых төзелә: син катерынны сатарга сүз бирәсен, мин теге чактагы сүзләрне кире алам.

Нишләмәк кирәк — алдым кәнфит белән «бомба»ны, кайттык өйгә. (Комлев урамы, 4 йорт) хатынымнын күзләре «шар» булды.

— Нигә китмәден? — ди, кәнфиткә карый, «крахмал» дигәнен ишетеп калам.

Фатих абый дилбегәне үз кулына ала: «Нелетная погода, билет сатмыйлар». Тышта, анын сүзен раслагандай, күк күкрәп яңгыр ява иде.

...Такси чакыртып, кунакны озаткач, вокзалга төшәргә әйберләремне тутырганда, хатын нервымда уйный: «нелетная погода булгач, кая жыенасын?» — ди.

Мин дә югалып калмадым: — «Поездга погода нипочем!» — дидем.

Фатих абыйга театрдагы «погода» сизелерлек йогынты ясагандыр дип уйламыйм. Ул гайбәттән кача — тынламый иде.

...Анын бертуган абыйсы Зәки абый Казандагы зур тегү фабрикасынын генераль директоры иде. Ана таянудан түгел, үзен бәйсез тоюдан Кульба тәм таба иде кебек. Әлбәттә, театр хужалары фабрика директорынын да кирәклеген онытмаганнардыр.

Фатих абыйга холкы, кирәкмәгән гадәтләре өчен озак кына исем бирмәделәр. Тукай премиясен беренчеләрдән булып алса да, исемсез булуына кимсенә иде шикелле. Әмма, үзенен талантлы булуын, «аристократ канлы» икәнен белеп яши иде. Жиденче буында өзелгән мулла династиясеннән бит ул!

Анын холкына кемнәндер, нәрсәдер ялвару, ялыну ят иде. Ягъни, «спай тунмас — калтырар» иде. Ул сорамады, үзенә кирәкне таләп итте. Әлбәттә, аны тынламадылар, ишетмәделәр, бирмәделәр.

Фатих абый Кульбарисовнын театр тирәсендә буталып, елышып йөргән яшь-жилкенчәк белән «каланчага менеп» әнгәмә кору «чире» бар иде.

Гадәттә, ул әнгәмә «нәрсә, аллә артист буласын килә?» — дигән сорау белән башланып, стакан чәкештерү белән тәмамлана иде. Анын бу чирен ничек дәвалап булуны без тиз анладык. Бездән сон килгән буыннар да «без үзебез артист булырга теләүчеләрне аулыйбыз» дип, Кульбадан качалар иде. Шул чакларда ул бик кызганыч була иде. Шулай да, Фатих абыйнын сөйләшеп утырырга теләү «магниты» көчле иде. Ул ялгызлыктан, кешеләргә артык булудан курка, һәрчак үзенә тынлау объекты эзли иде кебек. Анын сөйләр сүзләре күп, әмма күнеле бикле, «йозак» авыр ачыла, шул — артист булу-булмау темасы гына жинел чишелә иде.

1963 елнын августы бугай — Урта Азиядә гастрольләрдә йөрибез. Төп базабыз Алма-Атада, башка шәһәрләргә бара-килә уйныйбыз. Бер фото-рәсем Фрунзе шәһәренә барганда, маторы кызып, автобусыбыз тукталгач төшерелгән. Артистлар бик йончыган. Тирә-яктагы матурлыкны түгел, бер-берсен дә күрмәс хәлдәләр.

Фатих абый тегенен янына да, монын янына да килә, үзе һаман бер үк сүзне кабатлый: «таудан тау күренми икән! Кая Һималай, кая Памир?!» Мин аны әле хәзер дә аңлый алмыйм: Ала-Таудан Памир күренергә тиеш иде микәнни?

Гомумән, бик аңлаешлы булырга тырышса да, аны аңламаган чаклар була иде. Шулардан берсе: Фрунзеда (хәзерге Бишкек) спектакльдән соң кунакханәгә кайтып йокларга җыенганда, бүлмәгә Фатих абый килеп керә, гадәтенчә «кибә»не әйтә һәм әмер-боерыгын ирештерә: «Ничек тә табыгыз!» – ди. Сорамый – боера! Каян табасың? Чит республика. Безгә ят холыклы кыргызлар, төнлә гостиницадан чыгармыйлар.

Бүлмәдәшем Дунай әйтә:

— Акчаң бармы соң? – ди аңа туп-туры. Фатих абый андый сорауларга унай җавап биреп өйрәнмәгән. Шулай да, бу юлы акча санап куярга җөрьәт итә бит. Могҗиза! Нишләмәк кирәк?! Тапмый булмый – тәрәзәне ачып, ресторан ишеген саклаган каравылчыга гозеребезне җиткерәбез. Каравылчы үз хакын әйтә, Кульба өсти, һәм без, акчаны ташлап, простыняны сузабыз. Кыргыз карты акчаны тапмый, шешәне бәйләми. Ачуы килгән Дунай, ишекне ачтырып, аска юнәлә. Каравылчы, акчаның өстенә читеге белән басып, юри тапмаганга сабышкан икән! Иң кызыгы шунда – Фатих абый ул аракыны эчмәде, «азартым кайтты», диде. Анын урынына безнең азарт уянган иде. Шешәнең бөкесен мин ачтым. Стаканнарга салсак – сыеклык ның сыекланган, исе килерлек кенә спирте калган иде.

Хәтеремдә юк – Фатих абый нихәлдә чыгып китте икән?

...Без өстән кычкырып каравылчыны күпме генә чакырсак та, эндәшүче булмады. Бәлки, безне алдаучы кеше каравылчы да булмагандыр, шулай кәсеп итүче булгандыр? Бәлки... бәлки...

...Икенче көнне Кульба спектакльгә салып килгән иде. Бәхетенә роле «Казан сөлгесе»ндәге сүзсез диндар гына булганлыктан, бу «ЧП»ны тикшерү эшен чираттагы җыелышка калдырдылар.

...Җыелыш, ялгышмасам, Чимкент шәһәрендә уздырылды. Хәтердә калганы шул: Кульбадан: «Эчмәскә сүз бирәсеңме?» – дип сорый директорыбыз Рәшидә апа. Фатих абый: «Сүз бирәм!» – ди. Күп кеше кул чаба. Шунда ул шатланучыларны бүлдереп: «Эчмәскә түгел, исермәскә!» – дип өсти. Габдулла ага Фәтхуллин: «Биссәүсни! – дип кычкыра, — Син бит коллективка рәхмәт әйтергә тиешсең! – ди.

— Коллективка! Крокодилга түгел! – ди Фатих абый, — аннары: — Спектакль алдыннан син салып бирден миңа, мә, тынычлан, — диден, Дунай белән Әхтәмне төнлә аракы сатып яткан өчен хөкүмгә тарттырырга кирәк, — диден.

— Хәзер дә әйтәм: сатмасыннар төнлә!

— Мин аларга «молодец», — дим. Алар артист, син крокодил.

Шулай исермәскә сүз биргән Фатих абый, чынлап та гомеренең соңгы айларында эчмәде, эчмәгәч, исермәде дә. Кыскасы: аңа үзенә лаек эш җитмәде. Тәрҗемә белән дә шөгыльләнеп карады. Дәвамлы эшкә түземе җитмәде. Һавасыз бушлыкта кош оча алмаган кебек, Фатих абый биеккә күтәрелә алмады. Анын үзенә, талантына лаек дәрәҗәләре юк, әмма Фатих Кульбарисов дигән исеме бар иде. Үләре алдыннан больницада ятканда хәлен белергә бардым. Бик гаҗәпләнде, шатланды дип әйтә алмыйм. Мин телевидениедә, ул театрда «эшли» исәпләнә. Сирәк очрашыла. Ничәнче куелышы булгандыр – тагын «Казан сөлгесе»н куюларын әйттем. Тынычландырам, роль көтеп ятмасын, янәсе... ә ул иртәгә терелеп чыгар кешедәй: «Роле булмаса, картлар булып чыгармын!», — диде. Ә иртәгесен радио күңелсез хәбәр җиткерде... йөрәк... диделәр. Шулай, терeләм дип яткан талантлы артист үлеп тә китте. Озатырга күп кеше килгән иде... Беренче хатыныннан туган Зөфәр исемле улы һәм оныклары да. Анын турында сәхнәдәшләре күңелендә гел якты, матур хатирәләр генә калды. Чөнки ул беркатлы, зыянсыз, әдәпле, әхлаклы иҗади шәхес иде... Кульбарисов Фатих Әкърам улы!

## Зариф Закиров

Безне «Щепкинчылар» дип йөртәләр. Шулай аталудан зыян күрмәгәч, без каршылык күрсәтмәгәнбездер. Ә чынында исә, һәркайсыбыз диярлек татар җанлы татар баласы, күбебез авылдан, авыл мәктәбендә урта белем алган, читләтеп булса

да, «сугыш шулпасы» эчкән, эшләп үскән буын вәкилләре иде. Шул «эшләп үскәнлек» мине Зариф абый Закиров белән дуслаштырды да. «Дуслаштырды» дип әйтү артыграктыр, дөресе якынайткандыр.

Зариф абый Закировны без – «Щепкинчылар» декада спектакльләрендәге рольләре буенча 1957 елдан белә идек. Иң истә калганы «Хуҗа Насретдин» спектаклендәге Казый роле. Казанга кайтып эшли башласак, без белгән күп кенә өлкән артистлар труппа составында юк. Аларны, безнең кайтуга урын әзерләү максатында, штаттан чыгарганнар.

Зариф Закиров, Каюм Барыев, Мәрьям Сульва, Гөлсем Камская, Асия Мәсәгутова, Фатыйма Камалова, Гәүһәр Камалова, Закир Сафин, Асия һәм Шакир Харисовлар (репертуарда сакланган спектакльләрдә рольләре булса) махсус чакыру буенча гына килеп уйныйлар иде.



*«Каюм Насыйри». Мостафа — З.Закиров (сулда).*

Кыскасы, без кайтып эшкә урнашканда, театрның бинасы да, труппасы да туздырылган шөпшә оясына охшаш иде. «Безләгән», «выжлаган» тавыш ишетелә, шөпшәсе күренми. Күренгәне – чакмый узмый.

Зариф абый чакмый торган шөпшә кебек иде. Басынкы, сабыр, «мыжламый». Махсус укытып кайтарган артистларны «шөпшә оясы» белән каршылауга түзсәк тә, яшәр урын булмауга түзә алмыйча, без дә «мыжлый» башладык бер мәл.

«Чыгарылганнар»га «Щепкинчылар» да кушылып зарлануны Мәскәү ишетеп, комиссияләр килде, җыелышлар уза башлады. Нәтиҗәдә, безгә кемнәрдәндер бушап калган «почмак»лар бирделәр, чыгарылганнарның пенсия яшенә җитмәгәннәрен кире алдылар. (Бу – безнең җиңү дип аталды.)

...1961нче елның ноябрь башларында, тәкъдим ителгән ташландык бүлмәнең өч тәрәзәсеннән икесен томалап, яшәрлек итәр өчен, театр ишегалдына чыгарып ташланган такта башларын җыеп йөрим. Шунда ук Зариф абый Закиров та утынлык җыя.

— Сез... мич ягасызмыни, Зариф абый?

— Рәхәтләнеп яга идек тә, яңа елга яңага күчерәләр инде. Шунарчы күмер кабызырлык коры-сары кирәк. Ә сиңа бу такта калдыклары нәрсәгә?

— Ике катлы агач йортның аскы каты җимерелә башлагач, элекке хуҗалары күченеп киткән. Театр ярдәме белән без шуның черек диварын ныгыттык та, вакытлыча күчеп торырга булдык. Тәрәзәләрен томалап, эчтән фанер каксаң, кыш чыгарга була, диделәр. Ризалаштык. Балабыз бар бит.

— Кыш чыкканчы тормассыз. Әгәр яңа елга безгә яңа фатир бирсәләр, шунда – безнең искегә – сез күчәрсез...

— Аны безгә кем бирә?

— Менә мин бирәм, без бирәбез! ...Ул йортка театрның катнашы юк, минем хатын обком больницасында эшли. Фатир бирүчеләр – аның пациентлары. Сөйләшербез...

Зариф абыйның шикләнергә урын калдырмый әйтүе мине ышандырды. Фатирга өстәп, кайбер мебельләрен дә безгә калдырырга булып, шимбә көнгә бүлмәләрен карарга чакырды. Бардык. Мичтә пешкән өчпочмак ашап, чәй эчтек. Шунда мин ана бу кадәр җыйнак, иркен фатирны безгә бирмәсләр, дигән шигемне белдердем. Ә ул һаман үзенекен сөйли.

— Син мина ышанмасаң, олы артистлардан сора — бу фатирны мин юктан бар итеп, үзем ясаттым. Хөкүмәтнең тиен дә файдасы тимәде.

— Анысына ышанам.

— Кайсына ышанмыйсың?

...Зариф абый Закировның званиесе — исеме булмый.

...Театрның ул вакыттагы директоры Кәрим Гыйльманов әйтә, имеш: «Исемне бирәбез. Ләкин исем алуга театрдан китәсен. Яшьләр кайтуга урын кирәк», — ди. Шуңа җавап итеп Зариф абый: — «Указны укуга гариза бирәм», — ди. Һәм шулай эшли дә.

Форсаттан файдаланып, шул турыда сорадым, чынмы, дидем.

— Театрдан куылып киткәнче, үзең гариза биреп китү хәерлерәк.

— Шулай да кызганыч бит, — дидем мин.

— Әнә, зарланып, ялынып, ялварып гариза язучылар кызганыч, ә мин тыныч: әйттем, киттем!

...Һай бу дөнья... әйткәнчә, теләгәнчә генә бармый шул...

...Зариф абый фатирын карап киткәннән соң күпмедер вакыт узды. Ышанмасам да, күнелдә ниндидер өмет чаткысы «җемелдәп» куя. Өенә барырга, ана фатир алу-алмаулары турында сорарга кыенсынам. Радиода режиссер булып та эшләгән чак. Эдуард Касыймовның «Буразнада балык бар» дигән әкияте буенча радиоспектакльдә катнашырга чакырдым мин аны... Яна еллар узгач... Мәдрәсәдә укыганлыктан, догаларны бик оста укый иде ул. Аның карчыгы ролендә уйнарга Мәрьям Сульваны чакырдым.

Аларның бер-берләрен ничек сагынулары турында аерым язарга кирәк.

...Репетиция театр һәм артистлар турында хатирәләр тыңлау белән узды. Күчену, фатир турында Зариф абый да, мин дә искә алмадык.

...Соңыннан ишетеп белдем: Татарстанның атказанган артисты Зариф Закиров шул безгә бирәм дигән фатирында үлгән, яңа фатир бирүне билгесез вакытка кичектерү хәбәрен күтәрә алмаган, имеш дип сөйләделәр.

Озатырга гәүдәсен театрга куймадылар, хатыны рөхсәт бирмәгән, диделәр. Булса да булгандыр. Адашым Зариф абыйны еш искә алам. Адашым булганга гына түгел — фатир ала алмый калу буенча да язмышларыбыз охшаш булганга.

## Гөлсем Камская

Ничәнче ел икәнен төгәл генә хәтерләмим. Әмма Хрущев заманы икәнен беләм. Кибетләрдә азык-төлек беткән кытлык еллар иде. Сәхнә артында корылган әңгәмәләрдә дә ит, май турында сөйләшүче юк. Телләрендә талон, макарон гына. Унган кешеләр талон эзли, таба, аңа азык ала. Сирәк-мирәк янгыраган мәзәкләрдә дә төп персонажлар — талон, ризык. Ашау... Мәзәктән соң көлүне сүгенү алыштырган вакытлар да булгалый. Менә бер вакыйга. Кичке спектакльне уйнарга артистлар җыелып беткән энгер-менгер чак. Сәхнә артына бутафор Солтан килеп керә. Бер кулында каплы макароннар салынган ятьмә букча. Икенче кулында талоннар тасмасы. Ул аларны өзгәләп кесәсенә тутыра. Болай да тын гына утырган артистлар өнсез кала. Солтанда чын макарон һәм дөнья кадәр талон!

— Бутафор макарондыр ул, — ди кемдер, тынлыкны бозып.

Солтан бу сүзләрне ишетмәгәнгә салышып, букчасыннан берничә макарон ала да, расписание карый башлый. Үзе макарон ашый. Аңа бу ашауның да, расписание карауның да кирәге юк. Кылана бу. Тынлыкны Гөлсем апа Камская боза: «Ни булган бу Солтанга? Талоннар — дилбегә, букчасы тулы макарон!»

— Ун талоным чыкмый. Кибеткә барасы идем.

— Ун талон югалтып, шулай тыныч кына торасыңмы? Бар, әйберләреңне минем бүлмәдә калдыр да, барып кил кибетенә. Эзлә!

— Бүлмәдә макаронлы букча калдырсан...

— Алайса, бир, үзем саклап торам. Берсе дә югалмас.

— Юк, Гөлсем апа, калдырмыйм. Аяк өсте тәмләп торырлык кына алдым мин аны.

— Талонсыз бирделәрме?

— Мин үзем талон ич! Театрда эшләп тә талонга тилмерергә...
— Мина да алып бирмәссенме икән?
— Ничәү кирәк сон сина?
— Күпме булса да, артмас.
— Анда бер кулга биш килодан да артык бирмиләр. Партконтроль белән милиция саклап тора.
— Мә, алайса, биш кило ал да, калганы үзенә премиальный булыр.

Китә Солтан. Спектакль башлана. Тәнәфес житә. Артистлар таралыша. Гөлсем апа һаман Солтанны көтеп утыра. Кайтасы ерак түгел. Фатиры театр ишегалдындагы флигельдә генә. Аңа макарон кирәк — Әсфәне ач.

Менә бервакыт утларны сүндерергә дип, төнге каравыл килеп керә.

— Гөлсем апа, сез монда нишләп утырасыз?
— Солтанны көтәм.
— Бутафория бүлмәсендә бикләнеп утыралар алар. Итекче Женя, Солтан, Әхмәт — өчесе.
— Валлаһи, диген.



Г.Камская «Хаҗи әфәнде өйләнә» спектаклендә Нәсимә ролендә.

Төшеп, көч-хәл белән бүлмәне ачтырып керсәләр, чынлап та бикләнерлек тамаша күрәләр. Солтан өстәлгә сузып салынган, өстенә киндер ябылган. Әхмәт кулында гарәп язулы китап. Женя кулында шәмдәл. Гөлсем апа бу төркемнен кайбер шуклыкларыннан хәбәрдар булганлыктан, ниндидер этлек барлыгын сизенеп, Солтан өстендәге киндерне тартып ала.

— Ни булды, кая югалдың? Тор әйдә, тычкан күз!
— Спекулянт дип, милиция тотты. Әле шулар килде бугай дип, яшеренгән идек без. Беркая чыкмаска, бүлмәдә генә утырырга дип, кул куйдырттылар. Шул хәсрәттән бераз кәгеп алырга да өлгермәдек... Уз, утыр, Гөлсем апа.
— Макароным кая минем?
— Кая булсын? Кибеттә.
— Ни белән тоттылар сон сине?
— Алар мина бу кадәр талонны каян алдың, дип бәйләнделәр.
— Каян алганынны әйтергә дә кайтырга иден. Законныйлардыр бит?
— Әйттем дә кайттым. Менә хәзер баш ватып утырабыз — дөрес әйттем микән, дип...
— Каян алдым диден, кулданмы?
— Гөлсем Камская бирде, дидем. Әгәр иртәгә милициягә чакыртсалар, бәдрәфтән таптым диярга кирәк. Мин алар килүгә менә шулай итеп ятачакмын.
— Уф Аллам, башларымны ашагансың икән. Ач тамагым — тыныч колагым иде...
— Сезгә берни дә булмый, — дип сүзгә кушыла Әхмәт. — Аңлавымча, бездән алар яшерен типография эзләячәк. Ә типография юк. Без талоннарны итек табанын кисеп ясаган мөһер белән генә баскан идек. Кем уйлаган аны шулкадәр охшашлы килеп чыгар дип. Ә акчаң исән, Гөлсем апа, әнә, санап ал.
— Алдым ди сезнең өтермән исле акчагызны! Өнегез тыгылсын! Ачыгыз ишегегезне, мошенниклар.

Икенче көнне милиция килеп тикшергәч, талоннарның чыннан да реквизит өчен генә эшләнүе, жинаять юклыгы ачыклана. Мөһердәге сүзләрне лупа аша укып карасалар, анда вак хәрефләр белән: «Бутафория цехы. Әхмәт-Солтан», дип язылган.

**Әхтәм ЗАРИПОВ**

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Арча

Казан арты районнары үзәкләренең борынгысы һәм традицияләре белән аерылып торганнарыннан берсе – Арча эшчеләр бистәсе. Ул Казаннан 65 чакрым ераклыкта урнашкан.

Арча атамасы тарихи чыганакларда һәм татар халык иҗатында еш очрый.

Казансу ярына утырган Арча Казан ханлыгы чоры торак пунктлары исемлегенә теркәлгән. 1602-03 елларны эченә алган Казан өязе Теркәү кенәгәсендә Арча шәһәре, Арча юлы һәм Арча кыры күп тапкыр телгә алына. И.П.Ермолаевның "Казанский край во второй половине XVI – XVII вв." дигән хезмәтендә 1567-68 елның август ае белән Арча, Нугай, Чюваш (югары һәм урта), Алат, Атыз, Иске Йорт юллары искә алына.

Арча тарихы борынгы чорларга барып тоташа. Археологлар борынгы болгар-татар шәһәре Арчаның яшәү чорын XIII – XVI йөзләр дип билгелиләр.

Хәзерге Арча тимер юл станциясенең көньягында Казан ханлыгы дәвереннән калган каберташлар сакланган зират булган. Картларның әйтүенә караганда, әлеге ташларның (6-7 данә) күбесе чүп-чар астында калган. Аларның берсе мәчет халкы тарафыннан станциянең татар зиратына күчерелгән. Әлеге таштагы язуларның сакланышы начар, шулай да «тарих тукыз йөз иллик...» дигән сүзләрне укып була. Димәк, каберташ Арчада 1542-50 еллар арасында вафат булган кеше каберенә куелган. Ул чорларда Арча каласы Арча юлының (даругасының) административ үзәге булган.

Арча өязе 1866 елның 1 сентябрь – 1867 елның 30 гыйнвар арасында «Аграрный вопрос и крестьянское движение в Татарии XIX века» дип аталган тарихи чыганакта телгә алына, 1236 елда Болгар дәүләте җирләре монголлар тарафыннан буйсындырылганнан соң болгар халкы, әледән-әле баш күтәреп, ирек даулап яши. Шундый кузгалышларның берсе 1278 елда була. Бу турыда, төрле тарихи чыганакларга таянып, Әбелгази Баһадур хан үзенең «Төрки халыкларның шәҗәрәсе»ндә һәм күренекле татар галиме Шиһаб Мәрҗани «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» әсәрендә язып калдыралар. Әбелгази язмаларында мондый юллар бар: «1266-82 елларда идарә иткән Алтын Урда ханы Менгү Тимер баш күтәргән халыкны буйсындыру өчен Болгар иленә бара һәм ике ел буена сузылган сугышлардан соң, болгар халкын кабат буйсындырып, җиңү белән кире кайта». Менгү Тимер Болгар илендәге чуашларны бастыру өчен кайбер рус кенәзләренең ярдәменнән дә файдалана. 1278 елгы кузгалышларны бастыруда актив катнашкан рус кенәзе Федор Ростиславичка хан үзенең кызын кияүгә бирә һәм ана тагын 36 шәһәр бүләк итә. Алар арасында, Чернигов һәм Корсун кебек шәһәрләр белән бергә,

*Дәвамы. Башы 2006 елның 6нчы санында.*

Арча шәһәре дә искә алына. Бу турыда «Степенная книга» дип аталган чыганакта әйтелгән. Рус елъязмаларына караганда, Вятка ушкуйниклары (юлбасарлары) 1379 елда Арча җирләренә яу белән киләләр, ә 1496 елда шәһәргә Мамук житәкчелегендә нугайлар һөҗүм итүе мәгълүм.

1552 елда Казанны алу вакыйгаларына бәйләп, Арчаны кенәз А.Курбский да искә ала.

Арча турында фәнни хезмәтләр байтак. Е.Малов «Иске Казан шәһәрлеге һәм Арча шәһәре» дип аталган мәкаләсендә (1853) Арча шәһәренең ныгытмасы һәм аның җиде манарасы булганлыгын әйтә, аларның һәрберсенең урыны һәм төзелеше турында тәфсилләп сөйли.

В.Л.Борисов, Арча якларында яши торган татарлар сөйләвенә нигезләнеп, бу урында борынгы заманнарда шәһәр булуын, башта аның Алтын Урда ханнарына, аннан соң Казан ханлыгына буйсынганлыгын хәбәр итә. Ул Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте хәбәрләрендә (XVI том, 3 чыгарылыш) урнаштырылган. «Казан өязе Арча шәһәренең борынгы манарасы» дип исемләнгән мәкаләсендә ул үзе барып күргән, ул заманнарга инде кечерәеп калган Арчадагы тарихи агач манараны тасвирлый. Вакытлар үтү белән манара җимерелгән, ләкин автор Казан ханлыгы чорында зур әһәмияткә ия булган бу манараның кайчан салынуын һәм нинди вазифа үтәгәнлеген ачыкларга тырыша. Билгеле булганча, Арча гербында имәннән төзелгән өч манара бар: анда басу уртасына урнашкан ныгытма-крепость сурәтләнә. В.Л.Борисов Арча шәһәренең әле дә шушы гербтагыга охшашлыгын әйтә. Ләкин манараларның тик берсе генә сакланып калган була.

Н.И.Второв бу манараның Казан ханлыгын руслар яулап алганчыга кадәр үк төзелү ихтималын искәртә, чөнки аның формасы һәм архитектурасы шундый ук борынгы корылмаларга тартым. А.Артемьев та шушы фикерне куәтләгән. Ул Арча тирәсендәге борынгы өекнең (урның) сакланып калганлыгы турында яза. Кайбер галимнәр манараны корал саклау өчен, икенчеләре исә каравыл тору максатында төзелгән дип уйлый. Ләкин ничек кенә булмасын, ул Казан ханлыгы чорында төзелгән булырга тиеш. «Казан елъязмачысы» дигән тарихи чыганакта мондый юллар бар: «Ул кала Арча дип йөртелә, нык итеп шәһәрчә корылган, аның манаралары һәм күзләүләре (бойницалары) бар һәм анда кеше бик күп, шәһәрне яхшы саклыйлар, үзенең әле беркайчан да алынганы юк. Ул Казаннан 60 чакрым ераклыкта, ерып чыккысыз чытырманлы-сазлыклы җирдә урнашкан. Ана бары тик бер юл белән генә килеп яки чигенеп була. Воевода кенәз Симеон күрде: моны алай җинел генә алып булмый, халкы бик күп, гаскәре генә дә 15 мең; шуннан соң ул туплар һәм пищальләр китереп аттыра башлады».

Р.Г.Фәхретдинов Арча Алтын Урда чорының икенче яртысында, ягъни XIV йөз ахырларында һәм XV йөз башларында барлыкка килгән, дигән фикер үткәрә. Бу фикерен ныгыту өчен ул Арча шәһәрлегендә табылган Җучи акчасын дәлил итеп ала.

1859 ел мәгълүматларын эченә алган белешмәдә күрсәтелгәнчә, Казансу ярына утырган Арча каласының 315 йортында 587 ир-ат һәм 751 хатын-кыз көн иткән. 2 чиркәү эшләгән, ял көннәрендә базар үткәрелгән, приход (мәхәллә) училищесы, күн эшли торган, май ясый торган һәм башка заводлар булган.

Арча шәһәре стратегик яктан башка болгар шәһәрләре кебек үк уңайлы урынга утырган. Тау өстеннән Арчаның тирә-ягындагы җирләр уч төбендәге кебек күренеп ята. Шәһәрлек хәзерге Арча эшчеләр бистәсенең үзәгендә, «Мещаннар чиркәве» тирәсендә урнашкан булып, Казансуның уң як яр буе һәм зур, тирән чокыр арасындагы өчпочмаклы мәйданны биләп тора. Казан юлы белән килеп, Казансу аша салынган күперне чыккач та, каршыда ук шәһәрлек күренә. Арчага менеп житеп үзәк урамга кергәндә, уң яктагы тирән чокыр аша аның борынгы урларын күрәсең. Бу өчпочмакның як-якларында элек агач диварлар сузылып, алар арасында манаралар булган. XVIII йөздә әле ныгытма-кальга тулысынча сакланган булса кирәк, чөнки шул заман галиме И.Георги аның турында «агачтан төзелгән ныгытмалары булган, ачык урындагы кечерәк шәһәрчек» дип язып калдыра.

«Арча» сүзенең мәгънәсе күп кешене кызыксындыра. Тарихи әдәбиятта Арча арлар, ягъни удмуртлар шәһәре булган дигән фикер очрый. Бу фикер белән килешмәвен белдереп, Р.Г.Фәхретдинов хаклы рәвештә: «Казан ханлыгының үзәк җирендә удмурт шәһәре бөтен бер татар кенәзлегенең башкаласы була алмый. Арча тирәсендә хәзерге вакытта бер генә удмурт авылы да юк һәм алар элек тә булмаган. Без Казансу бассейнын, шул исәптән Арча якларын да бик җентекләп өйрәнеп чыктык, тик бер генә удмурт археологик истәлеге дә тапмадык», — дип яза. Арча атамасының барлыкка килүен ул артыш үсә торган тауга мөнәсәбәтле итеп карый (төрки телләрдә арча «артыш» мәгънәсендә кулланыла). Бу фикер игътибарга лаек, чөнки болгар шәһәреннән Тубылгытау һәм Җукәтау атамалары үзләре утырган тауда тубылгы һәм юкә агачлары үсүгә нисбәтән барлыкка килгәннәр. 1552 елда Явыз Иван Казанны алганнан соң Арчага укчылар һәм казаклар китереп утырта. Арча ныгытмалары русларга җирле халыкларның һөҗүмнәреннән саклану өчен хезмәт иткән.

Арча исемен йөртә торган бистә Ульян өлкәсендә дә бар. 1649 елда Казан өязенең Арча шәһәреннән 50 казакны, җир белән тәэмин итеп, Сельдь суы ярына, Сембер ныгытмаларын саклау өчен күчереп утырталар. Бу казаклар бистәләрен үзләре элек яшәгән шәһәр исеме белән Арча (Арск) дип атаганнар. Соңыннан бу бистәдән тагын Кече Арча дип исемләнгән авыл да аерылып чыга. Анысын Кротовка дип тә йөртәләр.

Арча атамасы төркиләр яши торган башка төбәкләрдә дә очрый. Кыргызстанда арча сүзе белән ясалган атамалар шактый: Арча-Башы бозлыгы, Арча-Башы елгасы, Арчагул авылы, Арча-Булак авылы, Арча-Даван, Арчалы үткелләре, Арчалы исемен йөрткән алты елга атамасы, Арчалы - ике авыл исеме, Арчалы үзәне, Арчалы суы елгасы, Арчалы-Тор елгасы бар.

1938 елдан башлап Арча эшчеләр бистәсе категориясенә кертелгән. Ул республикабызның төньяк-көнбатыш өлешендә, Казансуның урта агымында утырган, Арча районының үзәге.

Анда хәзер кирпеч заводы һәм башка төрле сәнәгать предприятиеләре бар. 1932 елдан бирле педагогика училищесы эшли.

Арча районы 1930 елның 10 августында оеша. 1990 елда Арча районыннан Әтнә районы аерылып чыга. Терлекчелектә мөгезле эре терлек үстерү алга киткән. Яңа Кенәр авылында агач эшкәртү комбинаты, Тукай-Кырлай авылында Габдулла Тукай музее бар.

Арча янында балыклы күлләр җәелеп ята. Алар ел тәүлегендә халыкны балык белән тәэмин итеп торалар.

Бистәдә чишмәләр дә шактый. Халык бигрәк тә Вахитов чишмәсе суын яратып эчә. Кешеләр чишмәләрне чистартып, төзекләндереп һәм улакларын карап торалар.

Арча шәһәр статусында.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

# Р

**РАХМАНИ** (Рахман) Равил Фәйзрахман улы (8.5.1949, Буа р-ны Адав-Толымбай а.), әдәбият галиме, әдәби тәнкыйтьче, шагыйрь, филология фәннәре кандидаты (1985), РТнын атказанган мәдәният хезмәткәре (1999). Казан ун-тын тәмамлый (1971). 1974 елдан (бүленеп) Татарстан китап нәшриятында. 2002-05 елларда ТРнын РФдагы вәкиллегендә, 2007 елдан соң ТР ФА Тел, әдәбият һәм сәнгать интында (2007-12 елларда бүлек мөдире). Хезмәтләре татар әдәбияты теориясенә һәм тарихына карый. «Татар балалар поэзиясе антологиясе» (1980) төзүчеләренен берсе.

Әсәр.: Шигъри бишек. К., 1981; Канатлы дөнья. К., 1984; Мең чакрымга мең чакрым. К., 2006.

Әдәб: Вәли М. Гасырлар ярында... // Казан утлары. 1999. № 5; Юныс М. Чакрымнарын югалткан мең чакрым... // Казан утлары. 2009. №5.

**РАХМАНКОЛЫЙ** (Рахманкулов) Солтан (Әхмәтсолтан) Габделмәннән улы (1888, Казан губернасы Олы Шынар авылы — 8.4.1916, Казан), язучы, тәрҗемәче, тел галиме. Казанда 1нче реаль уч-щесында укый, аннан 1905 елда студентлар дулкынлануында катнашкан өчен куыла. 1908 елдан «Йолдыз» газетасы редакциясендә эшли, анда үзенен беренче хикәяләрен бастыра. Соңыннан алар «Мәлиха куагы» (1918) җыентыгына кераләр (1979 елда М.Мәһдиев кабат бастыра). 20 йөз башы татар матбугатында Р.нын публицистик мәкаләләре һәм тәрҗемәләре актив бастырыла. Татар теленә А.С.Пушкин, Л.Н.Толстой, И.С.Тургенев, М.Горький, В.Гюго әсәрләрен, фәнни-популяр характердагы брошюралар тәрҗемә итә. Мәктәпләр һәм мәдрәсәләр өчен «Русча-татарча кесә лөгате» (1915, автордаш), башка рус-татар, татар-рус сүзлекләре һәм уку әсбаплары авторы.

Әдәб.: Гайнуллин М. Татарская литература и публицистика начала XX века. К., 1983; Татар әдипләре һәм мәгърифәтчеләре (XX йөз башы): Биобиблиографик сүзлек. К., 2005.

*А.М.Ахунов*

**РӘДИФ** (гарәп. җайдак артында утырып баручы), шәрык халыкларынын поэтика атамасы; шигъри юлнын ахырында, рифма артыннан (сирәк очракта алдыннан), үзгәртелмичә кабатланып килүче сүз (кыска Р.) яки сүзләр төркеме (кинәйтелгән Р.) Гарәп, фарсы, төрки поэзияләрендә шигырьнен интонацион янгырашын, музыкальлеген көчәйтү өчен поэтик фигура буларак кулланыла. Газәл, касыйда, робагый жанрларында очрый:

«Иктисар ит гадәтенчә, ян, күнел, сызлан, күнел!

Күп сөекледер бөтеннән — Тәнрегә сынган күнел!»

Лит.: Квятковский А. Поэтический словарь. М., 1966; Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990.

**РӘКЫЙБИ** (Габделрәкыйбов) Рәкиб Кәрим улы (1887, Оренбург губернасы Каргалы а. — 1963, бүтән мәгълүматлар буенча, 1967, Ташкент шәһәре), тәрҗемәче, журналист. «Хөсәения» мәдрәсәсендә укый, 1905 елда революцион хәрәкәттә катнашкан өчен аннан куыла. 1906-10 елларда «Казан мөхбире», «Бәянелхак» (Казан), «Вакыт» (Оренбург) газеталары хезмәткәре. 1910-19 елларда хәрби хезмәттә, Гражданнар сугышында катнаша. 1919 елдан партия эшендә (Минск, Севастополь, Феодосия, Чимкент һ.б. шәһәрләрдә). 1930 елларда Каракалпак автономия өлкәсе Төрткүл шәһәренен пед. техникумында, соңыннан Нукус шәһәренә күчә, анда җирле газета чыгаруны оештыра һәм аны 1950 елга кадәр житәкли. Татар теленә Л.Н.Андреев, В.М.Гаршин әсәрләрен, Гөлнар ханымнын (О.С.Лебедева) «Мөслимәләр хөррияте» («Об эмансипации мусульманских женщин», СПб., 1900)

*Дәвамы. 2005 елнын 4нче санынннан басылып килә.*

исемле хезмәтен, социал-революцион эчтәлекле брошюралар тәрҗемә итә.

Әдәб.: Татар әдипләре, мәгърифәтчеләре (XX йөз башы): Биобиблиографик сүзлек. К., 2005.

**РӘКЫЙПОВ** Роберт Жиһанша улы (10.11.1936, Чүпрәле р-ны Яна Чокалы ав. — 4.5.1995, Әлмәт шәһ.), шагыйрь. Казан ун-тының физика-математика факультетын тәмамлый (1970). 1969-74 елларда Чүпрәле р-ны мәктәпләрендә укытучы, соңрак мәктәп директоры булып эшли. 1974 тән Әлмәт шәһ. яшь һәм интернат-мәктәптә физика, математика фәннәрен укыта. «Сагыну» (1981), «Сина гына ачам күңелемне» (1983), «Яшьлегем башкаласы» (1985), «Жилкәннәрдә зәңгәр жилләр» (1986), «Хәтер урамы» (1988) исемле шигырь җыентыклары авторы. Иҗатында күбрәк дингез тематикасы, туган җиргә мәхәббәт. Р.ның шигырьләренә көйләр язылган; «Мин яратам сине, Татарстан!», Р.Андреев көе) җыры 2008 елда Г.Тукай исем. ТР дәүләт премиясенә лаек булды.

**РӘКЫЙПОВ** Шамил Жиһанша улы (22.9.1929, Буа кантоны Яна Чокалы ав. — 17.2.2005, Казан), язучы, РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1980). Казан ун-тын тәмамлый (1967). Туган авылында колхозда эшли. 1950 елда, колхоз амбарчысы булып эшләгәндә, авылдашларына ашлык бүлеп биргәне өчен аны җавапка тарталар һәм 10 елга Себергә мәҗбүри хезмәт колониясенә хөкем итәләр; 1954 тә амнистия белән азат ителә. 1955 тән Казанда. 1957 дән «Татарстан яшьләре» г-тасында: әдәби хезмәткәр, тәрҗемәче, бүлек мөдире. 1966 дан Татарстан кит. нәшриятының яшүсмерләр-балалар редакциясе бүлеге мөдире. 1993-2000 дә «Шәһри Казан» г-тасында әдәби хезмәткәр. Иҗатының башлангыч чорында Р. скетчлар, хикәяләр, очерклар, лирик парчалар яза («Сөю билгесе», 1959; «Тынгысыз яшьләр», 1963 җыентыклары). 1960 еллар уртасыннан иҗатында төп урынны Бөек Ватан сугышы темасы алып тора. Татар әдәбиятында документаль проза тармагының нигезенә, сәнгати яктан баюына үзеннән зур өлеш кертә. Әдип сугышта батырлык күрсәткән халык вәкилләренең тулы образларын тудыруны максат итеп куя: архивларда казына, сугыш булган урыннарга сәяхәт кыла, элекке фронтовиклар белән очрашып сөйләшә. Шул бай материалларга нигезләнеп үзенең «Геройлар үлмиләр» (1978), «Аяз көктә карлыгачлар» (1982) исемле очерк җыентыкларын, Советлар Союзы Геройларыннан: Бари Шәвәлиев турында «Чәчәкләр сөйли белә» (1967; русчага тәрҗемәсе «О чём говорят цветы?», 1971), Гыйльфан Батыршин турында «Таңнар һаман матурмы?» (1970; русчага тәрҗемәсе «Прекрасны ли зори?», 1973), Иван Кабушкин турында «Кайдан син, Жан?» (1969; русчага тәрҗемәсе «Откуда ты, Жан?», 1974) повестьларын, очучылар Мәгубә Сыртланова һәм Ольга Санфирова турында «Кызлар-йолдызлар» (1973; русчага тәрҗемәсе «Звёздные ночи», 1983) һәм «Кипарислар җыры» (1976), генерал В.Гордовның фаҗигале язмышын сурәтләгән «Ак канатлы хатирәләр» (1990) романнарын яза. Әсәрләре белорус һәм чуваш телләренә дә тәрҗемә ителгән.

*Г.М.Габделхакова.*

**РӘМИЕВ** Зөфәр Зәйни улы (25.6.1938, Кама Тамагы р-ны Уразлы а.), әдәбият галиме, текстолог, филология фәннәре докторы (2002), ТР ның атказ. мәдәният хезмәткәре (1998). Казан ун-тын тәмамлый (1967). 1970 елдан ТР ФА нең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тында: текстологик төркем җитәкчесе (1976-2006), бер үк ватытта кульязмалар һәм текстология бүлеге мөдире (1996-97), директор урынбасары (2002-04), текстология бүлеге баш фәнни хезмәткәре (2007 елдан). М.Гафури (1980, т.1; 1983, т.3), Ф.Әмирхан (1989, т.3), Н.Думави (1985), С.Сүнчәләй (2005), Г.Исхаки (2005, т.6; 2012, т.9, авторлаш), М.Җәлил (т.1-5, 2006), Г.Тукай (2006, т.2), Г.Сөнгати (2007) әсәрләрен басмага текстологик әзерләү эшендә катнашты, «Татар шигърияте (XX гасыр башы)» (2004) антологиясен төзеде. Г.Тукай, М.Гафури, Ф.Әмирхан, Г.Камал, С.Хәким, Ш.Маннур, Ә.Давыдов иҗатлары, текстология мәсьәләләре, 20 нче йөз башы татар әдәбиятына, туган төбәкне өйрәнүгә багышланган хезмәтләр авторы. «Габдулла Тукай» энциклопедиясен төзү буенча төркем җитәкчесе (1996 елдан).

Хезм.: XX йөз башы татар әдәбияты: авторлык, төп текст һәм хронология мәсьәләләре. К., 2000; Тукай һәм замандаш әдипләр. К., 2004; Уразлы (Уразлино, Иске Каратай) авылы үткәненнән. К., 2004; Текстология татарской литературы начала XX века. К., 2008.

Лит.: Әдәбиятчы, текстолог Зөфәр Рәмиев. К., 2008.

**РӘМИЕВ** Исмәгыйль Габдулла улы (1.1.1895, Уфа губернасы, Эстәрлетамак ш. — 28.12.1969, Казан), библиограф, журналист. Туган шәһәре мәдрәсәсендә белем ала. 1911 елда Казанга килә,

«Сәйяр» театр труппасында суфлёр булып эшли (1912-14). 1915-17 елларда хәрби хезмәттә. 1917 елда 2 нче Бөтенроссия мөселман съездына делегат булып сайлана. Гражданнар сугышында катнаша; «Кызыл яу», «Кызыл йолдыз», «Кызыл дөнья» фронт газеталары редакцияләрендә эшли. 1922 елда Д.Юлтый б-н берлектә Уфада «Бабич» исемле журнал чыгара башлый (тиздән совет органнары тарафыннан ябыла). 1925 елдан Казанда. Академүзәк каршындагы әдәби мирасны бастыру комиссиясе сәркатибе, «Чаян», «Яналиф» журналларында, «Гажур» нәшриятында, «Яналиф» җәмгыятендә; 1930 елдан Татгосиздатта эшли. Татар теленең берничә орфографик һәм атамалар сүзлекләрен төзи. Татар теленә С.М.Степняк-Кравчинскийның «Яңа көчләр» («Новообращённый», 1920) драмасын, А.П.Чеховның «Футлярдагы кеше» («Человек в футляре», 1936) хикәясен тәрҗемә итә. Энциклопедик характердагы «Вакытлы татар матбугаты» исемле басма авторы. 1937 елдан Урта Азиядә яши. 1942-44 елларда Хезмәт армиясендә. 1945 елдан соң Кайбычта яши, район газетасында, мәдәният сараенда эшли (1956 елга кадәр). 1961 елдан янә Казанда. «Истәлекләр. Татарча басма сүз» (1956) китабы, татар мәдәнияте һәм революциягә кадәр татар әдәбияты эшлекләренә багышланган «Әдәби сүзлек» (Р.Н.Даутов б-н берлектә) биобиблиографик белешмәлек авторы (Р.Н.Даутов тарафыннан 2001 елда тулыландырылган вариантта кабат чыгарыла).

*Р.Н.Даутов.*

**РӘСҮЛЕВА** Фәридә Атилла кызы (29.7.1948, Казан), шагыйрә. Рус телендә яза. Ташкент ун-тын (1974), А.М.Горький исем. Әдәби ин-т (Мәскәү, 1984) тәмамлый. «Пролог» (1984), «Салкын иртә» («Холодное утро», 1989), «Вакыт уза» («Кончается время», 2006), «Чыңгызханның алтын быргысы» («Золотая труба Чингиз-хана», 2007) шигъри җыентыклар авторы. Башлангыч чор лирикасына эчкерсезлек, самимилек хас. Тора-бара Р. поэзиясе фәлсәфи юнәлеш ала.

**РӘФИКЫЙ** Гали Лотфирахман улы (29.6.1890, Уфа губернасы Бәләбәй өязе Баязит а. — 11.3.1944, Бәләбәй ш.), журналист, язучы, тәрҗемәче. «Галия» мәдрәсәсендә (Уфа) белем ала. Казан Татар укытучылар мәктәбен (1915), Башкорт пед. ин-тын (1930 еллар) тәмамлый. Кыргызларда укытучылык итә. 1917 елдан соң Башкортстанда укыта (Бәләбәй татар-башкорт пед. техникумында һ.б.). «Шура», «Аң», «Ак юл», «Белем», «Культура революциясе» журналларында, «Вакыт», «Башкортстан», «Яңа авыл» газеталарында языша. «Алатау буйларында» (1913), «Вакытлы никах» (1913), «Артык кеше» (1914) һ.б. очерк һәм хикәяләр җыентыклары авторы. Татар теленә И.С.Тургенев, А.И.Куприн әсәрләрен тәрҗемә итә. Урта мәктәп өчен рус теле дәреслеге авторы.

**РӘФЫЙКОВ** Басыйр Шаһинур улы (10.2.1921, Мамадыш кантоны Мамадыш шәһ. туа), шагыйрь. Магнитогорск пед. ин-тын тәмамлый (1947). 1948-59 елларда Чиләбе өлкәсе Троицк татар-башкорт пед. уч-щесында тарих фәне укыта, соңрак директор урынбасары була. 1960-76 да шул ук шәһәрнең урта мәктәпләрендә завуч, соңрак директор. «Җырым сиңа минем» (1968), «Кадерле минутлар» (1971), «Туган тупсалар» (1981), «Кара каен = Чёрная берёза» (рус һәм татар телләрендә, Чиләбе, 1986), «Вакыт җиле» (1991), «Степь» (русчага тәрҗемә, Троицк, 1995). Иҗатында мәхәббәт лирикасына өстенлек бирә, фольклор мотивларын үзенчәлекле куллана. Халык арасыннан фольклор ядкарьләрен җыю белән шөгыльләнә. Аның тарафыннан язып алынган утызлап мәзәк «Мең дә бер мәзәк» (төзүчесе Г.Бәширов, 1963) җыентыгына кертелгән. Р.ның кайбер шигырьләре комп. Р.Бакиров тарафыннан көйгә салынган. Медальләр белән бүләкләнгән.

Әсәр.: Избранная лирика. Троицк-Челябинск. 2001.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

## «Казан утлары» архивыннан



*Күренекле әдәбият галиме, язучы-прозаик, җәмәгать эшлеклесе Гомәр Гали (1925-27 елларда «Безнең юл» журналының баш мөхәррире) яшәгән йортка мемориаль такта кую көнендә төшерелгән рәсем. 2006 ел. Казан.*



*Язучылар Гомәр Бәширов (1901-1999) һәм Ринат Мөхәммәдиев (1948).*



*Язучы Гариф Галиев (1903-1985).*



*Язучылар Мәскәүдә. Сулдан уңга: Шәүкәт Галиев, Илдар Юзеев, Әдип Маликов, Әхсән Баян. 1980 ел.*



*Равил Рахмани (1949) әдәбият галиме һәм шагыйрь.*



*Татарстаннан килгән бер төркем галимнәр Йосыф Акчура кабере янәшәсендә. Истанбул. 2005 ел.*

Нурихан
Фәттах

# ЧЕТЕРЕКЛЕ БУЛДЫ БЕЗНЕҢ ЗАМАН

ИСТӘЛЕКЛӘР

## Сәясәт һәм милли аң

Университетта барлык фәннәр политикалаштырылган булса да, чын политиканың нәрсә икәнлеген студент елларында без рәтләп аңламадык та, ахрысы. Нәрсә язалар, нәрсә сөйлиләр — шуңа ышандык. Һич югы, мин үзем шундый булдым.

Яшь чакта безне иң элек, барыннан да элек тамак кайгысы, өс-баш кайгысы буып торды. Безнең ярты гомер аудиториядә, ярты гомер чиратта үтте. Халык, милләт турында уйланырга вакыт та калмады. Хәер, бик үк алай да түгел. Халык, милләт һәм киләчәк турында без беркайчан да уйланудан туктамадык. Ләкин күбрәк хыяллану белән шөгыльләндек. Анысы да бары юлда йөргәндә генә, аннан соң йокы аралаш төштә күргәндә. Университетта без дөньяда бик күп халыклар булуы, аларның бай, бәхетле дәрәҗәле булуларын белдек.

Безнең дә үз халкыбызны данлы итәсебез килде. Безне иң элек, барыннан да элек әдәбият, культура кызыксындырды. Кешене кеше иткән, халыкны — халык иткән нәрсә — әдәбият. Югары дәрәҗәдәге әдәбият. Барлык халыклар кызыгып, көнләшеп укырдай әдәбият. Еш кына миңа шулай тоелды. Еллар буена мин үземне шундый югары әдәби әсәр иҗат итү өчен әзерләдем. Культураның, әдәбиятның, димәк, халык-милләт тормышының башка яклары, башка юнәлешләре булуы турында без, әйтерсең, күз алдына да китерә алмадык. Кая ул шундый шартларда политика турында уйланулар!

Ләкин безнең заманда да саф шигырь-хикәя турында гына түгел, чын политика, чын тормыш турында да баш ватучылар булды. Көз көне иде, ахрысы. Бөтен ил СССР Верховный советына сайлауларга әзерләнә. Кая карама лозуглар, плакатлар. Сайлау участоклары, сайлау комиссияләре, сайлау өчен әзерләнгән аерым бүлмәләр, кызыл җәелгән өстәлләр, өстәлләрдә беркем укымый торган газета-журналлар.

Ул вакытларда мин сайлауның нәрсә икәнлеген һәм аның ни өчен кирәклеген аңлый алмый аптырап бетә торган идем. Нәрсәне дә булса сайлап алу, сайлап кую өчен сайлана торган нәрсә кимендә ике булырга тиеш. Шуның берсен сайлап аласың, сайлап куясың. Русча «выбор», «выборы» да шуны күздә тота. Ә монда бер «исем» сайлыйсың. Күп вакытта син аны күрмисең, белмисең. Әйтик, иптәш Сталин, Молотов, Ворошилов... Аларны бөтен ил белә, ә монда син ниндидер Фәләнев, Төгәневне сайлыйсың имеш.

Шулай уйланган чаклар еш булды. Бу турыда кычкырып әйтергә, йә булмаса берәрсе белән фикер алышырга башыңа да килми. Аны эчтән генә уйлыйсың да, онытасың. Тарих-филология факультетының рус әдәбияты факультетының рус әдәбияты бүлеге студенты Васильев та, күрәсең, шулайрак фикер йөрткән.

*Дәвамы. Башы алдагы санда*

Белемле кеше буларак бу, күрәсең, Конституция статьяларын да өйрәнгән. Тоткан да бу, сайлау көнне сайлауга барудан баш тарткан.

Мондый хәбәр ишетеп, башта комиссия членнары, аннан комиссия председателе барган Васильев янына. Болай да кузгата алмагач, факультет житәкчеләре барган моның бүлмәсенә. Кем килсә дә, караватында сузылып тик ята ди, җүнсез. Сайлау мәҗбүри түгел, сайламаска минем хакым бар, дип әйтә ди. Шуннан соң иң ахырда, өченчеме-дүртенчеме курс студенты Васильев янына университет ректоры Ситдиков үзе киткән. Без тора торган дүртенче торакның ишек алдында өч-дүрт машина, ниндидер кешеләр телефон баганасыдай басып торалар. Ситдиковны тәрәзәдән мин дә күрдем. Васильев ректор үгетенә дә бирешмәгән, үз сүзендә калган.

Икенче-өченче көннәрне студентлар арасында сүз бары шул турыда гына булды.

Озын чәче күзенә төшеп торган, зур күзлекле, тәбәнәк буйлы Васильевны мин күреп беләм. Көлгәнен, шаярганын хәтерләмим, гел үртәлеп, ачуланып сөйләшүе генә истә калган. Аның шундый кыланышына без шаккаттык. Мин берни аңламадым. Васильев миңа акылдан шашкан кеше булып тоелды. Тапкан — сайлаудан баш тарта имеш! Шуның белән нәрсә исбат итә дә, нәрсәгә ирешә ала соң ул? Ирешкәне шул булды — сайлаулар үтеп, бераз шау-шу басылгач, аны алып киткәннәр дип ишеттек.

Шул ук өченчедәме, дүртенче курстамы Мәҗит Рафиков дигән студент белән бер бүлмәдә тордым. Мәҗит армиядә булган, сугышта катнашкан. Кайсыдыр кулында берме-икеме бармагы юк. Бездән калкурак, гәүдәгә тазарак. Өстендә яхшы яшел гимнастерка, френч, аягында хром итек. Сөйләшкәндә сүзләрне ничектер сәер итеп, тезеп кенә сөйли, бераз гына артистлык галәмәте сизелә. Шунлыктан миңа ул кылана булып тоела. Көлгәндә дә кирәгеннән артык кычкырып көлә сыман. Ләкин мактанчык та түгел, тар күнелле дә түгел, ягымлы, эчкерсез. Рус әдәбияты бүлегендә укый. Үзе татарча шигырьләр яза. Русча язгандырмы, юкмы — хәтердә калмаган. Җыелышларда, түгәрәк утырышларында катнаша, татарча шигырьләрен укый. Шигырьләрен безнең «Әдәби сүз» дип аталган стена газетасында да бастыра.

Мәҗит Рафиков үз яшьләрендәге өлкәнрәкләр белән генә аралаша бугай. Бер бүлмәдә торсак та, аның белән серләшеп, сүз озайтып утырганымны хәтерләмим. Бергә торган еллардан бары бер генә сүзе истә калган. Ничектер бервакытны «Минем беркайчан туйганчы ашаганым булмады», — диде бу. Безнең өчен бу әллә ни яңалык түгел. Без үзебез дә шундый хәлдә.

Бервакыт моның янына шар күзле дип әйтимме, кара чәчле чибәр генә бер татар килеп йөри башлады. Каян, ничек очрашканнардыр, ничек танышканнардыр — әйтә алмыйм. Бер-ике мәртәбә безнең бүлмәдә кунып та калды. Бер-берсенә болар русча шигырьләр укыйлар, бәхәсләшәләр, без белмәгән әллә кемнәрне искә төшерәләр. Милләт турында да сүзләр ишетелгәли. Иң гаҗәбе шул: әлеге ят иптәш Төркияне, төрек әдәбиятын яхшы белә икән. Мәҗит Рафиков рустан, русча тәрҗемәдәге инглиз, французлан мисаллар китерсә, бу төрекчә генә сиптерә.

Соңыннан беленде, бу иптәш Мозафаров дигән кеше икән. Сер итеп әйткән, сугыш елында, имеш, Төркиядә илчелектә эшләгән, шунда төрек телен, төрек әдәбиятын өйрәнгән. Илленче, алтмышынчы елларда шул Мозафаров Матбугат йортында чуалып йөрде. Ниндидер редакциядәме, Главлиттамы эшләде. Миңа да сыланып караганы булды. Сүзлек төзим, принцибы шундыйрак булачак, син ничегрәк уйлыйсың — синең белән бер сөйләшәсе бар әле иркенләп, диештергәләде. Мин беркайчан да аның белән якынаеп китә алмадым. Ниндидер чит һәм салкын бер иптәш иде ул.

Мәҗит Рафиков белән без бер бүлмәдә бер генә ел тордык. Икенче елны күренмәс булды. Бик соңлап мин аның кулга алынганлыгын белдем. Ник алганнар, ни өчен? Беркем берни аңлата алмады. Шул ук елларда университеттан, пединституттан берничә татар студентын кулга алганнар. Без аларын да бик соңлап кына белдек. 1956 елда алар барысы да акланып кире кайттылар, яңадан укуга кабул ителделәр.

Мәжит Рафиков кебек кайберләре танылган каләм осталары булып киттеләр. Теге елларда ни өчен кулга алынулары турында мин таныш-белештән сораштырып карадым. Алар үзләре берни әйтмиләр. Мәжит Рафиковны, имеш, милләтчелектә гаепләгәннәр. Аның милләтчелеге, имеш, шул булган — җәй көне каникулга кайткач, авылда кәләпүш киеп йөргән. Көлкеме? Хәзер, бәлки, чынлап та көлкедер. Ләкин ул елларда көлүче булмагандыр дип уйлыйм[1].

Сугыш елларында Ерак Көнчыгышта хезмәт иткән бер татар дингезчесе шундый хәл сөйләде. Сугышка кадәр ул шигырьләр язган, тел, әдәбият белән кызыксынган. Бу эшен флотта да дәвам иттергән, буш вакытларда шигырь язып, күрәсең, җыелышларда «татар әдәбияты», «татар культурасы», тегесе-монысы турында сүзләр ычкындыргандыр. Моңа шик төшкән. Күзәтә башлаганнар. Бер заман ничектер моны эләктереп тә алганнар. Тентү вакытында моның чемоданында башка китап-дәфтәрләр арасында «төрекчә-русча сүзлек» табылган. Сугышка кадәр Мәскәүдә чыккан ул сүзлекне мин дә беләм. Дәүләт типографиясендә, Главлит рөхсәте белән басылган. Читтән дә кертелмәгән, Советка каршы пропогандасы да юк. Шулай да әлеге дингезчене хәрби трибунал ун елгамы, унбиш елгамы хөкем иткән.

Күптән түгел, моннан ике-өч элек Уфадан бер карт килеп чыкты. Уфа ягыныкы булса да, яшьлеге моның Ленинградта үткән. Шунда ук институт бетереп, ниндидер заводта инженер булып эшләгән, блокада кичергән. Шул сөйләде. Ленинградта хәзер дә илле мең чамасы татар бар икән. Сугышка кадәр татар мәктәпләре, татар клублары булган, татарча концертлар куйганнар. Куркыныч утыз сигездә шундый хәл булган. Бу карт эшләгән заводта бик матур көчле тавышлы бер инженер булган. Бер кичне болар завод клубында татарча концерт куйганнар. Матур тавышлы инженер җырлаган. Татарча җырлаган өчен, матур тавышлы булган өчен халык яраткан аны. Болары имеш-мимеш. Чын «имеш-мимеш», чөнки мин аларны үз колагым белән ишеттем. Исем-фамилияләрне язмыйм, берәр төрле хәреф хатасы китәр дип куркам. Ясалма исем куясым килми. Бу — әдәби әсәр түгел. Бу — истәлек, бары чыны гына.

1952-53 елларда Чистайда газета редакциясендә Габдулла дигән (фамилиясе Сәйфетдинов шикелле) бер кеше белән эшләдем. Ул да минем кебек Казаннан килгән, ул да тәрҗемәче исәпләнелә. «Сталин байрагы»на материаллар русча әзерләнә, без шуны татарчага тәрҗемә итәбез. Габдулла абый миннән өлкәнрәк, үзе генә, гаиләсе юк. Элек Казанда юридик институтта укытучы булган. Кандидатлык диссертациясе язган. Шул диссертациясе белән янган да.

Моны институттан куалар. Ни өчен икәнен әйтмиләр, күрәсең, милләтчелек өчендер. Үзе турында ул беркайчан берни сөйләми иде. Шуннан бик нык истә калган: Габдулла абый татар телен, әдәбиятын теләсә кемнән яхшырак белә, теләсә нинди очракта Тукай сүзләре белән җавап бирә. Тукайны яттан белә иде.

1953 елда без кире Казанга кайттык. Анда-монда Габдулла абыйны очраткан чаклар булды. Алтмышынчы елларда моның фаҗигале үлеме турында ишеттем. Ул Ленин районында тора иде. Шунда ниндидер хулиганнар дүртенчеме, бишенчеме каттан баскыч башыннан күтәреп ыргытканнар моны. Имеш, исерек булган. Исерек булган һәркемне баскыч башыннан ыргытмыйлар, билгеле. Анысын мин бик яхшы беләм — эчсә дә кеше белән талаша торган, бәйләнә торган кеше түгел иде ул. Кемнәр ыргыткан? Ник ыргытканнар? Күрәсең, Ленин районында да, үзе торган йортта да ялгышып Тукай шигырьләре белән җавап бирә торган булгандыр.

## «Әрәм тамак»

Минем «Утлар» дип аталган беренче «олы» хикәям 1948 елда «Безнең хикәяләр» дип аталган җыентыкта басылып чыкты. Шуннан соң мине «башлап язучылар» рәтеннән санап йөри башладылар. Ләкин Тукай клубындагы бер җыелышта Шәйхи Маннур әйткән: «Яшь язучыларны икегә бүлеп карарга кирәк

[1] М.Рафиков, Г.Тавлин, А.Гыйләҗевнең кулга алыну сәбәпләре турында мәгълүматны »Сүнмәс утлар балкышы» дигән китапта Г.Тавлинның «Афәт» дигән романына бирелгән »Аныклагыч мәгълүмат» тан алырга мөмкин. 384 б. Ред.

— берсе «яшь язучылар», берсе «башлап язучылар». Ш.Маннур Н.Фәттахны, имеш, «яшь язучылар» исемлегенә керткән. Язучылар жыелышында синең исемне дә атадылар, дип, бу турыда мина кемдер житкерде. Минем күңел үсеп китте. Димәк, олы абыйлар мине дә күреп алганнар! «Утлар» өйрәнчек хикәя. Ясалма, күңелсез хикәя. Шулай да нидер бар. Нәрсә? «Бүгенге авыл тормышын» дөрес чагылдыру, ахрысы. Буә. Буәдә электр станциясе кору. Карангы авылга электр уты керәчәкме, кергәнме. Ни генә булмасын, киләчәктә тагын да яктырак булачак. Ул вакыттагы әдәбиятның бөтен мотивы шул — хәзер дә начар түгел, шулай да киләчәктә тагын да шәбрәк булачак.

Шуннан соң мин балалар өчен «Тегермәндә» дигән хикәя яздым. Студент елларында, аннан соңгы өч-дүрт ел бер-ике хикәя белән узды, ахрысы. Кешеләр бәйрәм саен, юбилей саен шигырь язып, шигырь бастырдылар, уч тутырып акча алдылар, мин туктаусыз хикәя яздым да хикәя яздым. Язам да, берәрсенә күрсәтеп карыйм. Ошамый — онытып торам да тагын тотынам, тагын язам. Редакцияләргә илтеп карыйм — юк, басмыйлар. Эшләр гел болай барса, яшь язучылар, хәтта башлап язучылар рәтеннән дә төшеп калуың ихтимал.

Мин инде күптән зур әсәр язу турында хыялланам. Мин инде аны яза да башладым. Ул роман булачак. Студентлар турында. «Бүгенге авыл» турында. Аңсын да бик озак яздым. 1953 елда Сталин үлгәч, Чистай өлкәсе бетерелде, без «Сталин байрагы» хезмәткәрләре Казанга кайтып киттек. Казанда без үзебезнең элекке фатирга урнаштык. Чистайга киткәнче мин Татарстан китап нәшриятында редактор булып эшли идем. Яңадан Казанга кайткач элекке эшемә кереп тормадым — язучылык белән генә көн күрергә булдым. Мин язарга тиеш. Бары язарга гына тиеш! Үземнең алга мин шундый максат куйдым. Минем өчен бу күптән билгеле иде инде. Мин чын язучы, исемле данлы язучы булырга тиеш. Минем өчен дөньяда башка эш-шөгыль юк һәм булырга да мөмкин түгел. Монарчы Китап нәшриятында, газета редакциясендә мәҗбүр булган өчен генә селкенеп йөрдем. ВУЗны бетергән кеше кимендә өч ел эшләргә тиеш. Бу — закон. Минем стажым өч ел да юк. Шулай да тәвәккәлләргә булдым. Бөтен дөньяны шаккатырырлык роман язсам, бөтенесе үз урынына утырачак.

Монысы мәсьәләнең бер ягы. Мәсьәләнең икенче ягы да бар: тору урыны, көндәлек тормыш, тегесе-монсы. Чистайга киткәнче дә без Чехов урамындагы сигезенче йортта, Федоровларда фатирда торган идек. Фатир дигәне тугыз-ун квадрат метрлы бер бүлмә. Кухня янында, кухня аша йөрисе. Зур мичнең бер ягы безнең бүлмәгә чыга. Ләкин ул мич шундый итеп салынган — безнең бүлмәне түгел, күршедәге хуҗалар бүлмәсен генә жылыта. Бүрәнә өй. Почмагында тычкы якта бармак сыярлык ярыклар. Кыш көне чыдарлык түгел. Роман язганда мин бердәнбер өстәл янына утырам. Аякта калын табанлы киез итек, өстә кышкы пальто. Өйдә яшь бала. Инәкәй. Хатын эштә. Мин бала да карыйм, язам да. Бала жылаганын, кухнядагы тавышны ишетмәс өчен кайчагында пальтоны башыма каплыйм, колакны томаларга тырышам.

Монарчы язарга иркен вакыт булмады. Нәшриятта эшләгәндә көне буе план эше эшлисең, Чистайда шулай ук үзеңә буш вакыт калмый. Бары ял көннәрендә генә әз-мәз сызгалыйсың. Хәзер мин тулысынча иҗат белән генә шөгыльләнә алам. Юк, бик үк тулысынча булмады ул. Мин үземне тулысынча иреккә чыккан кебек хис иттем, ләкин ул ирек чынлыкта тәмугка әйләнде. Хатын минем язучы булырга омтылышымны яклады. Элегрәк ул бөтенләй икенче иде. Бит без икебез дә әдәбиятчылар. Университета без бергә укыдык, татар әдәбияты бүлегендә. Укуны дә бергә тәмамладык. Ул минем хикәяләр язуымны, язучы булырга хыяллануымны белә. Бу эшне хуплый. Чистайдан кайткач, ул яшьләр газетасына эшкә керде. Кыскасы, икебез дә язу-сызу белән шөгыльләнүчеләр.

Казанга кайткач, редакцияләрдә эшләп йөри башлагач хатын алыштырып куйгандай үзгәрде. Көн дә бу минем өчен күңелсез хәбәрләр алып кайта. Синең турында фәлән иптәш шулай дип әйтте, төгән иптәш шулай дип әйтте. Эшкә керергә кирәк, синнән бернинди язучы чыкмаячак. Кеше кебек ай саен акча

алып кайтмагач, ничек карарга уйлыйсың семьянны? Акча кирәк, акча! Әйе, акча кирәк. Көн дә акча кирәк, әледән-әле кирәк. Фатир өчен аена ике йөз сум, кышка утын алырга кимендә мең сум. Балага чүпрәк-чапрак, фәлән-төгән алырга, кием-салым яңартырга, тегесенә-монысына...

Бөтен дөньясына төкереп, башны кышкы пальто белән каплап роман язарга утырганда, минем алай бөтенләй акча юк түгел иде. 1954 елда минем тәрҗемәдә В.Г.Гюгоның «Хокуксызлар» романы чыкты. Аның өчен заманына күрә күп кенә акча бирделәр. Ләкин көн дә тукый торгач мин үземне чит кеше, кирәксез кеше итеп тоя башладым. Хатын эшли, ул мине карый, имеш, ә мин — әрәм тамак. Ул елларда әрәм тамаклыкка каршы көрәш бара. Газеталарда берсеннән-берсе усалрак мәкаләләр басыла. Чыннан да әрәм тамаклар булгандыр. Ләкин мин бит тик утырмыйм, урамда селкенеп тә йөрмим. Мин эшлим. Иң җаваплы, иң авыр хезмәт белән мәшгульмен. Бу үзеннән-үзе аңлашыла кебек. Ләкин хатын анларга теләми.

Ул елларда, күрәсең, мине беркем аңламагандыр. Мине хәтта Язучылар союзында да якламадылар. Кайчан икәнен төгәл хәтерләмим — шул беренче романны язганда микән, соңыннанрак микән — Афзал Шамов язучылар җыелышында мине чыннан да «әрәм тамак» дип атаган. Шул сүзне ишеткәч, йөрәккә пычак белән кадагандай булды. Язучы кеше сине шулай дип атагач, башкаларга үпкәләргә урын да юк.

Ул елларда минем хәл шулайрак булды. Бар ышаныч язылачак романда. Ул миңа дигән булачак. Ул әле шаулатачак бөтен дөньяны! Ул чагында инде беркемнең дә яла ягарга батырлыгы җитмәячәк.

Роман язылды. Машинкада бастым да көннәрдән бер көнне киттем журнал редакциясенә. Кульязманы Габдрахман Әпсәләмов укыды. Редакциядә секретарь булып эшли иде бугай. Проза секциясе утырышында, ахрысы, беренче хәбәрне Әпсәләмов әйтте: Нурихан Фәттахның яңа романын укып чыктым, — диде, яшьләрнең әле мондый әсәр язганнары юк иде, — диде. Мактады, чын күңелдән мактады. Мин канатланып киттем. Ул көннәрдә мин шатлыгымнан кая басканымны белмичә йөрдем.

Шулай да иртәрәк сөенгәнмен икән. Күрелмәгән куаныч белән бергә көтелмәгән кайгы-хәсрәтләр дә килде. Минем тормыш гомумән көтелмәгән шатлык-куанычлардан, кайгы-хәсрәтләрдән, мавыктыргыч роман сюжетындагы кебек катлаулы конфликтлардан тора. Еш кына миңа шундый уй килә: минем һәр көнем — үзе бер роман. Мөмкинлегем булса, үз тормышымның һәр көне турында берәр әсәр яза алган булыр идем кебек. Бер өй эчендә яшәүче өч-дүрт кеше арасында да һәрвакыт каршылык чыга тора. Дөньяда һәркемнең үз юлы, үз максаты бар, һәркемнең үз аны, үз холкы-фигыле бар. Еш кына без моңа шуны исәпләп житкермибез. Өйдә, эштә туктаусыз каршылык һәм көрәш бара. Хатын белән ике арада салкынлык көчәйгәннән-көчәя, хәтта дошманлыкка күчә бара. Якынаерга, дуслашырга бернинди әмәл юк. Ир белән хатын арасында гына түгел, килен белән каенана арасында да дошманлык. Күптән инде хатын безнең белән сөйләшми. Эштән соң кайта, өйдә хәтта ашап та тормый. Безне бары бала гына, аннан соң уртак бүлмә генә берләштереп тора кебек. Әнисе эшкә киткәч, бала безнең карамакта. Ашатабыз, эчертәбез, астын алыштырабыз. Күтәреп йөрергә алып чыгам. Бервакыт ике куллап күтәреп барганда ул күктә каргалар очып барганын күрде. Шаккатты. Гаҗәпләнү күзенә-йөзенә чыкты. Кызымны, Наиләмне биик-бик яраттым. Дөньяда ул минем бердәнбер якын кеше иде, ахрысы. 1955 елның маенда хатын баланы үзләренең туган якларына, әнисе янына алып кайтып китте. Без ятим калдык. Күпмедер вакыттан соң хатын кайтты, кызны калдырып кайткан. Ул вакытта минем канатланып йөргән чак. Романны укыган һәркем мактый. Проза секциясендә тикшерделәр, журналда басарга кирәк диделәр.

Бер көнне шулай бик соңга калып кайтып керсәм, хатын күченеп чыгып киткән.

Шулай итеп, роман шатлыгы чәлперәмә килде. Бөтен дөнья баш-аяк

килде. Көн төнгә әйләнде. Без инәкәй белән тордык та калдык Федорованың кухня төбендәге бүлмәчегендә, ярык тагарак янында дип әйтер идем, бик үк дөрес булмас. Мин болай ук булыр дип уйламаган идем. Мин аны яраттым, чын күңелдән яраттым. Кызым тугач сөенеп бетә алмадым. Ике арадагы салкынлыкны, каршылыкны да әкренләп бетәр дип исәпләдем. Ни генә булмасын, мин аңа аерылышыр өчен өйләнмәдем.

Тиешле шартлар булса, без, күрәсең, беркайчан аерылышмас та идек. (Нәкъ шушы сүзләрне Нурихан үлгәч соңгы тапкыр күрергә, хушлашырга дип килгән Роза ханым Хафизова да әйтте. — Р.Ф.) Анысы шулай. Ул вакытта яшь гаиләләргә мөстәкыйль тормыш алып барырга иң гади, иң элементар шартлар җитмәде. Иң кирәге — аерым торак, аерым бүлмә. Яшьләр картлардан — каенана, каенаталардан аерым торырга тиеш. Монысы да бик зур нәрсә. Бездә аларның берсе дә булмады. Яшь киленгә каенана гына түгел, квартир хуҗасы да өйрәтергә, акыл сатарга җай чыкканын көтеп кенә тора.

Боларны мин хәзер бик яхшы аңлыйм. Кайчандыр үлеп яраткан, соңыннан иң явыз дошманым булып тоелган хатынымны хәзер гаепләргә җыенмыйм (гаепләмим дә). Без бары аяусыз тормыш, аяусыз шартлар кулында бер уенчык кына булганбыз.

...Минем шәп роман язуым турында әдәбият халкы белеп алды. Очраган бер кеше берәр төрле мактау сүзе әйтеп китә, сораштыра. Кайбер язучылар кулны кыса. Шундыйрак вакытта ничектер хатынның да йөзе чалынып калды. Көлеп, ягымлы итеп сөйләшергә чамалап карады.

Сизеп торам — татулашырга чамалый. Ләкин ул вакытта аның белән татулашыр хәлдә түгел идем. Безне әле яшьләр газетасы редакциясенә чакырып, өлкәнрәк кешеләр тагын татулаштырырга тырышып карадылар шикелле. Ләкин анда да берни барып чыкмады.

## «Даһи» Брежнев

Нурихан Фәттахның «Сезненчә ничек?» романын проза секциясендә дә, Язучылар союзында да мактадылар мактавын. Ләкин «Совет әдәбияты» журналының редакторы Гази Кашшаф романны бастырудан баш тартты. Редактор әсәрнең теленә бәйләнде. Телдә чыннан да халыкчан сүзләр күп кенә. Мина шундый сүзләрне үзгәртергә, әдәбиләштерергә куштылар. Мин карыштым. Һәр язучының телендә үзенчәлекле сүзләр, сүзтезмәләр булырга мөмкин. Мондый нәрсә әдәбиятта рөхсәт ителә. Бу билгеле нәрсә. Ләкин минем нәкъ шундый үзенчәлекле сүзләргә каныктылар. Бу, билгеле, бер сылтау гына булган. Әсәрнең әдәби эшләнелеше ярыйсы, идеясе бар. Заманча. Нәрсәсенә бәйләнәсең? Бәйләнгәндә дә бит ышандыргыч булырга тиеш.

Монда минем Гази Кашшаф турында бер-ике сүз әйтеп китәсем килә. Зур гәүдәле, аксак. Кул таягы белән йөри. Күзлекле. Сугышта булмаган. Университетта соңгы курсларда безне татар совет әдәбиятыннан укытты. Кандидатлык яклаган, доцент иде.

Бик озак Язучылар союзы тирәсендә йөрде. Сугыш башланыр алдыннан Кашшафны Язучылар союзы председателе итеп сайлаганнар. Ләкин тора-бара нишләптер председатель булып Әхмәт Ерикәй калган, Гази Кашшаф редактор булган. «Үзара берәр ничек килештеләр микән», — диде ул чакта Шәйхи абый.

Гази Кашшафны мин беркайчан ярата алмадым. Әкрен генә, эретеп кенә сөйли, дәртсез, күңелсез. Ул бит утыз җиденче, утыз сигезенче елларда исән калган кеше. Күрәсең, кырык мәртәбә үлеп, кырык мәртәбә терелгән, соңгы чиккә җитеп куркытылган, кинәшмичә, аларның рөхсәтен алмыйча үзлегеннән берни эшләми. Бәлки алай ук та булмагандыр. Хәтердә шулай калган.

1955 елда Язучылар союзының председателе Гомәр Бәширов иде. Журнал редакторы белән минем арадагы каршылык берничек тә хәл ителмәгәч, Гомәр абый Гази Кашшафны романны шул килеш бастырырга күндергән.

Җаваплылыкны тулысынча үз өстенә алгандыр, яисә югарыдагы иптәшләр белән килештергәндер инде. Бу турыда да «сер итеп» кенә Шәйхи Маннур әйтте: «Сибгат әйтте, идарәдә без аны якладык, диде».

Роман 1956 елда журналда басылып чыкты. Журналдан соң гадәттә китап булып чыга. Нәшрият планына кертелгән. Кульязма тапшырылган. Уңай рецензия килде. Ләкин монда тагын каршылык килеп чыкты. Монда да татар теленең сафлыгы өчен көрәшүчеләр табылды. Бу юлы инде андый-мондый гына редактор түгел, нәшрият директоры үзе каршы килә! Аяк чалу дәвам итә. Нәшриятта матур әдәбият бүлеге мөдире ул вакытта Мөхәммәт Садри иде, ахрысы[2]. Фронтта булган. Әллә капитан, әллә майор. Өстендә әле дә хәрби кием. Шуннан соң бу тотты да, бөтенесен үз җаваплылыгына алып тиешле кәгазьләргә кул куйды, кульязманы типографиягә төшереп тә җибәрде. Ул вакытта директор, бәлки, өйдә булмагандыр. Аннан соң Мөхәммәт Садри ышанычлы кеше, фронтовик. Аларның сүзе үтә.

Китап басылып чыкты. Укучы нindидер яңалык күрде. Яшьләрдән, картлардан бер-бер артлы хатлар килә башлады. Укучы конференцияләре уздырылды. Хәтта рецензия дә басылып чыкты. Рецензияне тәнкыйтьче яисә язучы түгел — Зеленодольскидан Икрам Фәйзуллин дигән бер һәвәскәр иптәш язды. Илле яшькә кадәр минем китапларга язылган бердәнбер рецензия булды бу.

Мине хәзер яшь язучылар, өметле язучылар рәтеннән санап йөртә башладылар.

Ләкин күпмедер вакыттан соң ишетелә — ВЛКСМның өлкә комитеты секретаре нindидер җыелыштамы, съездамы — мине пыр туздырып тәнкыйть итеп чыккан. Совет яшьләре тормышын бозып күрсәткән, фәлән-төгән. Иң кызыгы шул, тәнкыйтьләүче секретарь — рус кешесе. Роман әле русча басылмаган. Секретарь, билгеле, татарча укый белми. Бу турыда газетада да язылды бугай. Минем ачу килде. Үзе укымаган килеш ничек итеп тәнкыйтьләп була икән соң ул? Секретарь исеменә ачулы хат яздым.

Икенче зур әсәрем «Бала күңеле далада» белән дә төрле хәл булды. Роман Казакъстанда чирәм җирләрне үзләштерүгә багышланган. Илленче елларда Казакъстанда, Себер якларында дала җирләрендә яңа совхозлар төзеделәр, меңәр еллар буена буш яткан җирләргә иген чәчеп, азык проблемасын хәл итмәкче булдылар. Яңа совхозларга төрле төбәкләрдән яшьләрне җибәрделәр. Бу ыгы-зыгы азык проблемасын хәл итү белән бергә, буш җирләрне колонизацияләүне дә күз алдында тотты. Колонизацияләү турында бер сүз дә булмады, әмма ләкин патриотизм турында сүз күп сөйләнде. Чирәм җирләрне үзләштерү әдәбиятта иң дәрәҗәле темага әверелде. Безнең кайбер язучылар, журналистлар Татарстаннан киткән якташлар янында булып кайттылар, шигырьләр, очерк-мәкаләләр язып чыктылар. Мин роман язарга исәпләдем. Илле алтынчы-илле җиденче елларда Казакъстанның Павлодар өлкәсенә барып, берничә ай «Казанский» дигән совхозда эшләп кайттым. Барысын да үзем күрдем, үзем татыдым. Казанга кайткач, повесть сыман бер нәрсә язып ташладым. Ләкин укып караган кешеләргә ошамады бу. Бер-ике елдан соң янадан шул ук темага тотындым. Уйлап, җентекләп. Ягъни ашыкмыйча. Тагын бер мәртәбә Казакъстанга барып кайтырга дигән уй да килде. Чирәм җирләрне эшкәртүче яшьләр турында яңа әсәр язам, материал туплау өчен Казакъстанга барырга дип, Язучылар союзы идарәсенә гариза язып бирдем. Ул вакытта Союз яшьләргә шулай ярдәм итқәли иде. Гаризада мин мең сум акча сорадым. Мең сум ул хәзергечә йөз сум була. Әлләни күп түгел, шулай да безнең эше ярлы-ябагайга ярап торыр иде.

Ул чакта идарә председателе Афзал Шамов. Шактый тупас һәм коры кеше. Формалист. Гәзитчә әйтсәк, партия кушканча гына сөйләшә. Яшьләрне яратмый. Мине бигрәк тә. Тумышы мулла малае, ахрысы. Кайчандыр бик күптән туган авылыннан чыгып киткән икән дә, утыз ел инде кайтканы юк дип сөйләгәннәре истә калган. Үзенең мулла затыннан булган ата-анасы белән араны тулысынча өзүен күрсәтү өчендер инде.

[2] 1954-57 елларда бу бүлекнең мөдире Мәхмүт Хөсәен булган. Ред.

Гариза биргәч, Афзал Шамов әйтте: яза башлаган романынның кульязмасын китер, диде. Мин аптырап калдым. Бик яхшы беләм — мондый чакта беркемнән кульязма сорамыйлар. Нишләп болар миннән генә кульязма сорыйлар соң? Шулай да кульязмамны алып килдем, күрсәттем. Монысы, ахрысы, идарә утырышы вакытында булды. Афзал Шамов кульязмамны актарып карады, минем язганнарга күз төшереп алды. Сөйләгәндә шундыйрак фикер әйтте: кульязманы укып чыгып тикшерергә, мен сум акчаны шуннан соң гына бирергә, диде. Ни өчен тикшерергә? Мин анда Советка каршы берәр төрле пропаганда ясап ятмыйм микән — шуның өченме? Ул, ахрысы, шундыйрак фикерен сиздерде.

Бик нык хәтер калды. Димәк, миңа ышанмыйлар. Чын күңелдән йөрүгә, минем патриотлыкка ышанмыйлар. Чирәм җирләр турында язу үзе үк патриотизм түгелмени?! Бит татар язучыларыннан беркем ул темага роман язарга атлыгып тормый!

Афзал Шамовның сүзе бетәр-бетмәс сикереп тордым да, йөзенә бәреп әйттем: «Кашыгы белән бирә, сабы белән төртә. Кирәкми миңа сезнең мең тәңкә акчагыз!» — дидем дә, ишекне бәреп чыгып киттем идарә утырышыннан.

1962 елда роман язылып бетте. Чирәм җирләр турында татар әдәбиятында беренче роман. Укыган кешеләр кире какмадылар. Җиңел укыла, диделәр, тормышны дөрес чагылдыра, диделәр. Журналда да укыдылар, басарга кирәк, диделәр. Монда инде гадәттәгечә вак-төяк бәйләнү, аяк чалу, этләшү башланды. Редактор Газиз Мөхәммәтшин сызгалап чыкты да, яртылаш кыскартырга кушты. Гадәттә журналда романнарны шулай кыскартылган килеш басалар. Китапта тулы килеш чыкты. Татарстан китап нәшриятында беркем бәйләнмәде, яратып укыдылар, котладылар. Коридорда икәүдән-икәү генә очрашканда дуслар кулны кыстылар, мактау сүзләре әйттеләр. Җыелышларда «һ.б.» рәтеннән әйтеп киттеләр. Заманында күтәреп алынырга тиешле роман тавыш-тынсыз онытылып калды.

«Бала күңеле далада»ны җитмеш җиденче, җитмеш сигезенче елларда искә төшерделәр. Кинәт кенә мактый башладылар. Чирәм җирләр турында татарда бердәнбер роман, авторы — патриот, үзе яшьләр белән бергә эшләде, фәлән-фәсмәтән. Ни булды дисезме? Ул елларда чирәм җирләрне үзләштерүнең юбилей көннәре икән. Бөек революционер даһи Брежнев тырышлыгы белән без фәлән мең гектар җирләрне үзләштергәнбез, илебезгә фәлән мең тонна өстәмә ашлык биргәнбез...

1978 елның көзендә «Социалистик Татарстан»нан миңа чирәм җирләрне үзләштерүгә туры китереп мәкалә язарга тәкъдим иттеләр. Бик теләп риза булдым. Яздым. Артык зур булмаган мәкаләне, ахрысы, беренче биттә бастырып чыгардылар. Барысы да мин язганча, тик редакция кечкенә төзәтмә керткән: минем мәкаләдә булмаган «даһи», «бөек» «Брежнев» кебек сүзләр өстәгән. Шуның өчен кычкырышып йөрмәдем. Бары бераз эч тырналып куйды. Шул ук елның октябрендә миңа илле яшь тулды. Илле яшь тулган көндә язучыларга берәр төрле бүләк бирәләр, исем бирәләр. Миңа да бирделәр. Указ, карар гадәттә юбилей көннәрендә басыла. Минем турыдагысы 1979 елның февралендә басылды. Университетта бергә укыган Фәния Гайнанова нәшрият коридорында шул көннәрдә көлеп кенә әйтеп куйды: «Брежневны мактап мәкалә язмаган булсаң, сиңа «РСФСРның атказанган культура хезмәткәре» дигән исемне бирмәсләр иде», — диде. Ни әйтәсең — дөрес сүзгә җавап юк.

## Баш калкыту җилләре

Партиянең XX съездыннан соң илдә кайбер үзгәрешләр булды. Элек нахакка кыерсытылган, сөргенгә сөрелгән күп кенә кешеләр акланды. Галимҗан Ибраһимов, Кәрим Тинчурин, Шамил Усмановлар янадан халыкка кайтарылды. Хәсән Туфан, тагын берничә кеше сөргеннән кайтты. Элек тыелган кайбер башка исемнәр кабатлана башлады. Милли мөнәсәбәтләр турында бөтен илдә

фикер алышу сыман нәрсә булып алды. Газеталарда заманына күрә кыю гына фикерләр дә әйтелде. Бездә дә кайбер җанлану башланды. Ләкин шуннан ары узмады. Башланды да ташланды. Әкренләп бөтен нәрсә элекке хәленә кайтты.

Бөтен илдә барган җанлану, баш калкыту җилләре белән рухланып сугыш елларындагы авыл тормышы турында озын гына бер хикәя яздым. Хикәя башта «Кырык дүртнең май аенда» дип аталды. Хикәядә үзем күргән, үзем татыган тормышны мөмкин кадәр, батырлыгым җиткән кадәр дөрес итеп, кискен итеп күрсәтергә тырыштым. Ләкин ул шундый усал һәм дөрес булып чыкты ки, мина иң теләктәш кешеләр дә каушап калгандай булдылар. Хикәянең баштагы вариантында туган авылына торф эшеннән качып кайткан яшь хатын, дөньяда яшәү өчен бернинди мөмкинлек юклыгын күреп, имчәк баласын юл буена ташлап калдыра, үзе акылдан яза. Укыган абзыйлар хикәянең азагын яхшылык, яктылык белән тәмамларга киңәш иттеләр. Исеме дә үзгәрде. Заманча, стройга протест булып аңлашылмасын өчен, хикәя «Артта калган юллар» дип аталды. Шул исемдә ул 1965 елда «Казан утлары»нда басылып чыкты. Икенче вариантта яшь ана баласын ташлый ташлавын, шулай да аңа юлда бер атлы кеше очрый. Ул кеше сугыштан яраланып кайткан райком секретаре икән. Хәмдиягә ул туры юл күрсәтә. Шулай итеп, «юлдан язган» ананы да, баланы да партия коткарып кала.

Хәзер инде хикәянең идеясе тәртәгә керде. Менә дигән социалистик реализм. Күрәсең, бәйләнмәсләр. Нинди кыю хикәя язган дип мактарлар да әле. Әйе, мактадылар. Гадәттәгечә, коридорда, чит кеше күрмәгәндә дуслар мактау сүзләре әйттеләр, кыю, диделәр, шәп, диделәр.

Күп тә үтмәде, тәнкыйть башланды. Һәртөрле җыелышларда, гәзит-журналларда Н.Фәттахны, «Артта калган юллар»ны сүктеләр. Кем ничек булдыра ала, шулай сүкте. Гариф Ахуновның Әлмәттән Казанга кайтып, Язучылар союзы секретаре булып эшли башлаган елы иде, ахрысы. Яңа эшен Ахунов Нурихан Фәттахны сүгеп мәкалә бастырудан башлап җибәрде. Ул елларда мин редакция, нәшрият тирәсендә бик үк күренмәскә тырыштым. Шулай да бер барып чыккач, баскычта сабакташым Рафак Тимергалинны очраттым. Студент чагында Рафак шигырьләр язды, укуын бетергәч тә гәзит редакцияләрендә эшли башлады. Бик озак «Социалистик Татарстан»ның редактор урынбасары булды. Әле дә шунда. Очрашкач, үзе коридорда миннән алда бара, үзе кычкырып-кычкырып мине сүгә. Син бөтен илне төрмә итеп күрсәтәсең, фәлән-төгән. Малай-шалай урынына сүгә. Юкса икебез дә бер яшьтә. Хәзер инде мактанырга була — мине хәтта партия өлкә комитетының беренче секретаре Игнатьев та сүгеп чыкты. «Сүгү» димен, чөнки «тәнкыйть» алай булмый. Тәнкыйть ул әдәби әсәрнең кимчелеген күрсәтә. Болар миңа политик гаеп ташлыйлар. Мине нindидер «кара көчләрнең» Советка каршы яшерен көчләрнең бер вәкиле, иң төзәлмәс, иң кире бер вәкиле итеп күрсәтергә тырышалар. Русча «козел отпущения» дигән сүз бар. Татарда мондый сүз юк, чөнки «козел отпущения» ул христиан диненә хас йоланы чагылдыра. Башкаларның гөнаһы өчен кәҗә тәкәсен корбан итеп чалуны аңлата.

Ул елларда мин менә шул корбан итеп чалынган кәҗә тәкәсенә әвереледем. Ничәнчедер елны идарә председателе Мирсәй Әмир «Казан утлары»ның баш мәкаләсендә, исемне әйтмичә генә, татар әдәбиятында кайберәүләр «империализм тегәрмәненә су коялар», дип язып чыкты. «Кәҗә тәкәсе» булып йөргән елларда, хатынның, Руфинаның сөйләүләренә нигезләнеп «Мөдир Сажидә» дигән повесть язып ташладым. Повесть журналда да басылды. 1968 елда китап булып та чыкты. Бернинди тәнкыйть юк. Үзенә күрә мәхәббәте дә бар, авыл тормышы да бар. Җиңел укыла. Мактарлык булмаса да, сүгәрлек түгел. Шулай да нindидер бер зур җыелышта партия өлкә комитетының беренче секретаре Ф.Табиев Н.Фәттахны янә сүгеп чыга. Шул чакны Фатих Хөсни түзми, бөтенесе алдында мине якларга тотына. Н.Фәттах эшли, менә әле генә «Мөдир Сажидә» дигән яхшы әсәр язды, әдәбиятка файда китерә, кебегрәк

сүзләр әйтә. Жыелышта катнашкан кешеләр мина шулай дип сөйләделәр. Табиев тупас рәвештә Фатих Хөснинен үзенең «башына суккан».

Безнең житәкчеләр менә шулай тәрбияләделәр безне. Хәзер язуы жинел. Ләкин ул елларда жинел булды дип әйтсәм — телем корыр.

Бернинди гаеп эш эшләмәсәм дә, мин үземне гаепле итеп, чит-ят итеп сизә башладым. Кешеләр белән очрашмаска тырышам. Жыелышларга бармыйм. Дөньядан, гайбәттән, куркыту, кысу-изүгә нигезләнгән политикадан аерылырга тырышам. Кыен. Бик кыен. Акча юк, шунын аркасында өйдә тынычлык юк. Шулай булса да язарга кирәк. Язарга. Бары язу гына күнелгә әзме-күпме тынычлык бирә, киләчәккә өмет-ышаныч уята ала.

Ләкин мина алай эшләү дә рөхсәт ителми. Әледән-әле төрле шымчылар, озын колаклар, сатлыклар эзләп таба, өйгә килеп керәләр. Дөньядан, политикадан да аерылып булмый — радио бар. Газета-журналлар бар, чыбыксыз телефон бар. Бервакыт хәбәр ишетелде. Язучыларнын Тукай клубында Черек күлнең бер дәрәжәле кешесе язучылар алдында лекция сөйләгән. Хрущев, Брежнев елларында алар шулай халык алдына чыккалыйлар, язучыларны куркытып, политик яктан «дагалап» китәләр иде. Ә бер кыска буйлы, кара чәчле башкорт иртәдән башлап кичкә кадәр Язучылар союзы урнашкан коридорда селкенеп йөрде, кешеләр белән очрашты, дус булып бүлмәләргә кергәләп утырды. Кем кем белән очраша, кем кем белән дус, кем кем белән сөйләшә — күрәсең, барысын да өйрәнә.

Шулай бер көнне Тукай клубында Черек күл полковнигы: «Кайберәүләр хатынына да әйтмичә роман язып яталар», дигән. Жыелыштагыларнын барысы да минем турыда сүз барганын бик яхшы аңлаганнар. Шулай да полковник исемне әйтергә кыймаган, ләкин политик мәсьәләне үткәзеп әйткән: язучылар арасында кемнәрдер яшерен эш белән шөгыльләнәләр! Нинди рәк яшерен эш? Әйтеп булмый. Факт юк. Куркытылган, өенә, язу өстәле янына куалап кертелгән Нурихан иптәшнен яшерен эш алып бару кайгысы була да алмый. Ул шундый шартларга куелган — хәзер анын тормышы чәнечкеле читлеккә ябылган кебек.

Каян белгәннәр диген минем хатынга да әйтмичә нидер язып ятуымны! Үземнең алай сөйләнгәнем юк. Хатын Черек күлгә барып зарланып йөрмәгәндер дип уйлыйм. Аңа да әйтмәгәч, ул каян белсен минем ни язганны.

Дөрес, ул вакытта «Ител суы ака торур»ны яза башлаган идем. Бәлки, шул турыда ычкындырганмындыр берәрсенә. Тарих турында, татар тарихы турында роман язу — ул чыннан да жинаять эш. Дәүләт иминлегенә куркыныч тудыра торган эш.

Мин гомумән алдан кытакларга яратмыйм. Әсәр язу ул ир белән хатын мөнәсәбәте кебегрәк. Бик сирәк кешеләр генә үзенең ин серле, ин якын, интим эшләре турында башкаларга сөйләргә яраталар. Өлгермәгән, формалашмаган әсәр турында кычкырып әйтү кыен. «Хәзер нәрсә язасын?» дигән сорауга да мин теләмичә генә жавап бирәм. Төрле яктан шундый сораулар ишетелә башлагач, ул турыда бөтенләй сөйләмәс булдым. Отыры ныграк үз эчемә бикләнә бардым.

*Дәвамы киләсе саннарда*

## Өстәл китабы

Фәнзаман Баттал янына килгәләүче дуслары аның өстәлендә һәрвакыт бер үк китапны күрәләр. Үзе калын, үзе авыр да ул китап замананың бер төрәсе турында икән. Фәнзаман аны еллар буе кульъязмалары өстенә куя.

— Нәрсәгә тотасың бу китапны? Пүчтәк кеше турында бит ул!

— Минем өстәл китабы ул! Файдалы китап!

— Ничек?!!

— Анламасагыз, карап торыгыз, — ди дә Баттал, әлеге китапны кулына алып, балкон ишеген ача. Шулчак бөтен кәгазьләрен үтәли җил туздырып ташлый.

— Анладыгызмы инде? — ди Баттал. — Таш хезмәтен үти ул миндә!

## Озын җәймә

Шагыйрь Рәхбәр, ягъни Роберт Әхмәтҗанов, өстәл алырга акча җитми дип, Фәнзаман Батталдан акча алып тора. Биш-алты көн үтүгә, Фәнзаман җиденче төшен күреп ятканда, нәкъ төнге 12 дә, ишегенең кыңгыравына басалар. Ишекне ачса — Роберт килгән!..

Кесәсеннән йомарланып беткән берлек чыгарып өстәлгә сала да шагыйрь:

— Роберт... — дип куя.

Икенче кәгазь берлекне чыгарып тәгәрәткәч (барысы да йомгактай бөгәрләнеп беткән! ):

— Әхмәтҗановның... — дип өсти.

Өченче берлекне кесәсеннән каезлап алгач:

— Кешегә... — дип дәвам итә.

Соңгы берлекне чыгарганчыга кадәр әйткән сүзләре бер җөмләгә җыела: «Роберт Әхмәтҗановның кешегә бер чакта да бурычлы булып калганы юк».

Акчалар өстәлгә чәчелеп беткәч, йокысы ачылып бетмәгән Фәнзаман:

— Өстәл алдыңмы соң? — дип сорый.

— Бер аягын гына алган идем хәзергә, чыдам булмады. Дуслар белән сындырып ташлаганбыз.

— Юкәдән генә ясаганнардыр, алайса...

— Юк! — ди Рәхбәр. — Пыяладан иде...

## Поплар да татарча сөйләшә...

Концертлар алып баруда каешланып беткән, нәфис сүз остасы буларак бөтен татар дөньясына танылган Рәшит Сабировны Мәскәүгә чакырганнар. Анда татар композиторы Сәйәр Хәбибуллинга 75 яшь тулган икән дә, Рәшит шул унай белән оештырылган бенефис-концертны алып барган. Әлбәттә

инде, юбилярның матур көйләре, җырлары янгыраган, кул чапканнар, Мәскәү татарлары сәхнәгә бер-ике йөк чәчәк ташыганнар, бер-бер артлы менеп, мактау сүзләре сипкәннәр. «Сибүчеләрнең» берсе булып, сәхнәгә ниндидер мулла (Рәшитнең үзенчә әйтсәк, КГБ кителе белән фуражкасын әле кичә генә чалма белән чапанга алыштырган мулла) күтәрелгән дә, мона кадәр татарча гына барган бенефисның тап уртасында урысча сүз куерта башлаган. Бу мулла Рәшиткә татарның тәмле ашына кара таракан ташлаучы булып тоелган. Түзмәгән Рәшит:

— Хәзрәт, татарча сөйләсәгез лә! — дип үтенгән.

Мулла, әфисәрләрчә читеген-читеккә бәреп, үрә каткан да:

– По-татарский не знаю! — дигән.

Шулчак Рәшитнең:

– И, абзый, Казанда поплар булып поплар да татарлар белән татарча сөйләшә инде хәзер!.. — дияе булган, болай да теге муллага күнелләре болганып утырган Мәскәү тамашачылары (күбрәге чая мишәр өммәтеннән бит әле!), тәгәрәп китеп, көлүдән тынсыз катканнар.

Әле хәзер дә, ихлас күнелдән көләселәре килсә, Рәшитнең шул сүзен генә кабатлыйлар икән Мәскәү татарлары.

## Сай хәтер

Аяз Гыйләҗев Фәнзаман Батталга:

— Әгәр берәр вакыт синең янга килеп: «Карале, Фәнзаман Баттал кирәк иде, күрмәденме? » — дип сорасам, аптырап калма, ни өчен дигәндә, күз хәтере бик начар минем, — дип сөйләп бара икән. Шул вакыт боларга каршы килүче берәү Аяз Гыйләҗевне туктаткан, сөйләшеп торганнар. Әлеге кеше китеп баргач, Фәнзаман Баттал:

— Кем булды ул, Аяз абый? — дип сораган.

— Егерме биш еллап элек бер хикәясен укыткан иде бу кеше. Кыяфәте истә калган калуын, ә менә исемен хәтерләмим, — дигән өлкән әдип. — Әйтәм бит, хәтер бик сай минем, парин.

## Сара нигә кызган?

Танышларына мәгълүм: Сара апа Садыйкова сиксәнгә житкәндә дә үзенә өлкән итеп, карт итеп караганны яратмый иде. Аның күнеле соңгы көннәренә кадәр кызларныкы кебек күтәренке иде.

Бервакыт болар Татарстан радиосының режиссеры Госман Әхмәтжанов белән тукталышта очрашалар. Автобус килгәч, керәләр. Сара апа, керүгә үк, бер утыргыч аркасына тотына, ә Госман, билет хәстәрен күрү өчен, шофер тарафына ук тәпили. Шул вакыт автобуста җәнҗал куба — Сара Садыйкова пыр туздырып бер кызны сүгә:

— Нигә алай мыскыл итәсең әле син мине, ә?! Үзеңне миннән яшьрәк дип беләсеңме әллә?!

Килеп житкән Госман Әхмәтжанов хәлне бик тиз аңлап ала. Баксаң, теге кыз: «Утырыгыз, апа, сез өлкән кеше», — дип 75 яшьлек Сара апага урынын тәкъдим иткән булган икән.

## Саталар инде...

— И-и, саталар да инде сине кайбер дусларың, каләмдәшләрең! — диләр икән Фәнзаманга.

— Саталар инде, сатып алып булмагач, — дип авыр сулаган Фәнзаман.

## Санап та торма

Марсель Гали, нәшрият коридорында очрашкач,Фәнзаман Батталга:

– Соңгы вакытта язган әйберләреңне күрмим.Бөтенләй язмый башладың, ахрысы,– дигән.Фәнзаман Батталның йөзенә аптырау галәмәте ингән һәм шушы арада гына чыккан әсәрләрен саный башлаган:

–«Ватаным»да туп-тулы ике бит истәлек басылды, «Мәгърифәт»тә зур хикәям дәвам белән чыга бара, «Шәһри»дә сәяси-публицистик язмам дөнья күрде, «Казан утларын»да унбиш бит сатирик әсәрләремне биргәннәр ... Күпме радиотапшырулар тагын...

Каләмдәшен тыңлап-тыңлап торган да сүзен бирмәс Марсель:

–Санап та торма. Мин бит «СПИД-инфо» гына укыйм. Ә анда барыбер бернәрсәң дә юк, — дип, канәгатьсез генә китеп барган.

## Сүгенмә — сүгендермә

Чыгачак китабының хәлен белү өчен, бер язучы нәшрият мөхәррире Фәнзаман Баттал янына килә:

— Минем кульязманы укырга вакыт таба алмадыгызмы?

— Табуын-таптым, ләкин китап итеп чыгару ярамастыр...

— Ничек инде?! Ник?

— Китап укучылар сүгенергә өйрәнер дип куркам.

— Соң... минем китапта бер генә сүгенү сүзе дә юк лабаса!

— Югын юк, — дигән Баттал, авыр сулап. — Иллә дә мәгәр мондый китапны укып чыккан укучы, икебезнең дә исемне кыстыра-кыстыра, атна буе сүгенеп йөриячәк...

## Сызгыра беләбез, бәгырь!..

Театрга яшь талантлар кабул итү өчен имтихан-конкурс бара. Кабул итүчеләр арасында Салих Сәйдәшев тә бар. Болай да «С» хәрефен бик үк камил итеп әйтә белмәүче бөек композиторның аңкавы шешкән көннәр икән бу... «С»нең «һ»гә күчә язган вакыты...

Сәйдәштән көнләшеп, аңа хөсетлек саклап йөрүче сәнгать әһеле (ул имтихан алучыларның башлыгы икән) композиторның колагына:

— Минем тиз генә чыгып керәсем бар, Салих. Менә бу кызның дикциясен тикшерү өчен, «Сызгыртма син Сәйделсаҗиданең сыбызгысын!» дигән җөмләне әйттер әле, — дип пышылдаган. Шуннан соң, Сәйдәшнең көлкегә калуын ишек артыннан тыңлап-күзәтеп тору өчен, чыгып киткән.

Хикмәтнең нәрсәдә икәнен аңлап алган Сәйдәш, әлеге җөмләне кәгазьгә ачык итеп язган да, кызга тоттырган:

— Шуны яңгыратып, һаваны ярып җибәрердәй итеп әйт әле, матур туташ!

Кыз, мөгаен, үтә сәләтле булгандыр, ул әлеге җөмләне әйткәндә стеналар да, идән-түшәмнәр дә сызгырып торгандай булган.

— Булдырдың, туташ! Миннән — «ббишшле!» — дигән Сәйдәш.

Теге хөсет үзе дә килеп кергән һәм:

— Әйбәт сызгырттың кызны, — дип пышылдаган.

Сәйдәш тә үз сүзен пышылдап әйткән:

— Без булган җирдә бөтен нәрсә дә һызгыра, бәгырь!..

**Фәнзаман БАТТАЛ**

## Мөхәммәт Гайнуллин

Күпгасырлык татар әдәбияты гаять бай булып, халкыбызның яшәү рәвешен, теләк-омтылышын, хыялын чагылдырып килә. Аның үсеш-үзгәрешенә үзләреннән зур өлеш керткән әдипләрнең тормыш һәм иҗат юлын, сәнгати фикерләү үзенчәлекләрен киң катламга житкерү өлкәсендә унышлы эшләгән әдәбият галимнәре шактый күп булып, араларында филология фәннәре докторы, профессор М.Х.Гайнуллин исеме аеруча зур хөрмәткә лаек.

Мөхәммәт Хәйрулла улы Гайнуллин 1903 елның 18 августында (яңа стильдә — 31) хәзерге Татарстан Республикасының Апас районы Кызыл Тау (Коллар) авылында игенче гаиләсендә туып-үсә. Туган авылында жидееллык мәктәпне тәмамлаганнан соң, Төмәндәге укытучылар әзерли торган бер еллык курсларда белем ала. 1920 елдан аның педагоглык хезмәте башланып, берничә ел балалар укыта. Бераздан Казандагы Татар телен гамәлгә кертү курсларында укып чыга һәм Тәтеш төбәгенә жибәрелеп, анда хисапчы-кассир булып эшли, мәдәни чараларда актив катнаша, мәкаләләр бастыра, укый-яза белмәүчеләр өчен оештырылган курсларда белем бирә. 1928 елны М.Гайнуллин Казанга килә һәм Көнчыгыш педагогия институтының татар филологиясе факультетына укырга керә, аны тәмамлаганнан соң, профессор Г.Нигъмәти житәкчелегендә аспирантурада белем ала. Аспирантурада уку белән бергә, ул институтта татар әдәбияты тарихы һәм теориясе буенча лекцияләр укый, актив рәвештә фәнни тикшеренү эшчәнлеге алып бара, мәкаләләр бастырып чыгара. Бөек Ватан сугышы елларында М.Гайнуллин Казан педагогия институтында укыта, Татарстан дәүләт нәшрияты житәкчесе була. 1945 елда ул СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институты директоры итеп билгеләнә. Гаять жаваплы оештыру-административ эшләр башкару белән бергә, М.Гайнуллин татар әдәбияты тарихы буенча системалы тикшеренүләрен алып бара. 1946 елда «XIX гасыр ахыры һәм XX йөз башы татар әдәбияты турында тикшеренүләр» дигән темага кандидатлык, 1958 елда «Беренче рус революциясе чорында татар әдәбияты һәм публицистикасы» дигән темага докторлык диссертациясе яклый.

Галимнең аеруча кызыксынып өйрәнгән өлкәсе булып XIX йөз ахыры — XX йөз башы татар әдәбияты тора. Әле 1939 елларда ук ул Г.Тукай, М.Гафури, Г.Коләхмәтов, Г.Камал, Ш.Камал, С.Рәмиев, Дәрдемәнд, Ф.Әмирхан һ.б. иҗатын үз эченә алган дәреслек-хрестоматия төзү эшенә алына. Китап буларак сонарып мәйданга чыкса да, аерым әдипләр иҗаты буенча алып барган өйрәнүләре җәмәгатьчелектә кызыксыну тудыра. Галимнең «Горький һәм татар әдәбияты» (1944), «Каюм Насыйри» (1945) хезмәтләре рус һәм татар әдәбиятларын чагыштырма планда өйрәнү юнәлешенә зур этәргеч бирә.

М.Гайнуллин әдәбият тарихын истәлекләргә, публицистик язмаларга, тарихи чыганакларга һәм архив материалларына нигезләнеп өйрәнү кирәклеген тирәнтен аңлап эш итә. Ул беренчеләрдән булып К.Насыйри, М.Акъегетзадә, З.Бигиев, З.Һади, С.Рәмиев, Ш.Мөхәммәдев һ.б. турында замандашларының һәм әлеге әдипләр туганнарының, балаларының истәлекләрен, алар турындагы вакытлы матбугат материалларын туплый һәм, бер системага салып, фәнни хезмәтләр яза. Галимнең Ризаэтдин Фәхретдин, Фатыйх Кәрими, Галиәсгар Гафуров-Чыгътай кебек олы шәхесләр турындагы язмалары, озак еллар дәвамында читкә тибәрелгән әдипләрнең исемен, иҗатын аклау һәм яклау булу белән бергә, бүген дә кыйммәтен

җуймаган фәнни материал булып тора. М.Гайнуллин әдәбият тарихы өчен классик дәрәҗәсенә күтәрелгән әдипләр генә түгел, икенче пландагы язучыларның иҗаты да әһәмиятле булуны яхшы аңлый. Шул максатта киң катлау укучыларга исемнәре аз таныш булган Газизә Сәмитова, Маһруй Мозаффария, Галимәтелбәнат Акчурина, Зәйнәп Сәгыйдә һ.б. иҗатын кайтару буенча җитди эш башкара.

М.Гайнуллин татар әдәбиятын халыкның иҗтимагый фикере, мәгърифәтчелек хәрәкәте, милли үзаңы үсеше, Россиядәге революцияләр дулкыны белән тыгыз бәйләнештә тикшерүгә киң урын бирә. Фәнни эзләнүләре нәтиҗәсе буларак дөнья күргән «Татар әдәбияты. XIX йөз» (1957), «Татар әдәбияты. XX йөз» (1968), «Татарская литература и публицистика начала XX века» (1966), «Татар әдипләре» (1978), «Өмет йолдызлары» (1988), шулай ук «Каюм Насыри: очерк жизни и творчества» (1975), «Галиасгар Камал: очерк жизни и творчества» (1978) китаплары татар әдәбияты тарихын киң планда һәм иҗтимагый тормыш белән тирән бәйләнештә өйрәнүдә яңа тикшеренүләргә юл ача. Галим әдәбиятны һәм милли публицистиканы үзара тыгыз бәйләнештә өйрәнә. Анынча, нәкъ менә вакытлы матбугат үсеше XX йөз башында татар әдәбиятын «алтын чор»ына китерә. Язучы, тормышны башкаларга караганда тирәнрәк күрүче буларак, үзенең уй-фикерләре белән матбугатта чыгыш ясый, аннары алар образлы фикерләү формасында әдәби әсәрләр булып оеша. М.Гайнуллинның әдәбиятны иҗтимагый яшәеш белән тыгыз бәйләнештә өйрәнүгә нигезләнгән концепциясе җитди фикер-карашларга, нәтиҗәләргә китерә.

М.Гайнуллин Тел, әдәбият һәм тарих институты директоры булып озак еллар эшләү дәверендә туган телебезне һәм әдәбиятны, татар тарихын өйрәнүне оештыруга зур көч куя. Ул байтак еллар дәвамында мәктәп һәм югары уку йортлары өчен дәреслекләр төзү белән шөгыльләнә, күпсанлы фәнни хезмәтләрнең редакторы була, татар әдәбиятын ил күләмендә танытуга да үзеннән өлеш кертә.

Татарстанның һәм Россиянең атказанган фән эшлеклесе, профессор Мөхәммәт Хәйрулла улы Гайнуллин 1985 елның 24 маенда вафат була.

---

## Хөрмәтле укучыларыбыз һәм авторларыбыз!

**Журналыбыз белән даими танышып баручылар белә булыр: бездә «Казан утлары» архивыннан» дигән рубрика бар. Бу сәхифә байтак еллар гамәлдә булса да, элегрәк елларда материаллар сирәгрәк чыга иде. Соңгы вакытта «архив» активлашты, журналның һәр санында диярлек татар тарихыннан иҗтимагый әһәмияткә ия булган фотосурәтләр басылып килә. Теләгебез—алга таба да рубриканы кызыклырак һәм мәгънәлерәк итү. Бу эшне уңышлы дәвам итү өчен сезнең дә булышлык кирәк. Сезгә мөрәҗәгать-гозеребез шул: үзегезнең шәхси, гаилә альбомнарында яки оешма-учреждение архивларында сакланган кызыклы, тарихи-иҗтимагый кыйммәте булган (әдәбият һәм сәнгатебезнең мәшһүр шәхесләре, истәлекле мәдәни вакыйгаларга караган күренешләр, Казан һәм Татарстан тарихын яктырткан сурәтләр һ.б.) фоторәсемнәрне безгә юлласагыз икән! Шул рәсем турында аңлатма-комментарийларның булуы да шарт, әлбәттә. Без аларны журналда файдаланганнан соң, кире ияләренә кайтара алыр идек.**

**Әйдәгез, кадерле укучылар, мөхтәрәм милләттәшләр, кайдадыр киштә-шкафларда, альбом-папкаларда ябылып яткан истәлекле ядкярләрне яктыга чыгарыйк, халкыбызның рухи елъязмасы сәхифәләре булып киләчәк буыннарга хезмәт итсен алар! Сездән кызыклы фотоматериаллар көтәбез.**

### ИТАР-ТАСС БЕЛӘН КИЛЕШҮ

Хөкүмәт йортында республика белән ИТАР-ТАСС мәгълүмат агентлыгы арасында мәгълүмати хезмәттәшлек турында килешү имзаланды.

Документка ТР Президенты Рөстәм Миннеханов һәм ИТАР-ТАСС генераль директорының беренче урынбасары Михаил Гусман кул куйды. Килешүнең төп бурычы — Татарстанның уңай образын ныгыту буенча уртак бурычларны гамәлгә ашыру, республикабызның үсеш планнарын киң яктырту. Моннан тыш ИТАР-ТАСС Татарстан Республикасының чит ил һәм федераль гаммәви мәгълүмат чаралары белән турыдан-туры элемтәләрен җайга салуга ярдәм итәчәк.

### МИНИСТРНЫҢ ЯҢА ВАЗИФАСЫ

Татарстан Президенты Рөстәм Миннеханов Энгель Фәттаховны Татарстан Премьер-министры урынбасары — мәгариф һәм фән министры вазифаларын башкаручы итеп билгеләү турында Указны имзалады. «Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары — Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры вазифасына кандидатураны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы белән килештергәнче, Фәттахов Энгель Нәвап улын, моңа кадәр биләгән вазифасыннан азат итеп, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары — Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры вазифаларын башкаручы итеп билгеләргә», — диелә документта.

Шул рәвешле, хәзер Татарстан Хөкүмәте җитәкчесе урынбасарлары саны 7гә житте.

### «АК БҮРЕ» ДӨНЬЯ КҮРДЕ

Композитор Зөлфия Рәупова һәм шагыйрь Рүзәл Мөхәммәтшин иҗат иткән «Ак бүре» операсы Универсиада көннәрендә күп меңләгән тамашачылар өчен ачык мәйданда («Универсиада паркы»нда) күрсәтелде. Масштаблы бу тамашада Александр Сладковский җитәкчелегендәге ТР Дәүләт симфоник оркестры, ТР Дәүләт җыр һәм бию ансамбле, ТР Дәүләт камера хоры катнашты. «Ак бүре» образын җырчы Артур Исламов башкарды. Тамашаны ТР Дәүләт җыр һәм бию ансамбле җитәкчесе, Татарстанның халык артисты Айрат Хәмитов сәхнәләштерде.

### ИЛШАТ ӘМИНОВКА — ХАЛЫКАРА ПРЕМИЯ

«Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясенең генераль директоры Илшат Әминов «Медиа-Менеджер России-2013» бәйгесенең медиабизнес өлкәсендәге халыкара премиясенә ия булды. Ул «Электрон ММЧ» номинациясенең «Телевидение» категориясендә «Җәмгыятьнең социаль һәм эш өлкәсенә караган мәнфәгатьләрен берләштерүче милли медиахолдинг тудыру һәм үстерү өчен» бүләкләнде. Бүләкләү тантанасы Мәскәү шәһәрендә узды.

### ГАБДУЛЛА КАРИЕВКӘ БАГЫШЛАНА

2013-14 уку елында татар профессиональ театрына нигез салучы артист, режиссер Габдулла Кариев исемендәге конкурс башланып китә.

Әлеге конкурсны Г.Кариев исемендәге Казан Татар дәүләт яшь тамашачы театры «Журналистика», «Татар филологиясе», «Җәмәгатьчелек белән элемтә» белгечлекләре буенча белем алучы студентлар арасында үткәрә. Бәйгегә 2013 елның 1 июленнән 2014 елның маена кадәр әлеге театр турында татар яисә рус телендә язылган мәкаләләр, интервьюлар, радио аша яңгыраган яки телевидение аша күрсәтелгән тапшыру язмалары, шулай ук Интернет чараларында дөнья күргән төрле жанрлардагы журналистик әсәрләр кабул ителәчәк. Җиңүчеләргә 2014-15 уку елы дәвамында Г.Кариев исемендәге стипендия билгеләнәчәк.

Конкурска заявкалар 2014 елның 30 маена кадәр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: 420032 Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Гладилов урамы, 49 нчы йорт, 34 нче бүлмә.

Интернет адрес: e-mail:tattuz@ pochta.ru.

Белешмәләр өчен телефон: 55-37-27.

Бүләкләү тантанасы 2014 елның сентябрь аенда үткәреләчәк.

## РӘИС ҮЗЕБЕЗДӘН САЙЛАНДЫ

Бакуда Халыкара ТЮРКСОЙ оешмасы ярдәмендә төрки театрлар директорларының Халыкара киңәшмәсе узды. Анда төрки театрлар директорларының Халыкара советы рәисе итеп Г.Камал исемендәге татар дәүләт академия театры директоры Илфир Якупов сайланды. Әлеге советның утырышы 2014 елда «Нәүрүз» форумы кысаларында Казанда узачак.

## МӘСКӘҮГӘ — ӨЧ СӘГАТЬ ЯРЫМДА

Тагын 5 елдан Мәскәүгә тимер юл аша өч сәгать ярымда барып житеп булачак. Казан—Мәскәү арасында 2018 елга югары тизлекле тимер юл магистрале төзергә ниятлиләр. «РЖД» оешмасы исәпләп чыгарганча, магистраль аша Казаннан Мәскәүгә бару 3 мең 778 сум торачак. Беренче елда ук әлеге магистраль аша 7 миллион 46 мең пассажир узуы көтелә.

## СИКСӘН АЛТЫ ЯШЬЛЕК СТУДЕНТ

КФУның Алабугадагы институтында республикадагы иң өлкән — 86 яшьлек студентка диплом тапшырдылар. Ул институтның филология факультетын читтән торып тәмамлаган.

Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, жиде китап авторы Габдулла Галиев, Әгерҗедән килеп, шушы яшендә институтта укып йөрүен татар әдәбиятын тирәнтенрәк өйрәнәсе килүе белән аңлата. Чөнки ул — заманында медицина училищесын тәмамлап, гомере буе авылда фельдшер булып эшләгән шәхес. Афәрин, ветеран!

## КЕРӘШЕН КАРЕНДӘШЛӘР ХӘЗИНӘСЕ

Казан Кремлендә урнашкан «Хәзинә» милли сәнгать галереясендә «Керәшеннәр» дип аталган күргәзмә эшли башлады. Ул керәшеннәр тарихында беренче тапкыр оештырыла. Биредә аларның XIX-XX гасырларга караган гамәли сәнгатен, тарихын, гореф-гадәтләрен чагылдырган уникаль бизәнү әйберләре, эш кораллары, киемнәр, савыт-сабалар һәм башка бик күп кызыклы экспонатлар күрергә мөмкин.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Республиканың төзелеш тармагы үсешенә зур өлеш керткәне һәм намуслы хезмәте өчен «Әлмәт муниципаль районының административ-хуҗалык идарәсе» муниципаль унитар предприятиесе бүлеге башлыгы, язучы **Дәүләтов Зөфәр Мирхәйдәр улы** Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләнде.

***

Мәдәният үсешенә зур өлеш керткәне һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Бөтенроссия дәүләт телевидение һәм радиотапшырулар компаниясе» федераль дәүләт унитар предприятиесе филиалы «Татарстан» дәүләт телевидение һәм радиотапшырулар компаниясе» милли тапшырулар хезмәтенең телевидение режиссеры **Яркаев Зәйтүн Ләбиб улына** «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде.

## *Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* 2013 елда Казанда узган XXVII Бөтендөнья җәйге Универсиаданың ачылу тантанасы.

*Тышлыкның дүртенче битендә:* Универсиаданың ябылу тантанасы.

# УНИВЕРСИАДА. САННАР. ФАКТЛАР.

- Казанда узган җәйге Универсиадада дөньяның 162 иленнән 9300 спортчы катнашты.

- Казандагы спорт корылмаларында Универсиаданы 800 меңгә якын кеше тамаша кылды. Студентлар Уеннарына моңарчы андый зур игътибар күрсәтелгәне юк иде.

- Казан Универсиадасына 170 илдән 1,2 мең журналист һәм техник хезмәткәр аккредитацияләнде. Спорт ярышлары Россиянең 3 һәм 13 чит ил телеканалы тарафыннан 105 илдә трансляцияләнде.

- Казан Универсиадасында Россиянең һәм дөньяның 24 иленнән 20 мең волонтер катнашты. Аларның иң яшенә 15, ә иң өлкәненә 77 яшь иде.

- Студентлар уеннарында Россиянең төрле төбәкләреннән Эчке Эшләр министрлыгының 24 мең хезмәткәре тәртип саклады.

- Универсиадага әзерләнү һәм аны үткәрүгә тотылган 228 миллиард сумның 220 миллиарды шәһәр инфраструктурасын үстерүгә сарыф ителде.

- Казан Универсиадасында Россия командасы 155 алтын, 75 көмеш, 62 бронза – барлыгы 292 медаль яулады. Икенче урында – Кытай (26 алтын медаль), өченчедә – Япония (24 алтын медаль) командалары.



КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)